# казан утлары

8

АВГУСТ • 1978




# Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Указы

## Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасының Дәүләт гербы турында

Татарстан АССР Конституциясенең 157 нче статьясы нигезендә Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы **карар бирә:**

Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасының Дәүләт гербы сурәтен расларга (теркәлә).

**Татарстан АССР**
**Верховный Советы Президиумы**
**Председателе С. БАТЫЕВ.**
**Татарстан АССР**
**Верховный Советы Президиумы**
**Секретаре Ә. МУСИНА.**

Казан, Кремль.
1978 ел, 20 июнь.

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ОРГАНЫ
1922 елның май аеннан башлап чыга

8
АВГУСТ
1978

## Бу санда

Г. АХУНОВ. Без бит Арча яклары. Репортаж . . 3
Р. ГӘРӘЙ. Туган як шигырьләре . . . . . . . . 59
Г. РӘХИМ. Саргаймагыз, каштаннар. Повесть . . 63
Н. ИЗМАЙЛОВА. Юлга чыгам. Шигырьләр . . . 120

«ЗАМАНДАШ» КОНКУРСЫНА

Ә. ГАФФАР. Ак каен дегете. Хикәя . . . . . . 125

ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ

Р. ГЫЙЗЗӘТУЛЛИН. Казлар. Хикәя . . . . . . 135

КЛАССИК ПОЭЗИЯ ҮРНӘКЛӘРЕ

Р. ГАТАУЛЛИН. Җәлилнең рухи туганы . . . . 139
Ф. ГАРСИА ЛОРКА. Кереш моң. Шигырьләр . . 140

ӘДӘБИ МИРАС

М. НОГМАН. Кошлар базарында. Поэмадан өзек . 143

ИСТӘЛЕКЛӘР

М. ЗОРИН. Хәтернең кайнар күмере . . . . . 146

СӘНГАТЬ

Ф. ВӘЛИЕВ, Г. ВӘЛИЕВА. Татар декоратив сәнгатендә кош сурәте . . . . . . . . . . . . 156

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

М. ВӘЛИЕВ. Рухи тәҗрибә турында . . . . . 164

КИТАП КҮЗӘТҮ

Р. МОСТАФИН. Арышларның исе тәмлерәк . . 171

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

**Ә. ТЕНИШЕВ, Ф. САФИУЛЛИНА.** Үр артыннан үрләр күренә . . . . . . . . . . . . . . 177

ЕЛМАЕП ТА, КӨЛЕП ТӘ...

**Ш. ГАЛИЕВ.** Әз-мәз мәзәк яки Котбетдиннең кырык тартмасы . . . . . . . . . . . . 180

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 190

Редакциянең адресы. Казань, 420066, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар: Баш редактор — 3-07-60, баш редактор урынбасары — 3-07-69, җаваплы секретарь — 3-07-09, проза бүлеге — 3-07-69, поэзия бүлеге — 3-07-69, тәнкыйть бүлеге — 3-07-63, сәнгать бүлеге — 3-07-63, очерклар бүлеге — 3-07-61, хатлар бүлеге — 3-07-61, корректорлар — 3-07-65, техник редактор — 3-07-65, машинисткалар — 3-07-60.

Баш редактор: **Зәки Нури**

Редколлегия: **Әхсән Баянов** (баш редактор урынбасары), **Хәй Вахит, Шәүкәт Галиев, Аяз Гыйләҗев, Ләбибә Ихсанова** (җаваплы секретарь), **Шәйхи Маннур, Рәфыйк Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир**

Техник редакторы *Р. Нәбиуллина*
Корректорлары *Р. Сөләйманова, К. Корбангалиева*

Производствога бирелде 20/IV-1978 ел. Басарга кул куелды 26/VI-1978 ел. ПФ 09008. Кәгазь форматы $70 \times 108^1/_{16}$. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 91000 экз. Заказ В-133. Бәясе 50 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1978 ел.

## Гариф Ахунов

# БЕЗ БИТ АРЧА ЯКЛАРЫ

**МӘСКӘҮДӘН, АРЧАДАН ҺӘМ БОЛЬНИЦАДАН РЕПОРТАЖ**

### БЕРЕНЧЕ БҮЛЕК

## Гомернең биек ноктасы

Кеше гомеренең биек нокталары була. Әнә шул биеклектән караганда, узган юлың уч төбендәге тамырлар кебек күренеп ята.

Харис Зәйнуллин гомер юлының иң биек һәм иң якты ноктасы итеп 1976 елның 24 февраль көнен саный.

Күзләрне камаштырырлык кояш иде ул көнне. Мәскәү урамнары, йортлар, борынгы Кремль диварлары, манара башларындагы якут йолдызлар, түбәләргә кунган ак карлар — һәммәсе, һәммәсе ялт итеп, балкып тора иде.

Илнең төрле якларыннан җыелган биш мең кеше белән бергә, ул Кремль ишегалдына узды. Кремль диварларыннан күзен кыса төшеп, гүяки сынап карап торган гигант Ленин портреты аны Съездлар сараена озатып җибәрде.

— Хәерле юл, Арча малае! — дип әйтте кебек ул.

Хәерле юл. Бәхетле юл. Ышанычлы юл.

Йөзләгән прожекторлар берьюлы кабынып, съезд барасы залны яктыртты. Илебезнең иген басуларыннан, күмер шахталарыннан, мамык кырларыннан, төзелеш эстакадаларыннан һәм Совет Армиясе сафларыннан килгән делегатларга, чит илләрдәге коммунистлар һәм эшчеләр партияләре җитәкчеләренә 1976 елның 24 февралендә, иртәнге сәгать унда тантаналы тостә хәбәр ителде.

— Советлар Союзы Коммунистлар партиясенең XXV съезды үзенең эшен башлый.

Безнең Татарстан делегациясен югарырак урынга, амфитеатрга утырткannар иде. Зәйнуллин делегациягә билгеләнгән урынның беренче рәтләренә утырырга ашыкмады. Дулкынланудан алсуланып

киткән түгәрәк йөзен балкытып, гадәттәге күз камаштыргыч елмаюы белән елмаеп, минем янга килеп утырды.

«Чибәр безнең Арча яклары, чибәр, — дип уйладым мин аның йөзенә күз салып. — Дулкын каккан кара бөдрә чәч, чаткыланып, нур чәчеп торган коңгырт күзләр, күңелендәге тойгысын ашыгып белдерми, хисләрен тиз генә чыгарып аудармый, елмаюы аша гына белдерә торган ягымлы җитди чырай. Казан арты егетләре — халыкның әдәби телен тудырган яктан, Тукай ватаныннан килгән егетләр. Республиканың йөзенә кызыллык китермәстәй ир-егетләр...»

Әйе, Харис минем янга килеп утырды. Тыйнак кына, йомшак кына килеп утырды. КПСС Үзәк Комитетының Генеральный секретаре Леонид Ильич Брежнев ясаган хисап докладын тыңлады. Йөзендә кояш уйнап, күзләре янә дә балкып, нурланып тордылар.

Шушы минутларда, биш ел эчендә Советлар ватаны ирешкән уңышлар хакында тыңлаганда, бәлки ул Арча яклары кerткән өлеш турында да уйлагандыр. Кышкы озын төннәр, җәйге озын көннәр, яңгырсыз узган язлар, игеннәр өлгергәч, өзми-куймый яуган яңгырлар турында уйлагандыр. Бәлки аның күңеленнән иң коры килгән 1974 елны Арча игенчеләренең дәүләткә 75 мең тонна, ягъни өчләтә норма икмәк тапшырган вакыты узып киткәндер...

Зәйнуллин тыңлый, актив тыңлый, йөзе бер нурлана, бер моңсулана. Минем аның белән күптән инде бер иркенләп сөйләшәсем килә. Арча яклары хакында язасым килә, тик әле аның белән иркенләп сөйләшергә җайлы вакытын гына таба алмый йөри идем.

Менә мин теләгемә ирешү алдында торам. Без икебез дә партия съездына делегатлар булып сайлану бәхетенә ирештек. Мәскәүдә без ике атна бергә булачакбыз, бергәләп докладлар тыңлап, кичләрен концертларда, театрларда булып, съездан алган хисләребезне, уй-тойгыларыбызны уртаклашып үткәрәчәкбез.

Без хисап доклады тыңлыйбыз. Безнең күз алдыннан бер миллиард тонна иген үстергән Украина басулары уза — игеннәр шаулый. Үзбәкстан кырлары уза — ап-ак чәчәктәге мамык даласы тирбәлә, тауларны тишеп узган туннельләрдән, рельсләргә кага-кага, поездлар чаба, көмеш канатлы, җилдән җитез лайнерлар күккә күтәрелә, шундый иксез-чиксез илең барлыкка, аның улы булуыңа, шул ук вакытта аның төп-төгәл бер ноктасыннан, Татарстан республикасыннан, аның да Арча ягыннан, Тукай ватаныннан булуыңа горурланып утырасың.

Хисап докладының һәрбер сүзе синә кагылып, сине дулкынландырып уза.

Илдә ГЭСлар төзиләр: Нуректа, Камада, Каһарманда, Зәйдә, Себер елгаларында төзиләр ГЭСлар. Боларның барысында синең катнашың бар: син игенче, икмәк үстерүче, син иң борынгы һөнәргә ия булган кеше...

Игенче Зиннәтулла абзый гаиләсендә, Ашыт буйларында туган Харис. Туган ягының болыннары, кырлары хәтердә, арыш серкә очырган чаклар, болында чалгы чыңлаган заманнар. Дөньяга килгән елы да аның илдә икенче революция — корама юрган булып яткан басуларны күмәк хуҗалыкка берләштергән елларга туры килә. Төгәлрәк әйткәндә — 1931 ел. Кенәрдә ул урта мәктәпне бетерде. Тәтештә авыл хуҗалыгы техникумында укыды, дүрт ел Совет Армиясе сафларында хезмәт итте. Армиядән соң Кызыл юл районында, Кенәрдә райком инструкторы булып эшләде. Казанда югары партия мәктәбен тәмамлады. Аннары Минзәләдә райкомның агитация-пропаганда бүлеге мөдире, Биектауда райкомның икенче секретаре булды.

Арчада Зәйнуллин 1962 елдан. Эшнең биредә дә зурысын тапшырдылар: икенче секретарь. Игеннәр белән, колхоз авыллары, совхоз хуҗалыклары белән бәйле эш. Күптәнге партиец, Арча райкомының

беренче секретаре Мөхәммәт Закиров кул астында эшләде ул. Төннәрен, кышкы суыкларда авылларга чыгарып җибәрер иде. Өстә бәрән толып, аякта олтанлы киез итек булыр иде. Авыл хәлләрен, колхозчы агаеның тормышын Харис әнә шул елларны бик ныгытып өйрәнде, кешедән ишетеп түгел, китаплардан укып түгел, үз җилкәсендә татып өйрәнде.

Мөхәммәт Закиров үлгән чакта аны үз янына чакырып әйтте:

— Харис Зиннәтуллович, — диде, — партия эше ул җирне белү, елгаларны белү, язны-кышны белү, тургайлар сайравын белү, яз сулышын тою. Язны тоймаган, көзне тоймаган кеше, кышкы суыкларда туңмаган кеше кеше түгел ул, коммунист булуы турында әйтеп тә торасы юк. Колхозлар тәмам тернәкләнеп җиткәч кенә, сокланргыч көннәр килә башлагач кына якты дөнья белән саубуллашу үкенечле... Миннән соң сине куярлар инде, шуңа гына күңелемдә юаныч бар. Син — авыл малае, буразнада үскән малай, тырышлыгың, ихласлыгың бар, кешеләрдән үзеңне өстен куярга тырышма, оклау йоткан кебек үрә катып, аяк астындагы җирне күрми йөри күрмә, ник мин сиңа боларны әйтәм диген? «Без үзебез халыктан чыккан идек, халыкка яңадан ничек кайтырга инде»,— дип үкенеп йөргән кешеләрне беләм мин...

Съездның беренче көнендә без «Россия» гостиницасының Мәскәү елгасына караган Дәүләт концерт залында илебезнең сәнгать осталары концертын карадык.

Менә залда утлар сүнде. Сәхнәдә Ленин Мавзолее хасил булды. Каяндыр, безгә күренми торган урыннан төбәлгән прожекторлар Мавзолейны, юлбашчыбызның мәңгелек йортын балкытып яналар, Кремль курантлары суга иде. Биш мең кеше сыешлы залның түреннән япь-яшь дүрт солдат, винтовкаларын җилкәләренә кысып тоткан дүрт сугышчы, строевой адым белән чыкылдатып басып, Мавзолей янына уздылар.

Зал — концерт карарга килгән делегатлар — аяк өсте басты, алкышлар гөрләде, алар гүя Съездлар сараенда Партия Үзәк Комитетының хисап докладын тыңлагандагы алкышларның дәвамы булып күкрәделәр.

Аннары илебез алты дистә ел эчендә узган дәверләр сәхнәдә күренә башлады. Кәйлә белән тачкы, атлы арба белән чикмәнле мужик, беренче бишьеллыклар заманы. Ликбезлар, кулакның кыска мылтыгыннан һәлак булган коммунистлар, колхоз председательләре, активистлар. Беренче тракторлар, Бөек Ватан сугышы, Космос дәвере...

Һава лайнерлары сәнгать осталарын Ленинградтан, Киевтан, Казагыстаннан алып килделәр. Владивостоктан, Уралдан, таулар иле Кавказдан поездлар башкалага ашкынды. Төрле телләрдә җыр яңгырады, төрле халыкларның дәртле биюләре сәхнәдә өермәләнеп йөрде. Делегатлар алдында гүя иксез-чиксез Ватаныбыз шатлык-сөенечләре, кичергән кайгылары, михнәт-газаплары белән, дөньяны таң калдырган бөек җиңүләре белән безнең каршыбызга килеп басты. Бөтенләе белән, хезмәттә һәм сәнгатьтәге зурлыгы белән килеп басты.

Ул зурлыкны без Кремльнең Съездлар сараенда җыйнап әйткән теория итеп, марксизм тәгълиматының яңа шартлардагы дәвамы итеп кабул итсәк, монда Госконцерт залында сәнгать җәүһәрләребез итеп, халкыбызның рухи дөньясы итеп кабул иттек.

Съездның икенче көнендә безгә унар мең тираж белән чыккан ике брошюра тапшырдылар. Китапның берсендә — XXV съезд исеменә илебезнең төрле якларыннан килгән хезмәт рапортлары басылган булса, икенчесендә — съезд көндәлеге яктыртылган иде.

Мин ул китапларны кат-кат актардым. Бер кичтә унар мең тираж белән кичәге эшне түкми-чәчми бастырып чыгару һәм делегатларга

җиткерү өчен, типография һәм нәшрият эшчеләренә бик зур көч түгәргә кирәк булган, әлбәттә. Буяу исе аңкып торган битләрне сөенеп актара-актара, мин Зәйнуллинга хис-тойгыларымны әйттем.

Секретарьның йөзе җитди иде.

— Мәскәү китап басучыларының бер төн эчендә унар мең данәле ике китапны өлгертүләре гаҗәп түгел, иптәш Ахунов. Әгәр партия куша икән, безнең Казан китап басучылары да моны эшли ала. Иң гаҗәбе, иң таң калдырганы шул: безнең партиябезнең Үзәк Комитеты тугызынчы бишьеллык планны төзеде, коммунистларның башлангыч оешмалары аша халык күзәнәгенә кадәр үтеп, шул планнарны аңлатты, аларның үтәлүенә ирешә, инде менә хәзер коммунистлардан биш мең кешелек делегация җыеп, чит ил партияләре вәкилләрен җыеп, шул планнарның үтәлүе, арттырылып үтәлүе хакында хисап бирә. Менә бу ичмасам таң калырлык нәрсә! Коммунистлар гына эшли алырлык могҗиза.

Кеше гомеренең биек нокталары була дигән идем. Арча егете, минем якташым Харис Зиннәтулла улы Зәйнуллин, гомеренең биек ноктасыннан — XXV съезд залыннан миңа әнә шул хакыйкатьне әйтеп бирде.

## Йөрәкләр бергә тибә

Моңарчы эшләнгән барлык эшләребез белән горурлану, унынчы бишьеллыкта башкарачак зур эшләребез өчен җаваплылык тою — Советлар Союзы Коммунистлар партиясенең XXV съездында катнашкан һәрбер делегатның уртак тойгысы, мөгаен, шул булгандыр.

Биш мең коммунист — эшчеләр, игенчеләр, иҗат интеллигенциясе, гаскәриләр — илнең каймагы булган кешеләр узган бишьеллыкка йомгак ясап, киләчәккә юл сыздылар. Докладчыларны һәм чыгып сөйләгән ораторларны тыңлаган чакта безнең күз алдыбыздан заводлары, бөек төзелешләре, конкрет саннары һәм фактлары белән биниһая зур ил узды, куәтле держаның куәтле ритмын, баһадирларча сулыш алуын тойдык. Атаклы төзүче, ташчылар бригадиры Николай Злобин съездга планнан тыш алты катлы йорт бүләк итүен әйткәч, зал алкышларга күмелде. КПССның Татарстан өлкә комитеты беренче секретаре Фикрәт Әхмәтҗанович Табеев «КамАЗ» маркалы зур йөк машиналарының беренче колоннасы башкалабыз Мәскәүгә килеп җитүен һәм Кремль диварлары янына тезелүен әйткәч, автогигант төзүче батыр йөрәкле төзүчеләр исеменә шулай ук алкышлар күкрәде. Андый бүләкләр һәр рапортта, һәр оратор сүзендә бар иде. Ил съездны бүләкләр белән күмде. Хезмәт бүләкләре белән!

Болар халыкның һәм партиянең бер сулыштан сулавын, халык белән партиянең бердәмлеген әйтеп торалар иде.

Кремльнең Съездлар сарае залында утырганда без, делегатлар, бөек төзелеш программасының нинди энтузиазмнан, халыкның нинди батырлыгыннан туганын җаныбыз-тәнебез белән тойдык.

Кремль сараенда без стендлар күрдек. Анда төрле илләрнең коммунистлар һәм эшчеләр партияләре делегатлары алып килгән бүләкләр куелган иде. Алар арасында көрәшкә күтәрелгән пролетариатны гәүдәләндергән скульптура-символ да бар иде. Ул сын безнең күңелләрдә тирән бер тойгы уятты: планетаның бүгенге көне, егерменче гасыр чынбарлыгы барлык континентлардагы прогрессив көчләрнең бердәмлеген, оешканлыгын таләп итә.

Партия съезды көннәрендә без Харис Зәйнуллин белән туган-үскән җирләребезне, Татарстаныбызны, Арча якларын искә төшердек. Ни

генә сөйләмәсеннәр, барысы безгә, безнең эшләребезгә кагыла иде. Ул хакта мин укучыларыбызга да сөйләп бирүне кирәк табам.

Бервакытны, шулай Кызыл мәйданда әкрен генә сөйләшеп йөргән чакта Гомәр ага Бәширов миннән сорап куйды:

— Гариф энекәш, без икебез дә Арча малайлары, якташ булудан файдаланып сорыйм әле: син кайчан да булса Мәскәүдә китабың басылыр да, ул бөтен илгә таралыр дип уйлаганың бар идеме?

— Нигә алай дип сорыйсың, Гомәр абый?

— Син бит этисез үскән кеше. Кулаклар синең этиеңне үтергән. Мин ул елларны Арчаның җитәкче оешмаларында эшли идем, этиеңне үтерү бик зур вакыйгага әйләнде, Кәрим Тинчурин белән Салих Сәйдәшев «Кандыр буе» музыкаль драмасын язганда шул вакыйганы ишетеп башта Арчага, аннары Казанбашка барып чыкканнар иде. Әсәрдә бит этиең үз исеме белән алынган. Өчиле авылының колхоз председателе Акунҗанны үтергәннәр дип сөйләнелә...

— Әйе, андый эпизод бар «Кандыр буе»нда. Тик мин аңламыйм әле нигә сорау биргәнеңне, Гомәр абый?

— Ул бит болай, Гарифҗан. Кулаклар синең этиеңне үтереп, сине ятим калдырырга, сине ач калдырырга, сине, тагын да төгәлрәк әйтсәк, белемсез калдырырга, урамга чыгарып ташларга теләгәннәр. Сиздеңме эшләрнең кая барганын? Ялгышканнар бит алар, бик тә каты ялгышканнар. Мин ул хакта татар әдәбияты һәм сәнгате уңае белән үзәк матбугатта 1957 елда ук бер мәртәбә язып та чыккан идем инде. Тагын бер мәртәбә әйтәм: син ач калмадың, ялангач калмадың, ул гына да түгел әле... син югары белем алып, ил күләмендә китаплар чыгарырлык булып үсеп җиттең. Болар бит берсе дә үзеннән-үзе килгән, күктән төшкән нәрсәләр түгел, болар, төптәнрәк уйлап карасаң, совет властеның хезмәт кешеләренә биргән хокуклары, болар партиянең ленинчыл зирәк сәясәте нәтиҗәләре бит.

Менә хәзер съезд залында, биш мең делегат арасында утырганда, мин шул сөйләшүне исемә төшердем. Өлкән язучының, үзе дә СССР Верховный Советы депутаты һәм партия съезды делегаты булган әдипнең сүзләре бик тә уйланып, үз күңеленнән кичереп әйткән сүз икәнен аңладым.

Әлмәт каласында яшәгән чакларыбыз искә төште.

Яшь иде әле ул чакта Әлмәт. Ил байлыгын арттырырга килгән рус, башкорт, әзербәйҗан, төрекмән, грузин, украин егетләренең төрле акцент белән сөйләшүләреннән гөр килеп тора иде.

Әлмәтнең ун еллыгы идеме, яшь нефтьчеләр слеты идеме, анысы төгәл генә хәтеремдә түгел, бәйрәмгә дип нефтьчеләр шәһәренең үзәк мәйданына 41 метрлы вышка китереп утырттылар, аның башына ал байрак элеп куйдылар.

Бу комачта татар нефте ветераны Корбан Вәлиев, рус баһадиры Михаил Белоглазов, украинлы Константин Шевченко даны да балкый иде. Бу байракта татар егетләренә җир асты серләрен өйрәтергә килгән күп төрле милләт вәкилләренең даны балкый иде.

Татар нефтен җиде кат җир астыннан илебез халыкларының дуслык тойгылары җир өстенә күтәрде һәм «Дуслык» нефть үткәргече буйлап Европа илләренә озатты.

XXV съездның хисап докладында һәм ораторларның ялкынлы кайнар сүзендә әнә шул дуслык тойгылары чагылды.

Трансъевропа «Дуслык» магистрален биш илнең: СССР, Польша, Чехословакия, Венгрия, Германия Демократик Республикасының гражданнары салдылар.

Юбилей тантанасында катнашканнарга ул чакта документаль фильм күрсәткәннәр иде. «Миң чакрымнарга сузылган дуслык» дип атала иде ул фильм.

...Совет гаскәрләре Висланы кичәләр. Одерда — куәтле «ура!» авазлары. Безнең гаскәрләр белән бергә Польша һәм Чехословакия гаскәрләре атлый. Безнең гаскәрләр Европаны фашизм чирүеннән азат иткән көннәрдә совет геологлары Идел буеннан нефть эзлиләр. Экранда — Идел дәрьясы. Идел буйлап Казанга күтәреләбез, аннары самолетта Әлмәткә очабыз. Рәхим итеп карагыз, менә ул атаклы «Дуслык» магистраленең башы. Экранда — нефть каласы, аяз зәңгәр күк, гудронлы юллар; алардан машиналар чаба, грузовиклар, юлның ике ягында көмеш чаннар кояшта җемелдәп кала. «Дуслык» магистраленең бер участогында кинәт безнең алда фильмның беренче кадрларында күргән таныш чырай пәйда була — поляк Спановский. Анда ул — сугышчы, монда — нефтьче. Гаҗәеп бу дуслык җепләре!

«Дуслык» магистрален төрле илләрнең паспортларын йөрткән гражданнар салды, аларны бөек бер хис — пролетар интернационализм хисе берләштерде.

Юбилей көннәрендә Әлмәт кешеләре бер посылка алдылар.

Посылкада 35 репродукция һәм бәләкәй генә хат бар иде:

«Кадерле дуслар! Миңа яңа социалистик кала булган Әлмәтнең нигез ташларын салу бәхете эләкте. Беренче торак йортлар һәм промышленность объектларын без салдык. Нефть шәһәрен салышуда катнашканыма мин шат. Ул чакта безнең арада руслар, украиннар, грузиннар, әрмәннәр, татарлар бар иде. Бу бердәм гаилә армый-талмый эшләде. Хәзер сезнең шәһәр бөтен илгә билгеле. Без сезнең белән горурланабыз. Совет кешеләре Украинаның бөек кобзаре Т. Г. Шевченконың 150 еллыгын бик зурлап билгеләп үттеләр. Сезгә кечерәк бер посылка — аның рәсемнәре репродукциясен җибәрәм. Ул нефть шәһәренең бәйрәменә бүләк булсын, сезнең шәһәрдә минем дә өлешем бар бит.

К. Шевченко,  
Тарас Шевченконың энесе Никита  
ягыннан оныгының оныгы».

Безнең күңелләргә бик тә якын бу күргәзмә Әлмәт нефтьчеләренең Техника йортында бик озак торды. «Кара алтын» чыгаручылар аны дулкынланып карадылар. Бөек кобзарь шигырь сәнгатендә генә түгел, рәсем сәнгатендә дә якты истәлек калдырган икән бит. Украина шагыйренең туганы Татарстанда яңа кала салган диген, ә?! Хикмәт! Дуслык океаннар кичә, яңа калалар сала, салып кына калмый: тантана көннәрендә үзе салган каланы онытмыйча, аны искә төшереп, бүләк җибәрә!

Менә шушы түгелмени өлкән әдибебез Гомәр Бәшировның минем китабым Мәскәүдә басылып чыгу фактын тирән бәяләве?! Безнең илдә ятимнәр юк, безнең илдә япа-ялгыз калган, ачлыкка-мохтаҗлыкка, һәлакәткә дучар ителгән кешеләр юк. Безнең язмыш — ил язмышы. Дуслык-туганлык хисе гап-гади формулада чагыла: саумы, күрше, ярдәм кирәкмиме?

Туганнарча бердәмлекнең мин тагын бер мисалын китерә алам. Сугыштан соң украин шагыйре Иван Нехода безнең Татарстан язучылары съездында катнашып, болай дигән иде: Казанда мин күптәнге дустым Сибгат Хәкимне очраттым, ул безгә, украиннарга, әйбәт шагыйрь булганы өчен генә түгел, Бөек Ватан сугышы елларында үзенең взводы белән Харьковны азат итешкән булганы өчен дә кадерле.

Совет халыкларының юлы кайларда гына очрашмый!

Моннан берничә ел элек «Литературная газета» ел саен ил күләмендә басылып килә торган «Поэзия көне» дигән китаптан берничә шигырь бастырды. Монда Украинаның данлы шагыйре, академик Павло Тычинаның да бер шигыре бар. Шигырь «Муса Җәлил Киевта» дип атала, әсәрнең астына «1939» дип датасы куелган. Кызык булып китте: туктале, мин әйтәм, 1939 елны Җәлил нинди булган һәм Павло Тычина аның хакында ни әйтә алган икән? Бәлки Мусаның фашизм зинданыннан Павло Тычинага мөрәҗәгать итүе юкка түгелдер? Чыннан да, шигырьне укып карагач, зур гына бер хакыйкать ачылды. Муса Җәлил Бөек Ватан сугышы алдыннан Киевта Тарас Шевченкога багышланган пленумда катнашкан, ә шагыйрь Тычина моңа бик зур нәрсә итеп караган. Беренчедән, бу гадәти бер вакыйга түгел, бөек кобзарь пленумы, икенчедән, бу пленумда русның зур язучысы Алексей Толстой үзе доклад сөйли, ниһаять, өченчедән, Павло Тычина тугандаш әдәбиятлар вәкилләренең Киевка җыелуын хәбәр итеп кенә калмый, бу вакыйганың гаҗәеп тирән мәгънәгә ия булуын татар шагыйре Муса Җәлилгә карата дулкынландыргыч мөнәсәбәте белән билгеләп белдерә:

*Я гляжу на Джалиля... недавно*
*шли мы рядом. Стихи*
*он читал, и мне было так славно*
*понимать их без всякой подсказки.*

Шигырьне, әлбәттә, татарча да бирергә булыр иде, әмма мин моны зур бер тарихи документ итеп караганлыктан, русча хәлендә калдыруны кирәк таптым. «Понимать их без всякой подсказки» дигән юл мине уйга калдыра, сөендерә, уртак тойгыларыбызны кузгата. Хикмәт бит академик Павло Тычинаның төрки телләрен белүендә генә түгел, «тәрҗемәсез дә аңладым» дип әйткән сүздә тирәнрәк мәгънә ята: пленумга илебез халыкларының вәкилләре җыелган, алар берберсен ярты сүздән үк аңлый беләләр дип әйтергә тели шагыйрь. Моның шулай икәнен алдагы юллар тагын да ачыграк раслый:

А Толстой продолжал: — Злая доля
у Рылеева и Тараса,
но, их вольному голосу вторя,
Слышен голос восставшего класса!
Встрепенулся Джалиль, словно воин...

Бу 1939 елны булган. Монда — килер көннәр Җәлиле, фашизм зинданнарын ватып чыккан герой Җәлил портреты. Павло Тычинаның гаҗәеп бер сыйфаты бар иде: безнең чынбарлыгыбыз күренешләрен ул беркем әйтә алмаганча гомумиләштерә белә иде! Халыклар мәнфәгатенең бердәмлеге, әдәбиятлар бердәмлеге — менә нәрсә барыннан да бигрәк дулкынландыра украин шагыйрен. «Бердәм гаилә тойгысы» дигән канатлы сүзне дә беренче булып илгә ул җиткезде. Бу тәгъбир Бөек Октябрь казанышларының иң олысын — совет халыкларының дуслык, туганлык тойгыларын беркем әйтмәгәнчә әйтеп бирә алган!

XXV съезд Бөек Октябрьның алтмыш еллыгына якынлашып килгән чакта үткәрелде. Октябрь революциясенең алтмыш еллыгы хакында әйткәндә, Л. И. Брежнев безнең туткан юлыбызны, советча яшәүне болай дип билгеләде: «Чын коллективизм һәм иптәшлек атмосферасы, илебезнең барлык милләтләре һәм халыкларының көн

саен ныгый баручы тупланганлыгы һәм дуслыгы, безне көчле, нык итә торган әхлак сафлыгы — яшәү үрнәгебезнең якты сыйфатлары әнә шундый, социализмның чынбарлыгыбыз җанына һәм канына сеңгән бөек казанышлары әнә шундый».

Шушы төп фикер болай дәвам иттерелә: «...үтелгән 60 елның иң мөһим йомгагы — совет кешесе. Азатлык яулап алып, аны иң авыр сугышларда яклап калган кеше. Көчен кызганмыйча һәм теләсә нинди корбаннарга да барып, киләчәкне төзегән кеше. Барлык сынауларны үтеп, үзе дә танымаслык булып үзгәргән, үзендә идея инанганлыгын һәм гаять зур тормыш энергиясен, культураны, белемне һәм аларны куллану осталыгын берләштергән кеше. Ул — һәр вакыт кайнар патриот та, эзлекле интернационалист та булды һәм шулай булып калачак та».

— Я, иптәш язучы, Үзәк Комитетның хисап докладындагы бу сүзләргә син ничек карыйсың? — диде миңа Зәйнуллин, гостиницага кайткач.

— Монда уйланырлык нәрсәләр бар, — дидем мин. — Безнең китапларның төп темалары әйтеп бирелгән монда. Русча әйткәндә, генеральный темалары. Беренчесе — азатлыкны яулап алган һәм аны саклап калган совет кешесе. Икенчесе — коточкыч зур сынауларны узган, адәм түзә алмаслык шул сынауларда үзе дә үзгәргән кеше. Өченчесе — илен яраткан, шул ук вакытта башка илләрне дә үз күргән кеше. Монда безнең барыбызга да язар нәрсә күп, тик иренмә генә, җаваплылык хисен, таләпчәнлегеңне генә онытып җибәрмә.

Зәйнуллин болары белән канәгать булдымы, юкмы, шундук икенче соравын бирде:

— Язучыларга, сәнгать вәкилләренә карата докладта каты сүз әйтелмәде, таләпләр кую да булмады. Нилектән?

— Иң әүвәл: таләпләр XXIV съездда куелган иде, шул принцип көчендә кала икәне әйтелде. Икенчедән, съездда бит, барлык совет халкы белән бергә, эшче-крестьяннар белән бергә, иҗат интеллигенциясенә рәхмәт сүзе әйтелде. Бу, иптәш секретарь, таләпне ачыктаначык куюдан зуррак. Бу — ышаныч белдерү дигән сүз, бу — әдәбиятсәнгать әһелләрен үз арбаңа җигеп кую, партиянең сугышчан ярдәмчеләре дип тану дигән сүз. Бу — ниһаять, сәнгать кешеләренең ил алдындагы җаваплылыкны тирәнрәк тоюларына исәп тотып әйтелгән сүз.

Без ул кичне тормыш һәм әдәбият турында, бу ике өлкәнең берберсенә мөнәсәбәте турында озак сөйләшеп утырдык.

— Син әйткән сүзләр, мөгаен, дөрестер, ә шулай да синең үзеңне иң шатландырганы нәрсә булды? — диде миңа Зәйнуллин.

Хәйләкәр дә соң!

Аңа, Арчага кайкач, съезд турында киңәшмә үткәргән чакта күп төрле сораулар бирерләр, әдәбият-сәнгать мәсьәләләренә дә кагылмый калмаслар. Шуңа күрә ул үз уйларын башка кеше уйлары белән чагыштырып карарга теле.

— Мине иң сөендергәне, әгәр бик беләсең килсә, гражданлык тойгысы белән сугарылган әсәрләрнең — халыкның хезмәттәге һәм сугыштагы батырлыгына багышланган әсәрләрнең алгы планга чыгарылып куелуы. Кайбер эстетлар эшчеләр турындагы әсәрләрне тимер-томыр турындагы әсәрләр дип авыз ерып сөйләргә яраталар иде. Нефть ягында күп яшәдем мин, эшченең бәясе ни икәнне үз күзем белән күрдем, менә хәзер артык белдекләләр авызларын чамалабрак ачарлар инде. Хезмәт кешесе турындагы әсәрләрне партия беренче планга чыгарып куйды.

Зәйнуллин минем сүзләрдән янә дә үзенә файда китереп чыгарды:

— Арча хезмәтчәннәре турында да әсәр язылыр дип ышана алабызмы инде болай булгач?

— Ни өчен Арча?

— Ахуновны без моңарчы Арча малае дип белә идек. Бер юл да Арча хакында язмаганын да белә идек.

— Безнең өчен Тукай язган бит инде, — дидем мин шаяртып.

— Безнең якташ Сибгат Хәким дә: «Пушкин бар, Пушкин бар», дип әйтә әйтүен, ләкин аларның берсе дә: Тукай да, Пушкин да сезнең өчен килеп язганнары юк әле. Алар үзләренә тигәнне үтәгәннәр, үз заманнарын ачып, бөтен дөньяга сәнгать җәүһәрләре калдырганнар. Сибгат Хәким үзе дә аларга ышанып ятмый...

Бик дөрес әйтә Зәйнуллин. Минем авызымны шап итеп каплады да куйды.

— Ярар. Монысы иптәшләрчә. Татар әдәбиятын илебез әдәбиятлары арасында зур итеп күрергә теләгәннән. Чын дөресе — нәрсә комачаулый татар әдәбиятына алга килеп чыгарга? Яңа Пушкиннар, яңа Тукайлар туачакмы? Проза нишли? Драматургия? — дип, Зәйнуллин мәсьәләне кабыргасы белән куйды.

— Поэзия артта кала дип зарланырга хакыбыз юк. Тукае, Такташы, Туфаны булган поэзия — теләсә кайсы әдәбиятны көнләштерерлек поэзия ул. Берьюлы Ленин премиясе лауреаты да, Советлар Союзы Герое да булган шагыйрь бүтән бер генә әдәбиятта да юк. Бездә генә бар — Муса! Галимҗан Ибраһимовны казакълар, кыргызлар, тагын башка әдәбиятлар үзләренең элгәрләре дип, укытучылары дип саныйлар. Шуның янында бит әле безнең Шәриф Камалыбыз бар, Фатих Әмирханыбыз! Бүгенге бер дистә аксакал әдипләрне кая куясың? Драматургиябезнең дә тарихы зур безнең. Киләчәге дә бик өметле...

— Туктап тор, туктап тор. Без аларны беләбез, ә башкалар... башкалар беләме? Юкса бит теге мәзәктәге кебек килеп чыгуы бар: үзен ярма бөртеге дип саташкан берәүне дәвалаганнар, ул үзен ярма дип түгел, кеше дип карый башлагач, урамга чыгарганнар, тавыкны күргәч, теге янә дә куркып кычкырып җибәргән. «Син бит ярма түгел, беләсең бит», — дигәннәр. «Мин белүен беләм дә бит, тавык белә микән?» — дигән ди бу адәм. Без үзебезнең әдәбиятның зурлыгын беләбез дә беләбез, башка халыклар беләме аны?

— Совет власте елларында татар язучыларының 600 дән артык китабы рус телендә, башка халыклар телендә басылып чыккан. Азмы бу?

— Сан ягы күп. Сыйфат ягы?

— Сыйфат ягы да күбесенең әйбәт. Оригиналда. Русчасына карап: менә бу, чыннан да, оригиналына торырлык дип әйтерлекләре аз.

— Тукай әсәрләре тәрҗемәдә әнә шул югары критерийга җавап бирәме? Җәлил?

— Өлешчә генә җавап бирә. Чын художниклар кулы тигәне әйбәт. Урта кул язучылар тәрҗемә иткәне урта кул булып калган.

Зәйнуллин миннән аяк терәп сорау алырга тотынды:

— Ни өчен урта кул язучыларга бирәсез?

— Ил шундый зур, әдәбиятлар шундый күп, ил буйлап грамоталылык шундый артты, тәрҗемә эше хәзер дәүләт күләмендәге мәсьәләгә әйләнде.

— Классикларны тәрҗемә итү зур юлга салынсын өчен нинди чаралар күрелә?

— Язучылар союзы белән Галимҗан Ибраһимов исемендәге институт беркадәр эш алып баралар. Ләкин Татарстан китап нәшрияты яки институт каршысында аерым бүлек, классикларны ил күләмендә

чыгару эше белән шөгыльләнүче махсус бүлек ачылмый торып, әллә ни зур нәрсә өмет итеп булмый.

— Ала-а-ай... — дип сузып кына әйтеп куйды Зәйнуллин. — Сездәге проблемалар, болай булгач, материал байлыклар җитештерү өлкәсендәге проблемалардан да күбрәк булып чыга түгелме соң?

— Шулайрак булып чыга. Тәрҗемә проблемасы белән генә эш бетми әле. Милли әдәбиятлар хәзер, совет власте елларында, билгеле бер югарылыкка күтәрелделәр. Ул югарылыкка күтәрелү авыр иде. Әмма тиешле югарылыктан соң бер адым алга атлау тагын да авыррак. Зур традициясе булган рус әдәбияты, бигрәк тә прозасы, Горькийдан соң Шолоховны бирә алды. «Тын Дон» эпопеясе безнең республикалардагы әдәбиятлар ирешергә тиешле мавыктыргыч югарылык булып кала. Бу — киң колачлы талант туу белән генә дә хәл ителә торган проблема түгел. Роман үзе, — эпопеяне әйтмим дә, — җир һәм күк, шәһәрләр һәм авыллар, елгалар һәм диңгезләр дигән сүз. Роман ул — йөзләгән кешенең язмышы дигән сүз. Шундый зур эшне иректе баштан үз өстенә алган, бигрәк тә кискен тарихи борылыш чикләрендәге дәверне машстаблы полотнода сурәтләүне бурыч итеп алган прозаик карамагында күп төрле ярдәмлекләр, гыйльми хезмәтләр булырга тиеш. Идел буендагы революцион вакыйгалар да, гражданнар сугышы да Дон якларындагыдан ким булмаган. Әмма шушы көнгә чаклы бездә андый әсәр юк. Моның өчен, әлбәттә, шундый талантның тууы зарури. Шуның өстәвенә, фәннең җитәрлек эшләве кирәк. Шушы көнгә кадәр бездә татар революционерларының тулы исемлеге, аларның биографик белешмәләре язылмаган, патша төрмәләренең тарихы юк. Татар милләте революциягә кадәрле үк формалашкан, әдәби теле, китап басу эше юлга салынган, сигез гасырлык әдәби тарихы булган, капиталистик мөнәсәбәтләре нык урнашкан милләт. Аның дистәдән артык эре капиталисты гына булган, сәүдәгәрләре, фабрикантлары булган. Алар турында җитди итеп эшләнгән зур гыйльми хезмәтләр бармы? Университетта, Г. Ибраһимов исемендәге институтта эшләүче тарихчылар кайбер хезмәтләр тудырдылар. Рәхмәт аларга. Ул хезмәтләрнең нәтиҗәсе шундук әдәбиятта күренде. Пугачев хәрәкәтендә катнашкан татарлар турында китап басылып чыгу белән драматург Туфан Миңнуллин «Канкай улы Бәхтияр» драмасын язды. Прозаик Атилла Расих инде ничәмә-ничә еллар Хөсәен Ямашев, Мулланур Вахитов биографияләрен бөртекләп җыя. Гыйльми эшкәртелгән материал булса, ул аны тизрәк тәмамлый алган булыр иде. Революционерларны барлау эшендә М. Мөхәррәмов, Р. Нәфиков, Х. Хәсәнов кебек берничә галим эшли. Бу аз, ифрат аз. Эпопея дәрәҗәсенә күтәрелгән трилогияләр язу да, Тукайларны, Такташ, Җәлилләрне тулы зурлыгында илебез халыкларына җиткерү кебек зур һәм җитди эш тә саллы гыйльми хезмәтләрдән башка була алмый.

— Ә бит төгәл фәннәр өлкәсендә безнең бөтен дөньяга атаклы галимнәребез бар? Алар ничек ул дәрәҗәгә ирешкән?

— Әйе, бар. Академик Сәгъдиевне, химия галиме мәрхүм Камайны алыйк. Яшьрәк буыннан Зарипов, Бохараев, Нигъмәтуллин кебек галимнәребез бар. Математиклар, физиклар. Алар илебез фәне ирешкән гомуми җирлектә җитеште. Тарих һәм әдәбият гыйльме бездә әле илебез ирешкән югарылыкка ирешә алганмы икәне бәхәсле мәсьәлә. Бәхәсле, чөнки бу өлкәләрдә ак таплар күп. Аңлатмалы сүзлегебезнең беренче томын көч-хәл белән укучы кулына тапшырдык. Әдәбият энциклопедиясенә керешкәнебез дә юк. Театр тарихы да бик озак язылды.

Зәйнуллин мин сөйләгәннәрне игътибар белән тыңлагач, авыр итеп бер көрсенде.

— Менә без съезд залыннан Идел буена кайттык, Идел буеннан тагын ил күләменә килеп чыктык, — диде.

Безгә ял итәргә, иртәгә тагын съезд эшендә катнашырга кирәк. Ләкин безнең әле йокы килми. Партия съезды кузгаткан мәсьәләләрнең барысы да миңа да, райком секретаре Зәйнуллинга да кагыла иде.

Ул Арчага, райбашкарма җитәкчеләренең берсенә шалтыратты. Башта аның кем икәнен миңа әйтмәсә дә, телефоннан дулкынланып озак кына сөйләшкәннән соң әйтергә тиеш дип тапты.

— Тимерхан Борһанович белән сөйләштем.

— Нәрсәләр ди райбашкарма?

— Халыкка әйттем, ди, иптәш Зәйнуллин партсъезддан бик зур идеяләр белән кайтыр, йөзебезгә кызыллык китермәслек итеп эшлик, иптәш Зәйнуллинны шатланып каршыларлык булыйк, дидем, ди.

— Син нәрсә дидең соң?

— Нинди уңышларыгыз бар шатланырлык? — дидем.

— Сыерларның сөт бирүе артты, — ди.

— Ничек артты алар? — дим.

— Бюро членнарын колхозларга чыгардык, — ди.

— Мин барында да чыгалар иде, сөт артмый иде бит, — дидем.

— Сыерлар бозаулый башлады, иптәш Зәйнуллин, — ди.

— Ә син нәрсә дидең?

— Менә анысы — башка мәсьәлә, — дидем. — Карагыз аны, бозаулыйсы сыерларны нык саклагыз, запастагы ылыс онын шул сыерларга гына тотыгыз, ылыс оны ашаса, сыер бозау салмый, бу ил күләмендә сыналган инде, — дидем.

— Үзең тагын зоотехниклар белгәнне беләсең, — дидем мин Зәйнуллинга, мактавым да, шаяртып алырга теләвем дә иде.

— Беренчедән, мин, язучы иптәш, авыл хуҗалыгы белгече, икенчедән, Мөхәммәт Закировичның җирне бел, суны бел, кешеләрне бел дигән сүзләрен исемнән чыгарганым юк. Мин, кул астымда эшләгән кешеләр алдында авторитетым булсын өчен, кешеләрне генә түгел, хуҗалык эшен дә биш бармагым кебек белергә тиешмен. Шул чагында гына мин үземне кешеләр белән җитәкчелек итәргә яраклы дип саный алам.

...Иртәнге унынчы яртыда без, биш мең делегат белән бергә, Кремльнең Съездлар сараена ашыгабыз. Мәскәү нәширләре бер төн эчендә өлгертеп җиткергән ике китап бирәләр безгә. Типография буявы исе дә китеп бетмәгән китап. Аларның берсендә — съездның барышы, икенчесендә — хезмәт коллективларының хезмәт рапортлары. Шахталардан, заводлардан, төзелеш эстакадаларыннан килгән рапортлар. Зәйнуллиннар җитәкләгән, коммунистлар рухландырган коллективларның рапортлары.

Мин аларны иркенләп актарам.

Зәйнуллиннар башкарган эшнең мәгънәсе миңа зуррак булып ачыла бара.

## Гигантлар җилкәсендә

БАМнарның, КамАЗларның даны бөтен илгә таралган. Иптәш Табеевның съездда әйткән сүзләре бик күпләрне кузгатты, Съездлар сараеның фойесына КамАЗ машиналарын Мәскәүгә алып килгән кешеләрнең — машина йөртүчеләрнең рәсемнәрен элеп куйдылар. Бу — безнең өчен, Татарстан делегациясе өчен, горурлык булды. Үз өендә инде ияләнеп беткән, гадәти булып күренгән нәрсәләр дә, ил күләмендә чыккач, зурая, горурланырлык бер әйбергә әйләнә икән.

Тәнәфес вакытларында, төшке ашка чыккан чакларда, төрле иләрдән һәм үзебезнең республикалардан килгән делегатлар безнең гигантларны, мәгърур һәм тыныч басып торган «КамАЗ»ларны, ян-нарына килә-килә, озаклап карадылар. Без дә карадык. Шунда бер-мәлне мине үзебезнең «Литературная газета» редакциясеннән бер журналист тотып алды.

— Мин бит инде сезне биш көн буе эзлим. Сез миңа менә болай кирәк, — диде.

— Ник? — дидем мин.

— Мәкалә языгыз. КамАЗның зурлыгын ача торган.

— Аны сез мин эшли алыр дип ышанасызмы?

— Бөтен ышаныч сездә. Коткарыгыз. Машинкада 200 юл.

— Кайчан тапшырырга?

— Иртәгә иртүк.

— Китегез, булмаганны!

— Коткарыгыз. Зинһар. Шеф мине суячак. Республикалар белән эшләмисең диячәк. Килештек — 200 юл.

Каләмдәшне «коткарырга» кирәк иде, әлбәттә. Мин, КамАЗда булган чакларны, күңелне кузгаткан тәэсөратларымны искә төшереп, үзем танышкан кешеләрне барлап, каләмдәшемә иртәнгә чаклы мәкалә язу хакында уйлый башладым.

...Кичә генә булган шикелле әле. Исеме әле бик күпләргә билгеле булмаган Яр Чаллысы янында, далада экскаваторлар беренче бураз-наларны, канауларны ярдылар. Тынгысыз комсомол токымының беренче отрядлары шаулап-гөрләп Чаллыга килеп төште, аннары беренче биек йорт калкып чыкты, инде менә күз алдында бөтенләй башка күренеш. Гигант автомобиль комплексының барлык алты корпусы да җир өстендә горур басып тора, далада ике йөз меңнән артык халкы булган яңа кала үсеп чыкты — андый тизлек белән үскән каланы иң оста, иң тәҗрибәле демографлар да белми, һәм менә автогигант инде конвейер линияләрен барлый. Автомобильдә дүрт меңгә якын деталь. Башта ремонт-инструменталь заводы эшли башлады, аңарда җиһазларны, аерым узелларны җитештерделәр, аннары бер-бер артлы башка заводлар да сафка басты. Рамнар ясыйлар, кабина ясыйлар, беренче моторны җыйдылар, съезд көненә беренче машиналарны өлгерттеләр. Баш линия тулы көченә эшли башлар көннәргә дә ерак калмады.

Төзелешкә нибарысы биш ел. Күз иярмәс шундый тизлекнең сәбәбен эзли башласаң, КамАЗга кадәр булган легендар Днепрогэс һәм Магнитка, Уралдагы Березники химкомбинаты һәм Амурдагы Комсомольск, Братск гидростанциясе һәм чирәм җирләрне үзләштерү искә төшә. КамАЗ — ул безнең элекке тәҗрибәләребезнең экономик, политик, әхлакый тәҗрибәләребезнең чыгымтасы, концентрациясе. Аның шулай тиз генә үсүе юккамыни?! Элекке гигантлар җилкәсендә, Советлар ватанының куәтендә күтәрелде бит ул. Ә иң мөһиме, КамАЗ үзенә легендар беренче бишьеллык геройларының — Стахановларның, Демченколарның, Ардуан батырларның энтузиазмын, фидакарьлеген туплады, шулар янына бүгенге көн төзүчеләре ирешкән техник яңалыкны, куәтне китереп кушты. Тачкы белән, кәйлә белән, атлы арба белән алай тиз төзи алмас идең КамАЗны! Чыннан да, КамАЗның бүгенге геройлары — ташчылар бригадиры Вазих Мәүликов, Рәис Сәләхов, Рәвис Сабирҗанов, скреперчы Умат Наурбиев, монтажчы Виктор Филимонов һәм башка меңнәрчә энтузиастлар, — Кама ярларына илебезнең индустрия гигантын салырга килгән яшьләр, кайнар йөрәкле кызлар һәм егетләр, — бүгенге заман эшчеләр сыйныфының каймагы, иң яхшы вәкилләре бит алар. КамАЗчыларның нинди кызыклы сыйфатлары бар? Төзелешкә килгән мең-

нәрчә, ун меңнәрчә энтузиастларның кайберләре генә төзүче һөнәренә ия иделәр. Әнә шул кайберәүләр үзләре берне, бишне, унны төзүче һөнәренә өйрәтә башладылар — өсләренә авыр һәм мактаулы вазифа алдылар. Мин моны арттырып әйтмим. Кызык өчен дә әйтмим. Чыннан да, шулай булды. Мәсәлән, Вазих Мәүликов Чаллыга килгәнче зур бер химия заводын корышты, шунда аппаратчы булып эшләде. Көннәрдән бер көнне партия: «КамАЗ салырга!» дигән сүз әйткәч, улияләнгән-төпләнгән шәһәрен калдырып, гадәтләнгән эшен бер читкә куеп, беренчеләрнең берсе булып Чаллыга, Кама буена килеп җитте. Бригада җыйды. Анда теләсә нинди һөнәр иясе бар иде, тик ташчылар гына аз иде. Ныклы бер коллектив төзеде ул алардан, эшли-эшли укыдылар, укый-укый эшләделәр, бишьеллыкларын өч елда үтәп чыктылар. КамАЗда андый батырлык үрнәге йөзләгән, меңләгән. Бу биш ел эчендә Кама буенда кечерәк бер мәйданда өч миллиард сумга якын акча тотылды, мондый зур сумманы сигезенче бишьеллыкта бөтен республикабыз гамәлгә кертә алган иде. Никадәр көч сарыф ителгәнне шул бер сан үзе генә дә әйтеп бирә төсле!

Безнең драматургиядә Диас Вәлиев, поэзиядә Сибгат Хәким һәм Рөстәм Мингалимов Кама буендагы батырлык хакында укучылар игътибарын җәлеп итәрлек әсәрләр иҗат итүгә ирештеләр, әмма авыр артиллерия булган проза бу өлкәдә җитди уңышларга ирешә алмады әле. Ирешмәде, чөнки Кама батырлары сарыф иткән көчне сарыф итмәде. Бу һаман да безнең намуста — прозаиклар намусында кала. Ул көч сарыф ителергә тиеш.

Төзелештәге кешеләр һәм туган якларыбыз язмышы турында уйлый башласаң, бик тә ачык булып күз алдына бер нәрсә килеп баса: турыдан-туры төзелештә катнашканнар гына түгел, Кама буйларыннан еракта, читтә яшәгәннәр дә безнең республикабыз үсешенә зур өлеш керттеләр. КамАЗ ватаныбыз автомобиль төзелешенең барлык алдынгы тәҗрибәсен үзенә туплады. Скреперчылар әле төп корпуслар салыначак урыннарны тигезләп кенә өлгергәннәр иде, ә ЗИЛда инде конструкторлар булачак «КамАЗ» машиналарының төрле модельләрен өлгерттеләр, машина йөртү осталары әнә шул машиналарны илебезнең төрле юлларында сынау эшенә керештеләр. Таймырдан башлап Памир түбәләренә хәтле булган арада барлык юлларны узды сынау машиналары. Һәрбер республика, һәрбер өлкә, һәрбер шәһәр автомобиль гигантына үзеннән өлеш кертте. Украина да, Грузия да, РСФСР шәһәрләре дә, без КамАЗ төзедек, дип әйтә алалар.

КамАЗ Советлар иленең туганлык, дуслык, бердәмлек законнары нигезендә төзелде. «Нихәл, күрше, ярдәмләшимме?» дигән принцип, безнең матур гадәтебез, традициябез буенча, алгы планга килеп чыкты.

Биш ел, болай караганда, әллә ни зур вакыт түгел. Әмма эш белән, тырышлык белән узган биш ел күп. Анда ике меңгә якын көн һәм төн бар, әнә шул көн һәм төннәрдә Кама гигантына катнашы булган кешеләр, конвейердан беренче автомобильне тизрәк төшерәсе иде, дигән уй белән янып яшәделәр.

Ниһаять, ул көн килде! Партиянең XXV съезды ачылыр алдыннан ярыш уты кыза төште. «КамАЗ» машиналарының беренче колоннасын съезд ачылган көнгә өлгертергә кирәк иде. Нәкъ әнә шул көннәрдә төзүчеләрнең, монтажчыларның, эксплуатацияләүчеләрнең тырышлыгын бергә туплаган күмәк хезмәт ташкыны туды. КамАЗның беренче машиналары инде Мәскәүдә, Кремль диварлары буенда. Бу — гамәлгә ашкан факт.

КамАЗ гигантлар җилкәсендә күтәрелде. КамАЗ бөтен илебез иҗаты, егерменче гасыр иҗаты булып күтәрелде.

Иҗат дигән сүзне без һәр вакыт авыз тутырып әйтәбез. **Иҗат — үлемне җиңү.** Бу — күптән әйтелгән билгеле хакыйкать. Әмма ул безгә кадерле хакыйкать. Иҗат итеп, тикшеренү-эзләнүләр алып барып, төзеп яшәгән ил, — безнең беренче социализм иле, — кешелекне үлемсезлеккә алып бара. Монысы без әйткән хакыйкать, без иҗат иткән формула. Коммунистлар дөньяның иң зур форумнарында, планетаның иң җаваплы симпозиумнарында әйтә торган формула. Әнә шул формулага, кешелекне үлемсезлеккә алып барган формулага турылыклы булганга күрә дә, без, бөтен дөнья ишетерлек итеп: «Тынычлык! Дөньяга иминлек!» дип көр тавыш белән әйтәбез. Әйтеп кенә калмыйбыз, җир йөзендә ныклы Тынычлык, Иминлек урнашсын өчен өзлексез көрәшәбез. Безгә үзебезнең генә түгел, күршеләребезнең дә имин яшәүләре кадерле. Без үзебездән соң яшәячәк буыннарга гүзәл дөнья төзеп калдырырга телибез. Әнә шул безнең үлемсезлегебез.

КамАЗларның, БАМнарның мәгънәсе әнә шунда. Шул мәгънәне без истә калырдай кешеләр аркылы, кабатланмас образлар аркылы ачып бирә алабыз икән, димәк, без, иҗат интеллигенциясе дә, кешелек дөньясын үлемсезлеккә илтүдәге үз вазифабызны үтәгән булабыз. Моңа күп, бик күп көч сарыф итәргә кирәк.

«1976—1980 нче елларда СССР халык хуҗалыгын үстерүнең төп юнәлешләре»ндә, партиянең XXV съезды кабул иткән шушы документта экономикабызның, фәнебезнең, культурабызның барлык тармакларын үстерү күздә тотылган. Без, съезд залында утырганда, илебезнең гигант магистральләрен күз алдына китердек. Көнбатыш Себергә, Байкал—Амур магистрале төзелешенә, колхозларга һәм совхозларга йөк ташыган куәтле «КамАЗ»ларны күз алдына китердек. Бөтен ил булышлыгы белән күтәрелгән КамАЗның үзе бөтен илгә булышыр, бөтен илне гайрәтле җилкәсенә таяндырыр көннәре җитәчәген уйлап утырдык.

Безнең бөек илебезнең үсеш диалектикасы шундый.

ИКЕНЧЕ БҮЛЕК

## Съезддан Арчага

Гомер дигәнең уза тора. Көндәлек мәшәкатьләребез, олы һәм кече эшләребез шундый күп безнең, кайчагында, инде монысын эшләми калмыйм дип, күңелгә беркетеп куйган нәрсәләр дә еш кына бер читтә торып кала.

XXV съезддан Казанга кайтып төшкәндә, без Зәйнуллин белән тиз арада очрашырга сүз куешкан идек. Аның тормышны китаптан укып түгел, үз җилкәсендә татып белгән булуы, Арча якларында башкарган эшләре белән партия съездына делегат булып сайлануы миндә аңа карата зур ихтирам хисе уяткан иде. Мин Арчаны, туган-үскән ягымны, бик җентекләп, якыннан күрергә, якыннан белергә һәм аның хакында үз уйларымны матбугатта язып чыгарга тели идем.

Дөресен әйткәндә, соңгы елларда без партия эшендә эшләгән иптәшләребезне оныттык. Алар башкарган зур эшне, җаваплы эшне, халык массаларын рухи яктан тәрбияләү һәм җиңүләргә рухландыру эшен язмый башладык шикелле.

Моның кайбер сәбәпләре дә бар. Язылмаган кайбер законнар безнең кулыбызны тотып килде. Партия җитәкчесенә тыйнаклык роле бирелде һәм без шуның белән килештек.

Бактың исә, без, язучылар, халыкка җиткерелергә тиешле бик күп әйбәт секретарьларның образын очеркларыбызда тудырмадык. Безгә, соң булса да уң булсын, ул эшкә ныклап тотынырга вакыт. Бу, әлбәттә, райком секретарен мактап торуга корылган мәдхия булмаска тиеш, андый мәдхиядән берәүгә дә файда юк, мин райком секретаре аркылы бөтен бер районның яшәү сулышын тоя алам бит. Мине бигрәк тә әнә шунысы дулкынландыра.

Баштагы ике баруымда мин Зәйнуллинны очрата алмадым. Ул өйдә юк иде. Шулай да район җирләре буйлап, үзем туып-үскән һәм Арча педучилищесына укырга йөргән юлларым буйлап мин байтак җир айкадым.

Арчадан Балтачка бара торган олы юл өстендә, апрельнең азаккы атнасында, без, машинада узып барышлый, телеграмм баганасы төбенә чүмәшкән берничә кешене күреп алдык.

Арча районында әле бер җирдә дә чәчүгә чыкмаганнар, болар монда нишләп йөриләр икән дигән кызыксынуга бирелеп, яннарына туктадык. Миннән бигрәк, минем белән юлга чыккан радио корреспонденты Наил Гыйззәтуллин һәм якташым язучы Мөхәммәт Мәһдиев бу хәл белән кызыксындылар.

Төштек. Карыйбыз. Минем сабакташ Мирбат Хәстиев, мин белмәгән тагын ике егет телеграмм баганалары тирәли бодай чәчәләр, кул белән чәчәләр. Өсләрендә телогрейка, юл кожаны. Битләрен кояш ашаган, җил кискән. Кырык бишләр тирәсендәге ир уртасы кешеләр, чибәрләр, олыгайган кешеләрне көнләштерерлек тазалар, саусәламәтләр.

Мине күрүгә Мирбат Хәстиев, «Известия» колхозы председателе, бите-башы белән елмаеп, каршыга атлады, җилән чабулары кош канаты кебек җилпенеп киттеләр.

— И-ии, Гарифҗан абый, сине нинди җилләр ташлады монда?!

— Менә шулай, председатель иптәш, сабакташ, якташ, туган җирләрне карап кайтырга булдым әле. Багана төбендә нәрсә сихерлисез сез?

— Син инде партия съездында булган кеше, Гарифҗан абый, беләсең, сыйфат бишьеллыгы бит. Багана төпләре буш калмасын дип алданрак, чәчүгә кузгалганчы аяк киенебрәк кую иде. Чәчү узганнан соң онытыла, Тукай әйтмешли, татар башы кеби такыр кала бу җирләр, — диде Мирбат, өстә күренеп калган ике-өч бөртек бодайны күн итек башы белән күмеп куйды.

— Алай икән, алай икән, — дидем мин, — сине әйбәт председатель дип, җирне ярата дип, булсынга йөри дип бик мактыйлар иде, димәк, зерәгә түгел мактаулары...

Мирбат кызарды, уңайсызланып елмайды. Күзен кояштан ышыклый төшеп:

— Чыннан да, нинди йомыш белән килеп чыктыгыз әле? Бу иптәшләрне кем дип белик? — диде.

— Монысы — радио корреспонденты Наил Гыйззәтуллин, монысы — язучы Мәһдиев. Язгы басуларны карап, саф һава сулап кайтырга дип чыктык. Я, сөйлә, нинди яңалыклар, нинди искелекләр дигәндәй, нәрсәләр белән сөендерә аласың безне? Культура сарае салмадыңмы әле?

— Фундаментын салырга җыенабыз.

— Озак, туганнар, озак. Казанбаш бит колхоз оешкан елларны клублы булу ягыннан барлык авыллардан алда иде. Әтиең Бәдри абзыйлар, коммунист Заһидуллиннар эшне бит клубтан башлаганнар иде. Менә дигән таш клуб иде бит авылда. Шул заманнардан да артта калып барабызмы инде?

— Агач материалы да, кирпече дә, ташы да бар, чын осталары юк. Төзүче һөнәре бик кадерлегә әйләнде бит хәзер.

— Шулайдыр анысы, ләкин Казанбашны, театр труппалары беренче булып килә торган авылны, кайчандыр кантон булган Казанбашны клубсыз итеп күрү сәер.

— Аңладым инде, аңладым, маңгайга чиртеп әйтмәсәгез дә... — дип, ул кинәт «синнән» «сезгә» күчте. Шуның белән мин сүзне очлап куярга мәҗбүр булдым. — Ярый. Аңлагач әйбәт. Радио корреспондентына бирәр сүз әйтәсеңме?

— Әйтермен, кирәге булса...

Корреспондент, чәчүче егетләрне һәм мине арба янына чакырып, җилне ышыклап торырга кушты, үзе магнитофонын рәтләп җиргә чүгәләгән председатель янына иелде.

— Чәчүгә кайчан чыгасыз? — диде корреспондент.

— Тагын биш көннән, — диде председатель.

— Менә шул хакта, чәчүгә әзерләнү хакында сөйләсәгез иде.

Мирбат сөйли башлады. Мин кинәт авызымны ачып, шаккатып калдым. Әле генә уңайсыз елмаеп, кызарынып торган председателебез радио лекторларыннан да болайрак сөйли, тамчы бөртек тә уңайсызланмый, тотлыкмый, сөйләвен игенчеләрнең, механизаторларның исемнәре белән беркетеп бирә тора.

— ...Кояшлы булды 26 апрель көне. Күңел күтәрерлек булды. Механизатор Фәлән Фәләновлар көнлек нормаларын бер йөз дә илле процентка үтәп, чәчүне югары сыйфатлы итеп башкардылар...

Корреспондент магнитофонын шып туктатты.

— Туктагыз әле, ә сез ул көнне кемнең чәчүгә чыгасын һәм күпме эшләячәген каян беләсез? Мин бит сезнең язгы чәчүгә әзерлек турында сөйләвегезне генә үтендем, иптәш Хәстиев...

Председательнең бу юлы уңайсызлану хәбәрендә дә юк иде, ул аксыл кашларын югары чөеп, күзен дә йоммастан:

— Әгәр мин чәчүгә кайсы механизаторым чыгасын, аның күпме норма үтәсен биш көн алдан белмәсәм, минем председатель булып йөрүемнең бәһасы Арча базары көнне сукыр бер тиен. Бусы бер. Икенчедән, корреспондент иптәш, фамилиягез кем әле, әһә, Гыйззәтуллинмы, сезнең халыкны беләм бит мин, ничәмә-ничә мәртәбә язып алганнары бар, әй, әтәләнәләр, әй, кабаланалар, пәрәме ут чыккандай кыланалар, ә бактың исә, ашыгыч дип язып алган материалны бер атнадан, хәтта ун көннән соң бирәләр. Мин сөйләгәнне сез чәчү башланган көннән дә алдарак бирмисез бит. Шуңа күрә мин сезгә чәчү көнен сөйлим дә...

Без рәхәтләнеп көлдек. Менә әйтте бу, әйтеп карады!

Эшләр шуннан соң тизрәк китте. Сөйләтәсе сүзебезне сөйләтеп, өйгә кайтырга чыккач, Гыйззәтуллин миңа терсәге белән төртеп:

— Ай-яй, усалланды авылда халык, авызыңны ачып торсаң, төкереп китәргә дә күп сорамас, ха-ха-ха! — дип, тагын бер мәртәбә көлеп куйды.

— Тормыш дигәнең менә шул инде ул, бүген монда килмәгән булсак, председатель Хәстиевнең андый үткенлеген каян белер идек әле без, — дидем.

— Гариф абый, син бит аның белән авылдаш дип таныштың, сабакташ та дидең, бергә укыган идегез мәллә?

— Анысы сиңа ник кирәк? Әллә күңелеңдә бөре уяна башладымы? Минем якташ ошап куйды мәллә үзеңә?

— Ошамаслык түгел бит! Төп башына утыртып куя язды бит үзебезне! Радио өчен җилле генә бер очерк язып булмасмы дип торам әле мин аның турында. Чәчү чәчкән чагына килеп чыксам, урак өс-

тенә. Колхозчыларына булган мөнәсәбәтен чамалый башладым инде. Озак эшлиме ул председатель булып?

— Егерме елдан артыктыр инде.

— Әти-әниләре дә игенчеләрме? Механизаторлар ук түгелдер бит?

— Юк, механизатор түгел. Калыпка сугарга азапланма син бар нәрсәне. Әтисе дә, әнисе дә укытучылар иде аның. Әнисе — география, әтисе әдәбият укытты. Өстәвенә, ул әле хәзерге заман укытучылары кебек педагогика эшенә «туп-турыдан туп пашул» булып килеп кергән кеше дә түгел. Заманында хәлфә булган кеше, вәгазьләр сөйләгән кеше. Революциядән соң совет мәктәбендә балалар укытырга керешкән һәм шул эшнең остасы булып киткән кеше. Әгәр син кайчан да булса, Бәдри Хәстиевтә әдәбият сабагы алган берәр кешене очрата алсаң, ул ниндирәк кеше, ниндирәк укытучы иде дип сорасаң, алар сиңа аның кем икәнен аермачык әйтеп бирерләр. Дөнья бәясе кеше иде. Әдәбият турында сөйли башласа, авызларны ачып, дөньяларны онытып тыңлар идек. Казанбашта ул колхозлар оештырышты, балалар укытты, урта мәктәпнең директоры булып эшләде. Әнисе дә бик ягымлы, бик сабыр кеше аның. Ирле-хатынлы ике укытучы икесе дә Казанбашның күз өстендәге кашы кебек кешеләр, менә дигән бакчачылар иде. Казанбашта Бәдри абыйны сагынып сөйләмәгән бер генә кешене дә таба алмассың.

— Әтиләре укытучы, ә бу ничек игенче булып киткән?

— Хикмәт шунда да шул, әти-әнисе аңа җирнең кадерен белү кебек аңны бик матурлап сеңдергәннәр. Әтисе исән чагында ук председатель булып эшли башлаган иде инде ул. Өч ел чамасы авыл советы председателе булып та эшләде. Шул ук Казанбашта. Шул чагында председательлектән аерылып торды, әмма җирдән беркайчан да аерылмады.

— Ә колхозчылар белән мөнәсәбәте, эш стиле ничегрәк аның? — дип, иплэп кенә сорап куйды радио корреспонденты.

— Карале, Наил, зирә хәйләкәр кеше булып чыктың бит әле син, малай. Әкрен-әкрен хәйләсене китерәдер көйгә бу, дигән шикелле, син Хәстиев турындагы очеркыңны аның янына бармыйча гына язарга уйладың, ахрысы, әкәмәт.

— Һөҗүмгә күчәр алдыннан разведка дигән хикмәтләре дә бар бит. Син аны яхшы беләсең. Үземә кирәк димәсәң, берәр генә детален булса да әҗәткә биреп тор, үз янына барып өйрәнгәч, очерк итеп кайтарып бирермен.

— Шулай дисәң генә инде. Әйбәт очерк язам дисәң генә. Алайса, белеп тор: Мирбат Хәстиевнең колхозчылар белән, механизаторлар белән эшләве тирән педагогик алымнарга, психологиягә корылган. Бүген син аны багана төбенә бодай сибәргә юкка чыккан дисең мәллә? Чыгар сиңа бар! Эше аның муеннан. Әмма бүгенге эше, шәхси үрнәге чәчү беткәнче җитәчәк. Сыйфатның нинди икәнен үзе башлап күрсәтте диячәкләр. Шуның өстәвенә, син үз вакытында, Хәстиев әйткәнчә, нәкъ көнендә ул сөйләгәннәрне республикага тапшырсаң, Хәстиев ул синең җаныңда нәрсә ятканны бер атна алдан күрә диячәкләр. Белдеңме?

— Анысын мин үзем дә күрдем. Мин күрмәгәне...

— Син күрмәгәнеме? Син күрмәгәне шул: бер вакыт колхозда ике егет матур гына салып йөри башлыйлар. Эшкә уңган, сәләтле егетләр, чүп-чараман түгел. Бик эче поша мондый хәлгә Хәстиевнең. Ничек туктатырга? Турыдан-туры үгетләсәң — андыйны авыл халкы бик өнәп бетермәүчән. Нишләргә? Тәки бер җае чыга моның. Көннәрдән бер көнне әлеге ике егетнең ашыгыч йомыш белән колхоз идарәсенә килүен әйтәләр. «Эчкәннәрме?» — ди председатель. Ул өендә утыра әле. «Юк,— диләр,— икесе дә ап-аек!». «Яхшы, әйтегез үзләренә,

хәзер килеп җитәм»,— ди председатель, ә үзе идарәгә барырга бер дә ашыкмый. Тагын киләләр моңа. «Хәзер-хәзер,— ди председатель,— менә райкомга бирәсе ашыгыч отчетымны гына язып бетерим». Тагын бер сәгать килми бу, вакытны суза бирә, суза бирә. Ниһаять, көтә-көтә егетләр хәлдән тайгач, идарәгә килеп керә.

— Көттегезме, егетләр?

— Көттек, — диләр тегеләр яшермичә.

— Кыенмы көтүләре?

— Бик кыен.

— Нишләп килми торды дисезме?

— Шулай дибез шул. Бик аккуратный кеше ие председателебез, ни булды икән, дип баш ватабыз.

— Әйтимме ни икәнен? Беркемгә дә әйтмисезме?

— Әйтмибез.

— Чынмы?

— Ант итеп әйтәбез, үзара калыр.

— Алайса әйтәм: кичтән эчкән идем мин.

— Пиво эчкән идегезме?

— Эчсәм аракы гына эчәм мин.

Егетләр уңайсызланып идәнгә карыйлар, тамак кыргалыйлар.

— Көтүләре кыенмы? — дип кабат сорый Хәстиев.

— Бик кыен, — диләр егетләр, эшләрнең кай якка барганын абайлап.

— Миңа да бик кыен була, мин сезне кайчакларда көннәр буе көтәм, ләкин көтеп бетерә алмыйм...

Бу диалог шул көнне үк, сәгате-минуты белән халык арасына тарала, кабатланып сөйләнә торгач, арта-күперә һәм әлеге ике егетне шешәдән биздерер хәлгә китереп җиткерә. Чөнки алар халык телендә көлке объектына әйләнәләр. Ул гына да түгел, вакытсыз эчкәннәргә карата халык: «Көтүләре кыенмы?» — дип, ике генә сүз әйтә, бу шундук көлү өянәге кузгатып, салмыш адәмнәрнең йөрәк бәгыренә төшеп җитә...

— Болай булгач барам, бармый калмыйм, кызыклы характер бу, — диде Наил мавыгып.

— Бара күр, теге егетләр кебек озак көттерә торган булсаң, үзем язып куярмын, — дидем мин елмаеп.

Машинадан төшеп, кипшергән кара кырлар янына туктадык. Күкрәкләрне киңәйтеп, җанга яз һавасы тула, дымлы туфрак исе, узган елгы үләннәр исе, кайдадыр эскерт калдыгын яндырганнан килгән салам исе аңкый иде.

## Яңгырлар...

Язгы чәчү дә узды, игеннәр дә билдән булып шаулап үстеләр, печән якынлашты, ел да саен республикада үткәрелә торган сабан туйлары да килеп җитеп, узып китте. Башта мине әдәбият атналыгына Себергә чакырып алдылар, аннары Казанга Мәскәү әдипләре килеп җитте, яшь язучылар белән зурдан кубып семинарлар үткәрдек, озын сүзнең кыскасы — Арчага мин бары тик урак өсте гөрләп бара башлагач кына килеп чыга алдым.

Анда да әле менә киләм, менә киләм дигән чакта гына тоташ яңгыр коярга тотынды.

Яңгырда игенчеләрнең кәефе нинди икәнне беләсе килеп бик кымырҗысам да, секретарьның миндә дәхеле юктыр әле, үз борчуы үзе беләндер дигән уй мине тагын атна буе Казанда асрады.

Радио көн саен урып-сугуның торышын иртәнге алтыларда бөтен республикага хәбәр итеп торды. Яңгыр ява, яңгыр...

Арча артта.

Мин моның сәбәпләрен яхшы аңлыйм. Бу — төньяк район. Монда яз республиканың көньяк районнарына караганда соңрак килә, болар чәчүгә соңрак керешәләр, шулай булгач, табигыйдыр ки, урып-җыю эшен дә соңрак башлап җибәрәләр. Башка районнар урып-җыюга иртәрәк тотынганлыктан, инде игеннең байтагын урып өлгерделәр, корырак чакта сугып, дәүләт амбарларына да илтеп өлгерделәр, яңгыр Арчаны ике кулсыз итте дә куйды.

Боларны мин аңлыйм. Боларны Зәйнуллин аңлый. Ләкин бит радио булганны хәбәр итә, кем кайчан чәчкәнне, кем кайчан уракка төшкәнне тәфтишләп тормый.

Районнар тигез. Арча артта бара.

Бу, мөгаен, райком секретареның йөрәгенә пычак булып кадалады р.

Яңгырлар вакытында мин ике мәртәбә Арча якларына чыгып кердем. Берсе — Тукай-Кырлайга, икенчесе — «Куйбышев» колхозына.

Дөньяны сыек томан төсле яңгыр пәрдәсе томалаган иде. Без брезент япмалы газикта барабыз. Тукай-Кырлайга хәтле асфальт юл салынган, машина астына кара тасма булып юл йөгереп кереп бара, анда-санда серәеп утырган салам эскертләре, игененең әле яртысы да урылмаган тоташ кырлар күңелдә моңсулык, хәтта шом уята иде.

Без бит әле турыдан-туры шул эшкә, ягъни урып-җыюга катнашы булган кешеләр түгел, ә менә 110 мең гектар игенне җилкәсенә йөк итеп салган Зәйнуллинның күңелендә ни икән хәзер?

Тукай-Кырлай председателе безне шактый ук тоныкчырай белән каршы алды.

— Хәлләрегез ничек?— дип сорагач:

— Берничек тә түгел,— диде.

— Яңгыр туктамаса, нишләргә исәбегез соң?— дидек без, аның хәленә кереп.

— Туктамаячак инде ул. Бетте инде игеннәр!..— дип кул селтәде. Аның болай да караңгы чырайлы битен сакал-мыек баскан, үкчәсе тапталган кирза итекләре пычракка баткан иде.

«Әгәр барлык председательләрнең дә кәефләре шундый булса, Зәйнуллинның эшләре шәптән түгел бит. Игене тоташы белән кырда утырып калачак. Моның өчен аның башыннан сыйпамаслар...» —диде бу юлы да минем белән чыккан Мөхәммәт.

«Куйбышев» колхозына без Арчаның район газетасы редакторы Таҗиев машинасы белән бардык. Юлда Масрага, Курсага кереп чыктык. Кереп чыгуыбыз ярады. Бу ике колхозның барлык җитәкчеләре — председательләре дә, парторглары да, комсомол вожаклары да — барысы да ындыр табакларында, амбарларда, сушилкаларда иде. Монда әш туктамаган, монда ашлык киптерәләр, бөркәүле ындыр табакларында ашлык җилгәрәләр, аз гына көн аязу белән элеваторга җибәрергә әзерлиләр иде.

— Болай булгач, Зәйнуллинның хәле без уйлаганча ук начар түгел әле,— диде Мөхәммәт.

«Куйбышев» басуларына җитәрәк, көн аяза башлады. Яңгыр туктады. Күзне каплаган томан алып ташланды. Гөберчәк урманнары, бала чакта без кура җиләге, шомырт, миләш җыярга йөргән урманнар, шүрәлеләр качып ятардай куе кара урманнар, атна буена яуган яңгырлардан юылып, җәй буена җитәрлек дым алып, күкрәп утыралар иде.

Мөхәммәт Мәһдиев, Гөберчәк егете, Арча ягы язучысы, машинадан башын тыгып, каерылып-каерылып карады урманнарга.

Бәлки ул ялан аяклы бала чагын искә төшергәндер. Бәлки җәйләрен, сугыштан соңгы авыр елларда, үләрен-калырын белми, бәләкәй арба белән печән ташыган чакларын уйлагандыр. Әллә шушы урман буйларын яңгыратып тальян гармунга җырлый-җырлый, флотка чыгып киткән чакларын искә алды микән?

Ни генә булмасын, Гөберчәк урманнарына Гөберчәк егете каерылып-каерылып карады.

Авылга кайтып керергә ярты чакрымнар калгач, ул, ниһаять, түзмәде, сүз башлады.

— И-ии, бу урман туйдырып та карады инде Гөберчәкне!— диде. Аз гына тын баргач, өстәп әйтте: — Колхозга печәнгә төшәр алдыннан колхозчыларга өч көн бирелер иде. Эшләп тә карар иде соң халык. Ногманныкылар беренче тотынып иде. Хатыны Миңкамалттәй, үзе Ногман абзый, ике малае, ике кызы, киленнәре... Алар шул өч көндә, мөгаен, керфек тә какмаганнардыр. Ногманныкылар шул өч көндә эшләгән кадәр бөтен ил эшләсә, билләһи дип әйтәм, әллә кайчан коммунизм булган булыр иде инде. Өч көн эчендә ике кибән печән өеп куярлар иде шул. Башка берәү булса, кышын арган буыннарын хәл алдырып, рәхәтләнеп кенә ятар иде, сыеры бар, сарыклары абзар тулы, өй нарат бүрәнәдән, дөнья түгәрәк. Юк, иптәшкәем, Ногманныкылар итек баса, кыш буе баса, кайнар судан алган киез кулларын яндырып ала, өф-өф килә Ногманныкылар, кулын пешерә-пешерә, киез әвәли. Мәскәүгә илтеп күргәзмәгә куярлык чибәр булыр иде Ногманныкыларның итеге.— Тора торгач, Мөхәммәт үз алдына кеткелдәп көлеп куйды. Минем сәерсенеп аңа күтәрелеп каравымны күргәч, нигә көлгәнен аңлатырга тотынды: — Ногман абзый белән Миңкамалттәй безнең авылда эш ягыннан гына түгел, бер-берсенә мөнәсәбәтләре ягыннан да үрнәк иде алар. Ногман абзыйны авыл советына чакырып алсалар, Миңкамалттәй ярты сәгать эчендә аны сагынып өлгерә, капка төбенә чыгып, кулларын каш өстенә куеп, картын көтә торган иде. Коеп куйган Таһир белән Зөһрә! Бер-берсен көйләп кенә, кайгыртышып кына, өф итеп кенә яшәделәр инде. Әйтәсе дә юк — авылга үрнәк. Әсәрнең баш герое булырлык кешеләр. Кояшта да тап бар дигән шикелле, көнләшкән бит бер заман безнең Миңкамалттәй Ногманыннан. «Нишләп син катыннар утыра торган «эскәмбикәне» тәбәнәк итеп ясыйсың?» — дип бәйләнгән бу. «Утырырга җайлы булсын дип әйтәм», — дигән Ногман. «Юк, — дигән Миңкамалы, — син аны катыннар ботын югарырак күтәрсен дип шулай тәбәнәк итәсең, беләм мин сине, карт боргыч. Картаймыш көнеңдә азып-тузып барасың!» — дигән.

— Шуннан, шуннан? — дидек без редактор Таҗиев белән икебез берьюлы. — Шуннан ни булды?

Мөхәммәтнең карчыга борынлы, кап-кара кашлы чибәр чыраена моңсу күләгә кунды.

— Сиксәнгә җитеп килгән чаклары иде инде аларның. Ногман абзый бик нык рәнҗегән, «эскәмбикәне» дөрләп янган утка аткан. Шуннан соң алар итек басудан туктадылар. Берәр елдан үлеп тә киттеләр. Башта Миңкамалттәй үлде, Ногман абзый кая барырларга белмәде инде. Урал ягында тимер юлда эшләгән олы малае янына барып кайтты, Казанга китеп төпләнгән ике кызы янына килеп китте, тагын кайларгадыр барды. Кая гына бармасын — телендә Миңкамалттәй, күзендә — яшь. Тап-таза, сау-сәламәт кеше иде әле, карчыгы үлгәнгә ярты ел уздымы-юкмы, монысы да гүр иясе булды. Бар әле ул безнең заманда Таһир-Зөһрәләр, бар, иптәшкәем, без аларга игътибар гына итмибез...

Гөберчәктә без өч сәгатьләр чамасы булдык. Мөхәммәтләрнең төп йортларына кайтып тамак ялгап алдык. Мөхәммәтнең апасы, биш дистәне вакларга керешкән, әмма үзе әле яшь һәм бик тә мөлаем чырайлы Равилә, безне, көтеп алган кадерле кунаклар итеп, зурдан кубып сыйламакчы да булган иде. Мөхәммәт белән без кырт кистек:

— Ярамый!

— Нишләп? — диде Равилә, рәнҗегәндәй итеп.

— Эш вакыты. Күрәсе кешеләр, сөйләшәсе кешеләр бар, — диде Мөхәммәт. — Без көзгедәй чиста булырга тиеш.

— Әй, көннәре дә яңгырлы, сагышны бездә зәмзәм суы белән басалар, — диде Равилә.

— Кемнәр?

— Механизаторлар.

— Аларга ярый. Без механизаторлар түгел, без каләм әһелләре. Юкса болай да халык арасында язучы белән артистны зәмзәм суына мөкиббән китүче итеп карарга өйрәнгәннәр... — дидем мин.

Фәйзрахмановны без идарәдә очраттык. Озын буйлы, ак чырайлы — киеме дә, уйлаган уйлары да якты кеше булып чыкты «Куйбышев» колхозының председателе. Безне ул, Тукай-Кырлай председателе кебек, кашын-башын җимереп каршы алмады. Иң якын туганнарын, хезмәттәшләрен, коллегаларын каршылагандай каршылады.

— Саумы, туганнар! Исән-имин килеп җиттегезме? Яңгырлар куркытмадымы үзегезне?

— Безне яңгыр куркытмады. Арчаның Көтернас елгасын буып ясаган күлләренә яңгыр яуганны күрү үзе бер хозурлык булды. Киного төшереп алырлык күренеш! — дидем мин, Фәйзрахмановның моңа ничек каравын белергә теләдем. Яңгырлар үзәк бәгъренә үткән председатель миңа бу сүзләрем, юк кына нәрсәгә тилемсә соклануым өчен, һич югы, каш җыерып карарга тиеш иде.

Гаҗәп хәл — каш җыермады Фәйзрахманов. Тагын да яктыра төште.

— Гомер минем язучы белән артистка сокланып уза инде. Без күрмәгән гади генә нәрсәдән дә могҗиза таба беләсез бит сез. Механизаторлар яңгыр ява дип сагышланып утыра, игеннәр мура дип борсалана, ә сез...

— Ә сез, — дип эләктереп алды аның сүзен редактор Таҗиев. — Сез, председатель, моңайган кешегә бер дә охшамаган бит әле. Бу гайре табигыйрәк килеп чыга түгелме?

Фәйзрахмановның алчак чырае җитдиләнә төште. Кашлары, сорау галәмәте ясап, дугайланып тордылар да борын турысына тартылдылар.

— Беләсезме? Моңаерга сәбәп күрмим әле мин. Беренчедән, колхозның эше игеннәрне җыеп алу белән генә бетми бит. Бәрәңге бар әле. Бәрәңгегә бик тә кирәк иде яңгыр. Бер атна эчендә ул аңа үткәзде. Инде август ахырына кадәр яумаса да, дым җитәрлек. Икенчедән, урманнар корып бара иде, радио көн саен: урманга кермә, ут белән кайнашма, учак якма дип кисәтә башлаган иде. Өченчедән, без аяз вакытта игеннең кырык процентын җыеп, сугып калырга өлгердек.

— Ничек ул алай? Башкалар бит әле 20 процент кына урып өлгергәннәр, урганнары да җирдә ята, — диде Мөхәммәт.

— Син бит Гөберчәкләрнең эшкә нинди ярсынып тотынуларын беләсең, Мөхәммәт Сөнгатович. Комбайннарга гына ышанып ятмадык. Урак белән, чалгы белән халыкны күтәрдек, үсмерләрне, карткорыны. Борчакны гел дә менә өлкән яшьтәгеләр башкарып чыкты. Яңгырлы көннәрдә терлек абзарларын ремонтладык, симәнә ашлыгын югары кондициясенә җиткереп салып куйдык. Кичләрен клубка үзешчән сәнгатьне җыябыз...

Фәйзрахмановның сөйлисе сүзләре күп, йөзе һаман да якты, без килгәнгә ул чиксез сөенгән иде.

Күк йөзендә тагын болытлар куера, тамырлана башлаганны күреп, без кайту юлына ашыктык.

Курсаны чыгып, Арчага якынлашкач, Балык күлләре өстендә яңгыр бии башлады. Күз күреме җирдә тупырдашып бии яңгыр, машинаның брезент япмасына шыбыр-шыбыр коела, әнә шулар күңелдәге уйларны әллә кайларга алып китәләр, бала чакларны, яңгыр боткасы теләп чапкан вакытларны күңелдә яңарталар иде.

— Фәйзрахмановка район җитәкчеләре ничегрәк карыйлар? — дип сорадым мин Таҗиевтан.

— Сәеррәк кеше итеп карыйлар, — диде Таҗиев. — Сәерлеккә дә сәер бит. Мин моны начар мәгънәсендә әйтмим. Фәйзрахмановның райондагы башка бер генә председательгә дә охшамаган яклары бар. Әйтик, сәнгать белән мавыгу. Бер вакытны шулай райком секретаре килеп төшә Гөберчәккә, колхоз җитәкчеләрен күрүдән алда, Харис Зиннәтулловичның авыл белән таныша торган гадәте бар. Кырларны, амбарларны, ферма ихаталарын әйләнә бу. Фермага килсә — мөгрәү тавышы. Сузып-сузып мөгри сыерлар...

— Ник мөгриләр? — ди секретарь.

— Саумаганга, — ди шунда бүрәнә өстендә утырып торган бер карт.

— Ә ник саумыйлар?

— Савымчы кызларның вакыты юк, клубта җырлап-биеп йөриләр...

Менә шундый сәер гадәтләре дә чыгып куя кайвакыт «Куйбышев» председателенең. Яшь әле, мавыга торган чагы.

— Секретарьдан эләккәнме соң үзенә?

— Эләккәндер, күрәсең, әйтми анысын.

## Секретарь иртә уяна

Тагын ике көннән күк йөзе аязды. Яңгырлар туктады. Ниһаять, мин Зәйнуллин белән очрашырга булдым. Аны иртәнге якта ук очрату нияте белән кичтән үк Арчага кайтып кундым.

Туганнарым миңа Зәйнуллинның бик иртә торуын әйттеләр. Сәгать бишенче яртыда ук уятып, секретарьның кайсы урамда, ничәнче йортта торуын өйрәтеп җибәрделәр.

Арча урамыннан барам — машина-мазар юк. Иген басуларында, элеватор юлларында, күрәсең. Райүзәк халкы уянган, йөри. Арчада агач күп хәзер, урамнар ямь-яшел, шул яшеллек арасыннан йортлар күренми дә диярлек. Без Арча педучилищесында укыган елларны урамнар шәрә иде. Атлы арба чабып узса, тузан болыты куба иде. Хәзер дә тузан бетмәгән. Ике көн эчендә кибеп өлгергән урамнан йөк машинасы узды — артыннан тузан койрыгы сузылып калды. Тузан күп әле райүзәкләрдә, күп, кайчан бетәр ул?! Йортлар да таза, агачлар да күп, рәшәткәләре дә буяулы — тузаның бетерер хәл юк Арчаның. Юк, каһәр төшкересе!..

Сәгать иртәнге биш. Райком бинасына керәм: урам ягы ишекләре бикле түгел, кабинет ишеге дә ачык. Зәйнуллиныбыз күптән анда, колхозлар белән сөйләшеп утыра.

Ул шундый бирелеп, телефон трубкасына кереп китәрдәй булып сөйләшә, минем ишек төбенә килеп туктаганымны да сизми калды.

Костюмнан, ак күлмәктән, галстуктан. Чәчләре кара, бөдрә, йөзе алсу — урын җылысы да китеп бетмәгән әле. Күзләре борчулы, керфек төпләре ялкынсынган — йокысыз төннәр галәмәте.

Бер колхоз белән сөйләшеп бетереп, икенчесен җыярга тотынган арада мин үземнең дөньяда барлыгымны белдерәм:

— Исәнмесез, иптәш Зәйнуллин!

Ул тавыш килгән якка борыла. Йөзенә аптырау галәмәте чыга, йодрыклары белән күзен уа, шуннан соң гына үзенә хас ягымлы елмаюы белән елмаеп җибәрә:

— У-уу, иптәш Ахунов! Күземә күренәсеңме дип торам. Ничек болай иртә? Хатының белән талашып чыгып киттең мәллә?

Шаярта, янәсе!

Күрешәбез. Ике-өч сүз белән генә хәлләрне сорашабыз. Мин аңа көне буе иген басуларында йөрергә кайтканымны әйтәм. Комачауламасам, үзең белән алып йөр, кабинетыңда утыртып тор, элеваторларга алып төш, председательләреңне күрсәт, дим. Ул риза. Ул эшен дәвам иттерә. Мин аңардан арырак китеп, дөньяда юк төсле, үз эшемә керешәм — аның гамәлен күзәтәм, сүзләрен тыңлыйм.

Зәйнуллин телефонда:

— Фәйзи Әхмәтович, борчакны «ОС-4,5» аркылы чыгара күрегез. Казаннан Фәттахов килде — икмәк продуктларының республика идарәсе начальнигы. Заготзернода без тапшырган борчакны карадылар. Әйе. Килештермәделәр. Риза түгелләр, дим. Каралган, диләр. Ишетәсеңме — каралган өлеше процентан чигерелә. Чиге-ре-лә! Борчакны чыгармый тор, тиккә машина кума! «Комбикорма итеп Россиягә тарата алмыйм», — ди Фәттахов. Әйе. Шулай. Сөйләшеп чыктыңмы? Барысына да әйттеңме? Хәзер, имынны хәзер әйтергә. Әйтмәделәр дип әйтмәсеннәр өчен. Исәбе кирәк аның. Комбайннарың уракка киттеме? Симәнә? Борчак дисеңме? Кирәкми. Борчак белән азапланмасыннар. Яңгырсыз районнар борчакның бик әйбәтен тапшырганнар. Дәүләттән безгә ун мең тонна борчак бирергә вәгъдә иттеләр. Әйе. Симәнә борчагы. Арыш әзерләгез дәүләткә, бодай...

Телефон трубкасын куя, уйланып тора, миңа карамый гына икенче номерны җыя:

— Фазлыяхмәтов, «Ракета», Фазлыяхмәтов! Хәлләр ничек? График үтәләме? Тырышабыз дисең, алайса? Төнлә икмәк килдеме? Юк?! Нишләп «юк?» Китертегез. Колхоз машиналары төнлә икмәк китерсен. Шеф машиналары гына ял итсен. Пермьнекеләр. Аларның алмаш шоферлары юк. Шуңа күрә ял итәләр. Әйе. Бүген шимбә, иртәгә якшәмбе. Дүшәмбе көнне бюроны җыябыз, ике көн эчендә икмәкнең килү-килмәвен тикшерәбез. Кичә мин колхозлардан кайттым, кичке тугызда басуларда комбайн юк иде. Аңламыйм. Юк. Колхозларга көндез бармагыз, көндез сез кирәкми анда. Кичен барыгыз, төнлә. Борчак «ОС-4,5» аркылы чыгарылып, элеваторга килсен. Кичә кич син колхозда түгел идең. «Ракета»да түгел идең, дим. Тикшерермен...

Зәйнуллин янә телефонда:

— Алло, иптәш Пантелеев, «Власть Советов», алло! Нишләп кичә борчак чыгармадыгыз? Үз машинагыздан берәү дә юк иде элеватор юлында. Комбайннарны борчакка куярга кирәк. Графикны үтәргә. Төнлә белән барлык машинаны икмәк илтергә куйыйк.

Ул тагын кайсыдыр председательләр белән, колхозларга беркетелгән бюро членнары белән сөйләште, сөйләшә-сөйләшә тамагы карлыккач, хәл җыеп, туктап торды.

— Ничә центнер аласыз гектар башыннан? — дидем.

— Район буенча унҗиде. Төньяк районнарда уңыш гомер-гомергә тугыз-ун центнер булып килде. Ындыр табаклары, сушилкалар, амбарлар әнә шул ун центнерга көйләнгән иде. Сыйдыра алмыйлар

быел, куәтләре җитми. Китергән чакта арыш ыслана, корым йогыла, димәк, ашыгалар, карап-күзәтеп өлгермиләр.

— Район буенча унҗиде очраклы хәлме, әллә гел шулай булачакмы?

— Шулай булачак. Бөтен районда химизация үткәрелде. Ашлама күп кертелде. Республика булышты.

— Димәк, райком секретареның булдыклылыгы өлкә җитәкчеләренә дә бәйле.

— Бәйле булмаган кая! Бездә бит көлсу туфрак. Иң уңдырышсызы. Әгерҗедә тоташ ком, ком булып ком унике центнер бирә. Без тугыз белән утыра идек. Республика булышлыгы плюс механизаторларның маңгай тире — менә сиңа гектар башыннан унҗиде центнер.

— Тагын бер сорау: амбарларны, сушилкаларны, ындыр табакларын шул уңышка көйләргә туры киләчәкме?

— Һичшиксез!

— «ОС-4,5» дип бик күп кабатладың, анысы нинди могҗиза?

— Русчалатып әйткәндә, «очиститель семян с производительностью на час 4,5 тонны». Күрдең — нинди озын сүз! Моның аркылы, гадәттә, симәнә ашлыгын гына, орлыкка дигәнне генә үткәрә торган идек. Ул, әйтик, бөртекнең эресен — эрегә, вагын—вакка, кибәген кибәккә аера, кешеләрне аерган кебек. Быел елы шундый — борчакның дәүләткә сата торганын да «ОС-4,5» тән үткәрергә туры килә. Шул чагында гына ярый.

— Элеватордан китергән икмәгегезне борып җибәрү очраклары буламы?

— Булмыймы соң! Адым саен.

— Ул бәладән ничек чыгасыз?

— Икмәк продуктлары әзерләүнең республика начальнигы Фәттаховны чакырттым. Болай гына килми әле ул сиңа. Обком аркылы, совмин аркылы эш йөртергә туры килде. Килде Фәттахов, үзе белән ике белгеч — ике юан апай алып килгән. Хәлләрне белергә, нәрсә яраганны, нәрсә ярамаганны карарга дип, элеваторга керүем булды, әлеге апайларым икесе ике ягыма килеп бастылар да тотындылар, мин сиңайтим, кычкырырга! Кем сезгә, имеш, утыз процент бозык борчак тапшырырга рөхсәт итте? Нишләп сез, дәүләтне алдап, күз буяп, түбән кондицияле ашлык тапшырасыз? Киттеләр тезеп, киттеләр!

Яңгырлар, йокысыз төннәр, кырда үргән икмәк, казылмалы юллар минем сабырлыкны тәмам төкәндергән икән. Тотындым бер заманны тегеләргә үзем, тотындым, шәһәрдә, уңайлы квартирада яшәүләрен дә, көненә сигез сәгать, атнасына биш көн генә эшләүләрен дә, бизәнеп-ясанып театрларга йөрүләрен дә — берсен дә калдырмадым, утлы табага салып, борчак урынына куырдым. Аннары лабораториягә кереп, ишекне ныгытып яптым:

— Менә хәзер танышыйк инде, сезне Казаннан мин чакырып китердем, өлкә комитеты, совмин аркылы, — дидем.

— Ничава себе танышу, үтерергә килгәнсез дип торабыз, — диләр апайларым. Иплән кенә, кешечә итеп кенә аңлата башламасыннармы, мин сиңайтим. Менә шулай эшләр рәтләнде. Триерын билгеләдек, председательләргә җиткездек хәлне. Машиналар борылып кире кайтмый башлады элеватордан.

Авыл хуҗалыгы идарәсе начальнигы Сибгатуллин керде. Таза бәдәнле. Арча ягы кешеләренең күбесенә хас булганча, чибәр, киңчә йөзле.

Зәйнуллин аның белән бик үз итеп, ягымлы итеп хәлләрне сорашты. Дөресрәге — иртән телефоннан барлаганнарны тагын бер мәртәбә тикшереп-барлап чыккач:

— Нурзада Әсхәдуллович, без колхозларга чыгып керәбез. Сиңа телефон төбен сакларга туры киләчәк. Казаннан шалтыратулары ихтимал. Мин кичкә әйләнеп кайтырмын. Сводка әзер булсын, яме, — диде.

Без Зәйнуллин белән кырларга чыгып киттек.



## Арчадан Әтнәгә хәтле...

Арчадан Әтнәгә хәтле арада — кырык чакрымнарга сузылган уйсулыкта, — тоташ дала булып басулар җәйрәп ята. Игене урылган һәм саламы җыелган кырларда, ял итәргә чыккан гигант бегемотлар төсле, салам эскертләре тезелгән. Җилекләргә төшкән вак яңгыр саламның төсен алган, шулай да соңарып булса да калыккан һәм биек зәңгәр күк йөзенә менеп кунаклаган кояш әнә шул эскертләрне, камыл басуларын сары төскә мана, дым муллыктан тулышкан буй урманнарны куе-каракучкыл, фирүзәдәй яшел итеп күрсәтә, пәһлеван бер парикмахер бөдрәләп чыккан төсле, сөрлеккән арыш басулары — әле комбайннар урагы кагылырга өлгермәгән игеннәр — механизаторларны көтеп зарыгалар. Әнә шул иксез-чиксез иген басуларына карыйсың да: «Моны ничекләр итеп урырлар, гомумән, ура алырлармы?» — дип борчыла башлыйсың.

Ура механизатор.

Комбайн уraклары янына җиргә яткан игенне күтәрердәй җайланмалар, арата-колгалар куеп ура, җиргә бер башагын да төшерми урып бара; икенче бер урында комбайннар өстендә кара болыттай тузан өермәләнә — борчак сугалар, ындыр табакларында тау-тау булып көшелләр өелеп тора, сап-сары—бодаймы дип уйлыйсың, юк—борчак, нигә ак түгел, нигә сары булып күренә, көшелгә якын ук килеп, учны тутырып алгач, аңлыйсың: араларында өлгерми кипкәне, ватылганы, ярылганы күп икән, аны кат-кат җилләтәләр, киптерәләр, ничәмә-ничә триердан үткәрәләр, бер сүз белән әйткәндә — быелгы борчак элеваторга барып җиткәнче игенченең маңгаеннан кара тир агыза, башка елларны нибары бер җилләтү белән турыдан-туры элеваторга китеп бара торган борчак өчләтә хезмәт, мәшәкать таләп итә.

Арча-Әтнә өстендә чиләге-чиләге белән койган иде яңгыр, иген уру нык тоткарланганлыктан, игенчеләрнең кәефе бигүк әйбәт булмаска тиеш иде, әмма ике көн эчендә кипшереп өлгергән иген басуларында эш кайнаганлыгын без бер карауда күреп алдык.

— Борчагыгыз бик күп иде бит. Әллә җыеп бетердегез дәме?

— Борчакка егерме мең кешене күтәрдек: коммунистлар эшләде, комсомоллар йокы күрмәде, агитаторлар чатыр чапты, олысы-кечесе урак белән, чалгы белән чыкты, унар-егермешәр ел буе басуларның ни икәнен белмәгән, «шәһәрләшкән» Арча халкы кузгалды. Моны мин райкомның зур җиңүе дип саныйм.

— Республика ун көнлек график төзеде бугай. Арча графигында көн саен дәүләткә ашлык чыгару күпме?

— Удар ун көнлеккә — 25 мең тонна.

— Күпме машина тотыла шуңа?

— Колхозларның үзләренеке 600 машина, көндез комбайн белән ындыр арасында чабалар, кичен элеваторга ашлык илтәләр. Шуның өстәвенә, 500 машина — Казан белән Пермьнән килгәне.

— Бер мең дә бер йөз машина! Бер Арча районына шул хәтле транспорт? Республикага күпме була ул: утыз мең чамасымы?

— Әйе, шул тирә.

— Алай да дәүләт булыша игенчегә. Хәтерлим әле, мин үскәндә авылда бер генә дә машина юк иде. Көлтәне ындырга атлы арба белән ташыйлар иде.

— Әйе, булды андый заман, — ди Зәйнуллин, минем белән килешеп. — Урып-җыюга хәзер бөтен ил кузгала. Күршенең хәленә күрше керә, район белән район, шәһәр белән шәһәр үзара ярдәмләшеп эшли. Өстәмә 500 машина безне чын мәгънәсендә коткара. Мондый явымлы елларны үз машинаң белән генә ерак китә алмыйсың.

Юлның уң ягында тракторчы егет басу сөреп ята — арыш чәчәргә. Дымга туенган җир озын тасма булып каралып кала. Зәйнуллин җирне ошатмады. Ара-тирә күмелми калган камылларга башын чайкап карап торды да тракторның җир башыннан килеп җиткәнен көтеп алды: ямьшәйгән кепкалы, комбинезонлы, унҗиделәр тирәсендәге таза һәм сөйкемле егет райком секретаре белән тартынып кына күреште.

— Энем, син механизаторлар мәктәбендә агротехника уздыңмы? — диде Зәйнуллин.

— Уздым.

— Узсаң, менә шул: алгы кече төрәнеңне төшерергә кирәк. Бу бит борчак җире түгел. Күрмисеңмени — кукуруз камылы күмелми. Ә нигә каток такмадың? Каток тагасын белмисеңмени? Утырмый бит җирең. Дым күп, уҗым тишелеп чыккач, җирең утыра башласа, арышның тамырын харап итәчәк бит. Өзеп бетерәчәк тамырын. Әйтик, сине, юк, мине дип әйтик, авыр җир басып торса, бик тә кыен булачак бит. Аңлата алдыммы?

— Аңладым... — диде егет.

— Мин әйткәнчә эшләрсеңме?

— Хәзер каток китерәм.

— Председатель абыеңа әйт, агрономына аңлатсын, яме.

Без кузгалып киттек.

— Чамадан тыш йомшак сөйләштең. Егет җирне бозып ята. Катырак сөйләшсәң дә булыр иде, — дидем мин.

— Катырак та сөйләшкән чаклар бар минем. Ләкин бу юлы ярамый. Егете бик яшь әле, игенчелек эшеннән гайрәте чигеп куюы бар, — диде Зәйнуллин. Байтак вакыт сүзсез баргач, бик күптән булган бер хәлне исенә төшереп сөйли башлады.— Үземнең гыйбрәтле хәлгә тарыганым бар. Моннан күп еллар элек, егерме алты яшемдә авырдым мин. Аяксыз калып, өч ай больницада яттым. Шул чор минем тормыш принцибымны, кешеләргә булган мөнәсәбәтемне билгеләде.

Авыруым суык тиюдән башланды. Казанда югары партия мәктәбендә укый идем. Көзен, бик суык көнне Кенәрдән машина кузовында килдем, партмәктәпкә соң гына килеп җиттем, аягым авызыма кабарлык булып туңды. Аракы алып кайтыгыз әле дип ялвардым егетләргә, туңган аякны спирт белән уарга кирәк дип ишеткәнем бар иде. Чыгып киттеләр егетләрем, кибетләр ябылган, кем синең өчен ресторуннан кыйбат хакка аракы алып йөрсен. Ярый, нишләмәк кирәк — ятып йокладым мин ул көнне, иртәгесен мунчага барып карарга булдым. Эссе ләүкәдә чабынып, аяк туңганны мунча пары белән чыгарам, янәсе. Өскә бер ләгән җылы су сибеп җибәрүем булды, корсак тимгел-тимгел булып кызарып чыкты. Безнең партмәктәптә врачлар бар иде, йогышлы дип инфекционныйга җибәрделәр. Анда аны кызамык дип таптылар. Ә кызамык, үзеңә мәгълүм, балаларда гына була бит ул. Салып куйдылар мине балалар больницасына. Биш-алты көн яттым, битне кап-кара сакал басты. Партмәктәпкә хат язып салдым. Бер иптәшем тәрәзәгә килде, мине күргәч аптырап калды. Сакалбайны танымый тора. Тимгелләр бераздан бетте — кайтырга

чыктым. Казанда кардәшләребез бар иде, башта, мәктәпкә кайтканчы, аларга кереп чыгарга уйладым. Баскыч төпләренә килеп җитүем булды, киселгән имән кебек, аудым да киттем: аяклар йөрүдән туктады.

Өйләренә күтәреп алып керделәр.

«Больницага хәбәр итегез», — дим, итмиләр.

Өч көн торгач, түр тәрәзә турысына грузовик килеп туктады. Тәрәзәне ачып, шоферын чакырдым. Мине, мәйтәм, такси машинасына хәтле илтеп куя алмассыңмы, теләгән кадәр акча бирәм, мин әйтәм.

Илтеп куйды. Такси белән партмәктәпкә кайттым — өч егет икенче катка күтәреп алып менделәр. Аннары обком больницасына күчтем. Өч ай яттым аяксыз, 56 килога калдым — шыр сөяк. Мине укудан чыгару яки академик ял бирү турында сүз бара. Алары — партмәктәп тарихында сирәк була торган хәл.

Директор Назаров, Геннадий Спиридонович, үз янына чакырып алды. Кердем. Бик тырышып телефоннан сөйләшә. «Иптәш Тарасов, — ди, — ул әле бик яшь, — ди, — ябыкты, — ди. — Казан санаториена урнаштырырга кирәк,— ди.— обком исәбенә бушлай путевка бирегез», — ди. Тарасов дигәне — обком бухгалтеры. Ә мин аңламый торам. Бактың исә, директор мине кайгырта икән ләбаса!

Казан санаториенда бер ай ял итеп алты килограммга арттым. Стипендия дә сакланды. Анысына өс-баш рәтләдем. Авыр еллар иде бу. Укуны дәвам итәр алдыннан авылга кайтып килергә ниятләдем, энилэрне күреп киләсем килде. Кайтып төштем, аптырыйлар: Зиннәтулла малаен авырган дигәннәр иде, бу бит бер дә авыру кешегә охшамаган әле, диләр.

Аяклар авыртса да, баш ярыйсы эшли иде. Санаторийдан чыгуга ике фәнне дүртлегә тапшырдым. Калганнарын март аенда тапшырып бетердем.

— Әһә, аңладым, имәндә икән чикләвек.

— Нәрсә аңладың?

— Назаров синең күңелеңә гомерлеккә кереп калган.

— Әйе, чын җитәкче нинди дә, кәҗүнни җитәкче нинди булганны мин шунда төшендем. Геннадий Спиридонович мине партмәктәптән бик рәхәтләнеп чыгара ала иде, аңа беркем бер сүз әйтмәс иде. Ник дигәндә, мин әле нибарысы ике ай укыган идем. Икенчедән, ул шушы яшендә аяксыз яткан егеттән нинди партработник чыксын, дип уйлый ала иде. Алай итмәде, кешечә килде, мин аңа гомер буе рәхмәтле. Әнә шул сабак булды миңа, эшемдә булыша торган сабак.

— Назаровны күргәнең бармы соң?

— Бар.

— Әйткәнең дә бармы?

— Әйткәнем дә бар. Хәзер ул бер югары уку йортының доценты, педагог.

— Нәрсә ди?

— Онытткан. Исенә төшерә алмады.

— Димәк, ул яхшылык эшлим, үземне күрсәтим дип эшләмәгән.

— Гуманлык бар аның канында, кешеләргә ихтирам бар...

## Юл тулы утлар...

Фәйзи Галиев озак еллар җитәкләгән «Искра» колхозы басуына кереп чыктык. Салам җыялар. Гөрләп бара эшләре. Өч машина тора, өч трактор. Тракторларның икесе тимер рәшәткә төсле зур гына корылма тагып, урам киңлеге араны иңләп китеп бардылар. Артларын-

нан себереп куйган ишегалды кебек ялт итеп калды. Ике минут та узмагандыр, күз күреме җирнең саламы җыелып, зур бер эскерт өеп куелды. Сугышка кадәрге елларда бер эскерт салыр өчен ни гомерләр интегә торган иде колхозчы!

Аннары без Фәйзи Галиевне күрергә теләп (Зәйнуллинның аны миңа никтер бик тә күрсәтәсе килде!), тагын ике басуга, борчакны триердан үткәргән ындыр табагына, колхоз идарәсенә, амбарларга кереп чыктык, Фәйзи Галиев очрамады — Арча элеваторына киткән булып чыкты.

Кайтышлый, кояш баер алдыннан, без, тамак ачканны абайлап, кырга, дөресрәге, кыр уртасында тырпаеп торган агачлык янына туктадык. Зәйнуллин машина багажнигыннан термос белән чәй алды, өеннән биреп җибәргән азык-төлек алды, башка вак-төякне запас капчыгыннан чыгарды.

Саф һавада тамак ялгавы бик тә рәхәт иде.

— Карале, Харис Зиннәтуллович,— дидем мин.— Сиңа бик күп кеше белән сөйләшергә туры килә. Председательләр белән парторглардан башлап, гади бер механизатор яки сыер савучы кызга кадәр. Син шулар башкарган эшне биш бармагың кебек белергә тиешме? Әллә башка берәр әмәле бармы аның? Әйтик, әнә син җир сукалаучы егет белән белеп сөйләштең, аның сиңа ихтирамы арткандыр, әйеме?

— Ничек дип әйтим? Һәр эштә чама хисе булырга тиеш. Минем Харис исемле шоферым бар иде. Адаш-философ дип йөртә идем мин аны. Аз гына буш вакыты булдымы — кулында китап. Акылны бик күп җыйды шул егет китаплардан. Шулай көннәр буе чабып, телне асылындырыр хәлдә аргач, берәр яшел болынгамы, урман буенамы утырып, тамак ялгап алырга туктар идек. Бер вакытны шулай урман буена кырын төшеп, термостан чәй эчеп утырган чакта әйтте бу миңа:

— Һәр секретарьның җенләнгән бер нәрсәсе була, — диде, — Красиков Төбәк Чокырчаны күтәрәм дип җенләнде. Кая ул! Казанга чабып спекулянтка әйләнеп беткән Төбәкне ничек күтәрәсең! Закиров райкомга иртән иртүк килеп җенләнәдер иде. Миңа әйтә, караңгыда, таң атканда кил, ди, киләм. Райкомга кереп китә дә, сәгать унда гына чыга. Мин сәгатьләр буе машинада йоклыйм. Ул барында мин барлык йокымны машинада йокладым. Сезнең алдан эшләгән секретарьның гадәте барлык эшне, эресен-вагын үзе эшләп күрсәтү иде. Бервакытны кырга килеп туктыйбыз, комбайн эшләми. Ни булган? Барабанга салам тыгыла икән. Бите-башы тузанга буялып беткән комбайнчы егет шуны хәбәр итте. Секретарьның ачуы чыкты, үзе эшләп күрсәтмәкче булды. Пинжәген салып ташлап, җиңнәрен сызганып, барабаннан салам йолка. Комбайнчы да булыша моңа. Председатель килеп җитте — ул да йолка. Өчәүләп кара тир түгәләр. Йолкып бетереп ун метр бармыйлар, барабан тагын тыгыла. Өч сәгать азапландылар, тәки йолкып бетерә алмадылар. Комбайнчы минем янга бер читкә килеп, күз кысты: комбайннан салам йолку секретарь эшеме?! Мин бит аны хәзер юри тыгылдырам, кирәгеннән әкренрәк әйләндерсәм, тыгыла да куя, ди.

— Ә мин нәрсә белән җенләнәм? — дип сорадым ди Зәйнуллин.

— Нәрсә ди шофер-философ?

— Әйтми торам әле, — диде.

Шул көннән башлап мин һәрбер эшләгән эшемне монысы минем эшме дип карый башладым. Урып-җыю өчен җаваплы бюро членнарын да кисәтеп куйдым: комбайн артыннан йөрмәгез, аларын председатель кайгырта. Ә менә элеваторга борчак тапшыруны председатель хәл итә алмый — анысын без кайгыртырга, өлкә белән сөйләшеп хәл итәргә тиешле.

Кайтырга чыктык. Авыл яннарында яшел утрау булып зиратлар кала. Бервакытны Үзәк Комитеттан килгән бер җаваплы иптәш, адым саен очраган зиратларга таң калып: «Бу ниткән парклар?» — дип сораган иде. «Зират бу», — дигән җавапны ишеткәч: «Үлгәннәргә парк бар, тереләргә кайчан булыр?» — дигән иде...

Юлларда машиналар минут саен арта бара. Комбайннардан ындыр табакларына, ындыр табакларыннан Арча элеваторына чабалар. Эңгер иңә. Авылларда утлар кабына, сары утлар түгел, ак утлар, электр утлары. Машина фаралары да килеп кушылгач, Арча ягы тоташ ут диңгезенә әйләнә...

Машинаның ачык тәрәзәсеннән җаннарны айкап ала торган иген исе, актарылып ташланган буразналардан аңкыган җир исе, төнгеләккә ат сакларга чыккан малайларның елга тугайларында яккан учакларыннан җил белән безгә килеп җиткән төтен исләре истәлекләрне әллә кайларга алып китәләр, синең җир йөзендә барлыгыңны, яшәвеңне искә төшерәләр, син янә дә кабинет тузаннары йотып, каешланып беткән бер адәмнән чын табигать баласына әйләнеп каласың...

Райкомга кайттык. Зәйнуллин авыл хуҗалыгы идарәсе әзерләгән мәгълүматларны карарга кереште. Җәймә чаклы кәгазьдә барлык колхозларның исеме, көненә күпме сөт алуы, узган елгы белән чагыштырганда аның азмы-күпме булуы, уру, сугу, сукалау, дәүләткә ашлык тапшыру бик җентекләп күрсәтелгән иде.

Зәйнуллин белән бергә мин дә шул җәймә өстенә иелдем.

— Сөт арткан. Борчакны сугып бетерәләр. Гомумән, сугу —57 мең дә 65 га. Ашлык бүген — 27 мең центнер тапшырылган. Димәк, графикка тулысынча кердек. Болай булса, кубаньлыларга кушылып алган яңа йөкләмәне үтәрбез, — диде секретарь һәм миңа карап, бүген беренче мәртәбә иркенләп елмайды, арыган, талчыккан елмаю белән, бушка узмаган көннән канәгатьлек тапкан елмаю белән елмайды.



## ӨЧЕНЧЕ БҮЛЕК

# Арчадан больницага

Бу больница да башка больницалардан бер генә ягы белән дә аерылып тормый иде. Коридорларыннан хлор исе, корвалол исе, тагын нииндидер дару исләре килә иде.

Бу больницада да «Процедурная», «Служебная», «Электролечение» дигән бүлмәләр бар иде.

Биредә дә мебельләр, ишекләр ак, врачлар белән шәфкать туташларының халатлары ак, биредә дә укол кадыйлар, бармактан һәм венадан кан алалар, рентгеннан карап, электрокардиограмма үткәреп, авыруларга диагноз куялар, үз вакытында иртәнге ашны, көндезге һәм кичке ашны ашаталар, ял сәгатендә коридор утларын сүндереп бетереп, авыруларның бүлмәләренә керүләрен үтенәләр, хәтта шах белән мат арасында калган иң түземсез шахматчыларны да ял итәргә кертеп җибәрәләр, радио биредә ярым тавышка сөйли, кичләрен телевизорны өйләрдәге төсле каты кычкыртып куймыйлар. Биредә еллар буе урнашкан ныклы тәртип яши...

Кайчандыр чибәр булган, инде яшьлеге уза төшеп, йөзенә кырыслык һәм власть катылыгы чыккан Дания ханым, өлкән сестра, больница тәртипләрен идеаль дәрәҗәдә үтәтеп барырга тырыша иде.

Ярты гасыр гомер итеп, беркайчан да больницага һәм врачларга йөрмәгән кешегә, без фәкыйрегезгә, бу тәртип әкәмәт сәер тоела һәм ул минем шәхси ирегемне буадыр да кебек иде.

Көндезге сәгать өчтән дүрткә кадәрге арада, ял сәгатендә, мин палаталар арасында буш калган почмакка, дару шкафлары һәм аяклы зур үлчәү куелган, шәфкать туташлары җыелып, авырулардан арынып тора торган, көндәлек уй-тойгылары белән бүлешә торган аулак почмакка, диванга килеп утырам.

Мине беренче көнне Дания ханым куып караса да, мин аңа ашагач йокларга ярамаганлыгын, ашказанымның кислотасы аз булуын үтә дә ягымлы, беркатлы, сантыйрак чырай белән, елмая төшеп аңлатып биргәч, аннары минем берәүгә дә комачау итмәвемне, дәфтәр өстенә иелеп гел язып утыруымны күргәч, өлкән сестра, тешен кысып булса да, килешергә мәҗбүр булды.

Мин тынычлыкта калдым. Миңа күзәтү мәйданы ачылды. Минем һөнәрдәге кешегә шуннан да зуррак бәхет бармыни?!

Зифа буйлы, шомырт кара күзле, елмайган чакта бөтен коридорны яктыртып җибәрә торган ак тешле Роза белән, олырак битле, урта яшьләрдәге Ания ханым, авырулар тарихын, температураны яза торган өстәл янына утырган килеш, терапия бүлегендәге ике авыру хакында сүз алып баралар. Минушев белән Мангушев. Икесе дә йөрәк чиреннән интегәләр икән. Икесенә дә әле кузгалырга ярамый. Бу фамилияләр миңа таныш. Минушев дигәнен мин хәтта якыннан да беләм. Ул Татарстанның авыл хуҗалыгы министры булып эшләде, хәзер, хәтерем ялгышмаса, фәнни-тикшерену институтында директор, кандидатлык диссертациясе дә яклады шикелле.

Мин озын буйлы, кара бөдрә чәчле егетне күз алдына китерәм. Бу, әлбәттә, егерме ел элеккеге портрет. Ул — минем сабакташым белән бер авылдан, элекке Тархан районы Үтәмеш авылыннан. Үтәмеш безгә тәнкыйтьче Гали Халитны, академик Мирза Мәхмүтовны, тәрҗемәче Яхья Халитовны биргән. Берсеннән-берсе үткен телле, берсеннән-берсе җор табигатьле, ифрат чая кешеләр. Минушев Фатихны да беренче мәртәбә мин сабакташым Яхъя Халитовларда очраткан идем. Дөресен әйтәм: җиңелрәк бер кеше сыман тәэсир калдырган бу озын бөдрә егет оперетта артисты түгелме икән дигән уй да кузгаткан иде. Шуннан соң аның исемен обком, совмин исемлекләрендә күрә башлагач, озак та үтми, аның министр икәнен белгәч, бик тә сәерсенгән идем. Йөрәк белән ята диген, ә? Шундый җиңел-ваемсыз кешеләргә дә йөрәк чире йога микәнни?

...Уйга калып дәшми утыра идем, шәфкать туташларының берсе, Роза исемлесе, тирә-юньне елмаюы белән балкытып:

— Гарифҗан абый, сез безнең авылныкы бит, әйеме? — диде.

Мин көтелмәгән мондый сораудан югалыбрак калдым. Мин Кечкенә Өчиле авылында туганмын. Безнең авыл инде юк, аның урынында инде көтү йөри, коймасыз зираты тырпаеп утыра да, тау астыннан салкын чишмәләре генә агып ята...

Болар мине, мөгаен, Тукай-Кырлай янындагы Зур Өчиле белән бутыйлар булыр. Миңа, ник авылыбызны оныттың, дип шелтә белдерүчеләр дә байтак булды инде. Зур Өчиле белән Кечкенә Өчилене гел бутыйлар.

— Сез кайсы авылныкы соң, сеңелем? — дидем.

— Әбәү, Гарифҗан абый, Казанбашны онытгыгыз дамыни? Мин бит Миңниса Насыйбуллина кызы.

— Минем белән бергә укыган Миңнисамы? Сугышта пулеметчик булган кызмы?

— Шул инде, шул! — диде шәфкать туташы, кояштай балкып.

— Ә мин Әхмәт кызы, — диде шәфкать туташларының Ания исемлесе, олы коштай тыныч табигатьлесе. — Хәйруллин Әхмәтне беләсезме?

— Сугыштан ике аяксыз кайткан кешеме? Казанбашта парторг булып эшләде, озак еллар, шулмы?

— Ә сез аларын ук каян беләсез?

— Мин бит Өчиледә бригадир булып эшләдем. Уналты яшемнән. Өчиле Көтеккә карый, Казанбаш белән Көтек ярышалар иде. Казанбаш хәзер, ялгышмасам, Көтекне, Тернәлене, Көекне, Тылангырны берләштерә шикелле?

— Шуңа күрә авылдаш дибез бит инде! Арча яклары бит без. Әйе, шәфкать туташлары дөрес әйтә: без авылдашлар. Казанбашта мин җиденче классны тәмамладым. Анда мине белем дөньясына чыгарган укытучыларым яши. Анда минем сабакташ Мирбат Хәстиев колхоз председателе булып эшли. Казанбаш миңа икенче ягы белән дә газиз — анда кулаклар кулыннан һәлак булган әтиемнең кабере бар. Шулай булгач, Өчиледән соң, Казанбаш минем туган авылым санала ала.

Авылдаш сеңелләр белән безнең уртак сүзләребез күп булып чыкты. Без урманнарны, тегермән буаларын, Казанка елгасында су коенган чакларыбызны искә төшердек. Авылның тузанлы юллары, эре бөртекле җәйге яңгырлары, ак куянлы кышкы басулары безнең күз алдыннан узды. Сугыш елы авырлыкларын офтанып искә алдык, төрлесе төрле якка чәчелгән сабакташларымны сораштым мин алардан. Сагынып кешеләре күп тә соң адәм баласының!

Ания белән Роза бер көн, бер төн безнең терапия һәм хирургия бүлегендә эшләп, авыруларга дару өләшеп, температураларын үлчәп, укол кирәк булганнарына укол кадап, кемгә иртәгә нинди процедурага барырга икәнен әйтеп, арып-талып, ләкин бер генә авыруга да караңгы чырай күрсәтмичә, кешелекле булып өйләренә кайтып киттеләр.

Мин авылдашларым белән горурланып йөрдем. Күңелдәген яшерми әйтсәң, ике көн эчендә мин аларны хәтта сагынып та өлгердем... Ни дисәң дә, алар мин туган, мин үскән җирләр белән бәйле кешеләр шул. Арча якларыннан алар...

Әй, кадерле туган як, мин синең кешеләрең турында ике юл да язу язмадым бит әле. Ярты гомер нефть чыккан якларда узды, аннары мине карагайлы урманнары, тымызык күлләре белән Әгерҗе яклары биләп алды. Әгерҗе минем хатыным Шәһидә ягы. «Хатын ягы күбрәк тарта!» — дип, халык әйткән сүз әллә дөрес микән?

Әгерҗе дигәннән, миңа Әгерҗе ягы кешеләре гел очрап кына тора. Менә әле больницага кереп җитүем булды, күптәнге дусым, минем китабымның герое Хәммәт Исмәгыйлов очрады, Әгерҗедән ул, Салагыштан, «Пушкин» колхозы председателе. Ифрат мөлаем ул, ифрат әкрен сүзле. Аннан җайлы кешене көндез шәм яндырып эзләсәң дә таба алмассың. Куе кара кашлар, түгәрәк алсу йөз, сабыр карый торган кара күзләр... Корсак шәрифләре үсә төшкән, калынайган егетем, авылны зур юлга чыгарам дип тарта-тарта, кан басымы да күтәрелгән икән, шуңа күрә Казан больницасына китереп, врачлар күзәтүенә тапшырганнар.

Без аның белән шатланып күрештек. Кочаклашып күрештек дип үк әйтә алмыйм, күрешкән-очрашкан чакларда мин Хәммәтнең кочаклашканын да, төче сүзләр әйткәнен дә хәтерләмим, тышкы нәзакатлегенә күңел нәзакәтлеге аның бик тә туры килә.

— Гарифҗан Ахунҗанович, — дип, минем исемне дә, әтинең исемен дә авыз тутырып әйтеп башлады ул сүзен. Мин каршы килеп тормадым, шулай да күңелдә уй кыймылдап алды: безнең татарда

бит эти исемен кушып дәшү юк, я «абый», я «энем» бездә, Сәйфелмөлек Гаптелмөлекович дип дәшүгә без олы туганыбыз руслардан өйрәндек. Ул хәзер рәсми мөнәсәбәткә әйләнеп бара.

Ярый, без Гарифҗан Ахунҗанович булдык, ди. Хәммәт дус аны бик тә ягымлы итеп әйтте. Ни өчен минем больницага керүемне сорашты.

— Вак-төяк ремонт, — дидем мин, аны борчуга салмас өчен.

Ә чынлыкта минем эш шактый ук хөрти: бер ай эчендә мин ике өянәккә тарып, 6—7 килога кимегән идем. Мине оптимист итеп, шаян сүзле итеп күрергә өйрәнгән дусларым көл кебек ак, хәтта урыныурыны белән саргылтымга таба киткән ябык чыраема, утырып калган, чынаяктай зур күзләремә карап сискәнеп киткәндәй булалар, ә мин моны тәрбиясезлек дип саный идем. Сау-сәламәт кеше авыру янына килгәндә үзен кулда нык тотып килергә, сабыр һәм олы сымак булырга тиеш. Саксыз әйтелгән бер генә сүз дә, бер генә гамәл дә авыруны шундук аяктан ега ала, диләр врачлар.

Моны Исмәгыйлов яхшы белә иде, күрәсең.

— Гарифҗан Ахунҗанович, тартылып киткәнсең дип әйтимме, битең нәфисрәк булып калган дип әйтимме? — диде ул миңа. — Әллә бик күп эшлисеңме? Кстати, яңа романың безнең як укучыларының тынычлыгын алды. Дүрт-биш авыл җыелып конференция үткәрик, диләр.

— Беләсеңме, Хәммәт дус, хикмәт романда түгелдер. Вакыйгасы бит Салагыш тирәләреннән, әнә шул дулкынландырадыр.

— Бәхәсләшеп кәефеңне аласым килми, сине больницага китергән сәбәп нәрсә?

— Минем корсак шәрифләреннән булыжник эзлиләр, төзелешкә таш җитми бугай. Минем белән бер палатада төзелеш начальнигы Карасик ята, — дидем мин, шаяртып.

Исмәгыйлов ипле генә елмайды.

— Шаяртуны кабул иттек. Ә чын дөресе?

— Кислота аз минем. Гастрит. Үт куыгында таш юкмы икән, диләр.

— Рентгенга күренмәдеңме?

— Юк әле. Әзерлиләр.

— Алай икән. Авыруны юату кыен эш, әлбәттә. Шулай да дуслык хокукыннан файдаланып әйтер идем, больницада иҗат эшен онытып торсаң икән...

— Алдашу гадәтем юк. Күз күрер, Хәммәт дус. Үзеңне нәрсә белән дәвалыйлар?

— Төрле дару. Электр, ванна, душ. Кыскасы, ял иттерәләр. Нервыны үз урынына утыртмакчы булалар.

— Кирәк, — дидем мин. — Салагышны 16 ел буе тартасың, зур юлга алып чыктың колхозны. Ял итеп алырга да вакыттыр...

— Бәлки шулайдыр, — диде Исмәгыйлов, — ләкин шунда ук чырае сытылды. — Кайбер эшләр ярты юлда бүленеп калды. Менә шул күңелне тырнап тора...

— Кормозаводың әйбәт эшлиме?

— Алары әйбәт: тегермән дә, кормозавод та, машина паркы да... Кама күтәрелгәч, су басачак бер мең ярым гектар урынына комлы кашлакка мелиорация үткәрмәкче идек, дәүләт исәбенә — миллион ике йөз мең сум тора, шуның очына чыгасы бар. Вакытсызрак булды бу больница...

...Шифаханәдәге беренче авыруның, мин күптән белгән җитди-сабыр кешенең, ил күләмендә уйлый белә торган ир-егетнең уйлары белән танышкач, бүлмәмә кайтып утырдым. Бүлмәдәшем Карасик һава суларга чыгып киткән. Тын. Аулак. Транзисторны борып куй-

дым: Чайковскийның «Ел фасыллары» музыкасын бирәләр. Җанны тутырып, тыныч, ягымлы көй агыла. Ишегалдында кар ява. Әкрен, салмак ява, күңелләрне юатып, Исмәгыйлов кебек кешеләрнең нервыларын тынычландырып ява кар. Гомернең барлык мизгелләре, сөенечләре, кыен чаклары искә төшә. Күңелгә бер юл — шигырь юлы булып килә: «Түбәләргә ак кар яуган... Түбәләргә ак кар яуган...» Аннары икенчесе килә: «Көн яктырып киткән сыман...»

Авыру икәнең онытыла. Больницада икәнең онытыла. Өйләнеп Өчиледә туй ясап йөргән чаклар искә төшә. Иреннәр елмая. «Өчиленең Ахунҗан малае туйга бөтен авылны чакырган икән...» Ә безнең авылда нибарысы җиде йорт иде.

Үзем дә сизмәстән йоклап китәм. Төшемдә миңа зур су керә, суны күпер, күперне кар даласы алмаштыра. Суык. Җил исә. Түбәләргә, ямь-яшел агачларга кар ява. Мин белгәнчә, тыныч булып түгел, шыбырдап ява кар. Яңгыр кебек...

Мин ничектер туңып уянам. Яктырган, өстән юрган төшеп киткән. Урамга күз салам — кар эрегән, шыбырдап яңгыр ява. Кичәге шигырь юллары искә төшә, нибары бер көн гомер иткән кардан соң шыбырдап яуган ноябрь яңгырына кәеф китә һәм мин кичтән күңелгә килә башлаган шигырьне язып бетерәм:

Түбәләргә ак кар яуган,
Көн яктырып киткән сыман,
Ничә айлар күңел көткән
Ак туңлы кыш җиткән сыман.
Ап-ак карда керсез сафлык,
Пакьлек сакланган сыман,
Күпме еллар көтеп алган
Өмет акланган сыман...
Иртәгесен кар эрегән,
Күкне соры болыт баскан.
Күңелләрдә йөргән өмет,
Акланырсың икән кайчан?
Акланырсың икән кайчан?

## Врачлар дөньясы

Рәттән берничә көн бәйләнчек салкын вак яңгырлар явып торды. Авырулар боекты. Аз сөйләшүчән булып китте. Арада бер генә кеше боек түгел, ул минем бүлмәдәшем Карасик. Михаил Борисович. Яше инде алтмыштан узып китсә дә, атлетларча коеп куйган нык гәүдәсен туптай чөеп караваттан сикереп төшә ул, «Хәерле иртә!» дип миңе сәламли, пошкырына-пошкырына душ ала, иртәнге ашка тикле һава йөреп керергә дип киенә башлый. Маңгай турысы пеләшләнә башлаган дәү каты башына бүрек чәпи, озын карчыга борынын бер шоптырдатып тартып алгач, гадәттәге акыллы, зирәк сүзен әйтә:

«Минем өчен иң әшәке кешеләр — ялкау белән бирән. Алар арасында — бәлачел кеше».

Бу, әлбәттә, Михаил Борисовичның гомерлек тәҗрибәсеннән чыккан фәлсәфә, егерме ел буе төзү эшендә, главкада эшләү дәверендә ялкау белән бирән аның җан бәгыренә тиеп беткәндер. Больницага ул йөрәк авыруыннан керүен әйтеп, күбрәк һавада йөрергә куштылар, диде.

Ул кара-кучкыллы битен тутырып торган карчыга борынына киң кысалы күзлек атландырып куйды.

— Очки вам идут, — дидем мин русчалатып.

— Подлецу все к лицу! — дип көлеп җавап бирде ул һәм урамга чыгып китте, ләкин бер ун минуттан кире әйләнеп керде.

— Нишләп бик тиз кердегез, иптәш начальник? — дидем.

— Бик бәйләнчек яңгыр ява, вак сүзле министр кебек, — диде, өстәл астыннан әстерхан чикләвеге алып, аны пәке безе белән бик оста ватып ашый башлады.

Мине кызлар электрокардиограммага дип чакырып алдылар. Ул бүлмә аста, ярымподвалда ук икән, беренче мәртәбә больницада булгангамы, эзли-эзли аптырап беттем. Ниһаять, мин ул бүлмәне таптым. Тапкач, керергәме-юкмы дип аптырабрак тордым. Мин күз алдына китерә торгач шифаханәләрнең процедура бүлмәләренә бер дә охшамаган иде ул. Дөрес, анда да ак япмалы топчан бар, бер-ике табуретка бар, стеналарда, өстәл өстендә әкәмәт приборлар бар. Мине алары гаҗәпләндермәде, мине гаҗәпләндергәне менә нәрсә иде.

Шушы ярымподвал-кабинетта майлы буяу белән язылган ике зур картина эленеп тора. Картиналарның берсендә — нарат урманы эченә кереп киткән аулак юл, икенчесендә — яшел әрәмәлек белән уратып алынган бәләкәй күл. Картиналар табигатьнең үзе кебек чын, хис уятучан, моны бөек рәссам Шишкинның Казандагы берәр шәкерте ясаганы сизелеп тора иде.

— Кондрат Максимовмы? — дип сорадым мин үземне каршы алган кардиологтан.

Кардиолог, кырык яшьләрендәге ыспай гәүдәле, озын буйлы ханым, калпак читенә кыстырып куйган кып-кызыл роза чәчәген рәтләбрәк куйгач, сәерсенеп әйтте:

— Картинага игътибар иткән беренче авыруны күрәм. Ә баш врач миңа аларны бирергә дә теләмәгән иде.

— Чынмы? Ә ник?

— Нигә кирәк алар, ди. Авыруда сәнгать кайгысымыни, ди. Ә менә сәнгать кайгысы да бар икән авыруда, — диде ул, йөзе, күз карашы ягымлыланып китте. — Авыруны бит аны дару биреп кенә түгел, кәефен күтәреп тә дәвалап була.

Мин аның белән килешеп керфек кагам.

Кардиологның кырыс чыраена мөлаемлык җәелә, юка иреннәре кысылып торудан туктый, аларга елмаю галәмәте куна.

— Гафу итегез, әдәпсезгә санамагыз, калпак кырыена роза чәчәге кыстырып куюның берәр мәгънәсе бармы, әллә сез аны оригинал булыр өчен эшлисезме?

Ханым уйга кала, зур кабаклы күзләренә моңсулык йөгерә:

— Ә сез ни дип уйлыйсыз?

— Хәзергә әйтә алмыйм, әмма бу хәл миңа бер күренешне хәтерләтте.

— Нинди күренеш?

— Быел мин Һиндстанда булдым. Андагы һинд хатыннары, — байлары, әлбәттә, — чәчләренә роза чәчкәсе кадап йөриләр. Традиция. Чем-кара чәч, ут янып торган роза. Түтәлдән генә өзеп алган. Мин сезне әллә Һиндстанда булгансызмы дип торам.

— Юк, минем әле чит илгә чыкканым юк. Чыгуның кирәген дә тапмыйм. Башта мин үз илебезне күреп бетерергә тиеш.

— Күп күрдегезме инде?

— Унсигез яшемнән, студент чакта ук, Кавказ тауларында альпинист булып йөрдем. Утыздан туристлыкка күчтем. Балтик буен, Ерак Көнчыгышны, Себерне карап бетердем инде.

— Бәхетле кеше сез. Яшәү ямен мәгънәле нәрсәләрдән эзлисез.

Ул миңа, бил тиңентен чишенеп, топчанга ятарга кушты. Мин аның әмерен үтәдем. Ул минем ике аякка да, шайтан сөягеннән өстәрәк, юеш мамык куйды, каеш бәйләде. Ике кулның беләзегенә дә

мамык куеп, перәшкәле сары каеш бәйләде. Дымлы мамык ток әйбәтрәк узсын өчен кирәктер, күрәсең. Аннары ул минем күкрәккә сары резин тупка охшаш йодрык чаклы нәрсә куйды, һавасын кысып чыгарганга күрә, әлеге «туп» күкрәккә беректе, кардиолог тупны күкрәкнең төрле-төрле төшләренә куеп, өстәл өстендәге аппараты белән кәгазь тасмасына ниндидер сызыклар сызды, мин андый сызыкларны Әлмәттә нефтьчеләр карротаж эшен башкарган чакта күргән идем. Ханым кәгазь тасманы кулына алып озаклап карады, мин аның йөзендәге үзгәрешкә карап яттым. Ни әйтер? Ләкин ул миңа берни дә әйтмәде, шуның белән минем шигемне көчәйтә төште. Йөрәк минем бер тиенгә яраксыз мәллә? Әллә ул тузып эштән чыкканмы?

Ханым, гадәти эш башкаргандагы гади һәм тыныч тавыш белән:

— Торыгыз, киенегез, — диде.

Мин тордым, киендем. Аның хөкемен көттем. Тик көтеп бетерә алмадым.

Кабинетның бер почмагында космонавтлар кабинасын хәтерләткән тоташ пыяла кабина бар, анда әллә ниткән формалы приборлар бар. Берсүзсез чыгып китмәс өчен:

— Гафу итегез, ә монысы ни өчен кирәк? — дидем.

— Башы сызлаганнарны тикшерү өчен. Ми үзгәрешләрен. Япон аппараты, — диде кардиолог.

Мин, бәйләнчек болытдан куркып, электрокардиограмма ни күрсәткәнне сорамадым, ханымның әйтеп бирергә исенә килмәде, саубуллашып чыгып киттем...

Палатама кайтуга дәвалаучы врач килеп керде. Ханым кеше икән. Яше утыз бишләрдә булыр. Битеннән әле җәйге кояш нуры китмәгән, күзләре тамып төшәргә торган чия төсле. Табигать камил итеп биргән матурлыгына риза булмыйча, ул иренен чамадан тыш кызылга, күз кабакларын зәңгәргә буяган, күз төпләренә күләгә яткан төсле итеп сөрмә тарткан.

— Авыру Ахунов сез буласызмы? — диде. Тап-татарча әйтте.

— Авыру Ахунов мин булам,— дидем.

— Кай төшегез авырта?

— Кислота аз минем, хроник гастрит.

— Кислотагызны кайчан үлчәделәр?

— Үлчәмәделәр.

— Врачларга әйтмәдегезмени?

— Әйтмәдем. Врачка йөргән юк минем.

— Иллегә җитеп, врачка йөрмәдегезме?

— Йөрмәдем шул.

Дәвалаучы ханым башын чайкады. Дивана диде бугай.

— Телегезне күрсәтегез.

Күрсәттем. Тагын башын чайкап торды. Күзне ачып карады.

— Сары күптән коелдымы?

— Моннан өч көн элек.

— Профессор Харитонов карадымы?

— Карады.

— Нәрсә диде?

— Механически сары коелган,— диде.

— Тагын нәрсә диде?

— Үт куыгында таш булырга тиеш, диде.

— Ятыгыз әле караватка. Тезегезне җыегыз. Кулыгызны янтыкка куегыз. Менә шулай.

Ул музыкантларныкы төсле озын ак бармаклы кулы белән минем эчкә төрле-төрле төшеннән басып карады. Баскан саен: «Авыртмыймы?» — дип сорый торды. «Авыртмый»,— дидем мин. Чыннан да, авыртмый иде.

— Ятыгыз, ят, сезгә ятып торырга кирәк,— диде. Үзе минем караватъ янына утырып, кислота азлыгы кайчан башланганны, гастрит тарихын, быел ике мәртәбә булган өянәкне, Мәскәүнең Кремль больницасында күпме ятуымны, нинди дарулар белән дәвалангавымны сорашты.

— Аш алдыннан ярты сәгать элек алмагел эчертәләр иде,— дидем.

— Ярый. Аны кулланырга була. Гастритны тынычландыра. Тагын?

— Ашаганнан соң өч төрле сәдәп: титрациклин, ротер, митицин.

— Аларын туктатып торырбыз,— диде врач.

— Ник? — дидем мин.

— Эффект бирмәгәннәр бит. Шуннан соң өянәк булган. Шулаймы?

— Шуннан соң өянәк булды. Шулай.

— Тройчатка урынына без ашказаны согы эчәрбез! Ярты стакан кайнаган суга бер бал калагы сок. Ашаган чакта салам белән эчәргә туры килер. Коктейль эчкән кебек. Юкса сокның тешкә тия торган гадәте бар.— Боларны ул йөзенә бер төрле дә хис чыгармыйча, битараф чырай белән әйтте.— Ризамы сез?

— Врач әйткәч, риза инде... Тик болары бит әле гастрит өчен. Ә таш дигәнегез, үт куыгы дигәнегез?..

— Сары коелган идеме?

— Коелган иде.

— Инде бетәме?

— Бетеп килә.

— Димәк, таш кисәге үт юлына аркылы яткан булган. Шул сәбәпле тәнгә үт сыекчасы таралган. Таш хәзер я иреккә чыгып киткән, я өскәрәк күтәрелгән, шуның белән сыкрау-сызлау басылган. Авыру Ахунов, аңлыйсызмы, басылган гына сызлау, бетмәгән.

— Сез хәзер мине нишләтәсез инде?

— Тикшерү алып барабыз.

— Бәлки таш юктыр, очраклы гына бер нәрсәдер ул сары коелу? Аны бит уколны ялгыш кадаганнан да була, диләр.

Врач ханым беренче мәртәбә миңа, авыру кешегә караган кебек түгел, башын исәрлеккә салган кешегә караган кебек, шелтәле-җитди итеп карады. Аның күзләре кырысланып киттеләр.

— Дөньяда бернинди могҗиза да юк, авыру иптәш. Таш бар сездә. Операция ясарга туры киләчәк.

## Белгечләр ни әйтә

Врач агай-эне мине чынлап торып операциягә әзерли булса кирәк, тикшерү эшен ныклы юлга салдылар. «Ташларның» атаклы белгече профессор Кузнецовка хәбәр иткәнлекләрен әйттеләр, хәл белергә баш врач Чугунов та керде, аннары барысы бергә җыелып, мине уртага алып сөйләштеләр, гаять зур әдәплелек һәм такт белән миңа операциягә әзерләнергә кирәклеген аңлаттылар.

— Башта сез миңа ташның сурәтен күрсәтегез,— дидем мин.— Аннары операция турында сөйләрсез.

Рентген рәсемнәре булсын дигән сүзем иде бу. Булды алары да. Касторка мае эчертеп, ач тотып, минем үт куыгын көннең-көн буе рәсемгә төшерделәр.

Мине дәвалаучы Гөлүсә ханым, җомга көнне көндезге сәгать уникеләр тирәсендә ут капкандай ашыктырып, «Служебный» кабинетка алып кереп китте.

Керсәм — баһадир гәүдәле Чугунов, баш врач, сигарет тарта-тарта, ишекле-түрле йөреп тора. Өстәл янында соры костюмы өстеннән җилкәсенә ак халат салган, сәламәтлеге ташып торган кырык яшьләрендәге берәү утыра. Керү белән танылым — профессор Кузнецов.

— Исәнмесез, Вадим Алексеевич,— дидем.

— О, Гариф Ахунович! Ничә җәй, ничә кыш күрешмәдек без сезнең белән! Бишел бардыр, мөгаен...

— Пожалый. Мин ул чакта журналда...

— «Казан утлары»нда,— дип эләктереп алды профессор.— Минем кемгә операция ясавымны караган идегез әле сез?

— Сарман егете, җиде потлы көрәшчегә.

— Бик дөрес. Мин бит сезне күзәтәм, туганкай. Биш ел эчендә сезне бик күтәрделәр. Председатель, депутат, делегат...

— Булды, булды андый хәл! — дидем мин, сүзне уенга борырга теләп.

Аннары ул бик иркенләп минем хәлләрне сорашты. Аның кара калын кашлары, әле бер генә бөртек тә чалы булмаган кап-кара чәчләре, сау-сәламәт түгәрәк йөзе, моннан биш ел элек күргәндәге төсле чүкечтәй нык базык гәүдәсе минем күңелемдә бер генә мизгелгә аңардан көнләшү хисе уяттылар.

Әйе, моннан биш еллар элек без сәламәтлек ягыннан тигез идек, бер баскычка басып, тиңдәшләр булып сөйләшә ала идек. Ул миңа хәтта операциясенә керергә рөхсәт иткән иде...

...Авыруны шәфкать туташлары операциягә әзерләп куйганнар иде инде. Бил турысына ак япма япкан җиде потлы баһадир операция өстәлен тутырып, наркоздан йоклап ята иде.

Вадим Алексеевич кулына сары резин перчатка кигән, авыз-борынын марля белән каплаган килеш, эшкә тотынды. Авыруның корсагын башта спирт белән юып, йод белән көрән сызык сызды, аннары скальпель белән сак кына яра башлады. Тамчылап сарыккан канны, ярылган майлы тирене күрүгә минем күз алларым караңгыланып, операция бүлмәсеннән чыгып киткән идем...

Кузнецов минем арттан шәфкать туташын җибәргән иде. Туташ, форточкага минем башны тыгып биш минут чамасы һава сулаткач, баш әйләнү узды. Аннары мин тыныч һәм нык күңел белән профессорның бавырга операция ясаганын ике сәгать буе карап тордым. «Бавыр ташы» дигән повесть язарга ниятләнеп, Кузнецов эшләгән больницага ике ай буе йөргән идем. Мин аны, ихтимал, язган да булыр идем, күңелне башка бер әсәр биләп алу сәбәпле, «бавыр ташы» бер читтә торып калды. Инде менә биш елдан соң без профессор белән янә очраштык. Минем язмышым хәзер аның кулында.

Профессор мине топчанга яткырып, башка хирурглар кебек үк, минем корсакка кулы белән баса-баса, кайсы төше авыртканны тикшерә башлагач, мин янә дә аның операциясен күз алдыма китердем. Миңа бу юлы куркынычрак булып китте. Чөнки операция бу юлы башка берәүгә түгел, турыдан-туры үземә ясалырга тиеш иде.

Без тагын өстәл янына килеп утырдык. Каядыр китеп югалган җиреннән баш врач Чугунов кайтты. Шырпыны шартлатып сызып, сигарет кабызды, өстәл тирәсендә буталып алды. Утырмады. Үз-үзен тотышыннан кулында власть барлыгы сизелә, тик шушы баһадир адәмнең көтмәгәндә сабый төсле елмаеп җибәрүе, зәңгәр күзләренең кояшлы зәңгәр күк йөзедәй балкуы авыру белән аның арасындагы дистанцияне киметә төшә иде.

— Хәзер аның кыяфәте ярый инде,— диде ул, көрәктәй дәү кулы белән минем якка күрсәтеп.— Безгә килеп кергәндә, моннан бер атна элек, ул менә нинди иде: — авызын ачты, кулы белән авыз кырыена

басып, эчкә баткан яңакны күрсәтте. Аннары ул өстәл тартмасыннан кара пленкалар алды, бәләкәй экранга ут кабызып, беренче пленканы утка куйды: — Менә таш, менә бит. Ул әле, җитмәсә, үт юлында ук утыра икән. Күрәсезме нинди, бармак башы чаклы. Ярырга, кичекмәстән ярырга! Ишетәсезме, Вадим Алексеевич?

Профессор, аның сүзен колак яныннан уздырып җибәргәндәй, дәшмәде. Әйтеп бетергәнен, кулындагы властьны безгә күрсәткәнен сабыр гына көтте, аннары әйтте:

— Николай Иванович, рөхсәт итсәгез, мин авыру белән икәүдән-икәү генә сөйләшергә теләр идем.

Чугунов: «Пожалуйста»,— диде, рәнҗетелгән кыяфәт белән кабинеттан чыгып китте — артыннан зәңгәр тасма булып сигарет төтене сузылып калды.

— Менә нәрсә,— диде профессор миңа, без икәүдән-икәү генә калгач.— Кризис узган, организм нормасына кайта. Ләкин операция кирәк.

— Кичектереп булмыймы?

— Хәзер организмның тыныч чоры, ныгайган чоры. Операция уңышлы узачак. Тагын бер-ике мәртәбә өянәк булса, берничә мәртәбә сары коелса, операция уңышлы чыгар дип өметләндерү кыен булачак. Ә бит өянәкнең юлда булуы да ихтимал.

— Үзегез ясыйсызмы?

— Миңа ышансагыз, мин ясыйм.

— Уйларга ирек бирегез, Вадим Алексеевич. Гаилә бар бит. Хатыным белән киңәшим.

— Принципта ул каршы түгелдер бит?

— Ясатасы килми шул.

— Алай икән...— диде Кузнецов сузып кына, гадел һәм нык караш белән миңа карады.— Сезнең язмышка без битараф карый алмыйбыз, Гариф Ахунович! Аңлыйсыздыр?

— Аңлыйм, профессор. Рәхмәт. Тик мине баш врач кына аңларга теләми.

— Каян чыгып әйтәсез?

— Бар белгәне: ярырга, ярырга!

— Сез бит язучылар — кеше рухының инженерлары, аңларга тиешсез. Николай Ивановичның холкы гына шундый бит аның. Үзе ул бик кайгыртучан, мәрхәмәтле.

Без кул кысышып аерылдык.

Ләкин мин кичкә кадәр басынкы йөрдем. Күңелдә операция дигән, «ярырга, ярырга!» дигән уй яши. Бер караганда, мин килешеп тә куям: бәлки операциягә риза булыргадыр. Уты-ялы бер көн булыр. Икенче юлы акыл каршы килә. Барлык операция дә уңышлы чыкмый бит. Үт куыгының үз функциясе бар. Аны кисеп алгач, организмның башка әгъзалары эштән чыкмасмы? Минем алда әле трилогия... Аның әле беренче китабы гына язылган... Башкалары күңелдә генә яши әле... Нишләргә? Кем белән киңәшергә?

Шул хакта мин бүлмәдәшем Карасикка әйттем. Михаил Борисович моңа бик җитди карады.

— Операция, язучы иптәш, сезнең үз эшегез. Мин үзем, мәсәлән, операция кебек нәрсәдән бик куркам. Сәламәтлегем операциягә килеп терәлер дәрәҗәдә начарланса да, пычак астына ята алмас идем. Минем бер кордашым әйтә, больницада дәваланыр өчен дә тазалык кирәк, ди. Бер караганда — абсурд. Ныклабрак уйлап карасаң, ул хаклы: таза йөрәкле, корыч ихтыярлы кеше теләсә нинди авыруны җиңә ала. Мин сезгә бер генә сүз әйтә алам: дилетант киңәшчеләрнең сүзен тыңламагыз, врачлар сүзенә колак салып, үзегезчә эшләгез.

# Фэйзи Галиев —
# «Искра» председателе

Миңа борчулы уйларымнан арынып торырга кирәк иде. Күптәнге дусым һәм китап героем Хәммәт Исмәгыйловны эзләп киттем.

Мин килеп кергәндә, ул бүлмәдәге, түгәрәк ак чырайлы, кыяфәтенә караганда бик тә сабыр табигатьле берәү белән чәй эчеп утыра иде.

— Таныш бул, Гарифҗан Ахунҗанович, менә бу чибәр егет синең якташ: Арчадагы иң усал кеше, халык контроле председателе,— диде ул.— Исеме Мәхмүт, фамилиясе Сафин булыр.

Сафин минем белән уңайсызланып кына күреште.

— Усал кешегә бик тә охшаган бу!— дидем мин шаяртып.

Мәхмүт белән Хәммәт елмаештылар.

Арча хәлләренә кереп киттек.

— Зәйнуллин ни хәлдә?— дидем мин.

— Зәйнуллинның эш ярыйсы иде. Урып-җыюны да әйбәт кенә төгәлләгән иде, нишләптер йөрәгеннән зарлана башлады. Больницага салмагайлары.

— Кит! Кая?

— Шушында инде, кая булсын, республиканскига.

— Кайчан?— дидем мин сабырсызланып. Әйтерсең лә Зәйнуллин миңа бәйрәмгә килә.

— Пожалый, ике көннән килеп җитәр.

Алар мине кыстый-кыстый чәй янына утырттылар, без озаклап дөнья хәлләрен сөйләштек.

Ә кичен өчәүләп беренче катка төштек. Анда Исмәгыйлов колхозыннан, Яморзадан бер кыз — Ләйсирә Заянова шәфкать туташы булып эшли икән. Заманында аны Казанга Хәммәт үзе җибәргән булса кирәк, хәзер шуның хәлен белергә теләде.

Киңрәк җилкәле, ак халатны тыйнак кына төртеп торган йомры күкрәкле, тәмам тулып пешкән, яше инде егермеләрдән узган бер туташ җәлт-җәлт атлап килде дә, безнең белән ике куллап күреште. Кулы нык, җылы. Йөзендә — тартынулы елмаю, озын кара керфекләре коңгырт төстәге керсез саф күзләрен күләгәләп, тетрәнгәләп куя иде.

— Я, сеңелем Ләйсирә, тормышларың ничек, эшеңнән ризамы?— диде Исмәгыйлов, аңа хас йомшак, үз итүчән тавыш белән.

— Канәгать соң... Ярыйсы...— диде кыз, ак халатының путасын бөтереп. Аннары иренен бөрештереп елмайды да нинди генә халәттә дә ифрат мәгънәле, серле күзләрен мөлдерәтеп безгә карады.— Яшәвебез шушында, больница шәһәрчегендә...

— Утыр, сеңелем, утырып сөйлә.

Утырмады Ләйсирә, дарулар буфеты кырыена баскан килеш, оялчан әкрен тавыш белән сүзен дәвам иттерде:

— Эш урыны ярыйсы. Торакта бер бүлмә бирделәр. Дүрт кыз торабыз.

— Укырга ниятең бармы соң?— диде Исмәгыйлов, аның хәленә кереп.

— Бар. Тик врачлыкка түгел,— диде кыз.

— Нишләп?

— Әллә нигә күңел тартмый.

Аны авыру янына чакырып алдылар — укол кадарга.

— Ләйсирә кияүгә чыкмаган булса кирәк,— дидем мин.

— Нигә алай дисең?

— Кыюсыз күренә. Артык саф бала. Авылдан китүе дә җан телəгәне булмаудан түгелме?

— Менә анысын әйтә алмыйм.

— Әйе шул, кеше күңеле — карурман... Белеп кара син анда ниләр барын...

Безнең янга илле тирәләрендәге бер кеше килде. Егетләр кебек ыспай гәүдәле, күгелҗем свитердан, чалбары яшькелт — больницаныкы. Чәче ак, түбәдән коелып бара. Әле җәйге кояш нуры уңып бетмәгән озынча битендә, юка иреннәрендә елмаю посып тора, коңгырт тере күзләре бәләкәй йолдызлар кебек чаткыланып яна.

Кыяфәтенә, үз-үзен тотышына караганда, мин аны шәһәр интеллигенты дип уйлаган идем. Әмма ул колхоз председателе, өстәвенә, мин былтыр өзлексез яуган яңгырлар вакытында Әтнә ягыннан эзләп йөргән «Искра» колхозы председателе Фәйзи Галиев булып чыкты. Мин аның хакында Зәйнуллиннан сорашып байтак мәгълүмат җыйган идем. Беренчедән, ул минем кордаш, биш дистәне инде тутырган, икенчедән, сугыш ветераны, өченчедән, бик озак еллар председатель булып эшли. Бирим дисә колына, чыгарып куяр юлына, ди. Борчак пеште болай булгач.

Исмәгыйловның безне таныштырганын сабыр гына көтеп бетердем дә, форсатны ычкындырмас өчен, үзем һөҗүмгә күчтем.

— Мин сезне озак эзләдем, Фәйзи кордаш. Колхозыгызны, кырбасуларыгызны күрдем, кешеләрегезне күрдем, сорашып бетерәсе кайбер нәрсәләр бар, хәлегез бик авыр түгелме?

— Рәхим итәсез, хәлем бик авыр булса, торып йөрмәс идем,— диде Галиев.

— Председательлектә күптәнме?

— 1944 елдан. Күпме була ул?

— Утыз өч ел, ялгышмасам.

— Республикада иң зур стажлы председатель,— диде Исмәгыйлов, ихтирам белән Галиевкә карап.

— Әйе, 1944 елны, фронттан яраланып кайткач, колхоз башлыгы итеп куйдылар. Унтугыз яшь иде.

— Быел безнең Арча якларында яңгыр яумады шикелле. Игеннәр ничегрәк, буралар буш калмадымы?

— Безнең якта яңгыр булмады дип әйтсәм, ялган булыр. Әтнә тирәсендә яугалады. Иген мәсьәләсенә килгәндә, зарлана алмыйм: гектарыннан круглый егерме өч центнер алдык.

— Район буенча күпме?

— Унике.

— Колхозыгыз зурмы?

— Җиде авыл. Бар зурысы, бар кечкенәсе. Үзәге Күңгәрдә. Урта мәктәп салдык. 64 трактор, 57 автомобиль, мастерскойлар.

— Ындыр табагы, сушилка?

— Алары да бар, хәзергә кечерәк. Заманча түгел.

— Ферма каралтыларыгыз?

— Комплекс салып ятабыз.

— Тегермән? Азык цехы яки завод? Алары бармы?

— Заводка хәтле үк барып җитмәдек җитүен, азык цехы бар. Әйбәт эшли.

— Яшьләр белән мөнәсәбәт? Халык китмиме?

— Галимлеккә, шагыйрьлеккә киткәннәрен тотмыйбыз. Аларына ак юл теләп калабыз. Болай үзләре китәргә бик ашкынып тормыйлар.

— Кызык. Бик күп җирдә авылдан китәләр бит. Тулаем алганда, Арчадан да китәләр. Нинди бау белән бәйләп тотасыз яшьләрне?

Фәйзи Галиев тагын бер мәртәбә хәйләкәр генә елмайды. Күзләре җилпәзә-җыерчыклар эченә күмелеп, кечерәеп калдылар.

— Борынгы заманда кызык эшләр булган. Акыл иясе бер зирәк карт миңа сөйләде. «Туганыңа таян, дустыңа ышанма, күршеңә актык сереңне чыгарып селкемә»,— диде. «Ничек инде ул алай,— дидем мин.— Күршеңә дә сөйләмәгәч, тагын кемгә сөйлисең сереңне?» Картым әйтә: торып тор, ди, хикмәтле сүзгә колак сал, ди. Берәү бер капчык күтәреп кайткан. Капчыктан кан агып тора. Күршесенә әйтә, тизрәк яшерик, белеп алсалар, баганага терәп атарлар мине, ач тизрәк базыңны, ди. Ярый, хуш. Яшерәләр. Бер көн уза, икенче көнне әлеге кеше күршесе белән сүзгә килә. Бакчасына кәҗәсе кергән, имеш, кәбестә кыягын ашаган, имеш. Күршесе, каравыл кычкырып, урамга ташлана: фәлән абзый кеше үтерде, мәете базда! Гаепләне алып китәләр, шундук суд ясап, пүкәнгә бастыралар. Баш өстендә әлмәкләнгән бау. Элмәкне сабынларга тотыналар. Ярый, хуш. Дусы килә янына, әй, ди, дус кеше, ди, син миннән ун тәңкә акча алып торганыең, ди, дөньяныкы дөньялыкта бетсен, биреп үл әҗәтеңне, ди. Туганыннан да алып торган икән бу адәм ун тәңкә, туганы әҗәтне бир дип тыкырдатмый, кайгыдан нишләргә белмичә, бер читтә күз яше түгә.

Муенына элмәк кидертә башлагач, әлеге адәм әйтә, ашыкмый тор, минем гаебем юк, ди. Базда кеше түгел, сарык түшкәсе ята, ди. Мин күршемне, туганымны, дусымны сынамак булдым, ди. «Сиздеңме,— ди миңа зирәк карт,— туганыңа таян, дусыңа ышанма, күршеңә актык сереңне чыгарып селкемә». Бу элекке заманда булган. Хәзер дуслык, бер-береңә ярдәмләшү принцибы алга куела.

Галиев иренен очлайтып миңа карады, коңгырт күзләре җилпәзәҗыерчыклардан арынып зурая, җитдиләнә төште.

— Мин эштә гаделлек булсын дип тырышам. Колхозчылар белән дә, район җитәкчеләре белән дә артык якынаерга омтылмыйм. Дистанция тотабыз. Алай объективрак. Андый чакта район җитәкчеләренең шелтәсен ишетү дә күңелгә авыр тоелмый, чөнки дистанция бар. Шулай тиеш дип кабул итәсең. Үзем колхозчыларны шелтәләгәндә дә үпкәләмиләр. Бездә — эш мөнәсәбәте, җитди, эшлекле атмосфера хөкем сөрә, партия кушканча — таләпчән, принципиаль мөнәсәбәт. Кем белә, бәлки шул да яшьләрнең авылда торып калуларына сәбәп буладыр...

Сөйләп бетергәч, председатель Галиев елмайды. Бу беркатлы, тәпсерсез кеше елмаюы түгел, үз акылы үзендә булган, үз кадерен һәм дөнья кадерен белгән кеше елмаюы иде.

«Әйе,— дип уйладым мин.— Колхозларда хәзер килде-китте генә председательләр эшләми. Менә Хәммәт Исмәгыйлов янына тагын бер акыллы, эшлекле, хәтта хәйләкәр председатель өстәлде. Болар — җилкәләренә авыр йөкне күтәрүдән курыкмый торган кешеләр, болар — монда ятканнары да, ятачаклары да — зур эш күтәрүдән авыручылар. Шәфкать туташларының һәм врачларның боларны терелтәбез дип көч түгүләре юкка түгел икән...»

## Вакытның кадерен белүчеләр

Михаил Борисович Карасик, минем бүлмәдәшем, тормышка буйсынып, баш иеп яши торган кеше түгел, тормышны бугазыннан алып, умырып тотып, чүп-чарын селкеп яшәүче кеше булып чыкты.

Инде пенсия яшен узган булса да, аңарда бетмәс-төкәнмәс энергия бар. Ул ким дигәндә ун мәртәбә телефоннан шалтырата. Үз кул астындагы төзелеш трестларына боерык-әмерләр бирә. Иртән сәгать

9 да аңар шофер бүгенге яңа газеталарны китереп җиткерә. Ә бит кайбер башлыкларның шоферлары үзләре бер-ике көнгә эштән китеп тору белән юкка чыгалар.

— Шоферның шундый тәртиплесен каян алдыгыз? — дидем мин аңар.

— Мактану әйбәт сыйфат түгел, шулай да кайвакыт мактанырга туры килә,— диде Карасик.— Минем бәхетем шунда, язучы иптәш, кул астымда эшләүчеләргә мин гомер буе яхшы мөгамәләдә булдым. Беркайчан да алар белән өстән торып, тавышымны күтәреп сөйләшмәдем. Алар мине аңладылар, яхшылыкка яхшылык белән җавап кайтардылар. Мисал өчен минем шоферны алыйк. Мин аны моннан унике ел элек эзләп таптым, эшкә алган чакта әйттем, синнән өч нәрсә таләп ителә, дидем. Төгәллек, намуслылык, машинаны чиста тоту. Беренче мәртәбәсендә мин аңар сигез туларга биш минут кала килергә куштым, өч минут соңга калып килде. Мин аны, үткәзеп яуган җәйге яңгыр кебек, көне буе пешекләдем. Әрәмгә узган өч минут өчен пешекләдем. Синең аркаңда мин иң кирәкле оешмага вакытында барып җитә алмадым, дидем. Шуннан бирле ул мин кайчан килергә кушсам, шунда килә. Чамадан тыш пөхтә: машина, кайчан карама, ялт иткән булыр. Мин дә аңар карата рәхмәтле — сәгатьләр буе суыкта тотмыйм. Аз гына салкын тидерсә дә, шунда ук өенә кайтарып җибәрәм.

Карасик медицинаны биш бармагы кебек белә. Үзен дәвалаучы Калерия Николаевна белән аяк терәп сөйләшә, ә тегесе зәңгәр күзләреннән чаткы чәчрәтеп:

— Авырулар бик акыллы булып китте, врачтан күбрәк белә башладылар,— ди.

Михаил Борисович бу сүзләрдән рәхәтләнеп көлә, врач киткәч, бер кушуч әчтерхан чикләвеге ашый, лимонлап, вареньелап чәй эчә, өстәлне җыештырып, кулын-битен юып, урамга чыгып китә.

Бер сәгатьтән безнең бүлмәгә җиде-сигез кеше кереп тула. Костюмлы, галстуклы кешеләр. Ул алар белән эш турында кыска һәм бик конкрет сөйләшә, алар алып килгән җиләк-җимешне фруктылар өеменә куя, кулларын нык кысып, тагын бер атнадан больницадан чыгачагын әйтеп, егетләрен озатып кала...

Менә шулай яшибез.

Карасик минем оптимист булуымны, шаян сүз өчен кесәгә кереп тормавымны яратты. Чамадан тыш ачы даруны йоткан чагында:

— С богом, урра, коммунисты, вперед!— дип әйтергә ярата иде.

...Хәммәт Исмәгыйловны соңгы өч көндә бик азапладылар. Венасыннан биш кубик кан алдылар. Ашказаны согын тикшерү өчен эчәк йоттырып, өч сәгать бер бүлмәдә тоттылар. Ниһаять, ул аннан кайтты. Алсу йөзе агарып, сулып калган иде. Ашарга яратучан кеше булса да, ризыкны теләр-теләмәс кенә ашады.

Кичке бишләр тирәсендә аның янына Калерия Николаевна керде.

— Карыйк әле, без ничек алга киттек икән, кадерлем.— Йөрәген тыңлады, беләгенә кара тасма бәйләп, резина «груша»ны кулы белән кыса-кыса, тасманы тутырды, приборына карады:— 140—90, нормага кайтып киләбез. Кайтып та җиткән булыр идек, үлчәвебез бик зур. Кстати, биредә ашау җитәме сезгә?

— Ашау? Көләсезме, чынлап әйтәсезме?

— Чынлап.

— Мин бит авылда бер утыруда ике тәлинкә аш, бер тавык, бер буханка ипи ашыйм.

Калерия Николаевна артына егылып китә язды.

— Китегез булмаганны! Сез нәрсә?! — диде ул, кулларын селтәп.

Ул чыгып киткәч, Исмәгыйлов рәхәтләнеп көлде:

— Йөрәген алдым врач апагызның! Ышанды бит тәки, — диде, миңа күз кысып.

Кәефе шәп икәне күренеп тора.

Кичен Калерия Николаевна кереп аңа ике көннән юлга әзерләнергә кушты. Миңа ифрат моңсу булып китте.

Исмәгыйлов телефон төбенә утырып, телефонисткадан Салагышны таптыра башлады.

Иртәгесен аңа Әгерҗедән райком секретаре шалтыратты: Салагыш машинасы бер йөз километр килгәч ватылып калган.

Калерия Николаевна аңа тагын ике көн өстәде.

Менә шул вакыт эчендә Хәммәт Фәсәхетдин улы Исмәгыйлов шәһәргә чыгарга баш врачтан рөхсәт алып, совминга, обкомга, Верховный Советка барып кайтты. Әле генә врачлар әмерен үтәп йөрүче мөлаем, сабыр кешедән бер генә минутын да әрәм итми торган эшлекле, өлгер колхоз җитәкчесенә әйләнде.

Кыскасы, врач өстәп биргән ике көндә ул дөньяны айкады, ниләр эшләгәнен миңа хәбәр итеп торды. Пединститутта укыган кызын күрде, су басачак җирләр бәрабәренә кашлак җирдә үткәреләчәк мелиорация эшләренә бер миллион сумга документ әзерләтеп ду килеп йөрде.

Мин аның, әкрен, җайлы, салмак кешенең, шул хәтле җитезлекне каян алуына таң калып:

— Әллә сиңа, Хәммәт дус, колхозның оештыру эшләрен япа-ялгызыңа алып барырга туры киләме? — дип сорадым.

— Юк, нигә алай дисең?

— Авырудан башың чыгып җитмәгән, инде кайларга гына чапмадың! Башкаларга бу исәптән эш тә калмыйдыр, эшләдек дип сөйләп йөрергә генә каладыр?!

— Мин күп сөйләп, юкка-барга тәнкыйтьләп йөрүчеләрне тәрбияләү методы таптым. Колхозчы егет, авыл советы председателенең энесе, 27 яшьтә, җыелыш булдымы, идарә җыелдымы, чәчри дә чыга, чәчри дә чыга. Алланың бирмеш көне ферма мөдиренә ябырыла, и тирги, и ача җитешсезлеген! Бер түзде моңа ферма мөдире, ике түзде, түземлекнең дә чиге бар бит. Килеп әйтмәсенме бу миңа бер көнне: иптәш председатель, ди, авыртынып та торам, ди, куйыйк булмаса шул егетне ферма мөдире итеп, ди. Карасана, идея бит бу! Көзге яңгырлар башланган чак иде, коточкыч кыен вакыт, тоттым да куйдым мин моны ферма мөдире итеп. Юк, үзем генә куймадым, идарәне җыеп куйдырттым. Ничә йөз баш сыер өчен җавап бирү, ул сиңа, туганкаем, җыелышта тәнкыйтьләү генә түгел, анда көннәр буе чабарга, төннәр буе уйлап чыгарга кирәк. Алты ай көчәнде мескенем, ябыкты, хәлдән тайды, авыруга сабышты. Миңа килеп, ялыныпялварып, ферма мөдирлегеннән бушатуны үтенде. Үзем генә бушатмадым, җыелышка куеп бушаттык. Шуннан соң ни идарәдә, ни җыелышта берәүне бер тәнкыйтьләгәне булмады. Аңардан соң да әле үзләре шар сугып, корыны бушка әйләндереп йөргән биш-алты критикан табылды. Аларын да «тәрбияләдек». Так што, эшсез кеше юк бездә, сафсата сатучылар да бетә бара. Колхозлар зур бит хәзер, барыбызга да эш муеннан.

Больницадан чыгуын ул беркемгә дә фаш итмичә, бер-ике якын кешесенә, шул исәптән миңа әйтеп, дусларча саубуллашты. Иртәгесен

иртүк брезент япмалы яшькелт газик аны Әгерҗе ягына таба алып чапты.

Хәммәт дус белән аерылу моңсулыгын кичереп бетерергә дә өлгермәдем, Карасикка больницадан чыгарга хәбәр булды. Михаил Борисович, Исмәгыйлов кебек, больница белән араны алай тиз өзмәде, биш көнгәме, бер атнагамы больничный алып, уколын-мазарын, массажын-ваннасын дигәндәй алырга килеп торды.

Киткән чакта ул миңа:

— Ну, Гариф Ахунович, мин китткәч, ничек яшәрсез икән инде сез?— диде.

— Сезнең койка турысына мин портретыгызны элеп, шул портретка табынып торырмын,— дидем.

Ул рәхәтләнеп көлде.

— Ә портретны каян аласыз?

Мин аның дөньясын онытып китап укып утырган чагында карандаш белән зур күзлекле, пеләш башлы рәсемен сызып алган идем, шуны күрсәттем.

Михаил Борисович рәсемгә озак карап торды.

— Мин бит сезне сөйләргә генә оста дип торам. Сезнең мондый һөнәрегез дә бармыни әле?!— диде, зур кабаклы, кабарынкы күзләрен ачып миңа төбәлде.

— Хатын кубыз уйнаганга бии дә беләм әле мин,— дидем.

Минем шаярту аның күңеленә ошады, ул минем белән озаклап күреште, адресларын, телефоннарын язып бирде, аннары китеп барды — кара йон костюмнан, ныкыш һәм базык гәүдәсен төз тотып атлый, әллә ниткән бетмәс-төкәнмәс энергия, көч-гайрәт, үз-үзенә ышанганлык бар бу кешедә...

Мин бүлмәдә ялгызым торып калдым. Караңгы иңә башлады. Язу язасы килми, бернәрсәгә дә кул бармый.

Мине дәвалаучы врач бүген безнең палатага кереп тә карамады. Нигә мин аны искә төшердем әле? Хәммәт дус белән инженер Карасик киткәнгәдер инде. Абашева бүген ике авыруның сукыр эчәгесен кисеп алды. Безнең терапия бүлеге көн буе шул вакыйга белән яшәде. Операциядән кайткан егетләрне Мәхмүт белән кереп карап чыктык. Хәлсез яталар...

Коридорда, тешкә тиярлек булып, ят бер тавыш ишетелә. Җитмешләрне узган кызыл халатлы әби өч ай кузгалмый ятканнан соң йөрергә өйрәнә башлаган икән — урындыкның тәрәгенә ябышып, шуны этеп бара.

...Больницада төнге уннарда, гадәттә, утлар сүндерелә, авыруларны, Дания ханым таләбе белән, шәфкать туташлары палаталарына кертеп җибәрәләр. Дөнья тына, аяз булса, күк йөзенә сары ай калка. Мин авыл урамнарын, анда-санда җемелдәгән утлы тәрәзәләрне күз алдыма китерәм. Саташып өргән эт тавышларын сагынам, югары очта уйнаган тальян моңы, урамнар аша саркып, түбән очка төшеп килә...

«Узган гомер кире кайтмый, сулар кирегә акса да...» — дип җырлый торган идек без. Яшь идек әле, үсмер егет кенә идек, каннар кайнар, хыяллар җитез иде. Бу җырның тирән мәгънәсен, ярты гасыр яшәгәннән соң, менә хәзер генә аңлагандай булдым. Гомернең алтын чагы узып киткән икән шул инде...

Авыруларның хәлен җиңеләйтеп йөргән шәфкать туташлары — Яморзаның Ләйсирә, Казанбашның Роза белән Ания, Балык Бистәсе кызлары Финәүзә белән тагын бер Роза — берсе кара, берсе сары чәчле куян балалары бер-бер артлы күз алдына киләләр. Күңелдә янә шигырь уяна:

Саумы, сеңелем, чибәрем,
Хыялларың матурмы?
Яшь боландай чапкан чаклар
Бер әйләнеп кайтырмы?
Туган як болыннары
Хыялда яңарырмы?
Ташкын сулар куңелдә
Шаулый-шаулый барырмы?..

# Арчаны күтәргән егет

Зәп-зәңгәр спорт костюмы кигән ул. Буе озын, гәүдәсе ыспай. Коридорның аргы башында стенага сөялеп тора.

— Я хода, Фатих, син түгелме?

— Мин бу, Гариф.

— Сине бит йөрәк бәреп еккан дигәннәр иде, ничек торып чыктың әле син, эт каешы?

Фатих, моннан егерме ел элек кара булган, инде чал кереп сорыланган бөдрә чәчле башын артка ташлап, дөнья шаулатып көлә.

Әчке яктан шәфкать туташлары йөгерешеп чыктылар. «Ыш-ш-ш!» — диләр, шауларга ярамаганны аңлаталар. Больница халкы йоклый, тынычлык сакларга кирәк.

— Миңа керик,— дидем мин.

Коридор буйлап киттек. Фатих, сыгылмалы төз гәүдәсе белән артистларча кыланып, кәкрәйгән-бөкрәйгән берәүне ясап, шаяртып атлый. Көләсе килә — ярамый.

Безгә кергәч, Фатих өстәл буена килеп утырды. Китап уку һәм көндәлек алып бару өчен дип мин өйдән бик якты лампочка китерткән идем, Фатих аны өнәмәде, шактый ук йончылган, күз һәм авыз тирәләренә җыерчыклар кунган битен кулы белән ышыклап:

— Сүндер әле шул җәһәннәм прожекторын!— диде.

Мин аны бик яхшы аңладым, чөнки чамадан тыш якты ут безнең «больница чыраебызны», ягъни йончыганлыгыбызны, җыерчык-буразналарыбызны аермачык күрсәтте, Фатих аны теләми, эңгер-меңгердә, интимлык тойгысы уята торган тонык ут яктысында гына булуыбызны тели иде.

Төнге утны яндырдым. Сөйләшеп киттек. Әлмәт якларында йөреп үткәргән ун ел эчендә мин Фатих Минушевны күз уңыннан югалтыбрак торган икәнмен, аның министр булудан тыш бүтән вазифасын белми идем.

Фатих тормышта очраган күп төрле мәзәк хәлләрне һәм эшләгән урыннарын артистларча матур итеп, мавыгып сөйләде. Аның белән сөйләшү рәхәт, ул маңгайга чиртеп сөйләми, сине басмый, ялыктырмый, сине, тыңлап утыручыдан бигрәк, әңгәмәдәшенә әйләндерә иде.

Артист булу — Фатихның тәүге хыялы булган икән. Казаннанмы, Минзәләдәнме артистлар килеп төшсә, Фатих клубка чаба, ләкин акча каян алырга? Әтисе Хәлилнең дә, әнисе Сабираның да театр турында ишетү белән чырайлары бозыла. Театр җене кагылган малайга берәр сәгать алдан тәрәзәдән кереп, берәр почмакта качып торудан башка әмәл калмый. Халык клубка тула башлау белән сәхнә алдына чүмәшә Фатих. Клуб җыештыручы усал хатын — малайларның кан дошманы. Каян кергән булсаң, шуннан чыгара ул сине. Колагыңнан тартып ачык тәрәзә буена китерә дә артыңа тибә, яңгырлы суык урамга очып барып төшәсең!

Артист чыкмады Фатихтан — кая барырга, кая кереп укырга икәнен белми иде ул. Унынчыны тәмамлагач, Тәтешкә барып бер ел агрономлыкка укыды. Кырчылык белгеченә. Менә ичмасам монысы

эш, диделәр эти-әниләре. Иген басулары, терлек-туар каралтылары, клублар, уку йортлары белән танышлыгы шулай башланды Фатихның. Ләкин бер ел да узмады, Фатихны ФЗОга алдылар. Столярлык эшенә өйрәтеп, Юдинога, вагоннар ремонтлау депосына китерделәр.

Тәтеш якларындагы төсле зур су, хәтта Кама дәрьясыннан да зуррак су — Идел бар иде монда. Фатих Каманы сагынды, Үтәмешне сагынды, гармунлы урамнарны, таң әтәчләре кычкыруын сагынды. Еректан ишетелгән Идел пароходларының моңлы гудоклары аның йөрәген телеп ала иде. Әллә аның сагышын сизделәр, әллә ул үзе дөньяга бигүк бәхетсез булып тумаган иде, бер ел узар-узмаста, Тәтештә техникум ачылганы мәгълүм булды. Үзе укыган төштә, бер еллык курслар урынына авыл хуҗалыгы техникумы ачканнар. Китәргә шунда, китәргә. Ләкин ничек китәргә?

Фатих мастеры янына килде, бик тә мескенгә калып, бик тә гозерләнгән тавыш белән, хәл-әхвәлен сөйләп бирде. Менә кайчан кирәк булды аңа тумыштан килгән артистлыгы.

— Павел Яковлевич,— диде.— Мине авылда эшләрсең дип үстергәннәр иде. Тимер-томырга һич кенә дә җан ятмый минем. Тимергә тимер ышкылганны ишетсәм, тешем сызлый башлый. Язып бир депо начальнигына: тәртипсез, диген, эш яратмый, диген, дөньяда бер ата ялкау, диген, адәм имгәге дип яз...

Акыллы кеше иде Павел Яковлевич. Үсмер егетне янына утыртты, җилкәсенә кулын салды.

— Ә нигә сиңа яла ягарга? Тәртипле син, эш җаен да беләсең. Акылың да җитәрлек. Тимергә җаным ятмый дип ачыктан-ачык әйтүең дә шәп. Яратам намуслы кешеләрне! Бар, улым, үзең теләгән җиргә, тап, улым, җаның теләгән эшне, мин сине тотмыйм, изге урын буш тормый — икенче бер кеше табарбыз синең урыныңа. Начальникка үзем аңлатырмын.

Минушев техникумны 1951 елны бетерде, эти-әниләре аны агроном итеп эшләтергә теләсәләр дә, укырга дәртләнеп өлгергән егет, йөгерүдән туктала алмаган чабышчы кебек, бер урында калырга теләмәде, институтка барып керде.

Һәм менә, ниһаять, беренче җитди сынау. 1956 елның 4 апрелендә ул Арча районының Ашытбаш МТСына баш агроном булып кайтты.

Әгәр мин Фатих Минушевны «Без бит Арча яклары...»ның бер герое итеп алганмын икән, бу, димәк, юкка гына түгел. Аның тормышы, гомеренең дәртле, гайрәтле заманы, омтылышлы һәм илһамлы чоры Арча яклары белән бәйле булганга күрә. Ашытбаш МТСын бер елдан «Северный» совхозына әйләндерделәр. Фатих Хәлил улы шушы совхозда бер ел эшләү дәверендә совхозның директоры Нәкыйп Сафиннан гаять зур тормыш сабагы алды. Нәкыйп Сафин фамилиясен Татарстанда ишетмәгән кеше юктыр дип беләм. Аны данлы иткән беренче сыйфаты — Советлар Союзы Герое булуы. Арча районының Мәрҗәм авылы егете ул. Әмма аның кул астында эшләүчеләр Сафинның герой булуын бик тиз оныталар, аның акыл байлыгына таң калалар: корыч логика, теләсә нинди кыен хәлдән чыга белүе, чын халык улына хас булган гадилек өлкән иптәшеннән Фатихка да күчте, эшендә аңа ныклык бирде. Райбашкарма председателе урынбасары булып эшләгәндә дә, район авыл хуҗалыгы инспекциясе начальнигы булганда да, соңыннан Әтнәдә райбашкарма председателе вазифасын үтәгәндә дә Фатих гел Нәкыйп абыйсын истә тотты. Әтнә ягы кешеләре Фатих Минушевның алтмышынчы елларда Әтнәдә 500 урынлы культура сарае, 320 урынлы урта мәктәп, 55 урынлы ашханә, 27 километр озынлыгындагы таш юл һәм күп кенә торак йортлар салдыруын әле дә сагынып сөйлиләр. Каян килгән ул чагында көч-

гайрәт, йокысыз-ялсыз эшләүләр! Шулар өстенә бит әле Кенәрдә республика интернат-мәктәбе ачып, сугыш чорында ятим калган 300 баланы җыйдылар. Бу эштә аңа мәгариф министры Мирза Мәхмүтов бик булышты. Ике теләк бергә кушылып, тәки үз дигәннәрен эшләделәр, ул мәктәпнең кирәклеген Мәскәү каршында исбатлый алдылар. Мәктәп хәзер дә яши, белемле, тәрбияле яшьләр әзерләп чыгара. Мәктәп янына кирпечтән мастерской салдылар, тегү эшенә, слесарьлыкка өйрәтәләр балаларны. Анысын шушы мәктәпнең беренче көннәреннән үк директор булып эшли башлаган акыллы һәм булдыклы Рәкыйп Халитов башкарып чыкты.

Фатихның Арча белән бәйле тагын бер истәлеге бар: анысы авыл хуҗалыгы министры булып эшли башлагач булды. Партия Үзәк Комитеты алтмышынчы еллар ахырында һәрбер өлкәнең берәр районын химияләштерү хакында карар чыгарган иде. Химияләштерү дигән зур һәм катлаулы сүз җиргә органик һәм минераль ашлама кертү, известьлау һәм иген корткычларына каршы көрәшүне эченә ала иде.

Кайсы районны алырга?

Өлкә комитетында киңәшеп, Чистайны карап чыктылар — ерак, ашлама ташу өчен бик кыен. Буаны тикшерделәр — кара туфрак — болай да яши ала. Биектауга тукталдылар — районы кечкенә. Иң зурысы — Арча, 230 мең гектар җире бар. Аңа бит элекке Әтнә, Кызыл юл районнары кереп китте. Гектарына бишәр центнердан ашлама бирергә кирәк. Эшелоны-эшелоны белән ашлама кайтты. Ташып кына өлгер...

Химизация үткәрүнең нәкъ менә Арчада кирәклеген Фатих Минушев яклады, республика җитәкчеләрен дә шуңа ышандыра алды. Һәм ул ялгышмады.

Җирне фән кушканча эшкәртүнең ни икәнен Фатих Минушев шунда күрде. Район хезмәт ияләренең кайнар тире, фидакарь хезмәте белән кушылган ашлама иген уңышын бермә-бер арттырды. Җәй коры килгән 1974 елда да арчалылар гектарыннан 16 центнер уңыш алып, дәүләткә 75 мең тонна ашлык тапшырдылар. Анысы районга яшь һәм тынгысыз секретарь Харис Зәйнуллин килгәч булды.

Әгәр республика күләмендә, өлкәләр, крайлар, бөтен илебез күләмендә химияләштерү үткәрелсә, шуның өстәвенә, алтыннан кадерле дымны күккә күз төбәп көтәргә калмаса, ягъни сугару системалары эшләнсә, игеннәрнең дугалы ат күмеләсе көннәре алда әле...

## Тагын очраштык

Харис Зәйнуллин без көткән көнне килмәде. Иртәнге якта да без аның хакында Мәхмүт Сафин белән сөйләштек, көндез дә сүз куерттык, кичен кинофильм карап кайтканда да аны искә төшердек.

Юк Зәйнуллиныбыз. Суга төшкән кебек югалды. Икенче көнне дә көтә-көтә өметне өзгәч, башка уйлар, тормышның башка мәшәкатьләре белән яши башлагач, кичкырын, һич көтмәгәндә, ул килеп төште.

Гади, ягымлы, елмаеп килә — авызын җәйгән.

Карасик урыны буш иде — аны минем янга урнаштырдылар. Партиянең егерме бишенче съездыннан соң Арчада очрашкан идек, шуннан соң күрешкәнебез юк иде, сагынганмын икән үзен.

Сәгать буе Арча хәлләрен сөйләштек. Иплэп кенә авыруын белештем. Йөрәк инде шул, йөрәк. Азмы райком секретареның борчумәшәкатьләре. «Килә ява, килә ява — иянәңде бер болыт», дигәндәй, ике-өч ел рәттән, яз буе күзең күктә, яңгыр көтәсең, урак өсте җит-

теме — тотына орырга, тотына, мин сиңайтим. Аяз көннәрне көтеп зарыгып бетәсең.

Зәйнуллин баштагы ике көнне боеграк йөрде.

Өченче көнне аны дәвалаучы врачы Калерия Николаевна:

— Мин сезне шатландыра алмыйм, иптәш Зәйнуллин, кан басымыгыз югары, нервыларыгыз какшаган, йөрәк белән шаярырга ярамый. Иген белән терлекчелекне уйламый торыгыз,— диде.

Зәйнуллин үтә дә тыныч, гади итеп:

— Бер дә борчылмагыз, Калерия Николаевна, радио район яңалыкларын әйтә башлагач, нервы урынына утыра минем,— диде.

Зәйнуллинны тикшерү-барлауга керештеләр. Электрокардиограмма, рентген, венадан кан тапшыру, анализлар...

Иртәнге ашны ашар алдыннан, дөресрәге, йокыдан уянгач, температураны үлчәргә көндәгечә градусник керттеләр. Зәйнуллин урамга чыгарга өстен киенеп өлгергән иде инде.

— Гариф абый, минем өчен дә үлчә, яме, температураны, 36 градус дип әйт,— диде.

— Алдаша белмим шул мин.

— Безнең күршедә бер әби бар, кешегә зыяны тимәгән алдашу алдашуга керми, ди.

Ул урам йөреп кергәч, безнең палатага колба-приборкаларын, шприцларын күтәреп, шәфкать туташы килеп керде. Зәйнуллин телефоннан сөйләшкән арада, кызый аның бармагыннан кан алып өлгерде.

— Арчалар эшне куя белә, кызлар канны палатага үзләре кереп алалар,— дидем мин шаяртып.

— Обком кушкандыр,— диде Зәйнуллин, елмаеп. Әйткән сүзенең уен түгел икәнен раслар өчен җитди итеп өстәде: — Менә син, иптәш Ахунов, китап язасың, ул обком учетында түгел. Ә менә безнең савымчылар сауган һәр литр сөт обком учетында. Ник дисәң,— ул илнең материаль импульсын билгели.

— Дөрес сүзгә җавап юк,— дип әйтеп бетерергә өлгермәдем, Казан радиосы Арча районының терлек продуктлары буенча республикада беренче булып еллык йөкләмәне үтәвен хәбәр итте.

Зәйнуллин алмаштырып куйган кебек булды. Уколга барган җиреннән сөенеп кайтты:

— Шулай да медицина гыйльме нык алга киткән, иптәшләр. Үрдәк ботлы кыз шатырдатып өч укол кадаган иде, күз алларым яктырып, аллы-гөлле таңкәләр чәчелде...

Ул радио хәбәреннән соң ике көн, ике төн йоклады. «Райком секретареның хәле әдипләр хәленнән җиңел түгел икән шул. Йокысыз үткән төннәрен йоклый инде бу»,— дип уйладым мин.

Арча якларын искә төшердем.

## Бүгенге мәшәкатьләр

Арчада мин соңгы елларда байтак йөрдем.

Өстән туктаусыз яңгырлар яуганда да, гөлт итеп кояш карап торганда да, күктә йолдызлар тетрәнеп кабынганда да...

Секретарь Зәйнуллин белән мин Арчадан Тукай-Кырлайга, Тукай-Кырлайдан Әтнәгә барып җиттем. Механизаторларны, терлекчеләрне, агрономнарны күрдем. Түбәсе калай белән, шифер белән ябылган, капка-коймалары челтәрләп ясалган алты почмаклы, верандалы, алма бакчалы йортларны күрдем. Нарат бүрәнәдән, кызыл кирпечтән, ап-ак силикат кирпечтән салган йортларны күп очраттым. Авыл яңара, авыл мул яши, авыл түбәсен яңадан яба, дип уйлау рәхәт иде.

Элекке заманда, әйтик, утызынчы елларда, шушындый йорты, ике аты булганнарны себер җибәргәннәр. Хәзерге крестьянның гаражында унбиш ат көчле мотоцикл бар, «Москвич» та, «Жигули» машинасы да авыл өчен хәзер ят бер нәрсә түгел. Көзгедәй ялтырап торган полировкалы мебельне шәһәр өчен дә, авыл өчен дә бер үк фабрикалар ясый. Иркен зур бүлмәләргә серванты да, китап шкафлары да, затлы диваннары да бик матур кереп утырган.

Шулай булса да авылдан китәләр. Авызын корт чаккыры, китәләр авылдан! Бу ни хикмәт? Сәбәбе нәрсә соң? Шушы сораулар председательләрне дә, партия җитәкчеләрен дә гел борчый, гел бимазалый.

Бу хакта без Зәйнуллин белән дә сөйләшмәдек түгел, сөйләштек. Әллә инен 230 мең гектар җире булган зур бер район басып торганга, әллә соңгы еллардагы әле корылык, әле бәйләнчек яңгырлар җанын талаганга, ул чагында секретарь миңа бүгенге авылның мәшәкать-борчуларын сөйләмәгән иде. Менә хәзер больницада икебез дә бер үк хәлгә куелып, чәчү өсте, урак өсте, бәрәңге алу вакыты дигән аяусыз төшенчәләр аны өзлексез чыбыркылап тормый башлагач, иркенләп сөйләшерлек вакыт табылды.

Юк, мин Харис Зиннәтулловичның якасыннан урап алмадым. Минем бәхеткә, бик тә җайлы бер вакыйга килеп чыкты.

Мине дәвалаучы врач Гөлүсә ханым ул көнне безнең палатага ялгызы гына кермәде. Гадәти көннәрдәге төсле ашыгып-кабаланып та кермәде. Ул безгә коллегасы Калерия Николаевна белән бергә керде. Җай гына, ашыкмый гына керделәр алар. Икәүләшеп безгә хәерле кич теләделәр.

«Төрмә белән больница адәм баласы яши торган иң әйбәт урын түгел»,— дигән бер язучы.

Берьюлы ике ханым палатага килеп кергәч, без, ир-ат заты да, йөзгә кызыллык китерергә тырышмадык. Иң элек ачыклап китим: без дигәне өч кеше: Харис Зәйнуллин, Фәйзи Галиев һәм мин. Дүртенче кешебез дә бар иде — Мәхмүт Сафин, ул әллә ни арада бездән чыгып ычкынды. «Олылар» сүзенә катышасы килмәде, янәсе. Бактың исә, алай ук та түгел икән әле. Аны безнең халыктагы мәнлелек, тәрбияле-әдәпле булу сыйфаты чыгарга мәҗбүр иткән икән. Хәләхвәл сорашып, ханымнарга урын тәкъдим иткән арада безнең Мәхмүтебез, башка чакта йокымсырап кына йөри торган Мәхмүтебез, кухнядан кайнап чыккан гына су алып, цәйлүн чәе пешереп кертергә дә өлгерде.

Безнең ихтирамнан, Мәхмүтнең өлгергәнлегеннән каушабрак калган врач ханымнарны, ай-вайларына карамый, табын янына утырттык. Безнең өстәл, чыннан да, табын дип әйтерлек иде. Дус-иш, таныш-белеш, туган-тумача «передача» итеп китергән алма, лимон, әфлисуннан көшел өелгән, варенье банкыларының төрлесе тезеп куелган иде.

— Көне буе безне кайгыртып йөргән врачларга бер стакан кайнар чәй эчертү харам булмас,— дидем мин.

— Чәй эчертү взятка бирүгә керми,— диде Зәйнуллин, киеренкелекне бетерә торган елмаюы белән рәхәтләнеп елмайды. Андый елмаюны мин ике генә кешедә: Мостай Кәримдә һәм Харис Зәйнуллинда гына күргәнем бар.

— Карасана боларны, Калерия Николаевна, нинди ягымлылар, йөзләреннән елмаю китми,— диде Гөлүсә ханым, табын янына утыргач.— Кабинетларына барып кара, секретарьшалары сине көннең көн буе ишек төбендә тотар.

— Хәзергесе хәлдә власть сезнең кулда, ханымнар. Сез безне я дәвалыйсыз, я исән калдырасыз,— диде Зәйнуллин шаяртып. Аның бүген кәефе шәп, кан басымы әкренләп төшә башлаган иде.

Нинди генә шаян сүзләр сөйләшсәк тә, минем күңелдә, күгәргән кадак кебек, борчу утыра. Болар юкка кермәгән, болар җитди эш белән кергән. Болар, мөгаен, мине операциягә үгетләргә йөриләр булыр...

Мин ул хакта бүген сүз кузгалуын теләмим. Сүзне икенчегә, ян юлга борып җибәрергә кирәк.

— Әгәр дә без хәзер больницада түгел, иректә булсак,— дип башлыйм мин сүзне,— безнең өстәлдә әрмән коньягы булыр иде, хөрмәтле ханымнар саулыгына без тост әйтер идек.

— Әйтегез соң! — ди Гөлүсә ханым, аның чәйдән алсуланган бит алмалары уймаклана, тамарга торган чиядәй зур күзләре теләктәшлек белдереп карыйлар.— Язучыларның хатын-кызга атап тост әйткәнен минем беркайчан да ишеткәнем юк.

Батырлыгымны җыеп, чәйле стаканны кулыма алам:

— Әгәр биредә Дагстанның халык шагыйре Рәсүл Гамзатов булса, ул болай дияр иде: кадерле дуслар, врачлар, авырулар капризына түзгән батыр холыклы ханымнар! Революциягә кадәр Дагстанда конституция булган. Ул нибары биш статьядан торган. Беренче статьясында әйтелгән, ир-атның кыйммәте — хатын-кызны ихтирам итә белүдә, диелгән. Хәзерге Дагстан Конституциясендә бу 125 нче статья һәм анда: ир-ат белән хатын-кыз тигез хокуклы дип язылган.

Ханымнар елмаештылар.

— Мәкерле дә соң бу ир-ат! — диде Калерия Николаевна.

— Тостны дәвам итимме?

— Әлбәттә, әлбәттә!

— Әгәр биредә Башкортстанның халык шагыйре Мостай Кәрим булса, болай дияр иде: җир йөзендә ике әйбәт кеше яши: берсе — хатын-кыз, икенчесе — революция. Икесе дә башта иске тормышны җимерәләр, аннары яңасын коралар.

Ханымнар көлеп җибәрделәр.

— Әгәр биредә Грузиянең халык шагыйре Абашидзе булса, болай дияр иде: без күп нәрсә өчен тост күтәрдек, хуҗалар саулыгына күтәрдек, ак болытлар ак булсын, дип, кара болытлар кара булмасын дип, күтәрдек. Ләкин әле без табынубызны бизәп торган күркәм затлар — хатын-кызлар өчен тост күтәрмәдек. Үзегезгә мәгълүм, хатын-кыз бит ул балык кебек: я безгә йөзеп килә, я бездән йөзеп китә...

Абашидзенең шул сүзләрне әйтеп бетерүе була, мәҗлестә утырган бик тә ябык, бик тә чандыр сиксән яшьлек карчык урыныннан сикереп тора да яман да ачы, яман да чыелдык тавыш белән кычкырып җибәрә: «Безобразие! Мин бу тост өчен эчмим,— ди.— Минем беркайчан да иремнән йөзеп киткәнем, башка ирләргә йөзеп килгәнем юк». «Душа любезная,— ди Абашидзе,— сүз бит элеп киптергән балык турында бармый, йөзеп йөри ала торган тере балык турында бара».

Врач ханымнар рәхәтләнеп, күзләреннән яшь атылып чыкканчы көлделәр.

Киеренкелек, рәсмилек юкка чыкты.

Безнең сүз үз җаенда матур гына агып китте.

— Сугышка кадәр, әле врачлыкка укып кына чыккан елларым, мине бер иптәшем белән районнарга җибәрделәр,— дип, чәй эчә-эчә сөйли башлады Калерия Николаевна. Аңа илле яшьләр булыр. Юаная төшкән. Чәчләре рус хатын-кызларына хас булганча сары, күзләре зәңгәр, көлгәндә ул тыелып көлә, сүзен кыска итеп, өзеп әйтә белә, йомшак, мөлаем тавышын тыңлау рәхәт аның.— Бардык. Кыш. Суык. Толып бөркәнеп атлы чаналарда йөрибез. Өйгә килеп керәсең, пар эченнән берни күренми. Күз ияләнә төшкәч, карыйсың:

ярты өйне сәке алып тора, сәкедә бала-чага, ишек буенда — тагарак, сыер куши, сыерны бозау имә, идәндә сарык бәкәйләре чабышып йөри. Безне трахома эзләргә чыгарып җибәргәннәр иде. Хәзер инде трахомоталогия больницалары да юк.

— Әйе, андый чагы да булды авылларның,— диде Зәйнуллин.— Әнә сез хәзер Фәйзи Галиев колхозына барып карагыз, крестьян төшендә дә күрмәгән нәрсәләрне күрерсез.

Фәйзи Галиев,— күгелҗем свитерлы, егетләрчә ыспай гәүдәле,— ирен чите белән генә елмаеп куйды, сүзгә кушылмады. Мин бу кеннәрдә аның белән берничә мәртәбә очрашып, әңгәмә корып карадым, аның эчендәге бик тиз генә чыгарып аудармый торган кеше икәнен белдем. Ул, имеш, малай чактан ук шулай булган. Чәчрәп алга чыгуны яратмаган, әмма үз сүзен соңгы сүз итеп әйткән. Малай чакта бик тиз бәхәсләшеп, юк-бар өчен дә сугышып китә торган буласың. Фәйзи башта малайларның бәхәсен тыңлый, аннары сугышканнарын карап тора, малайлар мышкылдашып, хәлдән таеп, юл буендагы чирәмгә тезелеп утыргач һәм канаган борыннарын сөртеп бетергәч кенә:

— Юк, ул алай түгел,— дип, үз сүзен әйтеп куя икән.

Аның өчен Зәйнуллин сөйләп китте.

— Колхоз авылының мәшәкать-борчулары бүген дә муеннан. Яшьләр берсеннән-берсе уздырып, алты почмаклы йорт сала, мебель ала, мотоцикл. Шәһәр кешесенә бу, читтән карап торганда, бик җиңел, әкият тизлеге белән килә кебек. Йорт-җир, каралты-кура булдыргачы, бишекле мотоцикл яки «Москвич» машинасы алганчы яшь хуҗалар кара тир түгәләр, өйләрен күмер белән җылытуга корып, үзләре кочегарга әйләнәләр. Андыйлар кырык яшендә хронический гастрит яки бөсер авыруы ала.

— Харис Зиннәтуллович, азрак арттырмыйсыз микән? — диде Фәйзи Галиев, күзләрен кыса төшеп.

— Бәлки арттырып та җибәрәмдер, ләкин мин җанымны талаган нәрсәләрне сөйлим, Фәйзи абый. Яле, әйтегез, колхозчы өендә беренче планда нәрсә?

— Мал-туар үстерү,— диде Галиев.

— Ни өчен мал-туар беренче планда?

— Ит кыйбат, йортка акча җыясы бар.

— Икенче планда нәрсә? — диде Гөлүсә ханым да, әңгәмәгә кушылып.

— Икенче планда нәрсә түгел, кем! Әти карт белән әни карчык. Олылар күрә, өй ялт иткән, көзгедәй мебель, буяулы идән — озаграк яшисе килә. Килен, урынны җәй, килен, җылы су китер, килен, өйне як! Яшьләр боларны авырыксынмый үти, тик үзләрен карарга гына вакытлары калмый.

— Ә өченче планда? — дидем мин.

— Өченче планда нәрсә әле? — диде Зәйнуллин, колхоз председателенә карап.

— Өченче планда — балалар,— диде Фәйзи Галиев.— Аларны интернатка илтәсе, аларны киендерәсе, тәртипләрен кайгыртасы бар. Яшерен-батырын түгел, бала-чага тәрбияләү сугышка кадәргедән авырайды. Сугышка кадәр бала-чаганың буш вакыты да булмый торган иде: бакчада чүбе утый, каз көтүенә, сыер көтүенә чыга, өлкән көтүчеләргә булыша, әти-әнисе урактан кайтканчы, бәрәңге ала, аны пешереп куя, сабый баланы кабык арбада тирбәтеп йөри. Йорт саен алты-җиде бала, бер-берсен карап үстерәләр. юк-бар белән йөрергә бала-чаганың вакыты да калмый. Ундүрт яшеннән ул инде җәйләрен атлы эштә йөри иде. Ә хәзер нәрсә?

— Эшсез калды хәзерге яшүсмер. Олыларның аракы эчкәнен

күрергә калды. Ундүрттә тәмәке тарта, уналтыда шешә белән шаяра башлый. Ата-анага, яшь хуҗаларга күпме борчу...

— Бала үстерү — ата белән анага да тигез түгел,— диде Калерия Николаевна.— Ата өчен бала — бүшлай килгән бүләк. Андый бүләкнең кадере юк. Ә ана өчен бала — йөрәк бәгыреннән өзелеп төшкән җимеш.

Зәйнуллин безнең әңгәмәгә йомгак ясады:

— Мин бер язучыдан укыдым. Иван Стаднюктан. Җир турында, хәзерге яшьләр турында, җир белән крестьянның мөнәсәбәте турында. Кызык фикерләр бар анда. Элек ничек булган? Язгы тамчылар тама башладымы, күккә сабан тургае күтәрелдеме, игенченең җаны чуарлана башлый: җир ни хәлдә, уҗымнар өшеп чыкмаганмы, орлык ашлыгы исәнме? Игенче язын кырга кыз белән кавышырга чыккандай чыга. Яшүсмерләрдәге түземсезлек, җир-кәләшнең мәхәббәтен ашыгып аңлатмавы, зирәк акыллы игенченең горурлыгы һәм уянып килгән табигатьне күрүдән туган күңел җылысы — болар барысы игенче өчен әйтеп бетергесез куаныч һәм бәйрәм газабы бит. Яз килә! Өмет-юанычлары белән килә! Уңармы иген, уңармы?

Күмәк хуҗалыкларга берләшкәч, корама юрган хәлендәге кырлар бетеп, җир җәмәгать милке булып әверелгәч, игенченең җирне яратуы кимемени, арта төшә. Аның җир-анага булган мәхәббәте, ананың баланы яратуы кимемәгән кебек, беркайчан да кимемәс, бетмәс кебек. Күмәк эш, күрше белән күрше ярышу эшкә тагын да дәрт өсти. Гариф абый да, Фәйзи абый да онытмаганнардыр, сугыш алдыннан язгы чәчүгә смотр үткәрерләр иде. Тигез рәткә тезелгән сабаннар, чәчкечләр, ярсып кешнәгән атлар, МТС ягыннан кузгалган трактор гөрелтесе...

Аннары җәй. Урак өсте. Авыр, шулай да дәртле чор. Ындыр табагы, сугу, җилгәрү машиналарыннан чыгып өелгән бодай көшеле. Җанга газиз күренешләр бит алар...

Аннары машина заманы килде, мотор үкерә башлады. Игенчене машина авыр, ялыктыргыч хезмәттән коткарды, шул ук вакытта җир белән кавышу сөенечен дә алып ташлады. Трактор йөрткән, комбайн йөрткән кара чутыр үсмерне күз алдына китерегез: аңарда җирне ярату, актарылган бораздалардан килгән төче туфрак исенә сөенү бармы? Әллә машинаны буйсындыру, кодыч айгырны үз ихтыярына җигү хисе көчлерәкме?

Ферма комплексларына игътибар итегез. Төзелештәге егетләрне карагыз — шәһәрдәге төзүчеләрдән алар кай яклары белән аерылалар? Колхоз дип әйтүгә, безнең күз алдына хәзер җылы пар бөркегән бураздадан бигрәк зур бер производство килеп баса. Шулай булгачыннан үсмер егет, ун класс белеме һәм акылы булган егет, нигә авылда ятсын? Шәһәрдәге культура учаклары — аның карамагында, спорт мәйданнары — аның карамагында, институтлар — аның карамагында. Дөрес, күпмедер вакыт узгач, институт белеме алып, дөньяны тануы көчәйгәч, авылдан килгән егетебез җирси башлый, басуларны, тугайларны, язгы эшләрне сагына. Ләкин инде соң — ул шәһәрдә тамырланып өлгергән: хатыны заводта, үзе производствода, балалары мәктәптә...

Врач ханымнар безнең палатага нинди йомыш белән кергәнлекләрен онытып, Зәйнуллинны бирелеп тыңлыйлар, райком секретаренең үз эшенә никадәр җитди каравына, практик акылын әдәби китаплар акылы белән дә куша белүенә гаҗәпсенеп һәм сокланып утыралар. Карасана, кеше дигәнең нинди уйлар белән яши, нинди борчу-мәшәкатьләр аның җанын кимерә икән! Кан басымы югары, дибез, гамьсез кеше яки чамадан тыш нык нервылы, корыч нервылы кешенең генә басымы күтәрелми андый чакта...

«Харис Зәйнуллинда булган эчке мөлаемлык, кешеләргә карата йомшак-җылы мөнәсәбәт һәм интеллигентлык аңа үз вазифасын үтәгәндә принципиаль нык, партиячел иманлы булырга комачауламый икән,— дип уйладым мин.— Зәйнуллинның әйткәннәрен онытмаска, онытмаска. Болар кирәкле фикерләр. Җир белән игенченең кавышу шатлыгы. Ызансыз кырлар, авыр хезмәттән котылу. Моторлар үкерүе, кара чутыр егет. Җирне оныту. Җирне оныту, җирне оныту... Болар минем башыма чүкеч белән суккандай сугып торалар. Врачлар китү белән язып куясы булыр, язып куясы...»

Тик бер генә кеше — «Искра» колхозы председателе Фәйзи Галиев кенә тыныч утыра. Әллә ул бу борчуларны инде күптән узган, әллә...

Менә ул да телгә килде. Алга иелә биреп, күзләрен кыса төште, кашы, маңгаендагы җыерчыклары баш түбәсенә таба кыймылдаштылар.

— Харис Зиннәтуллович, мин сезнең белән бөтенләй үк килешмәс идем. Беренчедән, авылдан яшьләр кәтүләре белән китми. Икенчедән, шәһәргә киткән теләсә кем авылны сагынмый. Сагына икән инде, анысы авылдан китмәскә тиешле кеше була. Тумыштан игенче йөрәге типкән кеше!

— Бу мәсьәләдә сез хаклы, Фәйзи Әхмәтович. Безнең бурыч — авылдан китмәскә тиешлене җибәрмәү, күкрәгендә игенче йөрәге типкән яшьләрне саклап калу.

— Врачлар авыруны белгән кебек, кемдә эшче, кемдә колхозчы йөрәге типкәнен белеп булса иде...— дим мин.

— Ул чагында «халыктан аерылу», «кәгазь кортына әйләнү» дигән төшенчәләр булмас иде, Үзәк Комитет безнең вазифаларыбызны атлаган саен исебезгә төшереп тормас иде.

— Вазифа дигәннән, Гөлүсә, син вазифаңны онытмадыңмы? — диде Калерия Николаевна, коллегасының җиңенә кагылып.

Врач ханымнар җитдиләнделәр.

— Сез операциядән баш тарткан дип ишеттем мин, Гариф Ахунович. Бу ни хикмәт? Кем котыртты?

— Беләсезме, Гөлүсә ханым,— дип уңайсызланып сүз башладым мин.— Әле генә сез җир һәм җиргә булган мәхәббәт турында райком секретареның сүзен тыңладыгыз. Күзләрегездә ышану, хәтта соклану күрдем. Язучының да бит проблемалары бар. Мин операцияне үз бизмәнемә салып карадым. Сез миңа, ике хөрмәтле ханым, операция теләсә нинди очракта уңышлы чыга дип гарантия бирә аласызмы? — Врачлар дәшмәде, йөзләре уйчанланды.— Дәшмисез? Димәк, бирә алмыйсыз! Ә мин трилогия башладым.

— Нинди трилогия?

— «Идел кызы» дип атала. Беренче китабын журналда бастырдым. Тагын ике китабын күңелдә йөртәм. Миңа аны тәмамлар өчен биш ел вакыт кирәк. Биш ел бик зур вакыт. Әгәр шуңарчы таш кузгалмаса, хәзергә ул тыныч... Шуннан соң сез минем аяк-кулымны чабып өзегез, мин риза.

Врачлар тынды. Зәйнуллин белән Галиев тә тынды.

— Аңлата алдыммы? — дидем мин.

— Ә ул трилогияне хәзер үк язып бетерү мәҗбүримени?

— Мәҗбүри. Ул — минем рухи ихтыяҗым. Мин аңа 25 ел буе әзерләндем. Тау чаклы материал җыйдым. Күңелемне беркеттем. Ул минем язучылык эшемә, осталыгыма имтихан булачак. Ул — минем халкым турында әйтәчәк сүзем. «Идел кызы»н бүтән һичкем түгел, мин генә яза алачакмын.

— Алай бигүк тыйнак булырмы соң, иптәш Ахунов? — дип сүзгә катышты Фәйзи Галиев.

— Нәрсә тыйнак булырмы?
— «Мин генә» дигән сүз.
— Димәк, мин аңлата алмаганмын. «Намус» романы, «Тукай» романы яки «Ак чәчәкләр» романы димим бит мин. «Идел кызы» дим. Аны бары тик мин генә яза алам. Чөнки аңа мин әзерләндем, мин аңа күңелемне беркеттем.
— «Тыйнаклык» дигән төшенчәгә мин ачыклык кертергә теләр идем,— диде Зәйнуллин.— Без, татарлар, чамадан тыш тыйнаклык саклап, примитив хәлгә калмыйбыз микән? Без тарихыбызның башы кайда икәнне әйтмибез. Урта Азиядә революция яулаган Татбригаданы әйтмибез. Әдәбият-сәнгать казанышларыбызны ил байлыгы итүдән тартынабыз. Эшләгәнне эшләдем дип әйтү, яки масштаблы зур әсәр язарга план кору — тыйнаксызлык түгел, киресенчә, кыюлык! Миңа калса, Ахунов иптәш операциядән ни өчен баш тартуын тиешенчә дәлилли алды. Бу шул ук бер мәсьәлә: игенче һәм җир мәсьәләсе. Җан җылысы һәм күңел байлыгы мәсьәләсе. Аннары килеп, сез, врач иптәшләр, авыруның үз теләге белән ясалмаган операция уңышлырак чыга, дип әйтергә теләмисездер бит?
— Аллам сакласын,— диде Гөлүсә ханым уңайсызланып.— Без авыруның үз теленнән ишетергә теләдек. Бәлки үгетли алырбыз, ышандыра алырбыз, дип уйладык. Кызганыч... Без, врачлар, агитаторлар түгел шул...
Алар кайтып киттеләр. Ашханә бүлмәсендә халык телевизор карый. Коридорның аргы башында кызыл халатлы әби урындык этеп бара. Идән тешкә тиеп шыгырдый.
Аста, уналтынчы палатада Хәй Хисмәтуллин үлгән. Безнең Арча ягы кешесе. Кичә мин кергәндә, хәле авыр, хырылдап ята, янында хатыны басып тора иде. Сиксән ике яшендә. Галим, язучы, эрудит. Без аның «Морфология»сеннән тел укып үстек.
Адәм баласының язмышы — тумыштан ук фаҗигале. Үлемгә дучар булып туа кеше. Әмма ул үлем сәгате кайчан сугасын белми, бу — аның бәхете, юанычы...

## ДҮРТЕНЧЕ БҮЛЕК

# Тукай бәйрәме

Апрель дөньяга Ленинны тудырган.
Апрель дөньяга Тукайны алып килгән.
Табигатьнең илаһи көче дөньяга ике бөек кешене тудырган чакта, алар арасында бәйләнеш булыр дип кем дә булса башына китерде микән? Азатлык көрәшчесе һәм азатлык җырчысы. Табигать дигәнебез шундый бөек көч ул — аңарда бер-берсенә бәйле булмаган бер генә нәрсә дә юк...
Табигатьнең кояшлы ае, барлык җанлы-җансызны терелткән, ямьләндергән ае турында минем тагын шуны әйтәсем килә: Тукайны ул башка бер генә җирдә дә түгел, Арча ягында, шагыйрьнең үз сүзләре белән әйткәндә, нәкъ менә Казан артында тудырган.
Ни хикмәттер, Арча биргән кадәрле язучыны Татарстанның башка бер генә районы да биргәне юк. Андый район Россия Федерациясендә дә, хәтта барлык Советлар илендә дә юк. Бер районга унсигез язучы. Курсави һәм Күлтәси, Мәрҗани һәм Галиәсгар Камал, Мәхмүт Галәү һәм Хәй Хисмәтуллин, Госман Бакиров һәм Гомәр Бәширов, Сибгат Хәким һәм Рафаил Төхфәтуллин, Мостафа Ногман һәм Самат Шакир, Мөхәммәт Мәһдиев һәм Фарваз Миңнуллин, Хәкимҗан Халиков, Нәҗип Мадъяров һәм бу юлларның авторы.

Шуларның барысының тажы — бөек Тукай.

Арчада Советлар Союзы Герое генерал Гани Сафиуллин, Советлар Союзы Геройлары Нәкыйп Сафин, Валентин Ежков, Гани Садыйковлар туып үскән, Арча ягы егетләре Галимулла Әсхәдуллин, Нургали Барыев, Шәрифулла Сәгыйдуллин, Арча ягы кызы Дания Галимова Социалистик Хезмәт Геройлары булып җитешкән.

Арча ягыннан СССР, РСФСР һәм ТАССР Верховный Советларына унбиш кеше сайланган — алар арасында терлекчеләр, механизаторлар, колхоз председательләре, райком секретарьлары, язучылар бар.

Арча яклары илгә никадәр атаклы кеше үстергән!

Бүген, дөнья яз ямена күмелгән, агачлар яфрактан шаулап утырган бер заманда, Татарстан республикасы бөек улының бәйрәмен үткәрә.

Бәйрәмне без май аена билгеләдек. Кунакларга туган ягыбызның чәчәкле-гөлле аен күрсәтәсебез килде.

Тукай исән булса, бүген аңар 90 яшь булыр иде.

Бу — хыял түгел. Безнең илдә туксанга кадәр яшәгән кешеләр азмыни?!

Тукай исән булса, күкрәп чәчәк аткан Татарстанын, илебез халыкларының бердәм гаиләсендә бәхетле гомер сөргән, әдәбияты, сәнгате гөрләп үскән халкын күрер иде. Шагыйрь исән булса, Идел-суны ярып узган «Тукай» теплоходын, үз исемендәге районны, урамнарны, мәктәпләрне, культура йортларын күрер иде...

«Акбүз атлар кузгалдылар авылга таба туры...» — дигән бүгенге заман шагыйре. Тукай бәйрәменә, авылга таба кузгалдылар... машиналар. «Волга»лар, «Жигули»лар, «Москвич»лар кузгалды, иллешәр кеше төялгән ике зур автобус кузгалды. Мәскәүдән һәм Ленинградтан, Украинадан һәм Белоруссиядән, Урта Азиядән һәм Идел буе республикаларыннан, Урал-таудан һәм Себердән килгән кунакларны акбүз атлар гына сыйдырырлык түгел иде.

Тукайга дөнья гомер буе рәхимсез булган. Бүген, бәйрәм көнендә дә, никтер суык. Әмма ачы җилгә, суыкка карамастан, Тукай бәйрәменә, аның туган ягы Арчага, Тукай-Кырлайга барырга теләүчеләрнең исәбе-хисабы юк. Машиналар да, автобуслар да аларны сыйдырып бетерә алмады. Алар поездларга утырып, юлаучы машиналарга төялеп, үз җайлары белән китеп бардылар.

Урманнар, яшел болыннар, игене чайкалып утырган басулар аша узабыз. Арчага килеп җитәргә ун чакрымнар кала кунакларны Арча райкомы секретаре Харис Зәйнуллин белән райбашкарма председателе Тимерхан Борһанов каршылый.

— Гариф абый, хәлләр ничегрәк? — ди Зәйнуллин, кунаклар белән күрешеп чыккач.

— Хәлләр әйбәт. Кунакларның кәттәләре килде,— дим мин.— Үзегез әзерме?

— Әзер. Бөтен район кузгалды.

Арчадан Тукай-Кырлайга хәтле егерме чакрым. Асфальт юл. Бәйрәмгә махсус салынды. Юлның ике ягында урман полосасы, әлегә бәләкәй яшел ызан булып кына күренеп тора. Тагын ун елдан — Тукайның йөз еллыгына ул инде күкрәп утырган буй урман булыр. Тукай бәйрәменә килүчеләрне зифа буйлы каеннар, чыршылар, миләшләр каршы алып, шаулый-шаулый озата барыр.

Республика Тукай-Кырлайга көчне күп салды бу юлы. Яңа культура сарае, яңа урта мәктәп өлгерде. Бәләкәй Апушны, ятим малайны сыендырган Сәгъди абзый йорты үз урынына кайтып утырды. Районның иң атаклы балта осталары нарат бүрәнәдән Тукай йорты җиткезделәр — зурлыгы мең квадрат метр чамасы. Кышның-кыш буе балта осталарының балта чапкан тавышлары бөтен районга яң-

гырап торды. Кырлайның шүрәлеле урманнары аны көн саен ишетеп тордылар, Тукайның яңа йорты җитешә, дип тирә-юньгә хәбәр итеп тордылар.

Чыннан да, Тукай йорты әйбәт булып, иркен булып җитешкән. Халыкның мең еллык күңел байлыгы — милли орнаментлары бик килешле булып кәрнизләргә килеп кунган. Монда музей да бар, республиканың хәзерге көне дә чагыла, галимнәр эшләр өчен иркен, якты бүлмәләр дә исәпкә алынган. Йорт янында каен аллеясе, җиләк-җимеш бакчасы, гөл түтәлләре, балыклы буа булачак.

Кунакларга без шуларны сөйләп килдек.

— Күрербез, күрербез,— диде безгә Тукай юбилееның бөтенсоюз комиссиясе председателе, СССР Язучылар союзы секретаре, шагыйрь Михаил Луконин.

Һәм кунаклар күрделәр. Ерактан ук, көн яктысында балкып, гәрәбәдәй сары бүрәнәләре, көмеш калай түбәсе белән Тукай йорты үзе күренде, аннары мәктәп, клуб бинаалары калкып чыкты. Авыл башында, Тукай йорты янына халык җыелган, ерактанрак караганда күз явыңны алырдай чуар киемле халык, диңгездәй чайкалып, дулкынланып тора иде.

— Тукайга лаек бу! — диде Луконин әсәрләнеп.

Авылга килеп кердек.

Исәнме-саумы, Тукай ватаны!

Хис уртаклашу, күрешү-сәламләшү китте. Үзенең яңа йорты каршысында Тукай эскәмиядә утырып тора, гүя ул язып арганнан соң машиналар кәрваны килгәнен күргән дә каршы алырга чыккан.

Менә нинди көннәрең дә килде синең, Тукай!

Үз милли рәссамнарыбызны, шагыйрьләребезне, театрларыбызны күрергә хыялланган идең. Пушкиннарны, Кольцовларны — русның олы шагыйрьләрен тәрҗемә итүдән олы юлыңны башлаган идең. Инде синең әсәрләреңне бүген рус шагыйрьләре, илебезнең башка милләт шагыйрьләре тәрҗемә итә. Синең әсәрләрең илле биш телдә басылып чыкты. Илебез газеталары һәм журналлары нибары бер елда, юбилееең елында гына да синең хакта бер йөз илледән артык мәкалә бастырып чыгардылар. Кайсы илдә, кемгә тия мондый бәхет?!

Син гомер буе сугышкан, җир йөзендә юк булуларын телгән «кара көчләр» алып ташланды. Баш өстебездә алтмыш ел инде ирек кояшы, азатлык кояшы балкый.

Культура сарае каршысына, урамга, гигант сәхнә эшләнгән. Михаил Луконин, бөтенсоюз комиссиясе председателе, өлкән туганыбыз рус халкының күренекле вәкиле, әнә шул сәхнәгә басып, күңеленә тулышкан кайнар хисләрен белдерде:

— Татар халкының ике һәйкәле бар: берсе — батырлыкка, икенчесе — шигърияткә. Шундый һәйкәлләрнең хуҗасы булган халыкны олы бәйрәме белән котлыйм! Тукае һәм Җәлиле булган халык — бәхетле халык ул!

Трибунага бер-бер артлы шагыйрьләр күтәрелә. Төрле телдә шигырь яңгырый, Советлар ватаны турында, аның аерылмас бер өлеше булган Совет Татарстаны турында ялкынлы сүз яңгырый.

Тукай якташлары илебезне тыңлый, аның данлы вәкилләрен тыңлый, халыкның мең еллык тарихыннан, күңел газабыннан туган Тукай турындагы олы сүзне, хакыйкать сүзен тыңлый.

Минем янга Харис Зәйнуллин килә, якын кешесенә дәшкәндәй бик тә үз итеп дәшә:

— Ничек, Гариф абый? Бәйрәм әйбәт уза шикелле?..

— Әйбәт уза. Зур булып уза. Шулай булырга тиеш тә. Без бит Арча яклары, Тукай якташлары! — дим мин, горурланып.

Мәскәү — Казан — Арча.
1976—1978.

## Рәшит Гәрәй

# ТУГАН ЯК ШИГЫРЬЛӘРЕ

### Кайтып киләм басу юлыннан

Бүген генә түгел туган якның
Ашкындырып үзенә тартуы.
Һәрчак рәхәт шулай басу эчләп
Ат юлыннан җәяү кайтуы.

Җырга сыеп бетмәс уйларыңның
Һич чыгармын димә очына.
Чәчләремне сыйпап искән җилдә
Арышларым серкә очыра.

Тургайларның көр күңелле чагы,
Ашыкмыйлар җырдан туктарга.
Сиздермичә генә үзләренә,
Моңнарын, эх, ничек отарга!

Аяк тавышымнан таныптырмы,
Бытбылдыклар куя эндәшеп.
Бала чагымнан ук аларга мин
Серләремне йөрдем өләшеп.

Кайгы килсә, арыш арасыннан
Аваз салып шулар юаткан.
Тавышлары әле дә әүвәлгечә
Ишетелеп тора ерактан.

Бүлдермәскә тырышам мин аларны,
Җилкенсеннәр, әйдә, җилкенсен.
Изүемне чишәм... Куеныма
Үзәннәрдән искән җил керсен.

Ыспайлыкны сөйгән егетләргә
Тоелыр бәлки мәзәк кебек тә:
Ат юлыннан чалбар балакларын
Буяп кайтып киләм дегеткә.

## Кояш батканда

Көне буе күктә йөзгәннән соң
Әсир булып кошлар моңына, —
Кояш инде таулар арасына
Төшеп бара, әнә, тын гына.

Тик ул Җирне күпме күзәтсә дә,
Туймагандыр, ахры, кинәнеп:
Ерак сызылып киткән офыкларда
Йомшак нуры тора тирбәлеп.

Алсулыгы сибелә тау битенә
Кунаклаган каурый болытка.
Гыйбрәт ал син, йөрәк: кояш, әнә,
Батканда да җирне җылыта.

## Ак бәхетең белән

Башка чыгу начар йоламыни,
Дустыбызга бура күтәрдек.
...Күптән түгел аның бәби туен
Һәм өй туен бергә үткәрдек.

Касәләрсез табын китек була,
Бик түгәрәк булды бу табын.
Эчмәсәң дә бераз исерерсең,
Тыңлый-тыңлый дуслар котлавын.

Әйтелмичә калды икән монда
Теләкләрнең, белмим, кайсысы?
— Тәрәзәләрдә һәм йөзегездә
Балкып торсын күңел яктысы.

Йорт үзе дә телгә килде гүя:
— Сабыем, син — тормыш, җир яме.
Яшел чирәм шыткан бу нигезгә
Ак бәхетең белән кил, яме!

## Җидегән йолдыз таңга авышканчы...

Безнең якны чишмәле як диеп
Әйтмәгән шул халык тикмәгә:
Өянкеләр үскән бер төбәктә
Юлыктым мин җиде чишмәгә.

Җидесенә җиде сукмак төшә,
Яшьлек моңы сеңгән сукмаклар...
Тик чишмәләр генә белгән серне
Күңелендә, әй, соң кем саклар.

Ярлар сөзәк... Кичке талгын җилләр
Дулкыннарга кагылып исәләр.
Җидегән йолдыз таңга авышканчы
Серләремне тыңлый чишмәләр.

## Кайтам... Тукталам

Кайтам... Тукталам... Сак кына
Карыймын койма аша.
Туган нигезем... Җанны айкап,
Хисләрем тулып таша.

Кем җитмәгәнлеген беләм
Җирсегән күңелемә.
Белсәм дә, шуңа ышану
Һич мөмкин түгел миңа.

Ишегалды һаман шулай
Хуш исле яшел келәм.
Элеккечә ашыга-ашыга,
Ишекне ачып керәм.

Иртәнге як... Әнкәй әле
Өйдә булырга тиеш.
...Өч ел элек өеп куйган
Мендәрләре шул килеш.

## Ап-ак каурыйлар сибәмен

Каз канаты каурый-каурый,
Каурыйлары ак та соң!..
Кагып узу гаепмени
Кызлы йортлар капкасын?!

Гаепмени алдан шулай
Хәбәр салса егетләр...
Сеңелләрем, үзегездә дә
Күпме яшерен өметләр!

Сездәй бәхетле көннәрнең
Санын кемнәр санаган?!
Соңыннан җырланган җырлар
Искә төшә яңадан.

— Яшь гомерне уза, диләр,
Узулары хак икән.
Һай, аны уздырмый торган
Даруларын тап икән!

Тик ул ашыгып узса да,
Үкенерлек узмаган:
Мәхәббәте саклап калган
Безне яңгыр-бозлардан.

Саклап калган авыр чакта
Иң хәтәр үлемнәрдән.
Көйрәп янса да, йөрәкнең
Ялкыны сүрелмәгән.

Кайнар килеш сезгә күчкән —
Сезнең көр күңелләргә...
Сезне парлы-парлы күрү
Куаныч түгел мәллә?!

Куанып та, моңаеп та
Ел артыннан ел ага.
...Ап-ак каурыйлар сибәмен
Сез китәчәк юлларга.

## Нигә алдамадың...

Яз булып килермен, дидең,
Нигә алдаладың?
Яшьлек күгемдә йолдызлар
Булып яналмадың.

Җәй булып килермен, дидең,
Нигә алдаладың?
Сабан туйларында сине
Эзләп табалмадым.

Көз булып килермен, дидең,
Нигә алдаладың?
Көр күңелле малай идем,
Сүзгә саранландым.

Өлеше шулмы мәхәббәттә
Дөрләп янганнарның?
Кыш булып килермен, дидең,
Килдең — алдамадың.
Нигә алдамадың?

## Гәрәй Рәхим

# САРГАЙМАГЫЗ, КАШТАННАР...

ПОВЕСТЬ

*Кеше үзен тапты — нинди гүзәл ачыш!*

### I

Беренче булып каштан саргайды. Әле көннәр җылы иде, кешеләр кояшта кызыналар, диңгездә су коеналар иде, шулай да каштан саргайды. Чөнки инде октябрь җиткән һәм каштаннарга саргаерга бик вакыт. Һәм алар Кырымдагы бөтен агачлар арасында беренче булып саргайдылар. Әле ничек кенә саргайдылар!.. Аларның яфраклары аз гына да куырылмады, кипмәде, бөгәрләнмәде — җәй уртасында нинди булсалар, шулай сакландылар, тик аларга акрынлап сары иңде... сары инде... Бу сарылык бер мәлне шундый ачык һәм тере булып күренә башлады ки, кичләрен һәрбер каштан агачыннан сары яктылык бөркелеп тора иде.

Каштаннар бу гаҗәеп һәм ял-якты сарылыкларын озак сакладылар. Кырым имәне инде күптән кызгылт-көрән төскә кереп кипкән, куырылып беткән кыштырдык яфракларын коеп бетерде. Кузы чикләвеге агачының яфраклары бер төн эчендә юкка чыктылар. Хәтта инде мәңге яшел магнолиянең дә калын, итләч, ялтыравык яфрак асларына ниндидер кызгылт таплар кунды, әйтерсең ул да башка агачларга ияреп яфрак коярга әзерләнә иде. Ләкин магнолия беркайчан да яфрак коймаячак. Көзен дә һәм кышын да. Чөнки ул мәңге яшел агач. Табигать аны шулай бар иткән һәм көзләрен аның яшел яфракларын юк итмәячәк. Ә менә каштан яфрагын коячак. Озак та үтмәс, сары неон лампалары сыман ял-якты каштан яфраклары җир өстенә сибелеп китәр. Әйе, шулай булачак, чөнки табигать саргайган яфракларның агачта озак эленеп торуына һич кенә дә риза булмас. Ул аларны җир өстенә тузгытып таратыр, черетер, бетерер.

«Каштан, каштан...— дип куйды Гомәр үз-үзенә,— нәрсәне хәтерләтә соң әле миңа бу сарылык?» Ул, хәтерләргә тырышып, кулы белән маңгаен ышкыды, кашын җыерып бер ноктага карап торды. Ул караган якта ямь-яшел яфраклы инҗир куагы үсә иде. Ләкин Гомәр аны

күрмәде... Кинәт аның бөтен тәне эсселе-суыклы булып китте — соңгы мәртәбә күргәндә әнисенең йөзе нәкъ каштан яфрагы кебек сары иде. Әле моннан да сарырак түгел иде микән. Әнисен, үләр алдыннан, соңгы мәртәбә күрүе иде бу. Гомәр әнисенең йөзендәге шул сарылыкны күрү белән аның озакламый үләчәген аңлап алган иде. Һәм шулай булды да. Гомәр авылдан Казанга китеп бер атна да үтмәде, әнисенең үлгән хәбәре килде...

«Юк, миңа болай борчылырга ярамый,— дип уйлады Гомәр, бөтен күңелен биләп алган еламсыравык бер хисне тоеп.— Булды бит инде, әни өчен бөтен туганнар белән утырып еладык та, кайгыра-кайгыра минә чиремне дә аздырып җибәрдем. Ә хәзер, тәмам терелергә дип Кырымга килгәнмен икән, бары тик терелү турында гына уйларга, шул турыда гына кайгыртырга кирәк».

Шул чакта Кара диңгездән күтәрелгән салкынча чиста җил Гомәрнең сулышына килеп керде, битләрен иркәләп, чәчләрен тузгытып узды. Бу сафландыргыч, шифалы, сулышка тәмле булып тоелган диңгез җиле Гомәр күңеленә кереп оялый башлаган еламсыравык хисләрнең бер өлешен үзе белән әләктереп алды да, юлын Ай-Петри кыясына табан дәвам итте. Гомәр иркен сулап диңгез җиленә дустанә күз кысып куйды. Диңгез җиле дә аны аңлады булса кирәк, тагын бер әйләнеп Гомәрнең битен сыйпап узды. Бу юлы Гомәр диңгез җиленең күзгә күренми торган тозлы тәнен иреннәре белән үбеп үк алды. Аннары ул үзенең бу шуклыгыннан бик тә канәгать булып йөз тутырып елмайды. Шуны гына көтеп торган диңгез җиле Гомәрнең елмайганда хасил булган ирен уемнарына кереп тә урнашты. Ул инде Ай-Петри кыясына менүдән баш тарткан һәм Гомәр йөзендәге уемнарда гына калырга карар иткән иде бугай. Гомәр дә диңгез җиленең бу карарына каршы килмәде һәм Кара диңгездән күтәрелгән ионлы, татлы һәм кислородлы һаваны йотлыгып сулый башлады. Врачлар әйтүе буенча, аңа Кырымда нәкъ менә шундый һаваны күбрәк суларга кирәк тә иде.

*
* *

Гомәр дәвалана торган санаторий урнашкан Алып каласы Ай-Петри кыясы белән Кара диңгез арасына утырган. Бу кала Кырымның көньяк яр буендагы һәр шәһәр шикелле үк текә тау битенә урнашканга, Гомәр басып тора торган бу урамнан Кара диңгезгәчә булган ара уч төбендәгедәй күренеп тора. Түбәндә аргы ягы офыкка, бирге ягы олы-олы ташлар кукраеп торган ярга килеп тоташкан Кара диңгез, аннан бирерәк Урта диңгездәге бөтен субтропик агачларны диярлек үзенә җыйган атаклы парк. Анда кипарис, Кырым нараты, платан, инҗир кебек гадирәк агачлар белән бергә купшы магнолия, итальян нараты, Ливан һәм Һималай кедрлары, пальма, секвойя, туйя һәм без яфрагын ашка сала торган лавр агачлары да үсә. Гомәр инде бу паркта берничә мәртәбә булса да, андагы гаҗәеп агачлар һәм үсемлекләрнең барысын да белеп бетерми әле. Шулай да ул бала чактан ук китаплардан гына укып белгән серле зәйтүн, ташимән, хөрмә, айва, кузы чикләвеге агачларын, хризантема һәм олеандр гөлләрен таный. Ул инде кипарис агачының борынгы заманнарда ук нәкъ менә Алып каласына китерелгәнен, ватаны Кипр атавы булу сәбәпле, кипарис дип аталуын, аның Кырым ярыматавына һәм Кавказга шушы Алып каласыннан таралуын белә. Моннан берничә дистә ел элек урындагы кайбер акыллы баш җитәкчеләрнең кипариска каршы көрәшеп алуларын да ишетте инде Гомәр. Яр буендагы буфетта утыз ел буе сатучы булып эшләүче әрмән хатыны сөйләвенә караган-

да, Кырымда, патша заманында ук төзелгән купшы һәм бай бер сарайда ял итүче бер эшем кешесенниндидер черки тешләгән, имеш. Черки тешләгән урын кызарып бүртеп чыккан. Эшем кешесенә врачлар бу черкинең кипарис ботаклары арасында үрчүен әйткәннәр. Теге шунда ук кипарисларны кисәргә әмер биргән. Ләкин Кырымда фәнни эш алып баручы бакчачылар, врачлардан аермалы буларак, кипарисны яклый башлаганнар, бу черки үрчүгә кипарис гаепле түгел икәнен әйткәннәр һәм әгәр кипарисларны кисеп бетерсәң, Кырымның Кырым булмаячагын раслаганнар. Әлбәттә, эшем кешесе бик тә акыллы кеше булган, бакчачыларның соңгы сүзенә ышанган һәм әмерен кире алган. Шулай да мондый кеше авызыннан чыккан һәр сүзне көне-сәгате белән тормышка ашырылырга тиеш дип өйрәнгән кайбер җирле җитәкчеләр байтак кына кипарисны кистерергә һәм кипариска каршы көрәш башлап җибәрергә өлгергәннәр.

Гомәр әле бу паркта тагын күп мәртәбәләр булачак, андагы хыялый гөлләргә һәм агачларга сокланып йөриячәк.

Парктан күтәрелү белән беренче урамда ук — шәһәрнең үзәк мәйданы. Анда тирә-ягы аллы-гөлле чәчәкләр белән бизәлгән уртача зурлыктагы бер һәйкәл тора. Ул шушы Алып каласында туып-үскән Кырым татар егете, ике мәртәбә Советлар Союзы Герое Әмәт-хан Солтанга куелган. Бөек Ватан сугышы чорында ул үзе хезмәт иткән авиадивизионның иң яшь очучысы була. Белоруссия күгендә күрсәткән батырлыгы өчен алган беренче Алтын Йолдызы белән очучылар арасында иң яшь Советлар Союзы Герое булып йөргән. Гаять тә гайрәтле, кыю, җитез һәм акыллы егет буларак, озакламый аны авиамәктәп тәмамлап килгән очучыларны өйрәтүче итеп куялар. Шулай итеп, бу очучыларның укытучылары, остазлары үзләреннән берничә яшькә яшь, ләкин бик тә тәҗрибәле егет булып чыга. Озакламый Әмәт-хан Солтан тагын бер зур батырлык эшли. Шулай итеп, ул икенче Алтын Йолдызга һәм Советлар Союзы Герое исеменә лаек була.

Сугыштан соң Әмәт-хан Солтанны Хәрби Һава Флотының яңа самолетларын сынаучы-очучы итеп накыралар. Ул монда да үзен кыю сынаучы итеп таныта. 1972 елда ул тыныч күк йөзендә тагын бер зур батырлык күрсәтә. Ләкин бу батырлыгын ул үз гомере хисабына эшли — фаҗигале авариядә һәлак була.

Сугыштан соңгы елларда Әмәт-хан Солтан еш кына туган ягына, Алып каласына кайта торган булган. Шунысы кызык, аңа һәйкәлне үзе исән чакта куйганнар һәм ул еш кына үз һәйкәленә үзе чәчәк куя торган булган. Диңгез буендагы буфетта утыз ел эшләгән теге әрмән хатыны сөйләве буенча, Әмәт-хан Солтан малай чагында бу әрмән кызына күпмедер гашыйк та булып йөргән бугай әле.

Гомәргә әрмән хатыныннан Әмәт-хан Солтан турында тыңлау бик кызык булды. Чөнки әле аның гомерендә бер генә мәртәбә дә Советлар Союзы Героен исән чакта күреп белгән кеше белән сөйләшкәне юк иде. Гомәр инде берничә мәртәбә Әмәт-хан Солтан һәйкәле янына барды, ул аның татар егетләренә генә хас булган яңакларына, кue кашларына, сакалсыз иягенә һәм скульптор тарафыннан тишек кенә итеп калдырылган күзләренә озак карап торды. Бу яшь геройның һәйкәле дә, үзенең легендар гомере кебек, сокландыргыч иде.

Шәһәрнең үзәк мәйданыннан Гомәр басып тора торган урамга кадәр баскыч-баскыч булып Алып каласының урамнары тезелеп менә. Бу урамнар тау итәге буйлап борыла-сарыла еракка ук сузылалар. Ә бер урамнан икенче урамга таш баскычлар аша гына үтеп була. Урамнар арасында куе урман булып көньяк агачлары, әллә ничә төрле үрмә гөлләр үсә. Шулар эченә ниндидер могҗиза белән Алып каласында яшәүчеләрнең таш өйләре сыенган. Бу өйләрнең уч төбе

кадәр бакчасында әллә күпме виноград, хөрмә, гранат, инҗир, айва, груша агачлары, мең төрле гөлләр үсә.

«Дөньяда ике оҗмах булса, аның берсе Кырым икән»,— дип уйлады Гомәр, бу гүзәллеккә тагын бер күз ташлап.

*
* *

Гомәр Алып каласын күзәтеп торганда каядыр югалып торган диңгез җиле яңадан әйләнеп килде дә, шукланып Гомәрнең колак кетермәчләрен кытыклады. Диңгез җиленең бу шаяруы Гомәрнең күңелен кымырҗытып җибәрде һәм аның диңгез җиле белән шаярасы, шукланасы, хәтта аны җиңелчә генә мыскыл итәсе килә башлады. Гомәр күп уйлап тормады, теленә килгән беренче сорау белән диңгез җиленең битенә бәрде:

— Диңгез җиле, син дуракмы?

Диңгез җиле көтелмәгән сораудан кинәт тынып калды. Аннары ул нindидер бөтерчек хәрәкәтләр белән якындагы инҗир куагын селкеп салды, кырт кына борылып юл читендәге биек мәчет манарасы сыман сузылып менгән кипарисны уңга-сулга чайкалдырды да, карлыгач җитезлеге белән әйләнеп яңадан Гомәр янына төште. Юк, ул Гомәргә ачулы җил булып китереп бәрмәде, ә аның йөзен ионлы, тозлы, татлы тәне белән йомшак кына иркәләп болай диде:

— Син миңа дөрес сорау бирмәдең бугай. Гомумән, табигать күренешләренә мондый сорауны биреп булмый. Чөнки табигать күренешләре дурак та, акыллы да була алмыйлар. Табигать күренеше ул ничек яратылган булса, шул көенчә генә яши ала. Бу сорауны хәтта агачларга, кошларга, балыкларга, киекләргә һәм җәнлекләргә дә биреп булмый. Чөнки алар табигать тарафыннан җанлы итеп яратылсалар да, мантыйкый уйдан мәхрүмнәр һәм үзләре кылган эшләр өчен әхлакый яктан җаваплы түгелләр. Ә менә кешеләр — аңга, тирән уйга һәм иң югары моральгә тиенгән җан ияләре. Шуңа күрә мондый сорауны бары тик адәм балаларына карата гына куеп була. Мәсәлән, менә сиңа карата.

Гомәр үзенең мәгънәсез, шәхесне мыскыллый торган бу әшәке соравының үзенә үк кайтып төшүеннән бөтенләй югалып калды. Ул кызарынды-бүртенде, бик нык оялды һәм үзен бик вак, булдыксыз, көчсез, мескен бер җан иясе итеп тойды. Чөнки диңгез җиленең уй агышы төгәл һәм дөрес иде. Гомәр үзенең бу мәгънәсез халәтеннән ничек чыгарга белмәүдән гаҗиз булып, диңгез җиленә тагын сорау куйды:

— Син шундый төгәл фикер йөртәсең, сөйләшә дә беләсең, шулай булгач, син адәм баласыннан нәрсә белән аерыласың?

— Менә монысы юньле сорау,— диде диңгез җиле, шатлыгыннан инҗирның олы-олы яфракларын назлы лепердәтеп,— мин адәм балаларыннан бер генә сыйфатым белән аерылам. Әгәр һәр адәм баласының үз теләгендә булган һәр эшне кылырга көче җитсә, бу дөнья әллә кайчан буталып беткән булыр иде. Мәсәлән, берәүнең кит тотасы килде һәм кит тотты ди, икенче берәү самолетка билет ала алмыйча берничә көн аэропортта кунарга мәҗбүр булу сәбәпле таныш булмаган шәһәрне чәнчелеп китсен дип әрләде һәм чыннан да бөтен бер шәһәр кинәт чәнчелеп китте ди. Азмыни соң һәр адәм баласының теләгендә булган яхшы һәм яман нәрсәләр. Ярый әле, адәм баласының үз теләгендә булган һәр эшне эшләргә көче җитми. Ә менә мин, киресенчә. Минем һәр эшне эшләргә көчем җитә, тик миндә теләк дигән төшенчә юк. Минем коточкыч давыл булып җирдәге бөтен шәһәрне себереп түгәргә көчем җитә, минем әле хәтта Ай-Петрины җимереп ташларга да көчем җитәдер. Ләкин гап-гади бер табигать күренеше

буларак, миндә теләк дигән төшенчә була алмый. Теләк дигән әйбер ул бары тик югары акылга ирешкән җан ияләрендә генә була ала. Ләкин аларның һәр теләкне тормышка ашырырга көчләре генә җитми.

Диңгез җиленең бу фәлсәфәсеннән соң Гомәргә бик моңсу булып китте. Чөнки диңгез җиленең сүзләрендә бик зур дөреслек тә һәм бик зур ялгыш та бар иде бугай. Шул чакта Гомәрнең аяк астына сапсары бер каштан яфрагы килеп төште. Гомәр аны кулына алды да:

— Әни каштан яфрагы кебек саргаеп үлде,— дип пышылдады.

— Һәр нәрсә үләр алдыннан саргая,— диде диңгез җиле моңсу гына,— кешеләр дә, яфраклар да, ташлар да, ай да, хәтта җилләр дә үләр алдыннан саргаялар. Тик җилнең саргайганын кешеләр генә күрми, чөнки җил күзгә күренми торган әйбер.

— Әни иртәрәк китте шул бу дөньядан, аның теләгендә беркайчан да начарлык булмады, чөнки ул яхшы кеше иде.

— Яхшы кешеләр һәрвакыт иртә үләләр. Яхшы кешеләр туксанда үлсәләр дә, аларны иртәрәк үлде диләр. Ә менә начар кешеләр утызда үлсәләр дә, вакытында китте, урыны оҗмахта булсын диясе килә.

— Син яхшы кешедер, диңгез җиле.

— Мин кеше түгел, мин — җил.

— Җил булсаң, бар әле, дускай, тиз генә Татарстаннан гына очып әйләнеп кил. Анда Төбеташ дигән бәләкәй генә бер елга булыр. Шул елга буенда яшел талларга төренеп утырган нәни генә Калыплы авылы бар. Ул авылда унҗиде яшьлек Фәлинә исемле кыз булыр. Сердәшем бул, хәбәрчем бул, дускаем диңгез җиле, шул кызга миннән сәлам илтеп кайт.

— Мин аны ничек танырмын соң?

— Мирей Матьеның күзләрен, Нефертитиның борын очын, Тутанхамон кәләшенең яңакларын, Джоконданың ирен читләрен, Наташа Ростованың борын яфракларын, Крамскойның «Билгесез ханым»ының күз карашын, Йосыф Зөләйхасының нягеn, Пушкин Людмиласының бит алмаларын, Сөембикә гүзәлнең керфекләрен, айдагы Зөһрә кызның кашларын, Тамара патшаның маңгаен, һинд кызларының чигә төкләрен, чегән кызларының тешләрен, япон кызларының күз кабакларын, рус кызларының йөз алсулыгын, татар кызларының озын толымнарын бергә җыеп, шуңа бераз гына сипкелләр тәрткәләсәң, Фәлинәгә бик тә охшаш бер кыз килеп чыгар. Ләкин Фәлинә аңа карaганда да гүзәлрәк булыр.

— Синең ул кызыңа быел утыз биш яшь тулды...

— Миңа да утыз биш...

— Ул инде күптән калада яши...

— Мин дә калада яшим...

— Аның инде өч баласы бар...

— Минем дә малаем бар...

— Аның ире бар...

— Минем дә хатыным бар...

— Соң, шулай булгач, бу сәламнең нигә кирәге бар? Сез бит барыбер бергә була алмаячаксыз.

— Бергә була алмауның бер әһәмияте дә юк. Минем аның гомерен озынайтасым килә.

— Ничек итеп?

— Минем сәламем аның гомерен озынайтачак.

— Әгәр ул синең сәламеңне кабул итмәсә?

— Кабул итмәсә, минем гомер кыскарачак.

— Ә син ул кызның сәламеңне кабул итмәвеннән һәм гомереңкыскарудан курыкмыйсыңмы?

— Гомерем кыскарудан курыкмыйм, сәламемне кабул итмәүдән куркам.

Диңгез җиле тынып калды. Гомәр, җил бөтенләй китеп югалмасын тагын дип, кулы белән һаваны капшап карады. Тирә-якта аз гына да җил әсәре юк иде. Диңгез җиле якындагы инҗир куагы арасына гына кереп поскан һәм уйга талган икән. Бераздан ул яңадан килеп Гомәрнең колак кетермәчләрен иркәләде һәм катгый итеп:

— Юк, мин ул кызга сәлам әйтергә бара алмыйм,— диде.

— Ни өчен?

— Чөнки мин Таврия тауларын үтә алмаячакмын, мине Ай-Петри тотып калачак. Һәм, гомумән, Татарстанда диңгез җилләре исә алмый, анда гади җилләр генә исә, урман, болын, кыр җилләре.

— Һм-м-м... Алайса, син минем сәламемне гади җилләр аша юлла. Син бит ул җилләр белән Таврия тауларында очрашасың.

— Юк инде,— диде диңгез җиле җитди итеп,— мондый эшләрдә син җилләргә ышана торган булма. Мәхәббәт мәсьәләсендә җилләргә ышанырга ярамый. Гомумән, бу мәсьәләдә кемнеңдер яки нәрсәнеңдер ярдәмен көтеп яту егет кеше эше түгел. Мәхәббәт эшендә үз көчеңә, бары тик үз көчеңә генә таянырга кирәк! Мәхәббәт ул көчле рухлыларны ярата.

— Эх, диңгез җиле, диңгез җиле! Син дә миңа шуны әйтәсең. Мин инде моны үз-үземә күп мәртәбә әйттем. Күп әйттем һәм дөрес әйттем. Нишлим соң инде, диңгез җиле? Мәхәббәттә көчле рухлы булып булмады шул, булмады...

*
* *

Гомәр сәгатенә карап алды. Ашханәгә кымыз эчәргә төшәргә вакыт җиткән иде. Бу санаторийда режимны шул кадәр төгәл саклыйлар, аз гына соңга калдың исә, кымыздан, ашаудан, дару эчүдән һәм башка процедуралардан колак кагуыңны көт тә тор. Бу эшләрнең берсен генә эшләми калсаң да, баш врачка хәбәр итәләр һәм сине санаторийның эчке кагыйдәләрен бозуда гаеплиләр иде. «Һәм дөрес тә,— дип уйлады Гомәр,— без монда күңел ачарга түгел, ә дәваланырга дип килгән кешеләр».

Ашханәдә Гомәр Кырымның Чатыр-тау үзәнендәге дала үләннәре белән тукланып иркендә йөрүче бия сөтеннән ачытылган тәмле кымыз эчте. Кымызны монда Чатыр-таудан сәгате-минуты белән китереп җиткерәләр иде, шуңа күрә кымыз бүлмәсендә дала саруты, ат тиресе һәм дымлы туфрак исләре бөркеп тора. «Ата-баба эчемлеге,— дип уйлады Гомәр кымыз турында,— борын заманнардан ук тәмен-татын, дәвасихәтен белгәннәр бит».

Ике стакан кымыз Гомәрнең канын уйнатып, тәнен кыздырып җибәрде, ул үзен шактый кәефле сизеп урамга чыкты. Ләкин кымызның шырпы күкерте кебек дөртләп кабынган кайнарлыгы озакка сузылмады, берничә минуттан инде тәндәге кан үз эзенә төшеп ага башлады, кинәт күтәрелгән кәеф тә баягы урынына утырды.

Гомәр кинәт үзен бик тә ялгыз итеп тойды. Ялгыз гына түгел, хәтта ятим дә итеп. Дөрес, формаль яктан ул чыннан да, ятим иде инде — аның әтисе моннан ун ел элек вафат, күптән түгел генә әнисе үлеп китте. Ләкин инде утызны узган Гомәр өчен бу ятимлек фаҗигале ятимлек була алмый иде. Бу яшьтә күпләр ятим кала, һәм беркем дә үзенең ятимлеген фаҗигагә санамый. Чөнки бу яшьтә ятим калу табигый бер күренеш, буыннар алмашуының гап-гади бер чагылышы гына. Бу яшьтә инде кешенең ике кулына бер эше, гаиләсе, дус-ишләре, көнкүреш һәм рухи мәшәкатьләре була. Алда, киләчәктә ничек итеп тормыш алып бару, дөнья куу мәшәкатьләре ятимлек турында озак уйланып торырга ирек бирмиләр. Ахыр килеп инде кеше дигәнең бу

яшьтә үз ятимлеге турында түгел, ә балаларны ятим итмәү турында күбрәк уйлана. Бәс, шулай булгач, Гомәргә үз ятимлеге турында артык сүз куертып тору килешеп үк бетми бугай. Болай итеп үз-үзеңне көчсез һәм мескен бер хәлгә куюың да мөмкин. Я булмаса үз-үзеңне көчләп кызганырга яки кызгандырырга маташкандай булып күренүең.

Ә менә ялгызлык мәсьәләсендә Гомәр, чыннан да, ялгыз иде. Санаторийга килүенә атнадан артты инде, аның әле беркем белән дә дуслашканы, кемгәдер ачылып киткәне юк. Катгый рәвештә режим тота, дәвалана, ә менә сөйләшер кешесе юк. Дөресен генә әйткәндә, аның кемгәдер ачыласы, кем беләндер серләрен уртаклашасы да килеп тормый. Хәтта аның кемгәдер сөйләрлек сере дә юк кебек һәм ул ялгыз уйлануны кем беләндер буш сүз сөйләшүдән артыграк күрә иде. Шуңа күрә ул санаторийга килеп төшүгә ике урынлы буш палатага урнашты һәм мөмкин булса хәзергә аның янына кеше салмый торуларын үтенде. Инде октябрь булу сәбәпле Кырымда актив ял сезоны үткән иде һәм, вакытлыча дип, аның үтенечен канәгатьләндерделәр.

Шулай да...

Шулай да Гомәр өчен дөмә ялгызлык бик үк татлы нәрсә түгел иде. Ялгыз уйланасы уй да күп кебек, шул ук вакытта янәшәңдә кемдер житми дә төсле. Диңгез җиле белән сөйләшү кызык кына булып алды, ләкин бит гел-гел диңгез җиле белән генә сөйләшеп йөреп булмый.

Гомәр шундый мәлҗерәк кәеф һәм шактый мәгънәсез уйлар белән Кара диңгезгә карап торганда, аның янына бер кеше килеп басты. Киң җилкәле, тәбәнәк буйлы, бәләкәй генә башлы бер ир иде бу. Ул бер Гомәргә, бер Гомәр караган Кара диңгез ягына күз төшергәләп алды да ни өчендер:

— Кара диңгез...— дип куйды.

— Әйе, Кара диңгез,— диде Гомәр тегеңә иярәп кенә.

— Пүчтәк,— диде бәләкәй башлы кеше.

— Нәрсә пүчтәк? — дип сорады Гомәр аптырап.

— Кара диңгез дә, Кырым да һәм анда ял иткән без дә.

— Ә мин ял итмим, мин дәваланам.

— Анысы да пүчтәк,— диде бәләкәй баш. Гомәр бу адәмне бик мәгънәсез кеше икән дип күңеленә киртләп куйды.

— Сез уйлаган уй да пүчтәк,— диде бәләкәй баш, Гомәрне тәмам аптырашта калдырып.

— Ә сез минем нәрсә уйлаганны каян беләсез?

— Нәрсә уйлаганыгызны тәгаен генә белмим, тик сез барыбер пүчтәк уй уйлыйсыз.

— Анысы дөрес,— диде Гомәр килешеп.

— Монда пүчтәк уй уйламый мөмкин дә түгел,— диде бәләкәй баш,— житди уйның урыны бу түгел. Без үзебезнең өйдә, эштә, үзебез яши торган җирдә генә житди уй уйлыйбыз. Ә монда бет үтергән кебек вакыт үтерәбез шунда. Монда һәр кеше я гуләйт итә, я аракы эчә, я көннәр буе мәгънәсез уй уйлап йөри. Чөнки бүтән эш юк.

— Мин дәваланам,— дип кабатлады Гомәр баягы сүзен.

— Диңгез һавасы белән дәвалану ярый инде анысы, ә даруларны сез үзегез яшәгән җирдә дә эчә алган булыр идегез.

— Анысы да дөрес инде,— дип килеште Гомәр тагын.

— Аракы эчмәүче һәм хатын-кыз ягыннан әдәм рәтле кешегә монда бик кыен.

— Ә санаторийда үткәрелә торган культура чаралары?

— Пүчтәк, аларны күбесенчә эшләдемме эшләдемгә генә үткәрәләр. Мин монда дәвалана алмыйм, мин монда эшсезлектән һәм күңелсезлектән чирлим генә. Төкерәм Кырымыгызга, иртәгә үк кайтам да китәм.

Кайтып хатын белән бер ызгышсам да сулышларым киңәеп китәр кебек. Ә монда мәгънәсез рәвештә казна ипие черетеп яту минем авыруны аздыра гына.

Фу, шайтан алгырысы, нинди елак кеше булып чыкты соң бу бәләкәй баш?! Гомәрнең болай да ямьсез-тәмсез кәефенә шушы бәләкәй башның зарлануы гына җитмәгән иде. Кайтып китмәгәең соң, шайтаныма олаксана, үзеңнең сазаган кәефеңне кешегә йоктырмыйча гына ычкынсаң да яраган булыр иде.

Гомәр бу кешедән котылу өчен аның сүзләренә бик битараф бер кыяфәт белән Кара диңгезгә карап тора башлады. Бәләкәй баш моны шунда ук сизеп алды, беравык Гомәргә текәлеп карап торды-торды да, кулын селтәп:

— Пүчтәк,— диде һәм китеп тә барды.

«Дөмә ялгызлыктан да начаррак»,— дип уйлады Гомәр бәләкәй баш белән булып алган сөйләшү турында. Бәләкәй баш, чыннан да, Гомәрнең кәефен бөтенләй кырып ташлады. Шунда Гомәр һич кичекмәстән бу халәттән чыгарга, күңел күтәрә торганрак берәр шөгыль уйлап табарга кирәклеген төшенеп алды һәм Алып каласының үзәгенә табан атлады.

*

* *

Шәһәр үзәгендәге бер чатта бәләкәй генә тир бар иде. Гомәрнең иске-москы фанералар каккалап кына ясалган мондый тирларны җене сөймәсә дә, шунда кереп чыгарга булды. Чөнки ул кайчандыр әйбәт кенә ата торган иде. Унынчы классны тәмамлап, авыл китапханәсендә эшли башлагач, хәтта аны колхозның ДОСААФ оешмасы председателе итеп тә сайладылар. Шунда аңа еш атарга туры килә иде. Инде менә унбиш еллап бер генә мәртәбә дә атып караганы булмаса да, ул әлеге тирга керәсе итте, чөнки бу минутта аңа нинди дә булса бер шөгыль кирәк иде.

Һай, бу тир дигәннәре кая гына барсаң да бер төрле икән! Нәкъ шул Татарстандагы тирлар шикелле иске бер алачык, стенада шул ук җиңел кулдан ясалган куян, бүре, ни тавык, ни казга охшамаган бер кош, җил тегермәне, җепкә эленгән калай самолет, фанера танк һәм башка сурәтләр. Өстәлдә көпшәләре шылтыр-шылтыр килеп селкенеп торучы, кысылган һава белән ата торган шул ук мылтыклар. Алар белән никадәр генә төгәл атсаң да, нинди генә оста мәргән, хәтта Олимпия чемпионы булсаң да, ике пуляны бер ноктага, юк, бер ноктага ук та түгел, хәтта бер тирәгә дә тидерә алмаячаксың. Гомумән, мондый игезәк тирлар мәргәннәрне, килегез, атыгыз дип үзләренә чакырып түгел, ә миңа керә күрмәгез, үз-үзегезнең дәрәҗәгезне төшермәгез дип өндәп торгандай тоела. Чыннан да, менә Гомәр кергәндә дә тирда атучы кеше күренми. Тирчы карт үзенең биек урындыгында йокымсырап утыра. Гомәр, ачуы килеп, тирдан чыгып китәргә генә тора иде, тирчының биек урындыгына сөяп куелган оптик приборлы, авыр немец винтовкасын күреп туктап калды. Кысылган һава белән ата торган бу винтовка Гомәргә бик тә таныш иде. Колхозда ДОСААФ председателе булып йөргән чакта аны еш кына җәмгыятьнең район үзәгендә үткәрелә торган җыелышларына чакыралар иде. Җыелышларның берсендә аларга ГДРда эшләнгән шушындый винтовка күрсәттеләр һәм аттырып та карадылар. Урта кул мәргәннәр һәм Гомәр шикелле сирәк-мирәк ату дәрте кузгалып куя торган кешеләр өчен менә дигән винтовка иде бу.

Менә хәзер дә винтовка Гомәрнең күңелендә оста мәргәннәрдә һәм әзгын аучыларда гына була торган ату дәртен кузгатып җибәрде.

Гомәр тирчы карттан винтовканы сорап алды, аның оптик приборын, көпшә очына беркетелгән түгәрәк мушкасын тикшерде, авыр агач түтәне иңбашына терәп, оптик прибор аша тир түрендәге калай әтәчнең олы күзенә төбәп карады һәм винтовканың адәм рәтле икәнлегенә ышангач, ун пуля һәм бер мишень сатып алды. Аның арзанлы зәвык белән калайдан ясалган уенчык-мазарга атып бу затлы винтовканы мыскыл итәсе килми иде.

Тирчы карт мишеньне тир түренә беркетеп куйды, сөялеп ата торган өстәл өстенә кадаклап куелган нәни калай савытка ун пуля китереп салды да яңадан биек урындыгына барып утырды. Гомәр, өстен чишенеп, киемнәрен тир стенасындагы агач чөйгә элеп куйды. Ул, беренче пуляны корып, авыр агач түтәне иңбашына терәде, имән бармагын курок оясына тыкты, сул терсәге белән өстәлгә таянып, янтыгы һәм сул тезе белән бөтен гәүдәсен кымшанмаслык итеп өстәлгә терәде. Оста мәргәннәр генә булдыра ала торган бу төгәл һәм бераз гына артистларча да булган хәрәкәтләрне ясау Гомәргә рәхәтлек бирә иде. Хәрәкәтләрнең төгәллеге, чисталыгы, пөхтәлеге Гомәр күңелендә төз атуга ышаныч һәм ирләрчә горурлык хисләре уятты. Ул оптик прибор торбасы очына беркетелгән резина түгәрәкне уң кашына терәп, винтовканы иңбашына тагын да ныграк кысты. Бу минутта ул үз гәүдәсен винтовка белән берегеп үскән бер бөтен, бер тән итеп тойды. Шуннан соң гына ул сул күзен йомып, уң күзен оптик приборга төбәде һәм шуның аша тир түрендәге мишеньне эзләде. Мишень махсус рәвештә оптик приборлы винтовкадан атар өчен ясалган иде. Аның бердән алып сигезгә кадәр булган түгәрәкләре ак, тугызлы түгәрәге кара, унлы очко янә дә ак төстә иде.

Гомәр оптик прибор аша унлы түгәрәкне эзләп тапты. Шуннан ул үпкәсенә алган тынны кырт кисеп туктатты, приборда күренгән унлы түгәрәкне кыл уртада тоткан хәлдә, күптәнге гадәте буенча, курокка басар алдыннан эчтән генә санап алды: «Бер... ике... өч... дүрт...» — һәм уң кулының имән бармагы белән салмак кына курокка баса башлады.

Нәкъ шул мизгелдә генә тирчы карт йонлач кулы белән винтовка көпшәсен учлап тотты һәм Гомәр күз карашы белән шул кадәр тәфсилләп төзәгән унлы түгәрәк чалышаеп бер якка тайпылып китте.

— Гафу итегез,— диде тирчы карт,— мин сезне кисәтеп куярга онытканмын, винтовка бераз гына аскарак һәм сулгарак бәрә, төзәгәндә моны искә алыгыз.

Гомәр үпкәсендәге кырт кисеп туктаткан һаваны «пуф-ф» иттереп өреп чыгарды да эчтән генә: «Ананның ат башы»,— дип сүгенеп куйды. Әйе, тирчы карт аны ату процедурасының иң тәмле җирендә туктатты шул. Ләкин Гомәр үзенең кәефен кырмаска кирәклеген аңлый иде. Гомумән, кәефсез ир кеше беркайчан да кулына мылтык алырга тиеш түгел. Кәефсез көе мылтыкка тотынган ир-ат бервакытта да унга тидерә алмаячак. Һәм мылтыкны да, мишеньне да, үзен дә оятка гына калдырачак.

— Рәхмәт, вакытында әйттегез, югыйсә беренче пуля белән үк мишень пычрату начар булыр иде,— диде ул, тирчы картка рәхмәт белдерүдән бигрәк үзен тынычландырырга тырышып. Чыннан да, бер минут дигәндә Гомәргә яңадан мәргәннәр салкын канлылыгы кайтты. Ул әле хәтта куанып та куйды: «Ун мәртәбә төзәү рәхәте кичерәсе урынга, бу хисне унбер мәртәбә кичерергә туры киләчәк,— дип уйлады Гомәр.— Ә бер рәхәтлек адәм баласының гомерен берничә көнгә озынайта диләр бит».

Гомәр яңадан төзәгәндә инде мишеньнең унлы түгәрәген кыеклап өскәрәк һәм уңгарак чалыштырды. Аннары ул тынын кырт кисеп үзе

генә белгән ырым шикелле: «Арыш... бодай... солы... арпа...» — дип санап алды һәм салмак кына итеп курокны тартты.

Һәм рас та! Тирчы картның әйтүе рас һәм төп-төгәл! Мишеньдәге бер тиен акча кадәр унлы ак түгәрәкнең нәкъ уртасында тычкан күзе кебек кенә кара тишек күренә иде.

Гомәр тантана итте. Ләкин моны тирчы картка сиздермәде, чөнки ул кешегә күрсәтеп мактану, шатлану яки тантана итү мәргәннәр әхлагына сыймый торган бер нәрсә икәнен белә иде. Ләкин Гомәрнең бик тә салкын канлы булырга тырышып икенче пуляны коргандагы хәрәкәтләреннән аның бөтен эчке халәтен укып була иде. Бу юлы инде аның хәрәкәтләрендә артистлык бөтенләй ярылып ята...

Курокны басар алдыннан Гомәр тагын санап алды: «Тавык... чебеш... үрдәк... каз!» Юка гына катыргы мишеньгә «тып» итеп пуля төкерде — ун очко!..

«Шушма... Идел... Кама... Чулман...» — ун очко!..

«Уран... метан... пропан... бутан...» — ун очко!..

«Алма... чия... шомырт.. миләш...» — ун очко!..

...Ун очко!.. Ун очко!

Гомәрнең кәефе чамадан ашып күтәрелде. Әллә ничә елга бер атып, мишеньнең нәкъ уртасына, унлы очкога гына төртеп торырга кирәк бит! Гомәр инде, чыннан да, мәргәннәрчә төгәл, ләкин артистлыкның эзе дә булмаган матур хәрәкәтләр белән чираттагы пуляны корды, тәмләп төзәде.

«Ай... кояш... чәчәк... Фәлинә...»

Бу ни бу? Соңгы сүзне әйткәндә кинәт кул калтырап китте һәм приборда күренгән түгәрәкләр сизелер-сизелмәс кенә уйнап алдылар. Ләкин инде бу вакытта курокка басылган һәм пуля «тып» итеп мишеньгә барып тигән иде.

«Шайтан алгырысы!» Гомәр винтовканы өстәлгә куйды да мишеньгә текәлде. Ләкин мишеньдә унлы төгәрәкне теткәләгән тишекләрдән башка кара тап күренми иде. «Бетте баш,— дип уйлады Гомәр,— пуля тугызлы түгәрәкнең кара сызыгына эләккән, ә кара фонда кара тишек моннан күренми». Гомәрнең борчылганын тирчы карт та сизеп алды һәм күзлеген киеп мишеньгә карады.

— Борчылмагыз, барысы да унда,— диде ул, күзлеген сала-сала.

— Ә сез якынрак барып карагыз, берсе тугызда булса кирәк,— диде Гомәр.

Тирчы карт сукрана-сукрана биек урындыгыннан төште, күзлеген кия-кия мишень янына килде, беравык аңа текәлеп карап торды һәм карлыккан тавыш белән:

— Әйе, берсе тугызда,— диде.

Гомәрнең башыннан: «Фәлинәкәй, нигә кирәк иде инде бу эшең?»— дигән уй йөгереп узды, ләкин әле аның тагын ике пуля атасы бар иде. Гомәр аларның икесен дә унга утыртты. Тирчы карт мишеньне китереп биргәч тә, Гомәр Фәлинә пулясына карады. Пуля тугызлы очконың кара балдагын өчпочмаклы тишек белән ертып чыккан иде. Әйе, Фәлинәнең исемен әйтүгә үк йөрәк кысылып куйды, сизелер-сизелмәс кенә кул калтырады. Һәм менә нәтиҗәсе күз алдында...

Гомәр, үкенгәндәй, телен шартлатып куйды. Шул чакта аның артында ниндидер ир-ат тавышы ишетелде:

— Борчылма, Гомәр, яхшы атасың. Йөз мөмкинлектән туксан тугызны алу начар түгел инде ул.

Гомәр үз исемен ишетүдән гаҗәпләнеп артына борылып карады. Тир ишеге төбендә тәмәке тартып Юра басып тора иде.

Шактый көр күңелле бу якут егетен Гомәр моннан өч көн элек санаторийның төп корпусында врачка керергә чират торганда очрат-

кан иде. Юра Кырымга хатынын һәм өч яшьлек кызын алып килгән, алар Гомәр яши торган корпус янындагы бер өйгә фатирга урнашканнар, Юра санаторийга дару эчү һәм врачка күренү өчен генә килеп йөри. Врачка чират торганда ул Гомәрнең Казаннан икәнен белеп, Якутиядә мена дигән татар егетләре эшләвен әйтте, шулар турында сөйләшеп утырырга дип, Гомәрне фатирына да чакырды. Ләкин Гомәр бу чакыруны инсафлык өчен генә әйтелгән сүз дип кабул итте, һәм, әлбәттә, Кырымга тынгылык эзләп килгән гаилә янына бер сәбәпсез керүне кирәк тапмады.

Юра инде тирга бая ук килгән, Гомәрнең ничек атуын күзәтеп торган икән.

— Әйбәт атасың,— дип кабатлады Юра.

— Юк ла, мин эч пошканнан гына.

— Бәяңне күтәрмә,— диде Юра Гомәргә бармак янап. Аннары ул өстәлдә яткан винтовканы кулына алды.

— Бу винтовкадан Алып каласында мин һәм минем хатыным Лариса гына атабыз дип йөри идем. Менә хәзер өченчесе син булдың. Әйбәт, әйбәт, үзара ярыш ачып җибәрербез.

— Юк,— дип каршы төште Гомәр тагын,— мин монда, чыннан да, эч пошканнан гына керәсе иттем. Мин мәргән дә, спортчы да, аучы да түгел, мин очрак чыкканда гына ата торган кеше.

— Сигезенче пуляңны санамаганда син беренче классны мәргән. «Фәлинә пулясы»,— дип уйлады Гомәр.

Ул арада инде Юра тирчы карттан ун пуля һәм мишень сорап алды, өстен чишенеп ташлады да атарга әзерләнде.

— Сигезенче пуляң ул психологик пуля,— дип сүзен дәвам итте ул, винтовканы кора-кора.— Ун пулядан берәве генә психологик булу күп түгел. Ә миндә күбесенчә уннын икесе шундый була, сирәк кенә берсе, ә кайчакта хәтта өчкә җитә. «Нәрсә, әллә бу Юрада берьюлы өч бәхетсез мәхәббәт микән»,— дип уйлап куйды Гомәр үзалдына шаярып.

— Ә син борчылма,— дип дәвам итте Юра, винтовканы иңбашына җайлый-җайлый,— һәр мәргәндә була ул психологик пулялар. Хәтта халыкара класслы мәргәннәрне дә аямый алар. Җыен юк-бар нәрсә ачуын китерә бит ул безнең ир-ат халкының. Курокны тартыйм гына дигәндә я кесәңдә тәмәкең беткәне искә төшә, я хатынның кайчандыр сине мыскыл итеп әйткән әшәке сүзен хәтерлисең, я тирчы картның син атканда йокымсырап утыруы ачуны китерә.

Гомәр үзенең:

— Минем сигезенче пуляның сәбәбе тирәнрәк шул,— дип әйткәнен сизми дә калды. Әйтүе булды, үкенеп тә куйды.— Нигә кирәк инде гомереңдә икенче генә мәртәбә күргән кеше алдында болай ачылырга.

Юраның беренче пулясы унга тиде. Ләкин пуля тишеге унлы ак түгәрәкнең сул читендәрәк иде.

— Нәрсә, әллә халыкара проблемалар чишәсеңме? — диде ул Гомәрнең соңгы сүзенә ябышып.

— Әйе,— диде Гомәр, ни өчен болай җавап биргәненә үзе дә аптырап. Шулай да ул Юра икенче пулясын аткан арада уйланып торды да, үзенең дөрес җавап биргәненә төшенде. Чөнки бит мәхәббәт мәсьәләсе, чыннан да дөньядагы бөтен халыкларга да уртак булган бер проблема.

Юраның өч пулясы тугызга, калганнары унга тиде.

— Кәеф шәп түгел,— диде ул урамга чыккач,— хатын ит эзләргә чыгарып җибәрде, ә кибеттә ит юк.

— Тапкансың кәеф төшерерлек сәбәп.

— Синең халыкара проблемаларың каршында, әлбәттә, шулай,— диде Юра киная белән,— ләкин бит беренче чиратта тамак шәрифлә-

рен туйдырасы бар. Хатынныкын да, кызныкын да, үземнекен дә. Бу мәсьәләдә мин романтик түгел, ә практик.

Юра якутларга хас кысык күзләрен тагын да кыса төшеп, Гомәргә карады. Аның бик тә тар ярык аша күренеп торган күз карасында гаҗәеп тере мутлык очкынлана иде. Аннары ул тиз генә сәгатенә карап:

— Слуши, — диде. — Практик кеше буларак мин менә нәрсә тәкъдим итәм. Бүген кич яки иртәгә иртән җир тишегеннән булса да, ит эзләп табам. Ә син иртәгә төшке ашка санаторий ашханәсенә бармыйсың, минем фатирга киләсең. Сөйләшеп утырырбыз, без бит әле юньләп танышмаган да. Лариса белән бергәләп киләчәк ату ярышларының планын төзербез. Әйбәт ата ул җен кызы. Кара аны, бу инде икенче чакыруым, үпкәләтүең бар.

Гомәр бу юлы да чакыруны кабул итмәүне яхшысынмады һәм алар бүген кичке сәгать җидедә очрашырга сүз куешып аерылдылар.

## 2

Санаторийның өч корпусы Көбә төбе чокырының иң түренә үк урнашкан. Ямь-яшел көньяк үсемлекләре, мәңге яшел агачлар белән уратып алынган бу чокырны авырулар Кече Швейцария дип йөртәләр. Көбә төбенең бу урыныннан текә булып Ай-Петри күтәрелеп китә, шуңа күрә санаторий корпуслары янында гына берсе-берсе авыл өе кадәр ташлар, алардан арырак биек һәм шәрә кыялар тезелеп китә. Кыя ярыкларына, таш араларына кысылып мәңге яшел үрмә гөлләр, кәкребөкре Кырым наратлары үсә. Кайбер урыннарда бу ташлар, үрмә гөлләр һәм төрле чытырманлы куаклар шундый ешлыклар хасил итәләр ки, аларның эченә кереп утырсаң үзеңне өйдәге яки куыштагы кебек хис итәсең.

Санаторийга килеп Көбә төбендәге корпусларның берсенә урнашкач та, Хәрзан үзенә шундый бер аулак почмак эзләп тапты. Ул Кырымга дәвалану белән берр әттән эшләргә, языла башлаган докторлык диссертациясен дәвам итәргә дип килгән иде. Дәвалануны эш белән берләштерү өчен ул диссертацияне саф һавада язарга уйлады, врачлар рөхсәте белән үзе тапкан аулак урынга өстәл һәм урындык китереп куйды. Бу санаторийда авыруларны климат белән дәвалау ысулы киң файдаланылганга күрә, врачлар Хәрзанның саф һавада эшләвенә каршы килмәделәр.

Хәрзан урнашкан сигезенче корпуста ун палата булып, аның икесендә генә хатын-кызлар яши иде. Байтак кына санаторий һәм больницадагы кебек, монда да ир-атларның күбесе көннәрен карта яки домино уйнап, ә кичләрен телевидениенең беренче һәм икенче программаларында бик мул күрсәтелгән хоккей яки футбол уеннарын карап үткәрәләр иде. Алар арасында хатын-кыз тирәсендә чуалучылар да юк түгел, мондыйлар врачлар, сестралар һәм санитаркалар күзеннән читтәрәк булу өчен башка корпуслардагы хатын-кызлар белән танышалар иде.

Ләкин Хәрзан боларның берсенә дә игътибар итмәде, чөнки, беренчедән, аңа тиздән яраткан эшенә чумарга кирәк, икенчедән, ул карта яки домино уйнап, телевизордан хоккей яки футбол карап вакыт үткәрүне эшсез һәм булдыксыз кешеләр шөгыле генә дип саный. Институтларда эшләүче күпчелек гыйльми хезмәткәрләр шикелле үк, Хәрзан да баш-аягы белән үз фәненә бирелгән булу сәбәпле, бу дөньяның күп кенә уен-муеннарыннан, күңел ачу чараларыннан азат иде. Ул хәтта вакытын кино, театр, концерт карауга, матур әдәбият укырга да бүлә алмый, бу җәһәттән ул студент чоры багажы белән генә яши, бүгенге әдәбият һәм сәнгатьтән яңа исемнәр, яңа алымнар, яңа әсәрләрдән бик үк хәбәрдар түгел. Менә инде ун-унбиш еллап бардыр, геология фәне буенча булган йөзләрчә фәнни китаплар, әллә ничә илдә чыга торган

фәнни журналлар, үзенең бетмәс-төкәнмәс лаборатор эзләнүләре, төрле җыентыклар һәм журналларда басылып килә торган эреле-ваклы фәнни мәкаләләре, ниһаять, институттагы педагогик һәм җәмагать эшләре аның бөтен вакытын үзләренә рәхимсез йота баралар. Хәрзан инде үзенең бу фәнни тормышына күнегеп беткән, төрле минераллар, ташлар, балчыклар, сулар аның интеллектын тулысынча канәгатьләндерәләр һәм ул үзенең шушы тормышыннан бик риза иде.

Аның беренче өйләнүе уңышлы килеп чыкмады. Шат күңелле, уенчак Светлана Хәрзанның шактый коры һәм күңел ачулар белән бизәкләнмәгән фәнни тормышын аңламады да, аңларга да теләмәде. Өйләнешеп берничә ай үтүгә үк ул үзенең бу тормышта яши алмаячагын, мондый тормыш аның холкына бөтенләй капма-каршы икәнлеген әйтте. Әлбәттә, инде фәнне һәм фәнни тормышны тәмам идеаллаштырып өлгергән Хәрзан Светлана теләгән якка борыла алмаячагын белдерде, һәм алар ачуланышмый-нитми генә аерылыштылар. Балалары юк иде, фатир һәм җиһаз бүлүне катлауландырмадылар, Светлана Хәрзан белән елмаеп саубуллашты да бүтән шәһәргә үк китеп барды.

Хәрзанның икенче хатыны Рәмизә дә иренең фәнни проблемаларын аңлый дип әйтеп булмый иде. Ләкин Рәмизәнең Хәрзан өчен гаять әһәмияте булган бер ягы бар — ул иренең нинди дер бик тә катлаулы, бик тә кирәкле эш белән шөгыльләнүен аңлый, көнкүрештә аңа уңай шартлар тудырырга тырыша һәм иренең шулай аз сүзле, фәнни кешеләргә хас булганча академик холыклы, тормышта балаларча тәҗрибәсез һәм, гомумән, бераз гына сәеррәк кеше булуын хөрмәт итә иде. Шушы гадәтләре өчен ул ирен ярата һәм аны аналарча карый, тәрбияли. Гаҗәп, ләкин Рәмизә Хәрзаннан унөч яшькә кече булса да, аны һәр вакыт үзеннән кече бер ягымлы малай итеп тоя. Хәрзан хатынының бу мөгамәләсен белеп яши, бу мөгамәлә аңа бик тә ошый, һәм хатынын нәкъ шуның өчен ярата да иде.

Тугыз ел бергә яшәү дәверендә аларның уртак бәхетләрен тагын да зурайтып берсеннән-берсе матур ике кызлары туды.

Шулай да Рәмизәне Хәрзанның рухи дөньясын баетучы дип булмый. Авыл мәктәбендә урта белем алган, гап-гади колхозчы-крестьян семьясында тәрбияләнгән Рәмизә киләчәктә зур белемнәр алу, зур кеше булу турында хыялланмады. Унны бетерүгә шәһәрдә яшәү дәрте белән Себергә, әнисенең ерак туганнары яши торган шәһәргә килеп балалар бакчасына тәрбияче булып урнашты. Озакламый алар Хәрзан белән танышып киттеләр, өйләнештеләр. Шуннан соң инде Рәмизәнең бөтен рухи дөньясын яраткан ире, балалары били алды. Аларны тәрбияләү, аларны карау, матур гына итеп гаилә тормышын дәвам итү Рәмизәнең зур максаты һәм яшәү мәгънәсенә әверелде. Әдәбият-сәнгать, интеллектуаль тормыш мәсьәләсендә аның багажы Хәрзанныкыннан да азрак, ә инде иренең фәнни проблемаларын аңлау турында әйтеп тә торасы юк.

Шуңа күрә Рәмизә Хәрзанның фәнни хыялларын уртаклашучы да, эчке дөньясын кешелек тарихы ирешкән культура казанышлары белән баетучы да була алмады. Хәер, Хәрзанга боларның кирәге дә юк иде бугай, чөнки ул кызыксынган фәнни проблема аның гомеренең бөтен сәгате-минутын бары тик үзенә генә сарыф итүне сорый. Һәрхәлдә, Хәрзан үзе шулай уйлый иде.

Ләкин Хәрзанны зәвыксыз кеше дип булмый. Табигать тарафыннан аңа фәнни ачышлар сәләте, иҗади орлык бүләк ителгән булу сәбәпле, ул дөньяны, әдәбият-сәнгатьне тоюда шактый югары зәвыкка ия иде. Ләкин, әлеге дә баягы, буш вакытның бик тә кысрык булуы, күп чакта аның бөтенләй булмавы, бу югары зәвыкны әдәбияттагы, музыкадагы, сәнгатьтәге яңа казанышлар белән тулыландырып торырга мөмкинлек

бирми иде. Хәрзан моны күптән сизә, ләкин үз тормышының бу ягын үстерергә, аны баета барырга һаман буш вакыт таба алмый иде.

Менә Кырымга килгәч тә ул кешеләр белән аралашмады, санаторийда әледән-әле оештырылып торган театр-концертларга йөрмәде, көндезләрен Көбә төбендәге аулак эш «кабинеты»на качып диссертациясен язды, кичке сәгатьләрдә диңгез буена төшеп саф һава сулады. Ә төнен йокларга, ял итәргә кирәк иде.

* * *

Сигезенче корпусның ике палатасында яшәүче биш бөртек хатын-кыз, дөньядагы бөтен хатын-кызлар шикелле үк, корпустагы һәр ир-атның холык-фигыле; үз-үзен тотышы; кем белән, кайчан, кайда күңел ачуы; коры шәрабмы, ак аракымы, коньякмы эчүе, акчаны күпме, азмы туздыруы, сәнгатьнең, спортның, кулинариянең, моданың, хатын-кызларның ниндирәк төрләре белән кызыксынуы; белеме, шөгыле, хатыны, бала-чагалары ниндирәк булуы һәм ир-ат халкы өчен хас булган тагын йөзләгән билгеләр белән кызыксынып торалар иде. Бу биш хатын-кызның һәрберсеннән корпуста яшәүче һәр ир-ат турында теләсә нинди темадагы, теләсә күпме күләмдәге информация алырга мөмкин иде.

Хәрзан санаторийга килеп өч көн яшәүгә инде, ул беркем белән дә аралашмауга да карамастан, аның хатыны һәм ике баласы бар икәне дә, танцевать итүне (аеруча классик биюләрне) бик яратуы да, ике мәртәбә өйләнгән булуга карамастан, хатын-кыз мәсьәләсендә бөтенләй тәҗрибәсез һәм ифрат тәртипле булуы да, шактый коры, бертөрле тормыш алып баруы да, Көбә төбендәге аулак почмакка качып диссертация язуы да һәм институтта доцент булып эшләве дә биш хатын-кызның бишесенә дә билгеле иде. Доцентлыгы һәм хатын-кызларга битарафлыгы өчен корпус кызлары үзара гына аңа «дóцент-прóцент» дигән кушамат та тагып куйдылар. Янәсе, үзе доцент, ә үзе процент кебек коры, хиссез, битараф. Дóцент-прóцент дип сүзләрнең басымын беренче иҗеккә күчереп әйтү дә алар өчен бик кызык булып тоела иде.

Мәсьәләнең тагын бер әкәмәт ягы шунда, бу биш хатын-кыз үзләренә башка ир-атлар сырышып ятуга, аларны кино, театр, ресторанга яки санаторийда оештырылып торган күңелле сәяхәтләргә чакыруга да карамастан, аларны кире кагып, ни өчендер һаман Хәрзан белән кызыксыналар иде. Утыз биш яшьләрендәге чибәр, чая хатын Зина әлеге биш хатын-кыз арасында үзенең укымышлылыгы, поэзияне, әдәбиятны яратуы һәм бик яхшы белүе, бигрәк тә, үзе әйткәнчә, ир-ат психологиясен танып-белү буенча зур белгеч булуы белән аерылып тора иде.

Ләкин Хәрзан бу хатын-кызларга, аларның үзе белән бик нык кызыксынуларына, аны астыртын гына күзәтеп йөрүләренә карата бөтенләй сукыр әле. Гомумән, ул диссертация һәм дәвалану, Кырым табигате белән соклanудан башка санаторийда тагын ниндидер тормыш булуын уйлап та карамый.

Хәрзан сигезенче корпуска урнашып ике атна үтүгә, әлеге биш хатын-кыз санаторийда үткән бертөрле, игезәк көннәрен бераз җанландырып, аларга нәни генә бер үзгәреш кертү ниятеннән бу кеше белән кызыксына башладылар. Аларның «доцент-процент»ны юри генә үзләренә каратасылары, тегене шаяртасылар килә иде. Кызларның бу теләге җылы урынга куелган чүпрә кебек, көнләп түгел, ә сәгатьләп кабара барды, чөнки адәм баласына кулга ияләшми торган иң кыргый, тәрбиягә иң авыр бирелә торган җан иясен кулга ияләштерәсе килү теләге хас. Сигезенче корпус фәрештәләре Хәрзанның теләсә нинди хатын-кызның мутланып күз кысуына, яки мә минем көләчлегемне дип елмаюына бирешмәсен яхшы беләләр иде. Шуңа күрә, Зинаның кызларга әйтүе буенча, «дóцент-прóцент»ны ялгызлыктан аралау, үзләренә карату өчен алдан ук җентекләп хәзерләнгән наян стратегик плансыз булмый икән.

Беренче чиратта Зина «доцент-процент»ның йомшак якларын барларга кирәклеген әйтте. Хатын-кызлар аның иң йомшак ягы танцы яратуы икәнен билгеләп куйдылар. Аннары аны кулга иялэштерергә мөмкин булган күрсәткечләрнең берсе итеп аның фәнгә бирелгәнлеге, фәнгә мәхәббәте исәпкә алынды. Тагын аның табигатьне, агачларны, кошларны, киекләрне яратуы беленде. Зина планы буенча «доцент-процент» белән шушы мәсьәләләрдә адәм рәтлерәк сөйләшә алган хатын-кыз, һичшиксез, аның игътибарын үзенә җәлеп итә ала иде. Зина төзегән стратегик планның икенче пункты буенча «корбан»ның нинди мәсьәләләр буенча белем шәрифләре йомшаграк икәнен билгеләү кирәк. Кызларның берсе «доцент-процент» белән ашханәгә барган биш минут вакыт эчендә аның әдәбиятны, бигрәк тә бүгенге поэзияне бик аз белүен ачыклап кайткач, Зина кызларның һәрберсенә бүгенге модный шагыйрьләрдән берәр шигырь ятларга кушты. Монысы «корбан»ның төрле металл, кристалл, су, балчык, селте, кислота формулалары белән коргаксыган күңелен гүзәллек, поэзия, романтика дөньясына җәлеп итү өчен кирәк иде.

Стратегик план буенча хатын-кызлар баштан «корбан»ның яраткан әйберләре белән аның ышанычын яулап алырга, аннары ул белмәгән поэтик дөнья белән аның күңелен тәмам үзләренә җәлеп итәргә тиешләр иде. Шуларны эшләгәннән соң «доцент-процент» үзеннән-үзе бу хатын-кызлар белән кызыксына башлар дип аңлатты кызларга Зина. Ләкин планны җентекләп эшкәртә башлагач, шактый гына кыенлыклар да килеп чыкты. «Доцент-процент» белән булачак аңгәмәләр вакытында аның ышанычын яулау өчен кызлар үзләре ул яраткан фәнне яхшы белергә тиешләр. Ә бу биш хатын-кызның бишесенең берсе дә геология фәнендә әлепне таяк дип тә белмиләр, гомумән, аларның фән, фәнни эш, иҗат мәсьәләләрендәге белемнәре юк белән бер иде. Шуңа күрә алар Хәрзан белән сөйләшкәндә фәнгә, гомумән, кагылмаска, әгәр үзе сүз башласа, аңгәмәне бик оста гына бүтән якка борып җибәрергә килештеләр. Ә менә танцы мәсьәләсендә инде алар «доцент-процент»ка махы бирмәячәкләр. Аларның бишесен бергә җыйсаң төрле-төрле танцыларны белүче әйбәт кенә бер биюче килеп чыгачак та чыгачак. Шуңа күрә кызлар «доцент-процент»ка «һөҗүм» вакытында төп ударны танцыларга бирергә, аны ничек кенә булса да санаторийның җәйге уен мәйданчыгында шимбә саен үткәрелә торган танцы кичәсенә җәлеп итәргә сүз куештылар.

Хатын-кызларның җентекләп эшкәртелгән стратегик планы шактый уңышлы башланып китте. Бу уңышка Хәрзан үзе үк ярдәм итте бугай әле. Инде ике атна буе диссертация язып, кичләрен диңгез һавасы сулап йөргән Хәрзанны бу көндәлек бертөрлелек бераз ялкытып җибәрде һәм ул шимбә кичне кино карап чыгарга уйлады. Кичке сеанс сәгать сигездә башланырга тиеш иде. Танцы көне булу сәбәпле, биш хатын-кыз бүген көн буена сиздермичә генә «доцент-процент»ны күзәтеп йөрделәр, аның киногa керергә карар кылуын белгәч, корпустагы бер ирдән аны юк-бар сүз белән тоткарлап, сеанска соңга калдыруын үтенделәр. Теге ирне ярты сүздә ташлап китәргә кыенсынган Хәрзан, сөйләшеп тора-тора, чыннан да, сеанска соңга калды — ул клубка йөгереп төшкәндә инде билет сатучы кыз кассасын ябып куйган иде. Хәрзан кулын селтәп урамга чыкты һәм кичке һава сулый-сулый акрын гына кире корпуска табан атлады. Нәкъ шул вакытта аның каршында киенгән-ясанган, бизәнгән-сөртенгән биш хатын-кыз пәйда булды. Кызлар корпуска менә торган тар сукмакны иңләп киләләр иде, шаяра-шаяра юл бирмәгән булып, Хәрзанны туктаттылар. Бу шаярудан «доцент-процент» кинәт югалып калды, нәрсә әйтергә дә белмичә көлгән-елмайган булды. Кызларның берсе Хәрзанның киногa соңга калуын белмәмешкә салышып провокацион сорау бирде:

— Һай, берәр бәхетсезлеккә юлыктыгызмы әллә, кәефсезлегегез йөзегезгә чыккан?

— Киногa соңга калдым ла, — дип мыгырдады Хәрзан.

— Халыкара проблемалар белән чагыштырганда алай ук зур бәхетсезлек түгел икән, — дип мутланды Зина, стратегик планны тормышка ашыру дилбегәсен үз кулына алып. — Аның каравы, бүген җәйге уеннар мәйданчыгында танцылар була. Менә дигән оркестр уйнаячак. Сигезенче корпусның хатын-кызлар коллективы исеменнән без сезне танцыга чакырабыз.

Хәрзан әдәпле кеше иде. Ул, әлбәттә, хатын-кыз тәкъдимен кире кагуны тәрбиясезлек булыр дип уйлады һәм карышмый-нитми генә танцыга барырга риза булды. Дөрес, Хәрзан, бии белмим дип, бу тәкъдимне әдәпле генә кире кага да алган булыр иде, ләкин ул алдый белми торган кеше иде шул. Ахыр килеп, ул бүген барыбер кино карарга дип карар кылган кеше ич, кино карадың ни дә, танцыга бардың ни, барыбер түгелмени?! Җитмәсә, танцы яратучы кеше буларак, аның күптән бер бисе, сыгылмалы хәрәкәтләр, ритмика, музыка дөньясында буласы килеп йөри иде.

Кыскасы, сигезенче корпус хатын-кызлары җиңел сулап куйдылар— алар стратегик планның иң хәлиткеч, иң әһәмиятле мизгеле уңышлы хәл ителүгә шат иделәр.

Җәйге уеннар мәйданчыгы тирә-ягы мәһабәт кипарислар, җәлпәк яфраклы пальмалар, мимоза агачлары белән уратып алынган бер уйдык җир иде. Аның ишек яңакларына, шакмаклы рәшәткәләренә, электр баганаларына куе булып лианалар, үрмә гөлләр уралып үскән. Ә баш очында көньяк йолдызлары чекрәеп тора.

Оркестр күңелле вальс уйнап җибәргәч, Хәрзан, нәзакәтле генә баш иеп, кызларның берсен биергә чакырды. Сөйләшү буенча бүген кызларның берсе дә башка ир-ат чакыруын кабул итмәскә, бары тик «доцент-процент» белән генә биергә тиешләр иде.

Беренче бию Хәрзанны канәгатьләндереп үк бетермәде. Беренчедән, әле аның дулкынлануы, оялуы бетеп җитмәгән, икенчедән, партнершаның хәрәкәтләре бик үк төгәл түгел иде. Икенче биюгә ул Зинаны чакырды. Беренче әйләнүдә үк аның бик тә җайлы партнерша икәнен тоеп алды. Ул үзенең иңбашында Зинаның кулы бик ипле утыруын, әйләнгәндә һәм йөргәндә икесенең дә аяклары тигез һәм тәңгәл атлавын, үзенең уң учында Зинаның биле бик тә нәзакәтле ятуын сизде.

Хәрзанга Зина белән бию бик тә рәхәт иде. Аның инде берничә ел болай рәхәт биегәне юк. Оста биюче буларак, Хәрзан партнершаларга карата бик сизгер кеше. Үзе кебек оста биюче партнершалар аңа сирәк очрый иде. Соңгы елларда аңа бары тик хатыны белән генә биергә туры килде. Ләкин Рәмизәне танцы мәсьәләсендә бик оста партнерша дип булмый иде шул.

Ә Зина әйбәт бии. Дөресрәге, ул биеми дә бугай әле, ә партнер йөрткәнгә оста итеп буйсына белә. Бу инде биюнең иң төп кануннарыннан берсе. Оста партнер йөрткәнгә тулысынча буйсына белгән партнерша иң шәп биючеләрдән санала.

Хәрзан чиратлап хатын-кызларның бишесе белән дә биеп чыкты. Ләкин Зинадан башка партнершалар аңа ошамады. Кызларның берсе буйга аннан озынрак булып, читтән караганда мондый пар көлке булып күренә иде. Икенче бер кыз партнер йөртүенә бөтенләй буйсынмый торган булып чыкты, ул әйләнә башлагач йөртү вазифасын үз кулына алды да, Хәрзанны җилтерәтә дә башлады. Тегесе биюне абына-сөртенә көчкә ерып чыкты. Кызларның соңгысы бөтенләй әйләнә белми икән, үзе әйтүенчә, ул бары тик «современный» ритмнарга гына сикерә белә.

Чираттагы вальска Хәрзан яңадан Зинаны чакырды. Алар аякларын төп-төгәл чалыштырып баса-баса, музыка ритмына гаять тә тәңгәл ки-

тереп иннәрен сикертә-сикертә, зал буйлап йөзеп киттеләр. Кинәт Зина да үзенең стратегик планнары, Хәрзанны юри генә шаяртырга теләүләре турында бөтенләй онытып җибәрде. Аңа бөтен гәүдәсе белән Хәрзанның ныклы уң учында яту, дәртләнеп әйләнгәндә ычкынып китмәс өчен аның иңбашына ныграк тотыну рәхәт булып китте. Вальс уртасында ул партнерның көчле итеп әйләндерүеннән шундый бер халәткә килеп җитте ки, аяк астындагы идәнне туфлиенең очлары белән генә сиземләде. Әйе, Зина инде биеми, ә оча, оча, оча иде! «Очам, очам, очам... Рәхәт, рәхәт, рәхәт... Музыка, туктама, туктама, туктама...» — дип кабатлады Зинаның күңел түрендә бер аваз. Шул мизгелдә партнер шып итеп әйләнүне туктатты да, хәрәкәт инерциясе белән нәкъ музыка ритмына туры китереп кенә уң аягын кыйгачлап артка терәде һәм салмак йөрүгә күчте. Озак әйләнүгә карамастан, Зина да, Хәрзан да тигез сулыйлар, ләкин сулышлары бик тә кайнар иде. Салмак йөрүгә күчкәч, партнер көчле итеп әйләнгәндә Зинаның биленнән бераз читкәрәк шуышкан кулын бил уртасынарак күчереп куйды. Шул чакта Зинаның миеннән: «Стратегик планны онытмаска», — дигән мут уй узып китте һәм ул тыгыз уң күкрәген «дóцент-прóцент» пиджагының сул күкрәк кесәсенә китереп төртте. Моңа җавап итеп Хәрзанның бөтен тәне буйлап җиңелчә бер дерелдәү узып китте. Ләкин бу аң белән эшләнгән эш түгел иде, чөнки Хәрзан әле яңа гына булып узган тыелгысыз әйләнү тәэсиреннән айнып ук җитә алмады. Шулай да ниндидер билгесез көч аның Зина билендәге кулын тагын да алгарак шудырды. Зина карышмады, киресенчә, партнерга тагын да якынрак килеп елышты һәм, ни хикмәттер, аның биегәндә алсуланып киткән уң бит очы «дóцент-прóцент»ның нәкъ иреннәре белән янәшә туры килде. Шуннан соң Зина юри бәләкәй генә ялгыш адым ясаган булды һәм ритм чуалган бер мизгелдә кайнар бит очын партнерның шундый ук кайнар иреннәренә тидереп үк алды. Партнер, әлбәттә, бу тиюне ялгыш кына, ритм бозылганлыктан гына булган эш дип кабул итте, шулай да аның мондый ялгышны тагын бер кабатлыйсы килә иде. Ярамаган эш эшләвен никадәр генә аңласа да, ул юри аягын ялгыштырып ритмны бозудан тыелып кала алмады. Бу юлы инде ни өчендер аның иреннәре Зинаның бит очыннан аскарак, ирен читләренә туры килде. Җитмәсә, Зинасы да шул мизгелдә башын сизелер-сизелмәс кенә сулгарак борырга өлгерде һәм партнерның иреннәре аның ирен урталарыннан шуышып узды.

Әйе, кипарислар, пальмалар, мимозалар, лианалар, үрмә гөлләр белән уратып алынган кечкенә бию мәйданчыгында Зинаның стратегик планын тормышка ашырып, ә «дóцент-прóцент»ны тәмам алгысытып, ашкындырып, исәнгерәтеп аяклар бии, биллэр бии, күкрәкләр бии, я хода, иреннәр бии иде.

Вальс тәмамлангач, Хәрзан белән Зина мәйданчыкның кызлар басып калган икенче почмагына килделәр. Ләкин алар килгәндә инде кызлардан җилләр искән иде. Аларның стратегик планны тормышка ашыру эшен Зинага гына тапшырып, тизрәк корпуска кайтып китүләрен белми иде шул безнең «дóцент-прóцент». Хәрзан, ни өчен икәнен үзе дә белмәстән, кызларның кайтып китүенә эчтән генә шатланып та куйды.

Кайтырга чыккач, Зина куллары белән үз-үзен кочаклап:

— Миңа салкын, — диде.

Хәрзан ашыга-ашыга пиджагын салып, Зинаның иңнәренә япты. Төн караңгы булмаса, бу мизгелдә Зинаның мутланып елмаеп куюын күрми калмаган булыр иде ул. Ләкин күктә көньяк йолдызлары чекрәеп торуга да карамастан, төн мондый астыртын, мут елмаюларны күрерлек үк якты түгел иде шул.

Ике-өч адым атлауга Зина тагын:

— Миңа барыбер салкын, — дип куйды.

Менә сиңа әкәмәт. Нәрсә таләп итә бу хатын? Күлмәген дә салып бирә алмый ич инде аңа Хәрзан. Дөрес, мондый очракларда ул хатынын кочаклап җылыта торган иде, ләкин Зина бит аңа җиде ят кеше. Кочаклый башласаң, яңак төбеңә чалтыратып җибәрергә дә хакы бар. Шулай да «дөцент-прөцент» уң кулын йомшак кына итеп Зинаның иңбашына салды. Шуны гына көтеп торган Зина гәүдәсенең бөтен буе белән Хәрзанга килеп сыенды. Аның тыгыз һәм калку сул күкрәге «дөцент-прөцент»ның култык астына төртеп тора иде. Хәрзан да югалып калмады, Зинаны кысыбрак кочаклап алды.

— Бәлки сезгә дә салкындыр, әйдәгез, пиджакны икебезгә ябыныбыз, — диде Зина, бик тә әдәпле булырга тырышып. Ләкин аның көләсе килә иде. Хәтта ул пырхылдап көлеп җибәрүдән чак-чак кына тыелып калды. Чөнки аның стратегик планы бер кич эчендә шактый зур уңышка ирешеп маташа иде.

— Юк, — дип каршы төште Хәрзан, — миңа һич тә салкын түгел.

— Алай димәгез, — диде Зина. — Кырым дисәң дә, хәзер октябрь ае ич.

Ул да булмады, Зина Хәрзанның кочагыннан чыкмаган хәлдә генә пиджакның бер итәген аның иңбашына салды. Шулай итеп, алар икесе бер пиджак астында калдылар. Хәрзан юка күлмәге аша Зинаның тыгыз һәм кайнар тәнен тойды.

— Көньяк табигате нинди гүзәл, — диде Зина пышылдап кына һәм Есенинның фарсы мотивлары циклыннан көньяк табигатенә һәм саф мәхәббәткә багышланган бер шигырен укыды.

Хәрзан институтта укыган елларда әле Есенин әсәрләре халык арасына хәзерге кебек үк киң таралып китмәгән иде. Дөрес, ул кайчандыр Есенинны тулысынча укып чыкты, ләкин хәзер бер шигырен дә тәгаенләп кенә хәтерли алмый. Ә Зина укыган шигырь әйбәт иде. Ул, әлбәттә, Хәрзанга тәэсир итми калмады.

— Ә мин поэзияне бик үк яхшы белмим, — диде Хәрзан оялып.

— Китегезче, — дип, бик нык гаҗәпләнгән булды Зина. — Сезгә, шундый зур, укымышлы кешегә, фәнни ачышлар ясаучы иҗади әһелгә поэзиядән артка калу һич килешми. Поэзиядән артка калу заманнан артка калу белән бер ич ул.

— Анысы шулай. Тик вакыт дигән нәрсә кысрык бит.

— Теләк булганда һәр нәрсәгә вакыт җиткереп була. Сезнең яки теләгегез юк, яки вакытны дөрес бүлә белмисез.

— Теләк бар, ә менә вакытны бүлү мәсьәләсендә бәлки сез хаклыдыр.

— Әлбәттә, шулай. Ә хатыныгыз ни карый соң сезнең? Аның урынында булсам, мин сезне әдәбият, сәнгатьнең иң яңа казанышлары белән таныштырып барыр идем.

— Боларны ул үзе дә бик белеп бетерми шул, — диде «дөцент-прөцент» мыгырданып.

— Карагыз әле, — диде Зина, «дөцент-прөцент»ның хатыны турындагы сүзне шунда туктатып. — Безнең корпусның икенче катындагы буш палатада инде бер атнадан артык ниндидер бер егет яши. Милләте татар, Гомәр исемле, ди. Сәеррәк кеше ул. Сезнең шикелле үк, беркем белән дә аралашмый, шулай да бүген көндез теге, хатыны белән ял итүче Юра белән тирдан чыгып киләләр иде. Бәлки спортсмен-фәләндер. Мин аның кулында һәр вакыт китаплар күрәм. Әле кичә генә Есенинның ике томлыгын тотып йөри иде. Аннан алдан күргән китапларның исемен укый алмадым, алары үз телендә, татарча китаплардыр бәлки. Карта яки домино белән җенләнмәгән кешегә охшый, бәлки бергә җыелышып поэзия кичәләре үткәрербез, ә?

— Минем үз эшем бар шул, андый кичәләргә вакытым калмас.

— Юк, без ул кичәләрне сезнең эшегезгә комачауламый торган итеп

оештырырбыз. Сез бит көн саен кечке якта дингез буена төшәсез. Без барыбыз да бергә җыелырбыз да, ул кичәләрне шунда үткәрербез.

Дөресен әйткәндә, Хәрзан бу тәкъдимнең үзе өчен бик тә кирәкле икәнен шунда ук аңлап алды. Аңа бүгенге тормыштан артка калмаска, бик тә калмаска кирәк иде. Югыйсә болай гел формулалар, информация дөньясында гына яшәп бөтенләй кызыксыз, заманның койрыгында сөйрәлә торган кеше булып калуың да бар.

— Яхшы, — диде ул, Зина белән килешеп. — Чыннан да, поэзия әсәрләре тыңлый-тыңлый диңгез һавасы сулау безгә икеләтә файдалы булачак.

— Бик шулай, бик шулай, — дип, ике мәртәбә пичәт басып куйды Зина. — Карагыз әле, — дип дәвам итте ул, — иртәгә үк аның палатасына кереп танышып чыгыгыз әле, безгә, хатын-кызларга, ирләр белән танышып йөрү килешеп бетми, әле бүген сезне хатын-кызлар коллективы исеменнән танцыга чакыруыбыз өчен дә оялып торам.

«Тыйнак хатын,— дип уйлап куйды Хәрзан Зина турында.— Һәм заман белән бергә атлый торган җитди кеше».

— Ярый, ярый, иртәгә кереп чыгарга тырышырмын, — диде ул, Зинаның биленнән тагын да ныграк кыса төшеп.

Гаҗәп, ләкин Хәрзан Зинаны әллә кайчан таныш булган бер якын кешесе итеп тоя башлады. Зинаның үз гәүдәсенә бөтенләй сыланып елышулары, башын аның күкрәгенә куюлары, үзенең бер кул белән генә булса да Зинаны биленнән алып кочаклаулары һәм аларның бер пиджак астында бер тән булып атлаулары шулай булырга тиештер һәм монда бернинди гайре табигый, гаҗәпләнерлек нәрсә юктыр кебек иде. Ул гына да түгел, менә хәзер ул Зинаны әйләндереп алып күкрәгенә кысса, хәтта алсу иреннәреннән суырып үпсә дә, гаҗәпләнерлек берни дә булмас кебек иде. Һәм... Һәм ул шулай итте дә! Икесе дә еш-еш суладылар, иреннәрдән иреннәргә кайнарлык йөгерде, кашлар, күз керфекләре, борыннар бер-берсенә тиеп тәнне рәхәтләндерделәр. Хәрзанның кулдары Зинаның калак сөякләрен, җилкә чокырларын иркәләп сыйпады, ләкин Зина ачуланмады да, карышмады да. Юк, бу минутта ул үзенең стратегик планы турында да уйламады. Нинди дер бер хикмәт төшеп, Зинаның үзенә рәхәт иде. Ул гына да түгел, бу кочудан, бу үбүдән Зина тәмам башын югалтты, вакыт, чор, җир, ир, хатын, бала, стратегик план төшенчәләре кинәт бөтенләй юкка чыктылар, дөньяда бары тик ике генә нәрсә торып калды — рәхәтлек һәм кайнарлык.

— Ашыкмыйк, — диде Зина, азмы-күпме хәл алып. — Без бит бөтенләй таныш түгел кешеләр.

— Танышлар, бик танышлар, — дип пышылдады Хәрзан, Зинаны җибәрмичә. — Миңа инде без мәңге танышлар кебек.

— Миңа да шулай, — диде Зина да. — Ләкин без бөтенләй юл өстендә, асфальт сукмакта басып торабыз, кеше күрер.

Хәрзан Зинаны ычкындырды һәм алар алга атладылар. Алар инде Көбә төбенә үк килеп җиткәннәр иде. Сигезенче корпусның якты утлары алар атлап килгән асфальт сукмакны яктыртып тора. Корпус ишеге төбендә Хәрзан пиджагын өстенә киде һәм алар икәүләп эчкә керделәр. Ир-атлар кечкенә генә коридорга куелган телевизордан хоккей карыйлар иде, Хәрзан белән Зина саубуллашып үз палаталарына кереп киттеләр.

*
* *

— Бетте баш, кызлар, — диде Зина, палатага килеп керә-керешкә. Сигезенче корпусның калган дүрт хатын-кызы да бергә җыелып, аны көтеп торалар иде. — Тегене шаярта торгач, үзем әллә нишләдем әле.

Тәмам жанымны урынымнан куптарды, иләсләндерде, тилертте бу «доцент-процент» мине.

— Нәрсә, азгынмыни? — дип шаккаттылар кызлар.

— Юк шул менә, азгын булса, уенны шунда туктаттың да бетте-китте иде. Кыз чакларымны кире кайтарды ул минем.

— Нәрсә, чыннан да, тилерә башладыңмы әллә, сөйлә тизрәк, — дип, төрле яктан йолыккаладылар Зинаны кызлар.

— Туктагыз, — дип, лып итеп урынына барып ятты Зина, — бүген бер нәрсә дә сөйли алмыйм әле, башым буталды. Аңлатып булса, иртәгә аңлатырга тырышып карармын.

— Кыланма, кыланма, — дип чырылдадылар кызлар. — Иртәгәгә кадәр без чыдый алмыйбыз, шартлыйбыз, бүген сөйлә, ату сиңа төн йокысы юк.

— Китегез әле, — дип, үз яныннан куды кызларны Зина. — Ярты гына сәгать уйланырга ирек бирегез.

— Ярты сәгать түгел, бер минут та бирмибез. Нәрсәсен уйлап торасың инде аның, нәрсәләр эшләгәнегезне сөйлә дә, бетте-китте.

— Бер нәрсә дә эшләмәдек, танцевать иттек тә, корпуска кайттык. Дөрес, юлда бер мәртәбә үбештек.

— Үбәме? — дип кызыксындылар кызлар. — Шайтан алгыры, үбәрсең, беркая да китмәссең, «доцент-процент» булмагаең әллә кем бул.

— Үпми ул, кызлар, ул үтерә! — диде Зина уйланып.

Шуннан кызлар төп сүздән читкә китеп, үз гомерләрендә кем ничә ир-ат белән үбешкәнне саный башладылар.

Ә Зина уйлана иде. Чыннан да, ни булды соң әле бу? Дөрес, ул Рязаньда аны зар-интизар булып көтеп ятучы ире белән яратышып яшәми. Ул аның белән тол хатын булмас өчен генә бергә тора. Хәер, тагын кызлары хакына да яши бугай әле. Чөнки кыз этисен ярата, ә тегесе кызын да, Зинаны да ярата. Ләкин бит Зина үз иреннән башка да ир-ат күрмәгән хатын түгел. Һәм ул, гомумән, үзен ир-атларны ярата белүче хатын дип саный. Ләкин менә бүгенге хәл ничектер бөтенләй башка төрле тәэсир итте... Фу, шайтан алгырысы, нишләп мондый уйлар уйларга мәҗбүр итте соң әле бу «доцент-процент»?! Һәм Зинаны моңа кадәр һич тә татып карамаган илаһи бер халәткә кертте. Әллә соң Зина моңа кадәр чын ярату нәрсә икәнен белмичә йөрде микән? Ләкин бит ул хатын-кызлар арасында ир-ат психологиясен иң яхшы белүчеләрдән санала. Ул бит инде иренә турылыклы хатыннар рәтенә керә алмый һәм яше дә бара. Димәк, аңа чын ярату нәрсә икәнен аңларга вакыт инде, бик вакыт. Ләкин Зина үзенең бүгенге халәтен, һичшиксез, чын ярату галәмәте дип саный иде.

Ниһаять, палатадагы хатын-кызлар кемне ничә ир үпкәнен санап бетерделәр.

— Ә мине нибары дүрт ир үпкәне бар, — дип еламсырады озын Лида. — Аның да берсе үз ирем. Бөтен ирләр, буй җитми дип, мине үбүдән баш тарталар. Аның каравы, минем үземнең бер яшь кенә егетне көчләп үпкәнем бар, — диде ул аннары батыраеп. — Автобуста барганда карап-карап бардым да, бик ошады бу миңа. Нәфесемне тыя алмадым, тукталышта тегенең артыннан төшеп калдым да, куып җитеп каерып үптем бәләкәчемне.

Инде кызлар Лидага ябырылдылар:

— Я, я, шуннан нишләде соң теге манный боткасы?

— Күзләрен челт-челт йомгалап миңа карап торды-торды да, мин борылып киткәндә, кесәсеннән чип-чиста кулъяулык алып авызын сөртеп калды, кабахәт.

3

Гомәр юлны аркылы чыгыйм гына дип торганда, автобус тукталышында бәләкәй башны күреп алды. Ул бик олы чемодан тотып, автобус көтеп тора иде. Гомәр аңа дәшми китәргә кыенсынды һәм борылып тукталышка килде.

— Пүчтәк, — диде бәләкәй баш Гомәрне танып. — Юк, мин сезне әйтмим, үземнең санаторийны ташлап китүемне әйтәм. Минем санаторийга килүем дә, китүем дә пүчтәк.

— Чынлап китәргә уйлагансыз икән, — диде Гомәр.

— Китәм, ике дә уйламыйча китәм. Хатын-кыз ягыннан адәм рәтле кешегә монда ничу делать. Ә сез хатын-кыз ягыннан ниндирәк адәм ә?! — дип, күз кысты бәләкәй баш Гомәргә.

— Ничек булыйм, бөтен ирләр кебек инде,— диде Гомәр, ни җавап бирергә аптырап.

— Алайса, сезгә монда калырга ярый,— диде бәләкәй баш, Гомәрнең җавабын үзенчә аңлап.

— Авыруыгыз бик үк җитди түгелдер, шуңа китәсездер,— диде Гомәр, сүзне юньлерәк темага күчерергә теләп.

— Пүчтәк, авыруым пүчтәк кенә. Мин монда дөнья күрергә генә дип килгән идем. Пүчтәк икән. Карагыз әле, — диде аннары бәләкәй баш Гомәрнең колагына ук үрелеп. — Сез юньле кешегә охшыйсыз, хатынкызга алдана күрмәгез. Монда алар бик җор күренә. Карагыз аны, алдана күрмәгез. Дөрес, хатын-кыз белән бераз чуалырга ярый, ләкин алдана күрмәгез.

Гомәр бәләкәй башның нәрсә әйтергә теләгәнен һич кенә дә аңламады.

— Алдану бик тә пүчтәк нәрсә ул, — дип дәвам итте бәләкәй баш.— Алдану ул хатыннан, бала-чагадан, гаиләдән яздыра. Алданмагыз, нык торыгыз.

— Мин сезнең нәрсә әйтергә теләгәнегезгә төшенеп бетмим, — диде Гомәр аптырап.

— Вәт, пүчтәк кеше. Алданмагыз дим, хатын-кыз аркасында хатыныгызны, бала-чагагызны ташламагыз дим.

— Минем гаилә ташлау турында уйлаганым да юк, — диде Гомәр никтер авыр сулап. — Аерылышкан очракта да аңа ниндидер өченче кеше гаепле булмаячак.

— Пүчтәк,— диде бәләкәй баш.— Арага өченче кеше килеп кысылмаса, бер ир дә гаиләсен ташламый. Арага өченче кеше кереп харап итә безнең ир-ат башын. Ә менә миңа андый куркыныч янамый, чөнки мин хатын-кыз ягыннан адәм рәтле кеше. Ә сез моны пүчтәк әйбер дип саныйсызмы?

— Юк, киресенчә, мин үзем гаиләсенә турылыклы булган кешеләрне яратам.

— Алдыйсыз сез,— диде бәләкәй баш Гомәргә туп-туры карап.— Хатын-кыз ягыннан адәм рәтле булган кешене күп ирләр, бигрәк тә хатын-кызлар пүчтәк кеше дип исәплиләр. Минем моны үз колакларым белән ишеткәнем бар.

Һаман үз туксанын тукучы бу кеше Гомәрнең ачуын ук китерә башлады. Ярый әле, шул чакта алар янына автобус килеп туктады һәм бәләкәй баш зур чемоданын өстерәп автобуска керә башлады.

— Сез юньле кешегә охшыйсыз, — дип мыгырданды ул, чемоданы артыннан әчкә атлап,— пүчтәк хатын-кызларга алданмагыз.

Ул соңгы сүзен әйтеп бетерүгә шап итеп автобус ишеге ябылды. Бу ишек Гомәргә автобусны түгел, ә бәләкәй башның авызын ябып куйгандай тоелды. «Шул кирәк сиңа, бар, юлыңа ак җәймә, бәхетсез нити-

лист», — дип уйлап калды Гомәр бәләкәй баш турында. Аннары ул юлны аркылы йөгереп чыкты да, Юра яши торган фатирга юнәлде.

Гомәр килгәндә Юра ишегалдында краблар киптереп йөри иде. Гомәрне күрүгә ул кайнар кояш нурлары төшеп торган зур бер ташка тезгән крабларның берсен сайлап алды да Гомәргә сузды:

— Мә, киптер дә, улыңа алып кайтырсың. Кара дингезнең менә дигән кара крабы, пляждан үзем тотып мендем.

Краб, чыннан да, шәп иде. Инде күптән үлгән һәм яртылаш кибә башлаган булуга карамастан, аның кыяфәте гаҗәеп горур һәм сугышчан. Яңа гына тешәгән үткер урак кебек кәкре аяклар өстендә каты һәм калын түшен алга киергән кап-кара гәүдә. Бу түшнең почмакланып торган ике ягында еракка чекрәйгән ике зур күз. Юлында очраган һәр нәрсәне сыта-сыта окоп брустверына менеп килүче горур танкка охшаган бу крабның кыяфәте Гомәрнең кәефен дәррәү күтәреп җибәрде. Юра Гомәрнең крабны лаеклы бәяләвен шунда ук сизеп алды һәм шуңа кәефләнүеннән болай да монголныкы кебек кысык күзләрен тагын да кысып куйды. Бу аның шулай рәхәтләнүе иде. Аннары ул таш өстендәге крабларын корсаклары белән өскә әйләндереп тезде дә, ачык тәрәзәдән өйгә кычкырды:

— Лариса, өстәл әзерлә, кунак бар,— аннары ул, Гомәргә борылып, — хәзер коры шәраб чөмерәчәкбез, — дип өстәде.

Өстәл артында алар бер-берсе белән тәмам таныштылар, кемнең кайда, нәрсә эшләве, ниләр белән кызыксынуы турында сөйләштеләр.

Юра алтын эзләүче геолог икән. Ул елның тугыз аен кырда үткәрә, өч аен тоташ ял итә. Ул Гомәргә алтын эзләү хикмәтләре, геологлар тормышы, аучылык турында әллә никадәр кызыклы нәрсәләр сөйләп ташлады. Юраның үз эшен яратуы, ул гына да түгел, үз хезмәтенә, үз белгечлегенә карата булган мөнәсәбәте аның намусын билгели торган иң зур күрсәткеч дәрәҗәсендә булуы әллә каян күренеп тора иде. Шуңа күрә дә ул геолог хезмәтен үз тормышын әдәмчә итеп оештырган беренчел әһәмиятле фактор итеп саный. Хатын, бала, фатир, келәм һәм башка нәрсәләр аның өчен икенче чиратта иде булса кирәк.

Ә менә Гомәр Юра алдында эше белән бик үк мактана алмады...

*

* *

Гомәргә институтта үз яшьтәшләреннән шактый соң укырга туры килде. Гомумән, ул олы тормышка соңрак килеп керде, соңрак өлгерде бугай. Сугыштан соңгы авыр елларда аны беренче класска ел ярымга соңлап бирделәр. Җитмәсә, алтынчы класста ике ел утырырга туры килде, чөнки ул көздән үк сары белән авырып больницага эләкте, ә анда аның тәнендә сугыш елларыннан ук калган корчаңгы зәхмәте азып китте, бөтен тәнен кавыклы кызыл түгәрәкләр сырып алды. Бу авыруны тәмам бетерү өчен врачларга сигез ай вакыт кирәк булды.

Шулай итеп, Гомәр унынчы классны егерме яшендә генә тәмамлады. Ул елларда институтка керер алдыннан ике-өч ел производствода эшләп алу бик модада иде, һәрхәлдә, җыелышларда һәм газеталарда шуны пропагандаладылар. Гомәрнең байтак яшьтәшләре бу модага ирмәде, унны тәмамлау белән институтларга укырга керделәр. Ләкин Гомәр, гомум чакыруга кушылып, мәктәпне тәмамлау белән туган колхозында калырга булды. Ул анда урман кисте, колхоз машинасында йөкче булып йөрде, урак өсләрендә комбайнда салам ташлатучы булып эшләде, һәр эштә алдынгы булды Гомәр, авылдашлары һәм колхоз җитәкчеләре алдында хөрмәт казанды. Җитмәсә, мәктәптән үк килгән табигый сәләте, матур әдәбиятны, сәнгатьне яратуы аркасында җәмәгать эше тәртибендә колхозның үзешчән сәнгать түгәрәге эшен дә җайга

салып җибәрде һәм ике ел эчендә алар коллективы район смотрында беренче урынны алуга иреште. Гомәрнең сәләтенә һәм намуслы егет икәненә тәмам ышанган җитәкчеләр аны авыл китапханәсенә мөдир итеп куйдылар, ә яшьләр аны колхоз комсомол оешмасы секретаре һәм ДОСААФ председателе итеп сайлады. Ләкин Гомәрнең күңеле бол̆ар белән генә канәгатьләнми иде, бу өч елны ул һаман институтка укырга керү хыялы белән яшәде. Һәм ул шулай итте дә. Унны бетереп эшли башлавына өч ел тулгач, ул культура институтының китапханә бүлегенә укырга китте, аны тәмамлагач, шәһәрдә үк эшкә калды. Бу вакытта инде аңа утыз яшь тулып килә иде. Ул институтны тәмамлаганда инде аның яшьтәшләре күптән өйләнешеп, фатирлар алып, балалар тәрбияләп һәм үз эшләрендә карьера баскычлары буйлап югарыга үрләп яталар иде.

Хәер, өйләнү ягыннан Гомәр дә алардан калышмады. Институтның икенче курсында чакта ук өйләнде ул. Һәм өйләнүен дә өйләнергә вакыт җиткән һәм бүгенге хатынын өзелеп яраткан өчен түгел, ә бары тик Фәлинә аркасында гына өйләнде...

Фәлинә!..

Унынчы классны алар бергә, бер мәктәптә, бер класста тәмамладылар. Яратышулар иксез-чиксез булып тоелды, алар бу дөньяга бары тик бер-берсен бәхетле итү өчен генә килгән кешеләр кебек иде.

Гомәр Фәлинәне беренче мәртәбә сигезенче класста чакта күрде. Фәлинәнең туганнары күп еллар читтә йөреп, яңадан авылга кайтып төпләнергә уйлаганнар. Ләкин Башкортстандагы бер район үзәгендә җиткергән йорт-җирләрен саткалаганчы ярты еллап вакыт үтәчәк икән. Шуннан алар Фәлинәгә уку елы уртасында мәктәп алыштырырга туры килмәсен дип, сентябрь аенда аны авылга, ялгызы гына яшәп ятучы апайларына кайтарганнар. Бу апай ел саен Гомәрләр авылына унны тәмамларга дип килгән күрше авыл кызларын фатирга кертә иде. Апай, Фәлинәгә иптәш тә булырлар дип, быел да фатирга ике кыз кертте.

Фәлинә дә, аларда фатирда торучы ике кыз да җидене бетергәннәр иде, өчесе дә сигезенчегә, Гомәрләр классына туры килделәр. Шулай итеп Гомәр Фәлинәне беренче мәртәбә беренче сентябрьдә күрде. Дөресен әйткәндә, беренче сентябрь көнне ул аны күреп тә бетермәде бугай әле. Тагын да дөресрәген әйткәндә, Фәлинәнең читтән кайтып Гомәрләр классына укырга килүе Гомәр өчен барыбер иде — югары оч Хәчбикә апа сарыгының уң аягы сынды ни дә, ниндидер бер Фәлинә алар классына укырга килде ни, болар икесе дә Гомәргә печтек кенә дә тәэсир итми торган әһәмиятсез вакыйгалар иде.

Укый башладылар. Гомәр ул чакта хәзерге кебек еш кына тирән уйларга чума торган, басынкы һәм үз эченә бикләнгән кеше түгел иде әле. Киресенчә, ул шаян иде, шук иде, дөреслек хакына укучыларга, укытучыларга, хәтта мәктәп директорына да башбирмәс бер чәнечкеле шайтан таягы иде. Һәм ул алдый белмәде, эчендәге тышында иде, бөтен нәрсәне төп-төгәл, шәрран ярып әйтеп сала торган иде. Әгәр мәктәптә тыныч кына агып барган уку-укыту, тәрбия режимы көтмәгәндә бер яктан бүселеп чыкса, көт тә тор — бу Гомәрнең чираттагы шуклыгы булыр иде.

Ә мәктәптә тәртипләр каты. Илгә сугыш алып килгән авыр яраларны төзәтә торган кырыс еллар иде әле бу. Чорның кырыслыгы мәктәптә дә сизелә, кешеләр җитди эш белән шөгыльләнәләр һәм бу елларда әле мәктәпнең җәмәгать тормышында шаяру-көлүләргә, төрле шуклыкларга урын таррак иде. Шуңа күрә мәктәптә Гомәрнең җилбәзәгрәк холкы күпләргә ошамый иде. Укучылар арасыннан да, укытучылар арасыннан да. Шуның белән бергә бәйрәм-сәйрәм вакытларында, концерт-мазар куйганда Гомәр алыштыргысыз бер кешегә әйләнә. Чөнки ул менә дигән итеп шигырь укый һәм гаҗәп оста итеп концерт алып

бара белә иде. Җитди шигырьләрне ул күзләрдән яшьләр китерерлек итеп, ә шаян шигырьне эчең катып көләрлек итеп укый. Гомәр укучылар көче белән хәзерләнгән шактый булдыксыз гына концертларны да җанландырып җибәрә, кичәгә җан өрә иде.

Кызганычка каршы, аның бу кызыклары концерттан соң да, тәнәфесләрдә һәм дәресләрдә дә дәвам итә. Әлбәттә инде, җитди эш вакытында клоунланып утырган Гомәр дәрес бирергә дип класска кергән укытучының ачуын китерә. Бу бетмәс-төкәнмәс шаярулар, шуклыклар Гомәрнең укуына да тәэсир итә һәм аны әйбәт укучылардан санап булмый иде.

Шаянлыгы, чытлыклыгы белән җиде елдан артык укытучыларны интектергән, директор бүлмәсеннән башы чыкмаган Гомәр сигезенче классның икенче ярты еллыгында акрын-акрын уйчанлана барды һәм уку елы беткәндә инде тәмам моңаеп калды.

Аның уйчанлана баруына сәбәпче, һичшиксез, Фәлинә иде, ә менә тәмам моңаеп калуына Фәлинә генә сәбәпче булмады бугай.

Мәктәп тормышының кырысрак һәм җитдирәк эздән баруыннандырмы, әллә педагогик коллективның үсмерләр табигатен бик үк тирән төшенеп бетермәвеннәндерме, мәктәптә малайлар һәм кызларның үзара дуслашуы, аларның бер-берсенә гашыйк булулары, гомумән, мәктәп кысасындагы сөю-мәхәббәт хисләре белән яну коточкыч зур бер тәрбиясезлек, мәктәпнең эчке кагыйдәләрен тупас бозу, хәтта азгынлык дәрәҗәсендәге җинаять итеп санала иде.

Менә шушы шартларда Гомәр үзенең Фәлинәгә гашыйк була башлавын тойды. Менә инде ике айлап бар, ул Фәлинәне ничектер үзенең сумкасы, чалбары, күлмәге, партасы кебек үк үзенеке, ул гына кагылырга хаклы булган бер зат, җан иясе итеп тоя. Фәлинәнең бу әйберләрдән аермасы шунда гына, бик ачуы килсә яки бик теләсә, Гомәр сумкасын атып бәрә, чалбарын пычрата, күлмәген ертып ташлый, партасын пәке белән киртләп ала, ә менә Фәлинә белән нинди генә очракта да алай эшләмәс кебек. Юк, аллам сакласын, алай итәме соң ул Фәлинәне, киресенчә, аны берәрсе кимсетсә, якларга ук әзер бугай әле ул.

Мондый хиснең кайчан һәм ничек уянганын Гомәр тәгаен генә хәтерли алмый. Хәер, бераз хәтерли дә бугай.

... Фәлинәнең ике авыл кызы белән яши торган фатиры Гомәрләрдән биш-алты йорт аша иде. Бер класста укучылар булгач, Гомәр алар янына кереп чыккалый. Шуннан алар дүртәүләшеп бераз гына дуслашкандай итеп тә киттеләр. Ләкин Гомәр яшь иде, малай гына иде, шуңа күрә ул күбрәк авылдаш малай-шалайлар арасында була, байтак гомерен шулар белән үткәрә. Кышкы кичләрнең берсендә унынчыда укучы бер авылдаш егете Гомәрдән үзен Фәлинә белән таныштыруны сорады. Юк, таныштыруны сорады дисәк, авыл малае өчен бу артык зур итагатьлелек булыр иде, унынчыдагы егет Гомәрнең Фәлинәләр белән дус булуын белеп, мәктәп залындагы танцы кичәсеннән кайтканда Гомәрдән Фәлинәне тотып бирүен сорады. Чөнки Фәлинә белән теге ике кызның кичтән урамда үзләренә таба егет-җилән килә башласа, чырылдап кача торган гадәтләре бар иде. Ә менә азмы-күпме дус та, бер урамда яшәүче дә, классташ та буларак, алар Гомәрдән качмыйлар, киресенчә, кичләрен аның беләнрәк кайтырга тырышалар иде. Шуңа күрә Гомәргә бу өч кызның теләсә кайсысын теләсә кайсы егеткә тотып бирү ике тиен бер акча да тормый. Бая әйткән хиснең бәләкәй генә чаткылары да юк иде шул әле ул чакта Гомәрдә. Кичә бетүгә Гомәр Фәлинәләр белән кайтырга чыкты. Аларның урамы авылның түбән очында иде, ә мәктәптән түбән очка бөтен ягыннан да чишмәләр бәреп торучы Саз дигән зур гына буш бер урын аша үтәсе. Җәй көннәрендә Саз чишмәләре арасыннан мәктәпкә табан әллә ничә сукмак үтсә дә, кышын бу урыннарга калын кар салу сәбәпле, бер генә сукмак була иде. Гомәрләр шул

сукмак буйлап түбән очка төшеп киттеләр, теге егет илле адым чамасы арткарак калып, аларга иярде. Сөйләшү буенча Гомәр Фәлинәне Саз сукмагы олы урамга барып тоташкан урыннан бирерәк, чишмә буендагы кара мунчалар ышыгында теге егет килеп җиткәнче тотып торырга, ә күрше авыл кызларын тиз генә фатирларына куып кертергә тиеш иде. Егет монысын Гомәрнең колагына киртләп әйтте, чөнки аның Фәлинә белән чит-ят күзләргә күренәсе килми иде.

Мунчалар янына килеп җиткәч, Гомәр ике дә уйлап тормады, Фәлинәнең беләгеннән нык кына итеп эләктерде дә, теге ике кыздан йолкып та алды. Кинәт тартылудан кызлар чырылдашып куйдылар.

— Нәрсә чырылдашасыз, әйдә, элдерегез өегезгә,— диде Гомәр аларга тупас кына. Кызлар алны-артны белмичә фатирларына чаптылар.

Фәлинә Гомәрнең бу кыланышыннан аптырап калган иде.

— Нишләвең бу, Гомәр, җибәр әле кулымны, — диде ул тыныч кына.

Гомәр әледән-әле артка борылып теге егетнең килеп җиткәнен көтә иде. «Нишләп һаман килеп җитми инде, нишлим мин монда бу чәрелдек белән», — дип уйлады ул. Аның артка карангалавыннан эшнең нәрсәдә икәнен сизеп алган Фәлинә кинәт Гомәргә шундый йомшак итеп дәште:

— Зинһар җибәр, Гомәр җаным, оятлы итмә мине.

Һәм Гомәр болытлар арасыннан бер күренеп, бер күмелеп яктыртучы саран ай яктысында Фәлинәнең үзенә табан шундый бер ялварулы караш белән карап торуын күреп калды.

Әйе, «җаным» диде һәм шундый төбәп карады Фәлинә. Гомәр бу ике факттан ни өчендер шактый йомшарып калса да, теге егеткә биргән вәгъдәсен бозудан яхшысынмады.

— Туктале, шауламыйча гына тор, — диде ул Фәлинәгә бик ачуланмыйча гына, сукмактан монда табан килүче карамчыкны шәйләп. Карамчыкны Фәлинә дә күрде һәм тыпырчына ук башлады.

— Гомәркәй, дустым бул, җибәрсәнә, йөгеримче өйгә, апайдан оят бит, кызлар кайтты, ә мин юк, — диде Фәлинә гаҗәеп дустанә тавыш белән.

Нишләп болай мәлҗерәп төште соң әле Гомәр, Фәлинәнең һәр сүзе аңа ничектер йөрәкне авырттыра торган итеп тәэсир итә. Ләкин теге егеткә биргән вәгъдәне үтәми дә ярамый, ир-ат лабаса ул, әйткән вәгъдәсен җилгә очыра алмый.

Ул арада кар шыгырдатып теге егет килеп тә житте. Ул бик һавалы гына Фәлинәнең икенче беләгеннән эләктерде дә Гомәргә: «Ярый, ычкын», — дип, кызны кочагына ала башлады.

— Нишлисең син, кит, юньсез, иртәгә үк директорга әйтәм,— дип тыпырчынды кыз. Егет аның саен Фәлинәне кочагына алырга азапланды, тегесе һаман тыпырчынды.

Бәй, нишләп һаман китмичә басып тора соң әле Гомәр монда? Аның эше эшләнде, бөтенләй кирәге калмады ич инде.

Гомәр, ике кулын сырма кесәсенә тыгып, өлгереп килүче малайларга гына хас алпан-тилпән адымнар белән акрын гына өенә табан атлады. «Һәй, шайтаныма олаксынсана шул Фәлинәнең җаным дигән сүзе дә, ай яктысында күренеп калган ялварулы йөзе», — дип уйлады ул, һаман күз алдында ялварып басып торган Фәлинәне куып. Кинәт аңа бу уйлары өчен бик тә оят булып китте. Үз-үзеннән оялды Гомәр. Ир-ат кичәнең кызлар турында болай җитди уйлавы ничектер уңайсыз, оят һәм ярамаган эш булып тоелды аңа.

... Әйе, бәлки чишмә буендагы әнә шул тәбәнәк һәм кара мунчалар янында кузгалгандыр бу татлы хис?! Шунда кузгалгандыр да, тугызынчы һәм унынчы класларда Фәлинә белән сөешеп, яратышып үткәргән ике ел буе, матурая барып, азактан Гомәргә ияреп шәһәргә килгәндер, аннары Мәскәүгә, Ленинградка, Урта Азиягә сәяхәт вакытларында

да Гомәрдән калмагандыр, аннары хатыны белән бер түшәктә йоклаганда да аларның икесенең арасында җылынып ята торган булып киткәндер, инде менә хәзер дә, монда, гүзәл Кырымга ук, ияреп килгәндер.

Ләкин Гомәр бу мизгелдә алар турында уйламаска тырыша, бу мизгелдә ул шат күңелле, реалист һәм гаять оптимист якут егете Юра белән коры шәраб авыз итеп утыра. Дөресрәге, Юра коры шәрабне өнәмичә Кырым коньягы белән сыйлана, ә Гомәр шәраб белән ләззәтләнә. Юра инде үзенең сөекле Якутиясе, акча күп төшә һәм женнәренне чыгарырлык физик көч сорый, җанга иң зур ләззәтләр бирә торган геолог хезмәте турында сөйләп, коньяк уртлый-уртлый шактый кызмача бер хәлгә килде. Ә Гомәр күп эчмәде һәм күп сөйләшмәде. Озакламый сүз язучылар һәм китапларга күчте, Юра әдәби китаплар ярата икән, ләкин Якутиядә яхшы китаплар күп булмый дип зарлана. Китаплар байтак килә икән килүен, ләкин алар елның тугыз аен кырда үткәрүче геологлар кулына бөтенләй эләкми кала, кибетләрдә сатылып бетеп бара икән.

— Бездә дә әйбәт китап табуы ансат түгел, ләкин сездәгенә караганда җиңелрәк, — диде моңарчы Юраны тыңлап сүзгә бик үк кушылмыйчарак утырган Гомәр, китаплар турында сүз чыгуга җанланып.

— Слуши, мин бит практик кеше, үзең беләсең, — диде Юра, — давай болай килешәбез: санаторийдан кайткач, син миңа китаплар җибәрәсең, ә мин сиңа Якутиядән менә дигән бер аю тиресе.

— Нигә алай зурдан кубасың? — диде Гомәр. — Аю тиресе бит ул хәзер бик сирәк очрый торган затлы һәм кыйммәтле нәрсә санала. Мин сиңа китапларны болай гына җибәрермен.

— Беләм, беләм, — дип кысык күзләрен кыскалады кызмача Юра.— СССРның Европа өлешендәге бөтен интеллигент халкы хәзер өендә аю тиресе булдыру белән җенләнә. Лариса, безнең теге Илмән елгасы буендагы кышкы аучы өендә аю тиресе тора бит әле?

— Китсәнә, — диде Лариса иренә ачуланган булып, — кешегә шул тире турында сөйләп торма инде, иләнмәгән дә бит ул.

— Син шайтанымны да белмисең, — дип әтәчләнде Юра, — болар өчен ул, — (бу вакытта Юра Гомәргә бармагы белән төртеп күрсәтте) менә дигән тире әле. Боларга хәзер тузып беткән аю тиресенең колагын кисеп бирсәң дә, шуны затлы квартиралары стенасына Репин картинасы белән янәшә асып куялар. Аларга хәзер болан мөгезе, ишәк тоягы, ташбака кабыгы, буявы коелган икона, борынгы җиз кыңгырау, балык скелеты, читләре янган китап, бүрәнәләре череп беткән авыл өе, җирдә ята-ята каралып беткән шәмдәл, кулланудан төшеп калган акча, сасы челем, күгәргән комган кызык. Хобби, табигатькә якынайган цивилизация, экзотика! Гомәр, мә кәгазь, мә каләм, язып ал миңа нинди китаплар кирәген: «Хемингуэй, Ремарк, Поль Сартрларның теләсә нинди китаплары һәм «Бөтендөнья сәнгать тарихы»ның бөтен томы да. Геологларга шуларны белсәләр дә җиткән.

Аю тиресе дигәч, чыннан да, колагы тора башлаган Гомәр Юра әйткәннәрне кәгазьгә яза-яза: «Боларның җенләнүе безнекеннән кире якка табан икән», — дип уйлап куйды.

Ниһаять, урамда караңгы төште һәм Гомәргә китәргә вакыт иде. Юра аны озата чыкты. Кырым киче гаять җылы иде. Алар сигезенче корпус һәм Юраның фатиры арасындагы юл читендә үсеп утырган инҗир янына килеп җиттеләр. Гомәргә үзенең янәшәсендә Юра булу рәхәт иде. Юра көр күңелле, ачык йөзле һәм яшьләрчә җилле егет. Ә менә Гомәр гел басынкы һәм моңлы кеше. Менә хәзер дә яшьлеге, Фәлинә турында кузгалып куйган баягы уйлары һаман башыннан чыгып китми, миенең кайсыдыр бер почмагына посканнар да, янадан бөтен күңелне, җанны биләп алырга җай көтеп торалар.

— Нишләп син хатының һәм балаң турында бер сүз дә әйтмисең? —

дип сорады кинәт Юра. — Күпме сөйләшеп утырдык, хатының белән улың турында ләм-мим димәдең.

— Яратмыйлар алар мине, — диде Гомәр, болай да авыртып торган күңелен тагын да авырттырып.

— Юкны сөйләмә, — диде Юра каты гына, — яраттыра белмисеңдер. Әллә син аларга акчаны аз кайтарасыңмы?

— Күп кайтарган чакларым да булды.

— Әллә үзеннең игътибарың азмы аларга? Бүләк-мазарлар алып кайткалыйсыңмы соң үзләренә?

— Ул яктан мин үземне мәнсез кешеләрдән санамыйм. Кая гына барсам да, әллә никадәр бүләк алып кайтам. Үземә берни алмаганда да аларга кием-салымын, конфет, апельсин, икра-мазарын алып кайтам. Ләкин минем хатын ул бүләкләргә шатлана белми. Дөрес, малай шатлана, ләкин ул да минем игътибарлылыктан түгел, ә тәмле-томлы ашаячагына гына.

— Ничек инде шатлана белми? — дип кызды кызмача Юра, — минем хатын бер кульяулык алып кайтсам да, үбә-үбә битне кызартып бетерә.

— Телисеңме, мин сиңа бер эксперимент эшләп күрсәтәм, — диде Гомәр кинәт. — Озакламый Октябрь бәйрәме җитә бит. Бәйрәм алдыннан гына безнең санаторийда дәваланучы бер абзый Татарстанга кайтып китә. Мин шуның белән хатын белән улыма көньяк җимешләре җибәрергә телим: виноград, инжир, груша, гранат. Мондый җимешләр бездә дефицит, базарда да сирәк була. Бәйрәм алдыннан мин аларга котлау телеграммасы да җибәрәчәкмен. Күреп торырсың, алар миңа бәйрәм белән котлап телеграмма да җибәрмәячәкләр һәм теге абзый аша алган бүләкләргә рәхмәт хатын да кимендә бер атна соңлап язачаклар.

— Булмас, — диде Юра ышанмыйча, — алар бүләк алган көнне үк сиңа хат язачаклар. Алар сине яратмаган очракта да шулай эшләргә тиешләр. Малаең булса да хат язар әле.

— Ә малай миңа, гомумән, язмый. Менә инде санаторийга килгәнгә күпме вакыт үтте, аның әле миңа бер хат та язганы юк. Ә бит инде ул алтынчы класста укый, хат язарга гына булдыра ала.

— Кирәкми, бала-чаганы гаепләргә ярамый, — диде Юра, һаман күңелсезләнә барып.

— Юк, мин аны гаепләп әйтмим. Мин аңа өч көн саен нинди дә булса бүләк җибәреп торам. Хет әнисе булса бер-ике авыз сүзле хат яздырыр иде.

— Да-а-а-а, — дип сузды Юра, — сиңа алар белән тормыш итүе бик авырдыр.

— Бөтен хикмәт тә шунда шул, инде мин үзем дә алар турында уйламаска күнегеп беттем.

— Ә нигә соң, алайса, син гел уйчан, басынкы?

— Мин башка кеше турында уйланам.

— Туктале, нинди кеше соң син? — дип кызып китте Юра. — Кайчакта бөтенләй ир-атка охшамыйсың, ниндидер мәлҗерәк, пыскак, җебек бер кеше шунда. Юк, гомумән алганда, син начар малай түгел бугай. Күңелең яхшы синең, саф, чиста. Синең күңелең минекенә караганда да да чистарак бугай әле. Ләкин менә ир-атка хас булмаган ниндидер эчпошыргыч якларың бар синең. Я, дөресен генә әйт әле, сөяркәң бармы?

— Өйләнгәнгә кадәр юк иде, өйләнгәннән соң чуалгаладым.

— Ачыклабрак сөйлә.

— Болай уйнап-шаярып кочаклашкан-үбешкән хатын-кызлар бар да анысы, ә менә сөяркә дип әйтерлекләре икәү генә, алары да очраклылар гына.

— Хатының беләме?

— Юк, мин ул яктан сак кеше.

САРГАЯМАГЫЗ, КАШТАННАР... ◆ ГАРӘП РӘХИМ ◆

— Слуши, — диде Юра, — сиңа юри генә сөяркәм бар дигән сүз чыгарырга кирәк. Ләкин аны кем ашадыр хатының ишетергә тиеш. Кайбер хатыннарга көнләшү хисе яхшы якка гына тәэсир итә ул. Югыйсә синең ул хатының бөтенләй суынып бара бугай. Аңа бераз гына бензин сибеп көнләшү уты тәртергә кирәк, бер үрле-кырлы сикереп алудан яхшыра гына ул хатын-кыз заты.

— Аның яхшыру-яхшырмавы мине кызыксындырмый шул,— диде Гомәр.

— Хандра син, мең мәртәбә хандра, — дип әрләде аны Юра. — Нишләргә соң инде миңа синең белән?

4

Икенче көнне Гомәр янына Хәрзан кереп утырды. Гомәр яңа кешеләр белән авыр аралашып китә торган кеше булса да, Хәрзанга тиз ияләште. Хәрзанның тыйнак, басынкы табигате аңа ошады.

Хәрзан чыгышы белән Үзбәкстан оазисларының берсендә яшәүче аз санлы бер төрки халкыннан иде. Үзенең борынгы гореф-гадәтләрен, кием-салымнарын бүгенге көнгә кадәр нык саклап килүче бу халык, нибары берничә колхоз тәшкил итеп, мамык үстерү белән шөгыльләнә икән. Ләкин инде Хәрзан бала чактан ук әти-әнисе белән Себердәге бер шәһәргә күчеп, туган теленең татар теленә якын булуы аркасында, шунда беренче класстан бирле Себер татар балалары белән бер мәктәптә укыган, институт һәм аспирантура тәмамлаган, хәзер үзе укыган институтта геология кафедрасы мөдире булып эшли икән. Шуңа күрә ул татарчасын да, русчасын да бердәй яхшы белә. Аспирантураны тәмамлаган елны ук ул кандидатлык диссертациясе яклаган, шуннан бирле фәнни һәм педагогик эш белән шөгыльләнә, докторлык диссертациясе яза.

Хәрзан үзенең хатыны да татар булуы, бик яратышып торулары турында әйтергә дә онытмады.

Гомәр аңа үзенең культура институтының китапханә факультетын тәмамлавы, хәзер китапханәдә эшләве, бу эш аны канәгатьләндереп бетермәве турында сөйләде.

Әйе, Гомәр бу институтка укырга кереп ялгышрак эшләде бугай шул. Юк, ул бу институтта, бигрәк тә аның китапханә бүлегендә, укуны үзенә файдасыз булды дип санамый, киресенчә, китаплар дөньясы, димәк, белем, гыйлем дөньясы аның иң яраткан нәрсәләреннән санала. Ул бу институтта бик күпкә өйрәнде, монда аның ерак гасырлардан алып бүгенге көнгә кадәр булган кешелек тормышы, үсеш тарихына күзе ачылды. Шул ук вакытта ул үзенең төп эше китапханәче булуны азсына, хыялында булган бөтен мөмкинлекне ачып бетерергә бу белгечлекнең колачы җитенкерәмәвен сизә иде. Дөрес, ул мәктәп елларында ук дусишләреннән, үзен укыткан укытучылардан, гаиләсеннән, гомумән, бөтен кешедән яшереп кенә көндәлек тә сыман, елъязма да сыман һәм фәлсәфи фикерләүләр дә сыман нindидер язмалар алып бара башлады. Еллар үтү белән бу язмалар күбәеп һәм тематик яктан киңәеп, бер, ике, өч, биш дәфтәргә генә сыймыйча, яңадан-яңа дәфтәрләргә языла бардылар. Гомәр һәр дәфтәргә номер суга-суга һаман язды да язды. Ялгызы гына өйдә калган чакларында ул элеккеге дәфтәрләрне алып укыштыргалый да иде. Андагы язмалар Гомәр дөньяны, әдәбият-сәнгатьне, тарихны, кешеләрне тирәнрәк өйрәнгән, күбрәк күргән саен катлауланганнан-катлауланалар, шул ук вакытта тел, стиль ягыннан камилләшкәннән-камилләшәләр, уку өчен гаять кызыклы була баралар. Шунысы да бар, бу язмаларның буеннан-буена Фәлинә дигән бер исем сузылып

килә, дөресрәге, бу язмалар әле шул Фәлинә белән сөйләшү рәвешендәрәк язылганнар да бугай.

Гомәр соңгы еларда үзенең төп шөгыле булган китапханә эшеннән суынганнан-суына һәм шушы язмалары белән кызыксынганнан-кызыксына баруын сизеп яши иде. Һәрхәлдә, менә дүрт елдан артык китапханәдә эшли һәм ел саен бу эштән читләшә, ә язмалар белән шөгыльләнүен көчәйтә бара.

Ләкин Гомәр бу язмалар белән нәрсә эшләргә икәнен белми. Ул аларның ниндидер әһәмияткә ия икәнлекләрен аңлый да кебек, ләкин нинди әһәмияткә икәнен билгели алмый. Фәнниме? Юк кебек. Чөнки бу язмаларда конкрет кешеләрнең язмышлары, мәхәббәт һәм гүзәллек турында уйланулар, хәтта шигырь белән язылган урыннар да очрый. Бәлки ул берәр әдәби әсәрдер? Алай дисәң, анда артык фәнни телдә язылган урыннар да байтак.

Гомәр бу язмалары өчен борчыла да, шул ук вакытта ояла да. Бәлки алар бер тиенгә дә яраксыз коры язмалар гынадыр? Менә ни өчен Гомәр аларны кеше күзенә күрсәтүдән саклана, сер итеп саклый. Шуңа күрә дә ул аларны гел үзе белән йөртә. Чемодандагы ярты урынны алуга да карамастан, Гомәр ул дәфтәрләрне менә Кырымга да алып килде, өйдә калдырырга базмады. Гомәр бу дәфтәрләр турында һәр вакыт ялгызы гына уйлана. Һәм еш уйлана. Бәлки Гомәрнең басынкы, эченә бикләнгән бер адәм, Юра әйтмешли, хандра булуына менә шушы ялгыз уйланулар да бер сәбәптер.

Ә менә кичә Юра белән сөйләшеп утыру Гомәргә әллә ничегрәк тәэсир итте. Юраның үз эшен яратуы, геологлар турында шундый тере, якты, күтәренке итеп сөйләве Гомәрне кызыктырды. Юк, геолог эше түгел, ә үз эшеңә карата булган шундый шәп, яратулы һәм бирелгәнлек мөнәсәбәте. Гомәрнең дә ниндидер бер эшне, бер шөгыльне яратасы, үз итәсе, шуңа бөтен җан-тәнен, уй-фикерен, хәтта гомерен багышлыйсы килә башлады. Һәм күңеленең иң түрендәге бер тоем аңа андый эшнең әлеге язмаларда яшеренеп ятуын әйтте. Әйе, чын-чыннан шулай диде бу тоем Гомәргә: «Синең язмышың язмаларыңда»,— диде. Ләкин геолог эшен үз күңелендә үз серең генә итеп яшереп яткырып булмаган шикелле, бу язмаларны да кешеләргә, ватандашларыңа, дөньяга файдалы итим дисәң, яшереп яткырып булмаячак иде. Дөресрәге, яшереп була, ләкин бу яшерү Гомәрнең хәзерге хандра тормышы дәвам итү генә булып калачак. Шуңа күрә Гомәр, кичә Юра яныннан палатасына кайтып яткач, бу язмаларны кешеләргә, дөньяга күрсәтергә дигән карарга килде. Ләкин шунда ук мәсьәләгә кәкре ыргак булып яңа сорау килеп басты — кешеләргә күрсәтүен күрсәтергә, ләкин ничек итеп? Ничек? Әйе, бу сүз артында мең тимер ыргак булып сораулар тезелеп киткән иде. Һәм ул ыргаклар бу сүз артында шундый нык басып торалар, кузгалырга-кымшанырга һич исләрендә дә юк.

Ә менә бүген, Хәрзан белән очрашып сөйләшеп утырган арада, бу тимер ыргаклар кинәт селкенеп куйгандай һәм артка чигенгәндәй булдылар.

«Әгәр ул язмаларны Хәрзанга күрсәтеп карасаң?»— дигән яңа сорау узып китте Гомәр күңеленнән. Бу сорау ыргагы артында инде кымшанмый-кыймылдамый торган меңләгән тимер ыргак түгел, ә ниндидер яктылык, өмет галәмәтләре тора иде.

Гомәр күп уйлап тормады, ничә еллар буе сер итеп саклаган язмалары турында Хәрзанга сөйләп бирде. Язмалар турында сөйләгәндә Гомәр, әлбәттә, Фәлинә турында сөйләргә дә мәҗбүр иде. Чөнки язмаларны Фәлинәдән, Фәлинәне язмалардан аерып булмый.

Мәхәббәт хакында сүз чыккач, Хәрзан җиңелчә генә кызарып куйды. Кинәт ул кичә Зина белән булып үткән хәлләрне хәтерләде һәм аның Зинаны күрәсе килүдән йөрәге кысылып куйды.

*

* *

Ә бу вакытта күрше палатадагы дүрт хатын-кыз дүртесе дүрт яктан Зинаны тарткалыйлар иде.

— Кичә кичтән иртәгә аңлатам диден, я, сөйлә, ни эш майтардың кичә «дóцент-прóцент» белән? — дип чырылдашты алар.

Зинаның эшләре шәптән түгел иде. Кичә «дóцент-прóцент» аның күңелен айкап ташлады, шул исереклектән әле һаман да айный алганы юк. Ә монда кызлар ачу китерәләр, аннан нәрсәдер таләп итеп, дүртесе дүрт ягыннан тарткалыйлар. Ул гына да җитмәсә, әнә, кемдер шундый йомшак, шундый сак, шундый тыйнак кына итеп палата ишеген шакыды. Бу, әлбәттә, ул гына, «дóцент-прóцент» кына булырга мөмкин иде.

— Керегез!— дип кычкырдылар кызлар беравыздан.

Ишектә Хәрзан күренүгә, кызлар, бер-берсенә карашып, яшерен генә пырх-пырх көлештеләр, Зина җиңелчә кызарып куйды. Шулай да ул кызларга палатадан чыгып китәргә кирәген аңла́тып ишарә ясарга өлгерде.

— Гафу итегез, мин сезгә комачауладым бугай,— диде Хәрзан, кызларның дәррәү Зина яныннан таралышып киенә башлауларын күргәч.

— Юк, юк, без диңгезгә төшәргә әзерләнгән идек, ә Зинаны ияртмибез,— диделәр кызлар, соңгы сүзгә мут мәгънә салып.

— Я, күрше егетнең кылларын тарткалап карадыгызмы? — дип сорады Зина, кызлар чыгып китүгә үк үз-үзен кулга алып.

— Кызык кына кешегә охшый ул,— диде Хәрзан,— ләкин берьюлы гына аңларга кыенрак кеше.

Кинәт Зина караватына йөзтүбән капланды да бөтен гәүдәсе белән дерелдәп үкси-үкси еларга тотынды.

— Сезнең үзегезне дә аңлавы бик ансат түгел бит. Аһ, нинди бәхетсез хатын мин, нинди бәхетсез!

Хәрзан ни эшләргә дә белмичә катып тора бирде. Ләкин хатын-кыз үксеп-үксеп елаганда, ир кешегә болай басып тору килешми бит инде. Нәрсәдер эшләргә, һич югында, бу бәхетсез хатынны тынычландырырга кирәк бугай. Әйе шул, тынычландырырга, истерикага бирелдермәскә кирәк бу сөйкемле хатынны. Шайтан алгырысы, сөйкемле шул, чыннан да, бик сөйкемле бу хатын... Шайтан алгырысы.

Хәрзан карават янына килеп ниндидер җайсыз хәрәкәтләр белән кулын Зинаның калтырый торган иңбашына салды.

— Тынычланыгыз, кирәкми, еларга кирәкми,— диде ул, әнисен бик нык кызганган малай тавышы белән.

Зина торып утырды да, карават башындагы сөлгесен алып, күз яшьләрен сөртте һәм Хәрзанга утырырга янында урын күрсәтте. Хәрзан утырды да Зинаның иңнәреннән кысып ук алды. Зина карышмады. Карышмау гына түгел, ул әле бөтен гәүдәсе белән Хәрзанга якынрак елышты да бугай.

Һәм... Һәм кичәге ләззәтләр тагын кабатланды... Ләкин бүгенге ләззәт кичәгесеннән дә татлырак иде.

Менә Зина тәмам тынычланды. Шуннан ул стратегик планны дәвам итәргә кирәклеген сизеп алды. Дөресрәге, Зинаның стратегик планы инде теге көнне кызлар белән килешкәндәге эчтәлеген, ул чактагы мәгънәсен тәмам үзгәрткән иде. Стратегик планның максаты инде хәзер «дóцент-прóцент»ны юри хатын-кызлар белән мавыктырып шаярту, аның белән уйнау гына түгел, кичә кичтән туган хисне дәвам итәргә тырышу, шул хисне югалтмау һәм бу кешене үз яныннан җибәрмәскә теләүдән гыйбарәт иде. Дөрес, Зина боларны бөтенләй үк уйлап та бетермәде бугай, ул боларны хәзер бары тик хис мантыйгына буйсынып кына эшли иде.

— Мин бүген кунакка чакырулы,— диде Зина, нәрсәдер уйлап.— Теләсәгез, мин сезне дә үзем белән алыр идем.

Аннары ул бераз гына уйланып торды да:

— Минем белән генә барырга кыенсынсагыз, иптәшкә Гомәрне дә ала аласыз,— дип өстәде.

Кунакка бару мәсьәләсендә Зинаның башында өр-яңа план өлгереп килә иде. Эш шунда ки, санаторийдагы медсестралар арасында Зинаның бер дус тол хатыны бар. Ире аерылып киткән яшь, чибәр бу медсестраның Алып каласында ике бүлмәле кечкенә генә өе бар. Медсестра үзе өенең бер бүлмәсендә яшәп, икенче бүлмәсен җәй көннәрендә Кырымга килүче «дикарь»ларга фатирга биреп тора. Бүген ул Хәрзан белән шул медсестрага кунакка барырга планлаштырды, хуҗа хатынга пар итеп үзләре белән Гомәрне дә аласы итте.

Хәрзан Зина тәкъдименә каршы килерлек хәлдә түгел иде. Беренчедән, ул, тәртипле кеше буларак, тәкъдимгә каршы килүнең тагын Зинаны елатуыннан курыкты, икенчедән, аңа бу хатын белән бергә булу бик тәрәхәт иде.

Инде Гомәрне генә ризалатасы калды. Юра белән булган сөйләшүдән, Хәрзанның үз язмаларын укырга риза булуыннан кәефе күтәрелгән, күңел түрендә ниндидер якты өмет очкыннары кабына башлаган Гомәр дәррәү риза булды. Зина төшке аш вакытында тиз генә теге медсестраны күреп, аңа хәлләрне аңлатып бирде. Кичтән медсестра аларны кунакка чакырган булып кыланырга, ирләр арасында сирәк очрый торган тыйнак экземпляр Гомәрне үзенә каратырга тырышырга тиеш иде. Медсестра баштан өем җыештырмаган, бүгенгә мәҗлес оештыру җайсызрак, хәтта яхшы түгел дип караса да, Зина аны, бүгенгә түз, барысын да тәфсилләп сөйләп торырга вакыт юк, кичәне һичшиксез оештырырга кирәк, калганын иртәгә сөйләшербез, дип кырт кисте.

Гомәр белән Хәрзан кунакка буш кул белән баруны яхшысынмыйча, кибеткә барып ашамлык-мазар, әйбәт шараблар алып кайттылар.

Шулай итеп, Зинаның стратегик планын гаять тиз темплар һәм зур уңышлар белән тормышка ашырып, Алып каласының виноград куаклары, үрмәле гөлләр, хөрмә һәм гранат агачлары белән уратып алынган кечкенә генә таш өендә мәҗлес хәзерләнде.

Өйгә килеп керү белән Зина Гомәрне медсестра белән таныштырды.

— Таныш булыгыз, Лена: украин кызы.

— Гомәр, татар малае,— диде Гомәр, Ленаның нәни учын кысып.

Лена сизелер-сизелмәс кенә кызарып киткәндәй булды. Һәрхәлдә, Гомәргә шулай тоелды.

Ул арада хатын-кызлар ирләргә дә эш куштылар һәм алар дүртәүләшеп, юк-бар кызыклар сөйләшә-сөйләшә, мәҗлес әзерли башладылар.

Мәҗлес кәефле генә башланды. Зина белән Лена компанияне тота торган шаян, күркәм һәм уен-көлкегә оста хатыннар булып чыкты. Хәрзан шәраб уртлап куйганчы ук Зина белән янәшә утырудан да исереп киткән иде бугай, ә Гомәр үзенең Юра әйткән хандра кәефе югала баруга куанып утырды.

Зина белән Хәрзан өстәлнең бер ягына, ә Лена белән Гомәр икенче ягына парлашып утырганнар иде, өстәлдә яңа гына сабагыннан өзеп кергән салкын виноград, хөрмә, гранат, Гомәр белән Хәрзан кибеттән сатып алган осетр балыгы, лангуст муены һәм Лена белән Зина пешергән кәрчә-мәрчәләр иде. Гомәр белән Хәрзан егетлек күрсәтеп алган Массандра мускаты белән иң югары сыйфатлы бодайдан гына әзерләнгән ак аракы да өстәлне бизәп тора.

Танышу хөрмәтенә берәр аяк шәраб тотып алгач, Гомәр мәҗлескә тәкъдим кертте. Аның тәкъдиме буенча, өстәл артында утыручыларның дүртесе дүрт милләт вәкиле буларак, аларның һәрберсе тост урынына үз халкының бер җырын җырлап күрсәтергә тиеш иде.

Теле һәм көе барысына да аңлаешлы буларак, беренче булып рус халкы вәкиле Зина җырларга тиеш булды. Зина Есенин сүзләренә язылган җыр башкарды.

Отговорила роща золотая,
Березовым веселым языком.

Моңлы да, кешелекле дә булган бу җырны барысы да беләләр иде, дәррәү күтәреп алдылар. Юк, авыз күтәреп җырламадылар алар бу җырны, ә һәрбер сүзен, һәрбер моңын күңелләреннән сытып чыгардылар, акрын гына, түмен тоеп кына җырладылар. Бу дүрт миллэт вәкиле булган дүрт кешенең җырны шул кадәр ыспай, бердәм һәм бер-берсенең һәр авазын нык тойган хәлдә җырлаулары соклангыч иде. «Есенин көчле,— дип уйлады Гомәр,— юньләп таныш та булмаган кешеләрне ничек оста итеп берләштерә».

Мәҗлестәшләр җырның болай оста килеп чыгуына бик канәгать иделәр, азактан гөрләтеп кул чаптылар һәм шатлыкларын Массандра мускаты белән ныгытып куйдылар.

Икенче чират рус теленә бик якын булган украин халык вәкиле Ленага бирелде. Лена украиннарның шаян җырын башкарды. Бу җыр кыюсыз егет исеменнән әйтелә иде, шуңа күрә Лена, мөлаем һәм уйнак кашларын сикертә-сикертә Гомәргә карап, Гомәр исеменнән җырлагандай җырлады.

Ти, мене підманула,
Ти, мене підвела,
Ти ж мене, молодого
З ума-розума звела.

Җыр үзе дә шаян һәм мут иде, җырны болай башкару тагын да кызык килеп чыкты. Барысы да көлештеләр.

Инде чират Гомәргә житте. Гомәр моңлы җыр җырларга теләмәде. Татар җырлары болай да артык моңлы, мәҗлестәшләренә үз халкын ул яктан күрсәтәсе килмәде. Шуңа күрә ул бик үк моңлы да, кеше көлдерерлек шаян да булмаган дәртле көй җырлыйсы итте һәм «Каз канаты»н сайлап алды.

Каз канаты каурый-каурый,
Хатлар язарга ярый.
Уйнамагач та көлмәгәч,
Бу дөнья нигә ярый.

Гомәр бу җырны баштан сузынкырак итеп башласа да, ахырга табан кызулана барып, кызулана барып, көй һәм ритм тизлеге иң югары ноктасына менеп житкәч, җырны кырт кисеп тәмамлады. Көй ритмына кулларын, иреннәрен, иңбашларын биетеп утырган мәҗлестәшләр җырның тәмамлану ноктасын төгәл тойдылар һәм дәррәү кул чаптылар.

— Гомәр, җырыңның бер куплетын гына булса да тәрҗемә итеп бир әле, — дип сорады Зина.

Гомәр шәрабтан да, җырның оста чыгуыннан да дәртләнгән иде, кинәт мутланасы, шаярасы килеп китте.

— Если не веселиться и не смеяться, на чурт нужен этот Крым, диелә бу җырда,— дип тел чарлады ул. Кызлар кәефләнеп көлештеләр, бу сүзләр безнең мәҗлескә бик тәңгәл килә диештеләр.

Чират Хәрзанга килеп житте. Ул рус һәм татар җырларын яхшы белүе, ә үз телен инде тәмам онытa баруы турында әйтә башласа да, мәҗлестәшләр, аның ай-ваена карамыйча, үз халкының җырын таләп иттеләр.

— Ярый,— диде аннары Хәрзан,— миңа бала чакта еш кына туй җырлары ишетергә туры килә иде. Чөнки бездә туйны атна-ун көн

уткәрәләр һәм туй урам уртасында җырлы-биюле уеннар белән бергә алып барыла.

Кинәт бу кечкенә таш өй эченә мәҗлестәшләргә бөтенләй таныш булмаган бер моң тула башлады. Әйе, бу моң бу таш стеналарга да, Гомәргә дә, Ленага да һәм Зинага да бөтенләй ят иде. Шул ук вакытта ул күңелгә гаять якын да кебек. Гомәр җырның сүзләрен аңламады, алар һаман саен кабатланып торалар шикелле тоелды аңа. Көйдә шулай ук ниндидер сер, олы һәм кешелекле сер, халык сере бар иде. «Һәр милләт халкының үзенә генә аңлашыла торган интим хисләре бар,— дип уйлады Гомәр, җырны тыңлый-тыңлый.— Халыклар алар шәхесләр кебек. Һәр шәхеснең үзенә генә хас эч серләре, интим хисләре, башка кешеләр аңламый һәм аңлый да алмый торган рәхәт һәм сагышлы тоемнары була. Халыкларның да шулай. Дөрес, теләсә генә нинди халыкның, хәтта ул сан ягыннан бик аз булса да, бөек әсәрләре башка телләргә дә тәрҗемә ителергә тиеш. Ләкин әле һәр халыкның башка бер генә телгә дә тәрҗемә итеп булмый торган, илаһи, бөек, серле, шул ук вакытта гаять тә кешелекле хисләре, үзе генә белгән рәхәтлекләре була. Менә без хәзер Хәрзанны тыңлыйбыз һәм аның гаять тә тәэсирле көен аңлыйбыз да кебек. Ләкин без аны барыбер Хәрзанның үзе кебек үк аңлап бетерә алмыйбыз. Чөнки без аның моңын үз халкыбызда, яки бүтән халыкларда булган һәм үзебез аңлаган моңнар белән чагыштырып карыйбыз. Без чагыштырган моңнар матур, бөек, гүзәл. Ләкин әле Хәрзан көендә туган халкының башка халыкларда бөтенләй булмаган моңнары да бар. Аларын без бер халык моңы белән дә янәшә куеп карый алмыйбыз. Ә инде чагыштырып булмаган әйберне аңлап та булмый. Нәрсә беләндер янәшә куеп булмый торган әйберләр беркайчан да аңлашылмый».

Хәрзан җырлап бетерде. Мәҗлестәшләргә ят, яңа, өр-яңа һәм серле бу моң барысына да шундый нык тәэсир иткән иде, кул чабарга да оныттылар. Аннары кинәт кенә исләренә килеп Хәрзанны котлап кул чаптылар, ә Зина Хәрзан өчен шундый шат иде, үрелеп аның маңгаеннан үбеп алмыйча түзә алмады. Аннары Зина ниндидер кызык сөйли башлады. Бу арада инде Лена да шактый кәефләнеп өлгергән иде, урындыгын Гомәр ягынарак шудырып, бөтенләй аңа сыенып ук утырды. Тегесе дә аны-моны уйламыйча гына кулын Ленаның иңбашына салды. Шулай итеп, Лена Гомәрнең кочагына ук кереп поскан иде.

Ләкин Гомәр Хәрзан җырыннан, бу җыр кузгаткан уйлардан айный алмыйча утырды. Кинәт аңа бу җыр алдында оят булып китте. Ят бер өйдә, ят бер мәҗлестә, шушылай ят бер хатынны кочагына алып утыру аңа бу илаһи җыр алдында да, Зина һәм Хәрзан алдында да, үз намусы, инде күптән үлгән әнисе, быел апрельдә генә вафат булган әнисе, каядыр еракта, Татарстанда яшәп ятучы апасы, абыйсы, сеңелесе алдында да, ниһаять... ниһаять, Фәлинә алдында да оят иде.

Гомәр кинәт кенә урыныннан торды да ашыга-ашыга киенә башлады.

— Ни булды, кая барасың?— дип сүз башлады аңа Зина. Мәҗлестәгеләр барысы да аптыраушта иделәр.

— Миңа палатага кайтырга кирәк,— диде Гомәр, фуражкасын кия-кия,— мәҗлес өчен рәхмәт, сау булыгыз.

Ул ишектән чыгып киткәндә Ленаның:

— Һәй, тере мәет...— дип мыскыллавын ишетеп калды. Бу сүз аны чиркандырып, җирәндереп җибәрде.

Гомәр әле моңа кадәр дөньяда җирәнгеч әйбер, гомумән, юк дип йөри иде. Әйе, әйе, хәтта кан, үлек, шеш, кутыр, бәвел кебек әйберләр дә җирәнгеч түгел. Әнә бит аларны больницаларда медсестралар алып лабораторияләрдә тикшерәләр, үзләренең үтә чиста өстәлләренә куеп, әллә ниткән микроскоплар, электрон аппаратлар белән карыйлар. Шулай

булгач, алар нишләп җирәнгеч булсыннар?! Киресенчә, алар адәм баласының саулыгын, сәламәтлеген тикшерергә, дөрес диагноз куярга ярдәм итәләр әле. Шулай ук бакалар, еланнар, саранчалар, мәет белән тукланучы балыклар, кыслалар да җирәнгеч түгел. Аларның күбесе әле дөньядагы кайбер халыкларның менә дигән бәйрәм ашлары.

Әйе, дөньяга табигать бар иткән бер генә әйбер дә җирәнгеч була алмый. Алар бары тик безнең гореф-гадәтләребез, традицияләребез, тәрбиябез яктылыгында гына җирәнгеч булып тоелалар.

Шулай да... Җирәнгеч әйбер бар икән дөньяда. Ул — әшәке сүз. Адәм баласының адәм баласына карата мыскыллап әйткән әшәке сүзе. Әйе, Ленаның соңгы сүзеннән Гомәрнең косасы килеп китте.

Кәефе бик каты кырылса да, Гомәр бу халәтнең Юра әйткән хандра түгел икәнлеген тоеп алды. Юк, чыннан да, хандра түгел иде бу, ә нәрсәдер белән көрәшергә омтылу, нәрсәгәдер һөҗүм итү һәм ниндидер яктылыкка табан тартылу иде. Ул эченнән генә ни өчендер Ленаны да, хатынын да, санаторийны ташлап киткән теге бәләкәй башны да, күктәге айны да, юл читендә үскән инжирны да эт итеп әрләп ташлады. Ләкин Фәлинәгә ачуланмады. Гомәрнең тизрәк палатага кайтып Фәлинә турында уйлыйсы килә иде.

Палатада бер үзе генә яшәүгә дә карамастан, ул ни өчендер ут кабызмады. Кармалана-кармалана чишенеп, өс киемнәрен шифонерга, күлмәк-чалбарларын урындык артына элде, азаплана-азаплана урынын җәйде, идәнгә төшеп киткән мендәрне эзли торгач, аңа аягы белән бәсты, мендәрне каккалап баш очына салды да, караватына сузылып ятты. Аның күңеле инде шактый тынычланган, мәҗлестә булып үткән тәмсезлекләр каядыр таралып киткән, күңел түрендә япа-ялгыз булып Фәлинә генә торып калган иде.

## 5

...Теге тәбәнәк кара мунчалар янында Фәлинәне унынчы класстагы иптәш егетенә тотып биргәннән соң ниләр булды соң әле? Әйе, Фәлинә анда Гомәргә җаным диде һәм ай яктысында аның ялварулы йөзе күренеп калды.

Шуннан соң...

Менә бит ул ничек килеп чыга! Икенче көнне инде мәктәптә укучылар арасында: «Кичә төнлә Гомәр Фәлинәне Саз сукмагы буендагы кара мунчалар янында тотып торган икән», «Хи-хи-хи, Гомәр Фәлинәгә гашыйк икән»,— дигән чыш-пышлар таралды. Усалрак малайлар хәтта мунча, Фәлинә, Гомәр дигән сүзләрне укмаштырып шактый оятсыз рәвештә авыз да ердылар.

Гомәргә котчыккыч оят булды. Юк, ул әле соңгы сүзнең мәгънәсенә үк барып житмәде, аңа Фәлинәгә гашыйк булган дигән сүзне ишетү оят иде. Мондый яшьтә, гомумән, малайлар кызларга гашыйк булуны бик оят, гарьлек санийлар. Бу яшьтәге малайлар кызларны санламауны, аларны мыскыл итүне генә егетлеккә саный. Малай-шалай хәтта, чынлап та, берәр кызны ярата башласа да, бу хистән ояла, аны кешегә сиздермәс өчен җан талаша.

Ә монда Гомәргә гыйшык-мыйшык дигән нәрсә аның исендә-осында да булмаган көенчә әнә нинди гаеп тагалар. Оялды, гарьләнде Гомәр бу сүздән, хәтта Фәлинәгә җен ачуы чыкты. Җыен юк-бар сүз таралуга гаепле кешене ул дип санады Гомәр.

Анысы бер нәрсә, оялу булыр да бетәр, ә менә бу мәгънәсез сүзләр укытучыларга, мәктәп директорына барып җитсә нишләрсең. Ул чакта инде бу гайбәт классларның караңгы почмакларына посып чыш-пыш

килеп кенә йөрмәс, ә мәктәпнең гомуми җыелышында әйтелеп, Гомәрне бөтен кеше алдында хур итәр.

Гомәрнең яхшы якка караган бер уе да рас килми, ә менә начар якка караган һәр нәрсәсе тач рас килеп тора.

Башта класс җитәкчесе сигезенче класс җыелышында әйтеп хур итте Гомәрне. Класс җитәкчесе, усаллыгы йөзенә чыккан, әче теле белән бәгырьңне телем-телем кисеп ала торган, педагогик такт дигән нәрсәне гомерендә ишетмәгән авыл хатыны иде. Ул ишектән килеп керә-керешкә:

— Гомәр, бас! Нәрсә, маеңа чыдый алмый башладыңмы әллә, хатын-кыз белән мунча тирәләрен каезлыйсың киләме? Ничек оялмыйсың син бу мәктәп стеналарыннан? Мужыт синең өйләнәсең дә киләдер әле, алай маеңа бик чыдый алмый башлагач. Без сине укуга дәрте үссен дип тырышабыз, ә синең дәртең инде хатын-кыз тирәсендә чуаламы?— дип әрли дә башлады. Кызлар чырык-чырык көлештеләр, малайлар, эшнең зурга киткәнен сизеп, лышт-лышт борыннарын тарттылар.

Гомәр басмады. Партага йөзе белән капланды да, кызарыныи оялганын, хурланганын, гарьләнгәнен класска күрсәтмәс өчен, башын куллары белән каплады. Ә Фәлинә алгы партада алманың кояшка карап пешкән ярты ягы кебек кып-кызыл булып утыра бирде.

Укытучы Гомәрнең торып басмавын күреп, тагын да кыза гына төште:

— Әһә, ояласыңмыни?! Анда, Саз сукмагы буендагы кара мунчалар янында селәгәеңне агызып Фәлинәне кочаклап торганда оял идең, монда, мәктәптә, фән сараенда түгел.

Кинәт Гомәрнең башыннан бер уй узып китте. «Әллә соң акланыргамы? Дөресен генә сөйләп бирергә дә, бетте-китте. Шулай итсә ул, мөгаен, акланачак, укытучы Фәлинәгә генә бәйләнәчәк».

Ләкин класс җитәкчесе бик тә ямьсез итеп бәйләнә башлау белән, кинәт Гомәрнең Фәлинәгә карата булган ачуы сүрелеп китте. Аның эчендә инде Фәлинәгә карата түгел, ә класс җитәкчесенә, чышын-пышын килеп теләсә нәрсә сөйләп йөргән классташларына, бу мәктәпкә, андагы тәртипләргә, гомумән, укуга карата ачу кузгалган иде. Шуңа күрә ул аклануны кирәк тапмады. Аклану, бер яктан, көчсезлек, икенче яктан, чынында, бер гаебе дә булмаган Фәлинәне батыру булачак иде.

— Без бу эшне болай гына калдыра алмыйбыз,— дип зәһәр чәчте класс җитәкчесе,— Фәлинә, иртәгә үк эш ничек-ничек булганын тәфсилләп язган объяснительная записка китерәсең, бу эшне без педсоветта тикшерәчәкбез. Мәктәп тарихында булган эш түгел бу.

Фәлинә оялган, каушаган иде: «Минем бер гаебем дә юк»,— дип кенә әйтә алды.

Мәктәптән кайтканда Гомәр теге күрше авылдан килгән ике черелдек кызның ипи шүрлекләренә менеп төште. Чыш-пышның шулардан чыкканы көн кебек ачык иде. Аннары, ипи шүрлегегезгә менгәнне мәктәптә әйтсәгез, икегезнең дә кирәгегезне бирәм дип ныгытты. Класс җитәкчесе кубарып җибәргән бик зур эштә үзләре гаепле икәнне төшенеп, болай да җаннары үкчәләренә барып җиткән кызлар Гомәрнең куркытыр өчен генә әйткән сүзен чынга алдылар һәм яңакларын уа-уа: «Әйтмибез, телебезне киссәләр дә әйтмибез»,— дип ант эчтеләр.

Фәлинә аңлатма язуы язмады. Аны директорга чакырып әрләделәр, һаман объяснительная записка сорадылар, ләкин Фәлинә һаман да шул: «Минем бер гаебем дә юк»,— дигәнне генә кабатлады.

Фәлинә...

Менә ничек башланып китте бит безнең бер-беребезне яклавыбыз. Ләкин әле без ул чакта яратышуның нәрсә икәнен белми идек һәм безнең бу яклашуыбыз да аң белән эшләнгән эш булмады. Шулай да,

Гомәр үз күңелендәге беренче очкынны шушы шактый ямьсез хәлләрдән башланган дип уйлый. Чөнки бу хәлләр мәктәптә педсоветка кадәр үк барып җитмичә, тора-бара онытылып беткәч тә, Гомәр күңелендә Фәлинәгә карата мамык йомшаклыгы калдырды. Гомәр яшерен, бик яшерен, хәтта үзеннән дә яшерен рәвештә генә күзләре, карашлары, җаны белән Фәлинәне эзәрлекли башлады. Юк, бу яшеренү мәктәптәге катгый кагыйдәләрдән курку аркасында түгел, ә оялу, күңелдә уянып килүче билгесез бер тартылу өчен үзеннән-үзең оялу аркасында иде.

Бервакыт Гомәрнең җанын бөтенләй айкап ташлаган бер хәл булып алды. Икенче чирекне тәмамлар алдыннан, декабрьның бер көнендә, булды ул. Тышта коточкыч буран, класста җылы иде. Китап җене кагылган бер адәм буларак, Гомәрнең озын тәнәфесләрдә әдәби китап укып утыра торган гадәте бар. Бу көнне дә озын тәнәфестә иң арттагы партасында китап укып утыра иде ул. Башын күтәреп караса, укытучы өстәле янындагы тәрәзә төбенә сөялгән Фәлинә аңа томырылып карап тора. Бите алсуланып яна, карашын Гомәрдән ала алмый. Менә аларның карашлары кисеште һәм Гомәрнең күкрәгенә йөрәк турысыннан пычак белән сызып төшерделәрмени. Алар шулай озак, бик озак, хәтта бер минутлар тирәсе, бер-берсенә карашып тордылар. Гомәр күз карашы белән Фәлинәнең керфекләрен, кашларын, маңгаен, борын яфракларын, бит очларын иркәләде, сыйпады, чәчләреннән сыпырды. Фәлинә дә шулай итте. Гомәр үзенең бит очларын Фәлинәнең йомшак карашы сыйпаганны тойды, шул карашка рәхәтләнеп битен куйды.

Бу — аңлашу иде. Бу — мәхәббәттә аңлашуның иң югары формасы иде. Иң бөек, иң даһи, иң талантлы һәм иң табигый формасы.

Шул көннән соң мондый карашулар ешаеп китте. Бу карашуларның тагын бик тә шәп бер ягы бар — бер-береңә карашкан өчен гайбәт тә сөйләмиләр, укытучылар да ачуланмый, педсоветка да куймыйлар.

Ләкин мәхәббәт комсыз нәрсә бит ул. Гомәрнең Фәлинә белән икәүдән-икәү генә каласы, сер сөйләшәсе, күз карашы белән генә иркәли торган бит очына бармакларын да тидереп карыйсы килә иде. Ләкин ул боларны берничек тә класста-фәләндә, кеше алдында эшлисе килми шул. Дөрес, теге чакта, кара мунчалар янында ул Фәлинәне беләгеннән дә, бик тартыла башлагач, иңбашларыннан да тотып торды. Ләкин андагы тотып тору пүчтәк кенә булган икән шул, менә хәзер булсын иде ул.

Карашлар назы белән, шашкын теләкләр белән Яңа ел үтте, яз житте, май керде. Гомәр күңелендә көн дә үсә барган назлы дәртләргә язгы дәртләр килеп кушылды. Ниһаять, ул, бер карарга килеп, көн саен кичке караңгыда Фәлинә яши торган өй тирәсен сагаларга кереште. Хәер, озак сагаларга да туры килмәде. Майның караңгырак бер кичендә Фәлинә җил капкадан чыкты да, урамны кыйгачлап кына аркылы кисеп, туры юлдан мәктәпкә менә торган Саз сукмагына борылды. Гомәр күләгә булып кына Фәлинә артыннан Саз тыкрыгына чумды. Кара мунчаларны узгач, Гомәр Фәлинәгә якынайды. Артыннан кеше килгәнне сизгән Фәлинә сискәнеп китте.

— Фәлинә...

— Гомәр?!.

Гомәрне таныгач, Фәлинәнең куркуы басылды, шулай да ул нигәдер калтырый иде бугай.

— Фәлинә, риза бул,— диде Гомәр, кызның алдына төшеп.

— Кирәкми, Гомәр, безгә икәү генә очрашырга ярамый,— диде Фәлинә, Гомәрне берьюлы аңлап,— мәхәббәт өчен без әле яшь, без бит әле мәктәп балалары гына, укыйсыбыз бар. Мин куркам, Гомәр, кит юлымнан, кеше сүзеннән куркам мин. Укытучылар белсә, харап булабыз, кит, хур итмә мине дә, үзеңне дә. Әнә теге чакта да хур була яздык, бер дә юк өчен. Башкача беркайчан да, беркайчан да минем

арттан килмә, безгә иртә әле. Аннан соң мәктәптә минә алай карама, минә да бик кыен бит.

Фәлинә мәктәпкә табан менеп китте, Гомәр тораташ булып басып калды. Кая соң шунда бер җир тишеге?! Кереп китәргә иде дә, мәңге чыкмаска иде. Ну бу мәктәпне, ну бу туган-тумачаларны, ну бу кешеләрне... Нигә кирәге бар аларның Гомәргә?! Шушы дөньяда, шушы матур, язгы, гүзәл, зур дөньяда беркем дә булмыйча, Фәлинә белән икәү генә булсалар, ни булган инде?! Гел икәү генә! Урамнар да буп-буш, өйләр дә буп-буш, мәктәп тә, кәнсәләр дә, клуб та буп-буш — беркайда бер адәм әсәре дә юк. Абзарларда сыерлар мөгри дә, коймаларга менеп әтәчләр кычкыра да, челтер-челтер Саз чишмәләре ага да, йорт саен мич тулы кабарыпипи пешә дә, һәр өй стенасында келт-келт итеп сәгать йөри дә, Фәлинә белән Гомәр дөмә икәүдән-икәү генә житәкләшеп урамның кыл уртасыннан баралар, чөнки куркыр, өркер, гайбәт сатар өчен дөньяда бүтән бер генә адәм заты да юк.

Мәхәббәтне бик изге, әйбәт хис диләр диюен дә, анда шактый гына эгоизм да бар бугай. Югыйсә Гомәрнең башына мондый уйлар килер идемени?!

Бу көннән соң Гомәр тагын да басылды, тагын да йомыкыйланды. Хәзер инде ул концертларга да катнашмый, көне-төне китап кына укый. Авыл һәм мәктәп китапханәчеләре зарлана Гомәрдән: «Укымый бу, ашый китапны, кара чир булып төште бу малай китапка, китап тәнәтеп булмый, көн дә яңаны сорый»,— диләр.

Фәлинә элек тә басынкырак иде, хәзер тагын да йомыла төште. Шулай да ул укуына зыян китермәде, дүртле-бишлегә укуын дәвам итте. Ә менә Гомәрнең укуы элек тә бик шәптән түгел иде, хәзер ана ул бөтенләй суынды. Күңеле укуда түгел малайның, игътибарын сала алмый. Укытучылар да, әти-әнисе дә чара күрә-күрә, әйтә-әйтә арыдылар, әйтми башладылар. Бу балага керми икән инде дип кул селтәделәр.

Фәлинәнең әти-әнисе һаман авылга кайта алмадылар. Әтисе бик каты авырып киткән, күтәрәмгә калгач кына авылга кайтып егыласым килми, ди икән. Сәламәтләнеп китсә, киләсе елга кайтырга ди исәпләре. Ә уку елы тәмамлангач, җәйгә Фәлинә алар янына китәргә тиеш икән.

«Тужы шәп хәбәр түгел»,— дип уйлады Гомәр монысын. Хәбәр килеп озак та үтмәде, уку елы тәмамланып та китте. Иртәгә Фәлинә Башкортстанга китеп барачак. Гомәр бүген кичтән Фәлинә белән бер сәгатькә, юк, ярты сәгатькә генә, юк, алай ук та түгел, ун-унбиш минутка гына булса да икәүдән-икәү генә очрашырга дип үз-үзенә ныгытып куйды. Теге ике кыз авылларына китеп бардылар. Фәлинә урамгафәләнгә чыкса, ялгызы булачак иде.

Бәхеткә каршы, кичтән Фәлинә клубка менде. Гомәр дә кинога кереп, клубның урамга чыга торган ишеге төбендә генә басып торды да, экранда «конец фильма» дигән титр күренгәнче үк клубтан чыгып сызды. Кешеләр клубтан чыга башлаганда инде ул Саз сукмагы буйлап түбән очка йөгерә иде. Фәлинә яши торган өйдә ут юк, апакай иртә ятып йоклый. Гомәр шыпырт кына җил капка өстеннән ишегалдына төште, өйалды ишеге артына ук стенага сөяп куелган утын өемнәре артына посып Фәлинәнең кайтканын көтә башлады. Күктә ай чекрәеп яна, бөтен дөнья энә күзе күренерлек ап-якты иде. Утын өемнәре артында патша заманнарыннан ук калган иске таш келәт бар, келәт артында бәрәңге бакчасы башланып китә. Келәт белән бакча киртәсе арасында бәләкәй генә бер өй урыны кадәр чирәмлек бар. Бу — апакай ишегалдының яшел чирәмлеге. Әнә шул чирәмлекнең келәт артындагы почмагына кереп бассаң, иң аулак урын, беркем дә күрәчәк түгел иде. Гомәр Фәлинәне шул төшкә алып барырга дип уйлап куйды.

Клубтан чыккан халыкның шау-шу килеп монда табан төшеп килүләре ишетелде. Кызлар чыр-чыр чырыйлап куялар, егетләр иләмсез итеп акырып көлеп җибәрә, җыр башлагандай да итенәләр, аргы урамда кемдер гармун тарта. Ул да булмады, кемнендер тып-тып басып җил капкага табан килгәне ишетелде. Фәлинә... Гомәр аның аяк тавышын Чыңгыз чирүенең тояк тавышлары арасыннан танып алыр иде. Аһ, хәерсез, тегеннән кешеләр дә төшеп җитә бит инде. Алар күреп калса, Фәлинә Гомәрне мәңге дә гафу итмәс.

Фәлинә җил капканы баганага «тышаулап» куйган бауны ычкындырды, капка нәзек кенә шыгырдап ачылды, калынрак итеп шыгырдап ябылды. Шул арада Гомәр утыннар арасыннан шуып чыкты да Фәлинә килеп урелгән өйалды ишеген кулы белән каплады.

— Фәлинә, курыкма, бу мин, кинодан кайтучы кешеләр узып киткәнче менә монда качып тор,— дип, утыннар арасына күрсәтте. Кинодан кайтучылар инде өй турына килеп үк җитәләр иде. Фәлинәгә утыннар арасына кереп посудан башка чара калмады. Икесе дә тын да чыгармыйча басып тордылар. Гомәрнең беләгенә Фәлинәнең күлмәк җиңе тиеп-тиеп китте — ул җиңелчә калтырана иде.

— «Яшьлегем минем,— дип уйлый торган булды Гомәр соңыннан бу минутлар турында,— куркагым син минем, калтыравык йөрәгем, бичара көчегем».

Кешеләр үтеп киткәч, Гомәр Фәлинәне келәт артындагы чирәмлеккә алып барды. Фәлинә карышмады. Утыннар ышыгында куркыныч иде, ә келәт артында аулак икәнне Фәлинә үзе дә белә. Күктә ай чекрәеп яна, аның яктысында үләннәр көмеш сыман яшел булып күренәләр, өйалды стенасына сөяп куйган утын агачларының озын-озын очлары гайре табигый бер кыяфәттә күккә табан сузаеп торалар, бәрәңге бакчасы коймасыннан төшкән күләгәләр теш-теш булып ишегалды буйлап сузылып ятканнар.

Гомәр белән Фәлинә көмеш сыман чирәмнәр өстендә кара-каршы басып торалар. Фәлинә Гомәрнең күзләренә карады. Аннары карашын аның кашларына, борынына, бит очларына, иреннәренә күчерде. Менә Фәлинәнең сулыш алуы ешайды, күрәге бер күтәрелеп, бер төшеп тора. Кинәт Фәлинә:

— Гомәр, инде башкача яшәрә алмыйм,— дип, ике беләге белән Гомәрнең иңбашларына ташланды. Гомәр аны биленнән кысып алды. Күктә айлар, кояшлар, йолдызлар, планеталар тулганды, стенага сөяп куйган утын агачларының күккә сузайган очлары бер озынаеп, бер кыскарып биештеләр, патша заманыннан калган иске таш келәт ай яктысында алтын сарай булып ялтырады. Бу мәлдә Гомәр дөньяның бик тә, бик тә рәхәт икәненә мең мәртәбә, миллион мәртәбә, аннан да күбрәк мәртәбә ышанды. Фәлинә дигән бу җан, бу тән Гомәрнең мәңгелеге иде.

«Яшьлегем минем,— дип уйлый торган булды Гомәр соңыннан бу минутлар турында,— куркусызым син минем, батыр йөрәгем, арысланым».

Тыннары беткәнче, сулулары капканчы, тәннәре ут булып кызганчы кочаклаштылар алар бу кичтә. Хәтта үбешмәделәр дә. Чөнки әле алар ул чакта үбешә белмиләр иде.

Икенче көнне Фәлинә Башкорстанга китеп барды. Гомәр колхозга эшкә чыкты. Ул инде бишенче класстан бирле җәйләрен колхозда эшли иде.

Фәлинә җәен хат язышырга катгый рәвештә каршы килде. Хатлар кеше кулына эләксә, харап булырбыз, мәктәпкә, әти-әниләргә ишетелер дип курыкты. Инде монысына гына риза булды Гомәр. Менә генә җәй үтәр дә, сентябрь килеп җитәр, тугызынчыда тагын күрешербез дип уйлады. Аннары алар шунысын да сөйләштеләр, киләсе елга ике-

се дә әйбәт укырга, уку мәсьәләсендә беркемнән дә тел-теш тидертмәскә. Фәлинә Гомәрнең начар укуын өнәп бетерми икән. Гомәр әйбәт укырга сүз бирде, тырышсам, әйбәт уку миңа ике тиен бер акча диде. Һәм дөрес әйтте. Тугызынчыда уку башланып ике ай үтте, билгеләрен дүрттән-биштән төшергәне юк. Укытучылар Гомәрнең башлы малай икәнен элек тә беләләр иде, хәзер бөтенләй шаккаттылар. Башлылыгыннан бигрәк шушы кадәр дә акылга утыруның сәбәбен төшенә алмыйча иза чиктеләр алар.

Фәлинәнең әтисе һаман савыгып бетмәгән, өйне һаман сатмый торырга булганнар. Һаман саен мәктәп алыштырасылары килмичә, кызларын унны авылда бетертмәкчеләр икән.

Гомәр белән Фәлинә быел бик яшерен рәвештә генә очрашкалап тордылар. Менә ике айга җиде мәртәбә очраштылар инде алар. Гомәр санап бара. Санап кына түгел, лапас түбәсенең кул сыешлы гына ярыгына кыстырып куйган калын дәфтәренә һәр очрашуны язып та бара. Аннары язылганнарны кайтып-кайтып укый — рәхәт була. Дөрес, ул һәр очрашуның һәр детален күңеленнән дә хәтерли, ләкин күңелдән хәтерләү белән язганны уку бер түгел. Язганны уку ничектер рәхәтрәк Гомәргә, аның үз тәме бар. Хәрзанга биргән дәфтәрләрнең беренче номерлысы әнә шул лапас башында гомер кичереп яткан дәфтәр.

Әйе, алар бик яшерен рәвештә генә күрештеләр. Ләкин без капчыкта ятамыни соң?! Бигрәк тә кем галошының кем сыеры тизәгенә басканына хәтле бөтен кеше белеп торган авыл җирендә. Батыраеп китеп үзләре дә саксызрак кылана башлаганнар иде бугай шул. Дөресрәге, Фәлинә һаман сак иде, ә менә Гомәр соңгы вакытта очрак чыккан саен Фәлинәне кочып, татлы иреннәреннән үбеп алырга гына тырыша. Әгәр аңа китсә, Гомәр үзенең Фәлинәне яратуын кеше белер дип тамчы да курыкмый. Ә былтыргы малайларча оялулар инде күптән бетте, Гомәрнең күңелендә Фәлинәне яратудан оялу түгел, ә горурлык кына утырып калды. Мәктәп директорыннан да, укытучылардан да, газраилнең үзеннән дә курыкмый Гомәр. Ул бары тик Фәлинә хакына гына, укытучылар белеп араны өзмәсеннәр дип кенә яшеренеп очрашырга мәҗбүр.

Фәлинә алай түгел. Ул курка, курка, курка... Бетмәс-төкәнмәс курку, хәвеф, тәшвиш аның йөрәгендә. Әти-әнисе белүдән йөз курыкса, укытучылар белүдән мең курка. Нигә шушы кадәр куркуын ул тәгаен генә үзе дә белеп, аңлап, төшенеп бетерми. Кыз кеше шул ул, егет-җилән түгел, хурлыкка калу, начар исем чыгу аңа мең оят. Ә менә бер-берәңне саф, чиста яратуның начар исем чыгарга сәбәп түгел икәнен ул аңлап бетерми. Чөнки мәктәп алай дими, укытучылар алай дими. Алар сүзе әти-әнигә дә, авыл кешеләренә дә абруйлы сүз. Шуңа күрә сүз чыгудан курка Фәлинә, Гомәр белән аларның кочакланып, я хода, үбешеп ук торуларын берәр кеше күрсә, дөнья убырылып төшәр кебек, мәхәббәт тә, уку да, әти-әни алдындагы газиз бала булуын да, киләчәгең дә бетәр, юкка чыгар, боларның барысына да юл ябылыр кебек.

Ә күрделәр шул. Икәү генә сөйләшеп утырганны да түгел, кочаклашканны да түгел, үбешкәнне ук күрделәр.

Әйе, Гомәр саксызрак кыланды шул ул көнне. Мәктәптә Октябрь бәйрәменә багышланган кичә иде. Башта залда тарих укытучысының доклады булды, аннары укучылар хәзерләгән бәләкәй генә концерт, соңыннан танцылар башланды. Гомәр дә, Фәлинә дә бик дулкынланганнар иде. Чөнки Гомәр концертта үзенең «Ашкыну» дип аталган язмасын укыды. Юк, ул шигырь түгел иде. Шулай ук хикәя дә түгел иде ул. Горькийның «Давыл хәбәрче»сенә охшашрак бер әйбер килеп чыкты. Бу язманың рухында тыелгысыз дәрт, яңага омтылыш, көч-кыюлык, куркусызлык ярылып ята иде. Гомәрнең очкынланып, ялкынланып, кемнедер көрәшкә чакырып укуыннан укытучылар бераз сагаеп та калдылар бугай әле. Бу чыгышы белән Гомәр алардан нәрсәдер даулый кебек

тоелды, гомумән, укытучылар һәм мәктәп тормышы ничәмә еллар буе гадәтләнеп килгән гади һәм сөрсегән күңелләргә сары май булып ята торган гадәти декламация түгел иде бу.

Залга коточкыч тәэсир итте Гомәрнең чыгышы. Укучыларның дәррәү кул чабуыннан зал күтәрелеп бәрелгәндәй булды. Шулай да Гомәр чыгышының төп асылын Фәлинә генә аңлады. Саф мәхәббәтнең җирдәге бөтен нәрсәләрдән дә көчле икәнен раслый, мәхәббәт иреге, гүзәл хискә азатлык даулый иде Гомәр бу чыгышы белән.

Танцылар башлангач, дулкынлануыннан кая керергә белми йөргән Гомәр, халык арасыннан кысылып ишеккә табан узганда, тирә-яктагыларга сиздермичә генә Фәлинәнең учына кечкенә бер кәгазь кисәге салып китте. Фәлинә учын каплап кына язуны укыды. «Коридорның теге башына кил, көтәм»,— дип язылган иде анда. Фәлинә ике-өч минут кына утырды да, шым гына залдан чыгып сызды. Һай, класс җитәкчесенең аларның һәр хәрәкәтен күзәтеп, барысын да күреп торганын белерлек хәлдә иделәрмени соң алар?! Гомәрнең чыгышы икесен дә әсәрләндергән, сукырайткан иде шул. Ә шул ук чыгыш класс җитәкчесен сагайтты, нәрсәгәдер кисәтте.

Коридорның теге башында, малай-шалай шукланып йөрмәсен дип, утларны сүндергәннәр иде. Коридорның шул башыннан мәктәпнең икенче катына баскыч менеп китә, ә баскыч асты аеруча караңгы, аулак. Фәлинәне шунда көтеп торган Гомәр аны кулыннан тотып баскыч астына табан алып китте.

— Кирәкмәс, Гомәр, берәрсе күреп калса харап булабыз бит, кайтканда, аулаграк җирдә очрашырбыз,— диде Фәлинә карышып.

— Юк, Фәлинә, син миңа хәзер кирәк, менә шушы минутта,— диде Гомәр өзгәләнеп. Шуннан ул Фәлинәне дәррәү кысып кочаклап алды... Кайнар иреннәр бер-берсен иркәләделәр... Тәннәр буйлап яшь дулкын йөгерде... Ике яшь күңел бу дөньяның бар икәнен онытып планетада икәүдән-икәү генә калдылар... Иксез-чиксез галәмнең Җир дигән бәләкәй генә бер почмагында Җан белән Җан тоташты.

Шул вакытта каяндыр, ерактагы әшәке бер планетадан аларның битләренә күзләрне чагылдырырлык прожектор утлары кабызып җибәрделәр. Гомәр белән Фәлинә иреннәрне иреннәрдән, кулларны иңнәрдән алырга да өлгермәде, класс җитәкчесенең:

— Оятсызлар, үзегез укый торган мәктәп стеналары эчендә шушы эш белән шөгыльләнә башладыгызмыни инде? Ягез әле, туры карагыз күземә, оятыгыз качкан нәрсәләр!

Класс җитәкчесе кесә фонаре яктысын егет белән кызның күзенә туп-туры төшерә, тегеләре бу үтергеч яктылыктан кая качарга белмичә куллары белән күзләрен каплыйлар. Әй,кыен да иде соң бу минутта аларның икесенә, бигрәк кыен иде...

Икенче көнне Гомәрне директор бүлмәсенә чакырдылар. Гомәр бөтен шартын китереп ишекне шакып керде, керү белән бүреген салып ишек төбенә генә, идәннең ишек стенасына килеп терәлгән очларына гына басып башын аска иде. Директор бүлмә түрендәге язу өстәле артындагы урындыгыннан тормыйча гына:

— Я, алдамыйча гына барысын да сөйләп бир, — диде.

Гомәрнең күңелендә кинәт бер яп-якты очкын кабынып китте. Бу очкын өмет, ышаныч, яхшылык, изгелек очкыны иде. Аның хәзер директорга бөтенесен, үзенең мәхәббәтен, Фәлинә белән алар арасында булган саф сөюнең мәктәп тормышы өчен дә, Фәлинә белән үзенең укуы, киләчәкләре өчен дә бернинди куркынычы булмавын, киресенчә, аның Гомәргә дә, Фәлинәгә дә бөтен яклап әйбәт кенә тәэсир итүен дә сөйләп бирәсе, ачыласы, чишеләсе, аңлатасы килде. Ул гына да түгел, аның директорга ышанасы, аны сердәш итәсе килде.

— Әгәр мин барысын да дөресен генә сөйләп бирсәм, сез аны кешегә әйтмәссезме соң? — дип сорады ул икеләнеп.

— Мин иләкнекен чиләккә, чиләкнекен иләккә бушатучылардан түгел,— диде директор коры гына.

Ышанасы килеп торган кешегә шушы сүз җитмимени?! Ышанасы килгәндә бөтенләй кире сүз дә уңай сүз булып ишетелә бит ул, шайтан алгыры. Гомәр директорның бу сүзен вәгъдә дип аңлады. Ә вәгъдә аның өчен иман иде.

Гомәр барысын да сөйләде. Директор дәшми генә тыңлады. Мәктәп тарихында укучы белән директорның мондый аңлашуы беренче мәртәбә иде. Директорның педагогик практикасында, ул тоткан мораль-этик принципларда, менә инде ничәмә ел ул алып барган эш җаенда бу яңа нәрсә иде. Директор үзе дә аптырап калды. Юк, ул Гомәрне ачулана алмый. Элеккеге стажы, элеккеге эш тәҗрибәсе буенча ул Гомәрне ачуланырга тиеш икәнен тоя, ләкин ниндидер эчке бер сизенү, ниндидер бер кешелекле җил аны ачуланудан кисәтә дә.

— Мин сездән бер генә нәрсә сорыйм, директор абый,— диде Гомәр ахырдан.— Миңа Фәлинә белән очрашуларны дәвам итәргә рөхсәт итегез. Ә без мәктәпнең җәмәгать эшләрендә актив катнашырга, тәртипле булырга, яхшы укырга сүз бирәбез.

Үз-үзен тотышындагы бу йомшаклыктан, Гомәр белән нәрсә эшләргә икәнен белмәүдән аптырап калган директор ни өчен икәнен үзе дә аңламыйча:

— Ярый, бар, бу сөйләшү турында беркемгә дә әйтмә,— диде.

— Фәлинәгә дәме? — дип сорады чыгып китәргә әзерләнгән Гомәр.

Директор нәрсә әйтергә дә белмичә тынып калды. Чөнки бу сорауга ничек итеп дөрес җавап бирергә икәнен ул үзе дә төшенеп бетми иде. Гомумән, бу минутта директор сөйләшүне Гомәр ни өчен кешегә әйтмәскә тиешлеген дә, Фәлинәгә әйтергәме, юкмы икәнен дә, укучы белән директор арасында менә мондый мөнәсәбәтләр килеп чыккан очракта ул үз-үзен ничегрәк тотарга тиеш икәнен дә белми иде. Чөнки әле аның бер генә бала белән дә болай сөйләшкәне юк. Шуңа күрә ул Гомәрнең соравына җавап бирмәде һәм кулы белән ишарәләп кенә аны бүлмәсеннән чыгарып җибәрде.

Фу, шайтан алгырысы! Юк кына малай директор булып директор алдына мең төрле сорау өеп чыгып китте. Директор бу турыдагы мәсьәләне педсоветта кузгатырга карар итте.

Бу — директорның ялгышуы иде. Моны Гомәр хәзер уйлый. Хәер, хәзер бәлки директор да ялгышканмын дип уйлый торгандыр. Ә ул чакта Гомәр, үзе дә белмичә, гадәти педагогик алымнар һәм мәктәпнең эчке кагыйдәләре белән ничә еллар буе кагылгысыз канун булып сакланып килгән бер нәрсәне — укучы белән директор арасында булырга тиешле аралыкны бетерде, юкка чыгарды. Әйе, ул чактагы тәртипләр буенча укучы белән директор арасында кагылгысыз бер ара булырга тиеш иде. Җитәкче буларак директорның бөтен абруе әнә шул арага тупланган. Бу ара ниндидер бер сакчы шикелле, ул директорның Директорлыгына, ә Гомәрнең укучы гына икәнлегенә беркемне дә кагылдырмыйча саклап тора. Әгәр дә инде укучы белән директор арасындагы әнә шул серле араны бетерсәң, сакчы этне үтерсәң, директорның абруе, димәк ки, аның директорлыгы да бетәргә тиеш булып чыга.

Ә Гомәр әнә шул араны бетерде. Ул, теге сакчыны алып ташлап, директорның шул әлеге серле арада гына тотылып торган абруен бер читкә этәрде дә, бу куркыныч абыйны үзенә сердәш, бернинди арасыз, канунсыз сөйләшә торган ходавәндә итте. Юк, ул директорның абруен читкә алып томырмады, ә аны үз урынына, ягъни директорның намусына, чын мәгънәсендәге педагогикасына, күңеленә, җанына саласы итте. Сүз дә юк, Гомәр моны бары тик интуитив рәвештә генә эшләде.

Шулай ук Гомәр укучы белән директор арасындагы әлеге араны бөтенләй юкка чыгарудан да ерак тора. Алар арасында, һичшиксез, ниндидер ара калырга тиеш. Чөнки директор зур кеше, ә укучы кечкенә; директор укымышлы, ә укучы әле белемнәргә тиенеп кенә килә; директор тәҗрибәле, укучы рухи камыр; директор өйрәтүче, укучы өйрәнүче; ахыр килеп директор аксакал яки олы кеше, ә укучы нибары бала. Боларны беркая да куеп булмый, һәм болар укучы белән директор арасында ниндидер чикләр, дөресрәге, укучының директорга карата хөрмәтле булуын таләп итәләр. Ләкин бит кешелеклелек һәм рухи мәсьәләләрдә без шул ук директорны укучыга караганда баерак кеше, я булмаса аның хатынына (яки башка берәр хатын-кызга) карата булган мәхәббәте Гомәрнең Фәлинәгә булган мәхәббәтенә караганда зуррак дип әйтә алмыйбыз. Моны әйтү өчен аларның икесен дә тикшереп, сынап карарга кирәк әле. Дөрес, мәхәббәт мәсьәләсендә дә директорның Гомәрдән өстен булуы бар, ләкин бит Гомәрнең директордан өстен булуы ихтималы да юк түгел. Гомәр әле бәлки директорга караганда ныграк, көчлерәк, матуррак, баерак ярата беләдер? Һәм, Гомәр уенча, бу мәсьәләдә укучы белән директор арасында директор файдасына булырлык бер ара да юк. Гомәр шулай уйлый. Дөрес, ул аны теге чакта, директор мине аңлады, хәзер эшләр хутка китәчәк дип шатланып, канатланып, аның бүлмәсеннән чыгып киткәндә алай уйлый алмады, ул чакта әле болай ук уйларга аның башы яшь иде. Ул аны хәзер, Кырымның Алып каласындагы санаториенда, япа-ялгызы бер палатада уйлый.

Ә теге чакта Гомәр директор бүлмәсеннән, чыннан да, канатланып чыкты. Аңа директор бик тә яхшы кеше булып тоелды. «Чыннан да,— дип уйлады Гомәр,— безнең укытучылар да, мәктәп тормышы да, уку да, кайбер усаллыклары булуга карамастан, класс җитәкчесе дә шундый әйбәтләр, мин юкка гына алардан йөз чөереп йөргәнмен, менә бит барысы да ничек әйбәт булып бетте». Әй, шатланды, әй, куанды Гомәр, шул көнне үк кичтән Фәлинәне очратып барысын да сөйләп бирде. Тик Фәлинә генә шатланмады. Киресенчә, аның сөмсере коелды. Һаман шул куркуында булды Фәлинә: «Куркам мин, Гомәр, син бик зур ялгышлык эшләгәнсең бугай»,— диде. Ул көнне аларның ничектер сүзләре ябышмады, Төбеташ суының алар гел очраша торган аулак борылмасындагы су никтер күңелсез чупылдап акты, яр буендагы кибеп бара торган көзге бака әрекмәннәре, үги ана яфраклары, каз үләннәре, песи яфраклары моңсу булып күренделәр. Ай да моңсу иде, айдагы Зөһрә кыз да. Гомәр Фәлинәне озата кайткач, фатир хуҗасы апакайның өйалды стенасына сөяп куйган былтыргы утын агачларының күккә сузаеп торган очларына карады. Алар да узган май аендагы кебек бер озынаеп, бер кыскарып биешмиләр, көзге ай яктысында патша заманнарыннан калган иске таш келәт тә алтын сарай булып ялтырамый иде.

Фәлинәнең хәвефләнүләре рас килде. Директор мәсьәләне педсоветка куйды. Дөрес, махсус педсовет җыймадылар. Аның өчен ваграк мәсьәлә иде бу. Чираттагы педсовет азагында гына әйтте директор бу турыда. «Гомәр белән менә шундый-шундый сөйләшү булды, Гомәр менә шуларны-шуларны әйтте һәм Фәлинә белән очрашуларны дәвам итәргә рөхсәт сорады, нишлибез?»— диде. Әй, кызды укытучылар, әй, кыздылар, җыелыш алдындагы олы-олы мәсьәләләр моңын алдында чүп кенә булып калды кебек. Гаҗәеп булды җыелышның бу өлеше. Педсоветтагы фикерләр икегә аерылды. Берәүләр: «Без укучыларны артык каты режимда тотабыз бугай, болай ук кирәкмәс иде, Гомәр бит хәзер бөтенләй төзәлеп китте, Фәлинәнең укуы начар якка үзгәрмәде»,— диделәр. Икенчеләр беренчеләргә каршы төште. Ләкин соңгы

фикерне класс житәкчесе әйтергә тиеш иде. Бу — аның классы, андагы укучыларны ул күбрәк белә. Класс житәкчесе чәчрәп үк чыкты.

— Нишлибез без, иптәшләр, кая барабыз? Сез бит аларның ничек үбешкәнен берегез дә күрмәде, мин күрдем. Алар шундый итеп үбештеләр, гөнаһ шомлыгы, боз булып боз да эрер иде. Ә мин нык тордым, эремәдем, мине укытучы, тәрбияче, педагог булуым тотып калды. Мәктәп стеналары эчендә эшләнгән шундый амораль поступок алдында җебеп төшү укытучы дигән изге исемгә зур тап төшерү булыр иде, иптәшләр. Менә минем тәкъдим шул, икесенә дә директор исеменнән выговор бирергә, мәктәпнең гомуми җыелышында иптәшләре алдында әйтеп кызартырга. Әгәр дә мәгәр инде минем тәкъдим кабул ителмичә, бу эшне шул көе калдырабыз икән, ике кулымны кисәргә бирәм, озакламый безнең укучы кызларыбыз мәктәпкә бала алып килә башлаячаклар.

Педсоветтагыларның кайсылары: «Әй, син инде бигрәк тә арттырып җибәрәсең»,— дип, кайсылары: «Дөрес, дөрес, бик дөрес әйттең»,— дип тавышланып алдылар.

Һәр вакыт урта бер фикергә өйрәнгән директор мәсьәләгә бер гөнаһсыз чишелеш табарга тырышты. Ә урта фикерне табуы беркайчан да кыен түгел — Гомәр белән Фәлинәгә директор исеменнән шелтә бирмәскә, гомуми җыелышта укучылар алдында әйтеп йөзләрен кызартырга килештеләр.

Монысы да җитеп ашкан иде. Гомәр кызармады. Директорга, мәктәпкә, укытучыларга булган ышанычының мондый юнәлеш алуыннан аның җаны катты, ләкин мәхәббәткә иманы какшамады. Аның өчен барыбер иде. Аның Фәлинәгә карата булган мәхәббәтен кешеләр белде ни, белмәде ни, укучылар, авылдашлар аның турында гайбәт сөйләделәр ни, сөйләмәделәр ни, моннан аның саф хисләренә берни булмаячак иде.

Ә Фәлинәгә кыен булды. Котчыккыч кыен булды аңа. Җыелышта елый-елый шешенеп бетте Фәлинә, үкси-үкси үпкәсе каплана язды. Класс җитәкчесе аны хатын-кыз сафлыгын, кызлар горурлыгын саклый белмәгән бер тыйнаксыз, бозыклыкка табан бер генә адым ясыйсы калган кеше дип әйтте бит.

Фәлинә бөтен гаепне Гомәрдән күрде. Үзен бары тик бәйрәм кичәсендә коридорның теге башына барган өчен генә әрләде. Гомуми җыелыш булган көнне Фәлинә Гомәр белән очрашырга да теләмәде. Гомәр аны апакайның капка төбендә көч белән генә тотып калды.

— Биш яшьлек малай кебек директор алдында отчет биреп тормасаң,— дип әрләде аны Фәлинә,— мин бүтән сиңа ышанмыйм, бүтән минем янга килмә, безнең юллар киселгән, син безнең арадагы иң кадерле серне дөньяга түктең,— диде.

Бу сүзләрдән соң инде Фәлинәне тотып торуның мәгънәсе калмаган иде. Гомәр төн йокысы йокламады, ашамады-эчмәде, юньләп укымады, мәктәпкә дә Фәлинәне күрер өчен генә бара иде. Ул тәмам үз эченә бикләнде, сөмсере коелды, җанында энә очына әләрлек тә җылылык юк иде сыман.

«Менә кайчан башланган икән ул Юра әйткән хандра,— дип уйлады Гомәр палатасында.— Менә бу инде хандра дисәң дә хандра. Хандраларның да иң югары сыйфатлысы».

Ләкин әле Гомәрнең хандралары алда иде. Дөрес, ул унны тәмамлап колхозда һәм авыл китапханәсендә эшли башлагач, тернәкләнеп китте, активлашты, колхозның үзешчән сәнгать түгәрәген дә дәртләнеп җитәкләде, комсомол секретаре һәм ДОСААФ председателе булып сайлануга кадәр иреште. Ләкин боларына инде Фәлинә түгел, ә Тәнзилә сәбәпче иде. Фәлинә ул тугызны бетерде дә, Башкортстанга бөтенләйгә үк китеп барды. Әтисе чирдән тәки мантый алмады һәм алар

бер корган куыштан кузгалмаска булдылар. Алар мәктәп белән язышып, Фәлинәнең ничек укуы белән кызыксынып торалар иде, класс җитәкчесеннән Фәлинәнең үз-үзен тотышы турында хәвефле-хәвефле хатлар алдылар һәм, кыз бөтенләй харап булганчы дип, унда укырга үз яннарына алдылар. Ләкин Фәлинәне Гомәрдән бөтенләй суынды дип әйтеп булмый иде. Теге җыелыштан соң инде икәүдән-икәү генә очрашулар-күрешүләр булмаса да, алар бер класста укыйлар бит, Гомәр Фәлинәне көн дә күрә. Гомәр бөтен нәрсәдән ваз кичсә дә, әдәби китаплар укудан һәм лапас башындагы теге калын дәфтәрләргә (алар инде хәзер өчәү иде) нәрсәдер язудан туктамады. Тәнәфес вакытларында һаман китап укый иде. Кайвакытларда ул китап укып утырган җиреннән үзенең битендә ниндидер бер иркәлек тоя. Тоя, ләкин башын күтәреп карамый. Чөнки ул моны Фәлинә карашы икәнен белә, әгәр башын күтәреп караса, Фәлинә капыл гына читкә борылачак. Ә Гомәрнең бу иркәлекне озаграк дәвам итәсе килә, укый торган китабындагы берәр сүзгә төртелеп кала да, әлеге иркәлеккә, назга рәхәтләнеп тик тора. Фәлинә такта янына чыкса, үзе аны карашы белән иркәли.

Кичләрен ул Фәлинә яши торган өй турыннан берничә мәртәбә уза, сызгыргалый, тамак кыра. Ләкин Фәлинә чыкмый, тәрәз пәрдәләре селкенми, өйдә тавыш-тын ишетелми.

Шулай итеп, уку елы үтте, Фәлинә китте, Гомәр алдында газаплы, өметсез, шыксыз киләчәк кенә торып калды. Унынчыда Гомәр Фәлинәгә әллә күпме хатлар язды. Фәлинә дә язгалады, ләкин сирәк. Һәр хаты үзәк өзгеч, Гомәрне утка гына сала торган була иде.

«Гомәр, бик авыр миңа,— дип яза Фәлинә,— мин беркайчан да, беркемне дә сине яраткан кебек ярата алмаячакмын. Мин бит теге чакта кичләрен синең безнең фатир турыннан сызгыргалап, тамак кырып узганнарыңны ишетә идем. Син шулай мине чакыра идең бит. Мин синең өчен төннәр буе елап чыга идем, ә синең янга чыгарга йөрәгем җитми иде. Курка идем, тагын күрерләр дә адәм хуры ясарлар дип курка идем. Җитмәсә, әнидән шундый борчулы хатлар ала идем. Ул класс җитәкчесе аша синең белән минем араны белгән, миңа ялынып-ялварып хатлар язды, акылыңа кил, кызым, унны бетермичә бер егет белән дә йөрмә, без, әтиең белән әниең туып-үскән, сагынып яшәгән авылда начар исем чыгара күрмә, дип яза иде әни. Ул хәзер дә минем сине сагынганны белә, башыңнан юк-бар уйларны чыгарып ташла, бөтен дәртеңне укуга гына бир дип әрли. Укы, кеше бул, әтиең алай-болай була калса, бар ышанычым синдә ди. Ә минем әнине борчыйсым килми, Гомәр. Сине бик нык сагынсам да, әнине кызганам, авылга кунакка кайту турында да бер сүз дә әйтә алмыйм, синең янга кайтырга тели дип уйлар дим. Әйдә, араны өзик, хатлар язышмыйк, Гомәр, бер-беребезне онытыйк, шулай икебезгә дә җиңелрәк булыр. Бу минем соңгы хатым булыр, син дә бүтән язма. Начар якларым күп булган булса да, яхшы якларым белән генә искә ал, мин сине гел яхшы гына итеп күз алдыңа китерәчәкмен. Хуш, кызлар арасыннан үзеңә ошаган берәр иптәш тап. Соңгы үтенечем шул гына — ул миңа караганда яхшырак булсын».

Әй, яшьлек хатлары! Самими да, зурдан кубарга тырышуы белән бераз көлке дә һәм уңган хатыннарның тәрәзә пыяласы кебек чиста да.

Фәлинәнең соңгы хат дип язган хатлары артыннан ук Гомәр аңа бер-бер артлы әллә ничә хат яудыра иде. Фәлинә җавап бирмичә торатора да, айлар үткәч чираттагы «соңгы хатын» язып җибәрә. Барлыгы дүрт хат язды ул Гомәргә. Гомәр өчен алар мәхәббәтнең иң кадерле истәлекләре.

Гомәр унны «көчкә-мөчкә, өчтән-өчкә» генә бетереп чыкты. Мәктәп өчен аттестат алучыларның проценты югары булу кирәк иде, икелесен өчле ясап, өчлесен шул көе калдырып, артыннан этеп-төртеп, уф алла,

монысыннан да котылдык, дигәндәй, мәктәп стеналарының тышкы ягына чыгардылар. Унны бетергәндә әле Гомәрдә киләчәк укулар, киләчәк тормышлар өчен хыял-мыял дигән нәрсә юк иде, аларның килүенә, бая әйткәнчә, Гомәрнең хәзерге хатыны Тәнзилә сәбәпче булды...

Ә нишләп соң әле Гомәр монда, Кырымда, Тәнзилә белән түгел, ә Фәлинә белән? Менә Гомәр белән Фәлинә икәүләшеп Кара диңгездә йөзеп йөриләр. Юк, йөзеп тә йөрмиләр, ә диңгез өстендә сузылып яталар икән әле. Нәкъ комда кызынган шикелле, әле бер якка, әле икенче якка борылып яталар алар. Ә диңгез аларны батырмый. Әнә диңгездә коенучы бөтен кеше алар кебек дулкыннар өстенә кырын төшеп ятарга телиләр, ләкин аз гына яталар да, бата башлыйлар. Ә Гомәр белән Фәлинә батмыйлар, үзләре коенучылардан көләләр. Менә Гомәр шаярып диңгез өстендә мәтәлчек ата башлады. Ул дулкыннар буйлап йөгереп килә дә, өчәр мәртәбә әйләнеп чыга. Фәлинә дә Гомәр артыннан йөгерә, ләкин мәтәлчек атмый, Гомәрне карап кына тора. Кинәт Алып каласы паркында яшәүче ике тавис кош, диңгез өстенә төшеп кундылар да, дулкыннар алып килгән борчак кебек мәрҗәннәрне чүпли башладылар. Үзләре мәрҗән чүпли, үзләре Гомәр белән Фәлинәгә карап елмаялар. Гаҗәп икән ул кошлар елмаюы. Томшыклары белән әллә ничек, сәер итеп елмаялар. Ә Гомәр белән Фәлинә аларга игътибар да итмичә Кара диңгезнең күбекләнеп торган ап-ак, йомшак, җылы бер дулкынын юрган итеп өсләренә ябындылар да йоклап киттеләр. Рәхәт булды аларга бу ап-ак күбекле диңгез юрганы астында йоклавы. Ләкин озакламый аларны тавис кошлары кычкырып уятты һәм Гомәр Фәлинәне кочаклап ярга табан чыгып китте. Яр буенда аларны Тәнзилә көтеп тора иде. Ул аларның икесенә дә ак розалар бүләк итте. Кырым розалары.

...Ләкин болар инде Гомәрнең төше иде. Уйланып ята-ята ул йоклап китте һәм уйлар төшкә ялгандылар.

Уйның гомере кыска дип дөрес әйтәләр. Гомәрнең тәмсез мәҗлестән кайтып ятуына әле нибары бер сәгать вакыт үтте, шул арада ничәмә еллар күз алдыннан үтеп киткән.

6

Икенче көнне Гомәр Хәрзанны кымыз бүлмәсендә очратты. Хәрзан акыллы кеше иде. Гомәрнең кичә ни өчен мәҗлесне ташлап чыгып китүен сорашмады. Киресенчә, сүзне үзе турында башлап җибәрде ул.

— Мин харап булам бугай, малай,— диде,— мин аяк-кулымны чолгадым, ахры. Бу уеннан тиз генә чыгып та булмас кебек.

Гомәр Хәрзанны ярты сүздән аңлады. Хәрзан белән Зинаның мөнәсәбәтләре бик нык тирәнәеп киткән булырга тиеш.

Гомәр дөрес уйлый иде. Кичә Хәрзан белән Зина Ленаның бер бүлмәсендә кунып кайттылар. Иртәгә алар санаторий оештырган бер көнлек автосәяхәткә чыгып китәчәкләр.

Хәрзаннан аерылгач, Гомәр Юра янына керәсе итте. Гомәр, Юра, Лариса, нәни кыз Наташа дүртәүләп тирга киттеләр. Гомәр бүген бөтенләй начар атты, Лариса туксан тугыз очко җыйды, Юра, ниһаять, йөз очко җыеп бик кәефләнде. ДОСААФның Алып каласы шәһәр комитеты дипломын алды. Дипломны юарга бик кымырҗыган иде дә, Лариса тыеп калды. Юу мәсьәләсендә Гомәр дә активлык күрсәтмәде. Шуннан Юра диңгез буена төшеп краб тотарга тәкъдим итте. Барысы да риза булдылар, аеруча Наташа шатланды.

Краб тоту буенча Юраның үз әмәле бар икән. Әш шунда, иләмсез зур үрмәкүчләргә охшаган бу шөкәтсез җан ияләре бик хәрәкәтчәннәр һәм сизгерләр. Шул ук вакытта алар ис кергән колбаса, ит, балык ише

әйберләр алдында тәмам югалып калалар — бер чеметем сасы колбаса кабып карар өчен бөтен сизгерлекләрен югалталар. Краблар дингез буенда тәртипсез рәвештә бер-берсе өстенә өелешеп яткан ташлар арасында яшиләр. Якын килдең исә таш араларына эчкә үк кереп яшеренәләр. Юра ике кулына ике тимер чыбык тота да, краб ауларга керешә. Тимер чыбыкның берсе кисәү агачы кебек кәкре башлы, икенчесе туптуры. Әнә шул туры тимер чыбык очына сасы колбаса киертә ул һәм аны краб кереп качкан таш арасына тыгып җибәрә. Ә кисәү агачы кебек тимер чыбык бу ярыкка алдан ук тыгып куелган була. Юра тимер чыбыкның анысына кагылмый тора, итле тимер чыбыкны гына ярык эчендә селкеткәли һәм аны акрын-акрын үзенә табан тартып китерә. Сасы итнең баш әйләндергеч исен сизгән краб урак кебек кәкре аяклары белән кыек-мыек атлап тимер чыбыкка иярә. Шуннан аның беренче тимер чыбыкның кисәү агач кебек кәкре өлешен атлап бу якка чыгуы була, Юра аны мичтән күмер тарткан кебек бу якка сөйрәп тә чыгара. Җитезлеккә Юра да крабтан калышмый, келәшчә кебек бармаклары белән теге иләмсез үрмәкүчнең муеныннан эләктереп тә ала. Муеныннан кысарга өлгерә алмый калсаң, краб алгы аяклары очындагы кыскычлары белән бармак битен умырып кына ала икән. Юраның бармак битендә инде ике-өч яра бар.

Юраның крабны эләктереп алуына иң куанган кеше Наташа була. Ул шатлыгыннан бар тавышына әче итеп кычкыра-кычкыра таш өстендә сикергәли башлый. Шул арада Юра пиджак якасыннан энә алып крабның таш маңгаена, нәкъ ми турына кадый. Ләкин ул моны Наташага күрсәтмичә генә эшләргә тырыша.

— Мин кызымны үскәч аучы итәм бит, әйеме, Наташа,— ди ул кызына,— үскәч ул боланга каршы бер үзе барачак. Малай булган булса, аюга да каршы барган булыр иде дә, кыз булгач, боланга гына каршы барыр инде, әйеме, кызым?

— Юк,— дип, бик яман рәвештә кашларын җыера Наташа,— минем малай буласым килми, мин үскәч барыбер аюга каршы барам.

Малай буласы килми Наташаның. Малайларны җене сөйми аның. Ул малайларны хулиганнар, әшәкеләр дип әрли. Һәм бик яман әрли, бары тик якутлар гына булдыра алганча кашы-башы җимерелеп төшә. Әтисе Наташаның малайларны яратмаганын белә, шуңа күрә котырта да аны.

— Шул кадәр ямьсез итеп кашыңны җыерма,— ди Лариса Наташага,— егетләр яратмаслар үзеңне.

— Яратмый гына карасыннар,— ди Наташа,— яратмасалар мин аларны пух-пух-пух.— Наташа бармагы белән пистолеттан аткан кебек хәрәкәтләр ясый.— Мин, зур үсеп, аучы булгач, аларның барысын да пух-пух-пух.

— Кешеләрне пух итәргә ярамый,— ди Лариса.

— Ә нигә соң алар мине яратмыйлар?! Яратсыннар! Малайлар мине яратмасыннар, ә егетләр яратсын.

Малайларны булдыксызлар, ә егетләрне олы кешеләр, аучылар дип белә Наташа. Ә аучылар инде аны һичшиксез яратырга тиешләр. Чөнки ул үскәч үзе дә аучы булачак. Әтисе шулай ди, ә әти сүзе — закон.

Юра краб аулый, Лариса белән Наташа җыен юк-барны лыгырдыйлар, Гомәр аларны күзәтеп тора. «Бәхетле гаилә,— дип уйлый ул,— бер-берсеннән тәм таба беләләр».

— Бу краблар нәкъ минем хатын кебек,— ди Юра Ларисаны үртәргә теләп,— кыяфәтләре дә, хәйләкәрлекләре дә. Ә шулай да алар мин корган ауга килеп кабалар, ха-ха-ха!

— Авызыңны бик ермасана,— ди Лариса тыныч кына,— берәр краб авызыңа кереп, телеңне өзеп алмасын.

— Этине обижать итмә,— дип чәбәкли аны Наташа. Ул гел шулай этисен яклый. Юрага Ларисадан бер начар сүз дә әйттерми.

Юра уч төбе кадәр зур бер крабны муеныннан эләктереп алды. Наташа шатлыгыннан үрле-кырлы сикергәндә аягы таштан таеп китте дә, маңгае белән икенче бер ташка барып та төште. Барып та төште, маңгаеннан чәчрәп кан да чыкты. Юра крабларын атып бәрде дә: «Кызым»,— дип Наташага ташланды, кан күргәч Ларисаның йөзе көл төсле агарып чыкты. Наташа куллары белән чәбәләнә, чырыйлап кычкыра иде. Гомәр кесәсеннән чиста кулъяулыгын чыгарып Ларисага бирде. Лариса аны кызының маңгаена басты. Ләкин кан агуын болай гына туктатырга мөмкин түгел иде. Юра баласын күтәреп ярга табан йөгерде. Алар әлсерәп, пешеп санаторийга, врач янына килеп җиткәндә инде Наташаның бик күп каны акты һәм ул аңын югалтты. Лариса илереп елады. Юраның да күзләреннән туктаусыз яшь акты. Врачлар Наташаның ярасын бәйләделәр, аз-маз аңына китерделәр.

— Балага бары тик урын өстендә генә ятарга кирәк, ә безнең санаторийда балалар бүлеге юк,— диде врач.

— Безнең фатир әйбәт, өйдә генә ятар,— диде Лариса.

— Аны карап торырга врач кирәк бит,— дип каршы төште Юра.

Шунда Гомәр кичәге мәҗлестә Зинаның балалар врачы икәнлеген ишетеп калуын исенә төшерде.

— Борчылмагыз, санаторийда дәваланучылар арасында балалар врачы бар, ул Наташаны карап тора алыр,— диде ул.

Юра белән Лариса Наташаны алып фатирларына табан юнәлделәр, Гомәр Зинаны эзли китте.

Зина палатасында иде. Гомәр хәбәрне әйтүгә, ул Юраларга чыгып чапты. Гомәр дә аңа иярде. Наташа өзек-өзек сулыш алып караватта ята иде, Зина авыруны карады да, кирәкле приборлар, медикаментлар юнәтергә дип Лена янына китте һәм озакламый алып та кайтты.

— Авыруга кагылмагыз, хәзергә йокласын, көнгә өч мәртәбә килеп үзем карармын,— диде ул.

Юралардан алар Гомәр белән бергә кайттылар.

— Кичәге өчен миңа ачуланма,— диде Зина, — мин сине япа-ялгызлыктан коткарырга теләгән идем. Лена әйбәт хатын ул, сер саклый белә.

«Сыер сатамыни»— дип уйлады Гомәр, Зинаның бу сүзләренә ачуы килеп. Ләкин ул әле генә дусты Юраның баласына игелек кылырга вәгъдә иткән врачка каты кагылырга базмады.

— Зарар юк, мин үзем шундый сәеррәк кеше инде,— дип, сүзне очларга итте ул.

— Чыннан да, сез сәеррәк кешеләр,— дип элеп алды Зина,— син дә, Хәрзан да. Минем өчен шул сәерлеге белән кызык та ул Хәрзан. Ир-атлар бит барысы да бертөрлеләр алар. Ә бу бөтенләй аларга охшамаган. Гел унҗиде яшьтән үтмәгән әле ул. Аның белән кызык миңа, шундый кызык. Ул гына да түгел, мин үзем дә яшәреп киттем аның белән. Үзем үз-үземнән көләм, үзем унҗиде яшьлек кызлар кебек яратам, тәмам исердем, гашыйк булдым бит мин аңа.

Шул көннән соң Зина Наташаны бик тырышып дәвалады. Бер атнадан инде бала аякка басты. Ул Зинага бөтенләй нязләшеп бетте, аны тәмам яратып өлгерде.

Зина чын мәгънәсендә үз эшенең остасы иде. Авыру Наташага булган аналарча мөнәсәбәте, дару каптыру, укол ясау, ярасын бәйләү вакытында балага ярый белүе, тәмле теле һәм йомшак кулы бар. Зинаның һәр хәрәкәтеннән, авыру балага әйткән һәр ягымлы сүзеннән эчкерсезлек, үз эшенә мәхәббәт бөркелеп тора иде.

Хәрзанның Көбә төбендәге аулак «эш кабинеты»на барып та карамавына инде атнадан артып китте. Зина белән танышкан көннәрдә әле

ул кәгазьләрен алып монда килгәли иде. Ләкин диссертация алга бармады, күңел алгысынды, юк кына формула өстендә дә яртышар сәгать уйланып тора иде Хәрзан. Чөнки аның уе кинәт ике катлыга әврелде. Беренче катында диссертация, төрле формулалар, реакцияләр, закончалыклар, ә түрдәге икенче катта Зина басып тора. Ә күңел һаман түргәрәк, Зина янына омтылды. Шулай ике-өч көн азапланды да Хәрзан, диссертациянең язылган өлешен һәм пачкасы белән чиста кәгазьләрен чемоданына бикләп куйды. «Юк, миңа Кырымда гына булса да ял итәргә кирәк, эшләмәскә, мин психологик яктан арганмын»,— дип уйлады ул. Әлбәттә, бу аның үз-үзе алдында акланырга тырышуы гына иде.

*

* *

Октябрь бәйрәменнән соң атнадан артык вакыт үткәч, Гомәр Тәнзиләдән хат алды. Хат бәйрәм үткәч, тугызынчы ноябрьда язылган иде. Тәнзилә бәйрәм алдыннан Гомәр җибәргән бүләкләрне алуын хәбәр иткән, хәлләребез бер көе, яңалыклар юк дигән. Тәнзиләнең хаты һәр вакыттагыча хискә ярлы, коры, яңалыксыз һәм иренчәк иде. Тәнзилә хатларындагы җөмләләр шул кадәр эчпошыргыч булалар ки, бу хатны язучының язасы килмәве, ак кәгазь өстендә бик нык азапланып утыруы, хатны язарга кирәк булган өчен генә язуы сизелеп тора иде. Бу хатларда очкынланып торган бер генә сүз дә, күңелне ялмап алырдай бер генә хис тә булмый, анда хәтта ачуны китерерлек төртмә сүзләр дә юк. Ялыктыргыч, күңелдәге бөтен яктылык нокталарын сүндереп бетерә торган битарафлык кына була бу хатларда. Гомәр шулай ук хатыны һәм улыннан бәйрәм белән котлаган телеграмма да, открытка да алмады. Ләкин ул болар турында Юрага әйтеп торуның кирәген тапмады.

Бәйрәм вакытында санаторийдагыларның барысы да диярлек котлау телеграммалары, открыткалар, хатлар, акча яки посылка алдылар, бер-берсенә күрсәтешеп мактаныштылар. Санаторийга дару эчәргә килгәләп йөргән Юра боларның барысын да күреп торды һәм Гомәрнең ни телеграмма, ни хат алмавын белде. Ләкин Юра, егет кеше буларак, моның турында Гомәргә авыз ачып бер сүз дә әйтмәде.

Ноябрь урталары узгач, Юраның санаторийда булу срогы тулды һәм ул хатыны белән мангаенда нәни генә яра җөе сызылып калган кызын алып, Мәскәү аша Якутиягә кайтып китте. Гомәр аларны автобус тукталышына кадәр озата барды.

— Синең кебек кешеләрне мин бик еш очрата алмаячакмын,— диде Юра саубуллашыр алдыннан,— йомшак һәм ирләргә хас булмаганча көчсез булсаң да, эчке ягын бай синең. Синнән әйбәт кеше чыгачак. Юк, дөрес әйтмәдем, утыз биш яшьтә инде синнән әйбәт кеше чыгар дип тору бәлки берaз соңрактыр, синнән әйбәт эш чыгачак дип әйтмәкче идем мин. Бу дөньяга синнән әйбәт бер эш чыгачак әле, дускай. Мин моңа ышанам. Менә бу биш бармагыма ышанган кебек мин сиңа да ышанам. Ә хатының белән мәсьәләне хәл итәргә кирәк, Гомәр: син аны бер үрле-кырлы сикертеп ал әле, тамырларына бераз кайнар кан йөгерсен. Ләкин мин эшне аерылышуга кадәр үк китереп җиткермәс идем. Дөрес, хәзерге заманда аерылышу берни дә тормый, аерымаерым да менә дигән тормыш корып була. Шулай да ата-баба гадәте буенча аерылышу мактаулы эш түгел.

Гомәр Юралар утырып киткән автобус кузгалып киткәч, елмаеп кул болгады, тәрәзәдән якутларча итеп елмайган Наташаны күреп калды.

Юралар китеп берничә көн узгач, Хәрзанның да срогы тулырга тиеш иде. Бу көннәрне үткәрү Гомәргә тагын кыенлашып китте, чөнки Юралар ганләсенә иялешенгән иде инде. Гомәр инде Хәрзанга да яхшы

ук нялэште, лэкин Хэрзан соңгы көннәрдә гел Зина белән генә серләшеп йөри торган булып китте. Теге дәфтәрләрнең әлегә укылып бетмәгәнлеген чамалый Гомәр, ләкин Хәрзаннан сорарга читенсенә, ә тегесе һаман ул турыда сүз кузгатмыйча йөри бирә.

Гомәр тагын уйчанланды, тагын басынкыланды. Ләкин бу басынкылык инде элеккеге хандра түгел, ә ниндидер зур эш көткәндә була торган хәвефләнү иде. Бу хәвеф Хәрзанның теге дәфтәрләрне укуы белән бәйле, ахры. Гомәр бу көннәрдә дәфтәрләрдә язылганнарны кабат-кабат күңеленнән кичерде. Теге чакта, Леналардагы мәҗлестән соң палатасына кайтып яткач, ул дәфтәрләрдә язылганнарны сүзгә-сүз диярлек хәтерләп чыкты. Ләкин ул чакта барысы да хәтерләнеп бетмәде, чөнки йоклап китте һәм төш күрә башлады. Ниндирәк урынга житкәч йоклап китте соң әле ул теге чакта?.. Ә, әйе, ул чакта уйлар Тәнзиләгә килеп терәлгәннәр иде.

7

Тәнзилә Гомәргә караганда бер генә яшькә кечерәк иде. Гомәр тугызынчыда укыганда, ул, педучилище тәмамлап, Гомәрләр мәктәбенә укытучы булып килде. Чибәр, акыллы, сабыр кыз иде Тәнзилә. Теләсә нинди адәм баласына дөп-дөрес характеристика кирәк булса, өчдүрт айга авылга эшкә җибәр һәм шул вакыт эчендә аның турында авыл кешеләре нәрсә сөйләгәнне тыңлап йөр, ишеткәннәреңне язып бар. Моннан да төгәл биография, моннан да тирән психоанализ, моннан да дөрес характеристика, әлеге кешенең моннан да төгәл рухи һәм матди портреты дөньяда булырга мөмкин түгел. Авыл халкы әйттеме — бетте, начар икәнсең начар ди, яхшы икәнсең яхшы ди.

Тәнзиләне авыл кешеләре бөтенесе беравыздан әйбәт кешеләр рәтенә керттеләр. Ләкин Тәнзиләнең үз күңелендә булган кире якларны гаҗәеп оста итеп яшерә, аларны сер итеп саклый белә торган гадәте бар иде. Тимер келәт, тимер келәт эчендә таш келәт, таш келәт эчендә агач келәт, агач келәт эчендә җиде йозаклы сандык, диген мәкаль Тәнзилә характеры өчен бик тә тәңгәл килә. Әлбәттә, бу сандыкны авыл кешеләреннән беркем дә ача алмады. Тәнзиләнең серләрен беркем дә сизмәде, тоймады. Кызның бу гадәте әле соңрак кына һәм бары тик Гомәргә генә ачыла башладылар. Тәнзилә мәктәпкә килеп эшли башлаган көннәрдә әле Гомәр өчен Тәнзилә беркем дә түгел иде. Ул чакта Гомәр өчен мәктәпкә Тәнзилә килде ни дә, Хәҗирә килде ни, яки ник шунда ниндидер Кәҗирә килми — барыбер иде. Аларның аралашуы Тәнзилә житәкче, Гомәр шигырь укучы буларак мәктәпнең үзешчән сәнгать түгәрәге занятиеләрендә генә булгалады. Яшь укытучы буларак Тәнзиләгә бу түгәрәкне җитәкләүне тапшырдылар. Сәнгатькә өйрәтү ягыннан Тәнзиләдә әллә ни сәләт юк иде, ә менә занятиене оештыру, анда һәркемнең катнашуын тәэмин итү эшләрен шәп булдырды ул. Үзенең тәмле теле, кешеләр белән дусларча мөгамәләгә керүе белән күп кенә укучыны түгәрәккә тартты Тәнзилә. Ләкин менә әйбәт кенә тупланган шушы коллективка сәнгати житәкчелек итү, аларны өйрәтү куәсе җитми иде. Җыр, бию, шигырь сөйләүне үзе азмы-күпме белүенә карамастан, Тәнзилә боларны кешеләргә өйрәтә белми, ходай аңа режиссерлык сәләтен калак очы белән дә каптырмаган иде. Аның каравы, кәефе яхшы булып, Фәлинәсе белән матур гына мөнәсәбәтләрдә яшәгән чакта режиссерлык эшен тулысынча Гомәр үз кулына ала. Бигрәк тә җыр һәм нәфис сүз буенча ул менә диген яңа, кызыклы, үтемле номерлар әзерли иде. Шуңа күрә мәктәп концертларында һәрвакыт бию ягы аксый, аның каравы, җыр һәм нәфис сүз югары сыйфатлы итеп башкарыла иде. Ә инде Гомәр

кәефсезләнеп концертлардан кул селтәгән чорда Тәнзилә бик күңелсез, ялыктыргыч концертлар әзерли иде.

Гомәр мәктәпне тәмамлап колхозда эшли башлагач та, яшьтәшләре кебек, кызлар артыннан чапмады. Шулай да ул клубка йөрде һәм Фәлинәгә карата булган мәхәббәт сагышларын, күңелендә янган утларны колхозның үзешчән сәнгать түгәрәгенә бирде. Ул яңа җырлар, шигырьләр өйрәнде, кешеләрне өйрәтте шул җырлар һәм шигырьләр белән үзе янды, кешеләр йөрәгенә дә ялкын чәчте. Фәлинәнең тәмам араны өзүне таләп иткән соңгы хатын алганда инде Гомәр бу аерылышуның котылгысыз икәнлеген аңлый иде. Соңгы хат Гомәрне тәмам аптырашта калдырды. Фәлинәнең әтисе озак авырудан соң вафат булган, әнисе, аның кабереннән читкә китмим дип, авылга кайтудан бөтенләй баш тарткан. Ул Фәлинәнең институтка керүен таләп итә икән. Ни өчендер Гомәрне каргаган Фәлинәнең әнисе. Ул малай минем язмышым каршында кара тап булып тора, әтиеңнең авырулары синең шул малай белән чуалуларың өчен курка-курка гына азынып китте, ди икән. Ул Фәлинәгә яки Гомәр белән араңны өзәсең, яки мин дә харап булам, дип әйтә икән. Фәлинә инде бердәнбер әниемә, бичара әниемә каршы бара алмыйм, инде хат язма, югыйсә укымыйча кире җибәрәм, дип язган. Хат азагында үзенә каршы килеп булса да берәр хатынкыз белән дуслашырга тырыш, ә мин инде бер егет белән таныштым дип тә куйган. Гомәр Фәлинәнең бернинди егет белән дә танышмавын, үзеннән биздерер өчен юри шулай язуын аңлады. Ә менә Фәлинәне оныту өчен башка берәр кыз белән дуслашу турында уйлана калды ул. Чыннан да, бәлки берәр кызга няләшеп кителер? Болай яшәп булмый ич инде. Киләчәктә Фәлинә белән бергә булуга өмет бөтенләй сүнгән очракта да, алда яшәү, уку, эшләү, көн күрү дигән нәрсә бар бит әле. Һич тә булмаса, үз-үзеңне карау, тамак туйдыру, өс-баш бөтәйтү турында уйларга кирәк. Җитмәсә бит әле, дөньяда әнә сәнгать, җыр, шигырь һәм инде лапас түбәсеннән өйдәге китап шүрлегенә күчкән көндәлек дәфтәрләр кебек матур әйберләр дә бар. Фәлинә хакы хакланмаган очракта да, әнә шулар хакына булса да яшәргә ярый ич әле бу җирдә.

Фәлинәнең соңгы хаты килгәннән соң әкрен-әкрен әнә шундый уйларга бирелә башлады Гомәр. Һәм аның бу уйларын уртаклашучы, ул гына да түгел, аларның күңелдә ныгый баруына ярдәм итүчесе дә табылды. Ул кеше Тәнзилә иде. Тәнзиләнең басынкы, уйчан, сабыр, эченә бикләнгәнрәк булуы Гомәргә ошый иде. Үзешчән сәнгать түгәрәген җитәкли башлагач, ул Тәнзиләне дә концертларда катнашырга тартты. Тәнзилә, үзе артыннан авылның әллә ничә егете килеп караса да, минем көтә торган кешем бар дип, барысын да кире кага иде. Акыллы һәм чибәр булуына карамастан, озакламый авыл егетләре Тәнзилә артыннан йөрми башладылар. Шуңа күрә төнгә кадәр барган репетицияләрдән соң Гомәргә Тәнзиләне фатирына кадәр озатып куярга да туры килә иде. Фатирга кайтканда Тәнзилә Гомәрне укуын дәвам итәргә үгетли, киләчәктә укымышлы кешеләрнең генә илгә файдалы булачагы турында сөйли. Шулай итеп, Гомәр акрын-акрын Тәнзиләгә няләшә башлады. Хәтта ул Тәнзилә белән икәүдән-икәү генә калган чакларда Фәлинәне дә онытып тора торган булып китте. Гомәрне авыл китапханәсенә мөдир итеп куйганда, инде Тәнзилә дә мәктәптә хөрмәтле алдынгы укытучы иде. Ул шулай ук колхоз партоешмасы тарафыннан фермага билгеләнгән агитатор да, сайлау вакытларында сайлау комиссиясе члены да була иде. Авылда яшәгән саен эше күбәя, эше күбәйгән саен тырышлыгы арта иде Тәнзиләнең. Шуңа күрә ул кичке буш вакытларын гел китапханәдә төрле лекцияләргә, докладларга, фермада үткәрелә торган политмасса занятиеләренә әзерләнеп үткәрә. Гадәттә авыл китапханәләрендә мондый эшләр белән шөгыльләнүче кешеләр

күп булмый. Әдәбият сөючеләр китапханәгә китап алмаштыру өчен генә кереп чыгалар. Шуңа күрә күп вакытта Гомәр белән Тәнзилә китапханәдә икәүдән-икәү генә калалар иде. Гомәргә Тәнзиләнең бу тырышлыгы ошый. Хәтта ул аны башка укытучыларга караганда ныграк якын да итә бугай әле. Чөнки хәзер ул аны көндезләрен дә юксына. Тәнзилә китапханәгә озаграк керми торса, үзе мәктәпкә барып әйләнеп килә. Ял көннәрендә Тәнзилә күрше районга, әти-әниләре янына кайтып китә. Мондый көннәрдә Гомәр Тәнзиләне тәмам юксына, хәтта сагына да.

Тәнзилә педучилищеда бергә укыган кызлар белән хатлар язышып тора. Төрле авылларга таралып бер-ике ел укыту дәверендә аларның барысы да кияүгә чыгып беттеләр. Бу хәл Тәнзиләнең күңел түренә көнләшү корты салды. Гомәр Тәнзиләнең күңел түрендә яткан ямьсез күренешне беренче мәртәбә әнә шунда тойды. Үзе әле кияүгә чыкмаганга күрә, Тәнзилә үз дусларының кияүгә чыгуыннан көнләшә иде. Димәк, ул кеше бәхетеннән көнләшә! Гомәр өчен бу бөтенләй кыргый бер күренеш иде. Ләкин ул чакта әле Гомәр моңа бик үк игътибар итмәде, дөресрәге, ул турыда тирән итеп уйламады. Киреесенчә, аларның арасы якынайганнан-якынайды, һәм, ахыр килеп, алар бер-берсенә карата булган мөнәсәбәтләрен аңлатышмыйча гына кочаклашып үбештеләр. Бу хәл Тәнзилә укыта торган класста булды. Тәнзилә кайбер көннәрне төнгә кадәр бер ялгызы гына шул класста эшләп утыра торган иде. Мондый чакларда Гомәр китапханәсен бикли дә, Тәнзилә янына кереп газета-журнал укып утыра. Эше беткәч, ул аны фатирына озатып куя. Мондый чакларда инде, әлбәттә, Гомәр Тәнзиләне яки култыклап ала, яки бер кулы белән аның биленнән кочып бара. Ә менә теге көнне Тәнзилә кайтыр алдыннан класстагы утны сүндергәч, Гомәр күңелендә ниндидер алгысыну, дәрт кузгалып китте һәм ул Тәнзиләне кочаклап алуын сизми дә калды. Тегесе карышмады. Дөрес, ул үзе Гомәрне кочакламады, ләкин Гомәр кочаклаганда җай гына басып тора бирде. Гомәр бер кулы белән Тәнзиләне күкрәгенә кысты, икенче кулы белән аның иягеннән тотып башын күтәрде һәм матур иреннәреннән үбеп алды. Тәнзилә монысына да карышмады. Кинәт Гомәргә рәхәт булып китте, тәнендә кан уйнады, бу минутта ул Фәлинәне бөтенләй исенә дә төшермәде.

Шул көннән соң алар бөтенләй әллә кайчаннан танышкан кешеләр кебек булып киттеләр. Гомәр очрак чыккан саен Тәнзиләне кочаклый, үбә, иркәли, тегесе гел карышмыйча, ни кочакламый, ни үпмичә тын гына басып тора. Ләкин Гомәр монысына да шат иде, чиксез шат иде. Ул инде Фәлинәгә еракта калган бер яшьлек юләрләнүе генә итеп карый башлады, Тәнзиләне чын ярату, балаларча түгел, ә егетләрчә, ирләрчә ярату белән яратам дип уйлады. Район үзәгенә барган чакларда ул Тәнзиләгә күп итеп бүләкләр алып кайта. Ләкин Тәнзилә бу бүләкләрне алганда бернинди шатлык галәмәтләре күрсәтми, Гомәр нинди генә кызыклы бүләк бирсә дә, гап-гади бер әйбер алгандай сумкасына сала да, тыныч кына: «Рәхмәт инде», — дип куя. Үз бүләгеннән үзе дәртләнгән Гомәр мондый битарафлыктан кинәт сүлпәнәя, үз бүләген үзе ду китереп мактый алмый иде ул. Ләкин Гомәр Тәнзиләнең бу гадәтен тыйнаклыкка, аның сабыр холыклы булуына гына юрарга тырыша.

Тәнзилә Гомәрне культура институтының китапханә бүлегенә укырга керергә күндергәч тә шатланмады кебек. Гаҗәп, күпме үгетләде, үз профессиян буенча укырга керү әйбәт ул дип күпме нотык укыды ул Гомәргә, ә менә Гомәр аның тәкъдименә риза булып институтка керергә әзерләнә башлагач, үз теләге тормышка ашуга куанмады.

Гомәр имтиханнарны уңышлы тапшырды. Авылга очынып, дәртләнеп, инде, ниһаять, Тәнзиләне шатландырам дип кайтты. Ләкин Тәнзи-

лә: «Ярый, булган»,— диюдән узмады. Хәтта котламады да, Гомәрнең кайнар кочагында тик кенә басып тора бирде.

Беренче курста Гомәр Тәнзиләгә кайнарланып хатлар язды. Ә Тәнзиләнең хатлары дәртсез һәм коры иде. «Авыл бер көе, үзем укытам, җәмәгать эшләрендә йөрим»,— диюдән узмады. Каникулларга кайтуының берсендә Гомәр Тәнзиләгә өйләнешергә тәкъдим итте. Тәнзилә моны гап-гади бер вакыйга кебек кабул итте һәм алар дау-ду китереп туйлар ясамыйча гына, нәкъ Тәнзиләнең үзе кебек тыйнак-тыныч кына итеп өйләнештеләр. Тәнзилә Гомәргә кияүгә чыккач та, мәктәп биргән фатирын ташлыйсы килмичә, Гомәрләр өенә күчмәде, сирәк-мирәк кенә Гомәрнең әти-әнисе янына килеп йөргәли иде. Бу вакытта инде Тәнзилә Гомәргә бик ачылып бетмичә генә пединститутка читтән торып укырга кергән иде. Дөресрәге, Гомәр Тәнзиләнең укырга керүен белми дә калды. Гомәр аның бу эшен тагын тыйнаклыкка юрады, әшне тәмам җиренә җиткермичә алдан кычкырып йөрүчеләрдән түгел иде Тәнзилә. Өйләнешкән елны көзгә аларның уллары туды. Тәнзилә бала мәшәкатьләре белән институттан бер елга академик ял алды, ә Гомәргә борчылмыйча, институттан кузгалмыйча гына укуын дәвам иттерергә кушты.

Улларына дүрт яшь тулганда инде Гомәр институтны тәмамлап шәһәрдә эшкә калды. Бу вакытта Тәнзилә дүртенче курска җиткән иде. Гомәрне мондый аерым-төерем тормыш бик туйдырды һәм ул Тәнзиләгә шәһәргә килеп төпләнергә тәкъдим итте. Гомәргә, яшь белгеч буларак, шул елны ук шәһәрнең иске бер йортыннан бөтен уңайлыклары да булмаган бер бүлмәле квартира бирделәр. Шулай итеп, өч бөртек җан иясе, ниһаять, үз куышларында үзбаш яши башладылар.

Институтта укыган елларда Гомәр рухи яктан бик нык үсте. Укуны ул һәр вакыт яхшы укыды, фәнгә, белемгә омтылды. Ләкин Гомәр табигате белән хис кешесе дә иде. Тәнзилә белән улын бик тә ярата иде. Ләкин Тәнзилә һаман элеккечә салкын булып калды. Дөрес, ул көнкүреш ягыннан гаилә өчен менә дигән кеше иде. Ашау-эчү әзерләү дисеңме, чисталык-пөхтәлек дисеңме, бик үк иркенәергә мөмкинлек бирмәгән гаилә бюджетын оста итеп бүлү, акча тота белү дисеңме — бик сирәк хатыннар гына Тәнзиләгә тиңләшерлек иде. Баланы ярату, аны ашатукиендерүгә булган хисреслекләренең иге-чиге юк иде. Ул бөтен җаныннән балага, укуына, шушы уңайлыклары булмаган бүлмәгә бирде, алар өчен берни дә кызганмады. Гомәргә карата да бернинди начарлык һәм кыек эшләр эшләмәде Тәнзилә. Ләкин ул хис ягыннан Гомәргә тулысынча битараф иде. Кыз чактагы кебек үк Гомәр иркәләгәнгә аз гына да карышмый, ләкин хәзергә кадәр аның Гомәрне кысып бер кочаклаганы, суырып бер үпкәне дә юк. Гомәр иркәләмәсә, атналар буе иркәләнәсе килмәс, һаман шулай тып-тын гына эшләп йөрер дә йөрер. Юк, караңгы чырай күрсәтә, авыр сүзләр әйтә яки бөтенләй сөйләшми дип тә булмый аны. Ә менә битарафлыгы зур, гомумән, кайчакта аның төп асылы гел шул битарафлыктан гына торадыр кебек тоела иде Гомәргә. Бу битарафлык акрынлап улларына күчте. Ана белән бала арасында гаять кайнар яратышу бар, алар бер-берсе белән көннәр буена чыркылдашып уйный алалар. Ә менә улы Гомәр белән уйнамый. Гомәр исә аны уйнатыр өчен ниләр генә кыланмый, төрлечә якын килеп карый, ләкин малай суеп каплаган әнисе, Гомәргә тик тып-тын гына карап тора. Шуннан Гомәр улына уенчыклар алып кайта башлады. Яңа уенчык күрүгә малай очынып-очынып шатлана, тизрәк аның белән уйный башлый. Ләкин шатлануы бары тик уенчык өчен генә, аның уенына Гомәр дә килеп кушылса, ул уенчыкны читкәрәк алып китә дә, ялгызы уйный, яки әнисе белән уйнарга тырыша.

Тора-бара бу хәл Гомәрнең күңелендә ниндидер сагыш уятты. Аның иркәләнәсе, бу гаиләдә хис ягыннан да тулы хокуклы буласы килә иде. Төннәрен ул үзенең иңнәрендә кемнеңдер кайнар кулларын, иреннәрен-

дә кемнендер рәхәт иреннәрен тоя иде. Һәм аның күңеленә ерактан-ерактан, офыклар аръягыннан Фәлинә кайта башлады. Тора-бара Фәлинә офыкларның бу ягына чыкты, Гомәргә табан элеккеге иркәли торган күз карашларын ташлады. Гомәр, күзләрен йомып, битләрендә йөргән бу карашка иркәләнде. Ул еш кына Фәлинәне Тәнзилә белән чагыштыра торган булып китте. Ә чагыштыруларның берсе дә Тәнзилә файдасына түгел иде. Шулай итеп, ничәмә еллар буе каядыр югалып йөргән Фәлинә яңадан үз урынына, Гомәрнең күңел түренә кайтып урнашты. Гомәр тагын Фәлинә белән, аңа булган мәхәббәте белән генә яши башлады. Теге дәфтәрләрдәге язмаларда тагы ялкыннар уйнады, ул язмалар яңадан яшьлек дәрте, яшәү көче, бөек мәхәббәткә генә инану белән яктырдылар.

Гомәр бик күп дусларына хатлар яза-яза Фәлинә язмышы белән кызыксынды. Хәбәрләр күрсәтүенчә, Фәлинә бик әйбәт кешегә кияүгә чыккан, өч балалары бар, әниләрен үз яннарына алдырып, Башкортстандагы бер шәһәрдә яшәп яталар икән. Ләкин инде ни өчендер бу Фәлинә Гомәрне бик үк кызыксындырмады. Аның язмышы белән кызыксыну да мәхәббәт кызыксынуы түгел, ә гади беләсе килү теләге генә иде. Әйе, Гомәр Фәлинәне ярата, ләкин ул теге Фәлинәне, унъеллык мәктәптә бергә укып йөргән, куллары, иреннәре белән генә түгел, ә күз нурлары, күз карашлары белән дә иркәли белә торган Фәлинәне ярата.

Гомәр үзенең китапханәдәге эшен яратып ук бетерми иде. Дөрес, ул эшне эленке-салынкы, яки миннән үтсенгә генә эшләми. Ул үз абонентлары белән уртак тел таба белә, аларга кирәкле әдәбиятны табарга булыша, китапханәнең тәкъдимнәр кенәгәсенә инде әллә ничә мәртәбә аны мактап та яздылар. Ләкин Гомәр өчен бу эш үзе булдыра алган мөмкинлекләрдән кимрәк булып тоела. Ул моны үз күңелендә тоеп яши, белемен, сәләтен, көчен тагын каядыр куярга, ниндидер башка эшкә дә җигәргә мөмкин икәнлеген белә, ләкин кая икәнен генә белми. Ахыр килеп бу тоем аны китапханәчелек эшеннән алып китәчәген дә тоя бугай әле Гомәр. Шуңа күрә ул үзен монда ничектер вакытлыча гына эшкә кергән кеше итеп тә тойгалый.

Гаҗәп, ләкин Тәнзилә белән булган гаилә тормышы да нәкъ шулай вакытлыча гынадыр кебек тоела Гомәргә. Менә-менә ниндидер вакыйга булыр да, Тәнзилә белән Гомәр елмаешып кына саубуллашырлар да, Тәнзилә үз тормышына, Гомәр үз тормышына китеп барыр кебек. Ә бала?

«Ә бала?.. Ә бала?.. Ә бала?..»

Бу сорау Гомәрнең миен бораулый. Аны инде Гомәр үзенә мең мәртәбә куеп карады, һаман җавап бирә алганы юк. Аптырагач, ул бу сорауны күңелендәге Фәлинәгә биреп карады. Тегесе мутланып елмайды да, бармак селкеп: «Ятим итәсе булма»,— диде. Шуннан соң Гомәр шул ук сорауны күңелендәге Тәнзиләгә бирде. Тегесе иңбашларын гына җыерды да: «Теләсәң нишлә»,— диде. Менә сиңа әкәмәт. Баланың әнисе баланы чәчрәп чыгып якламый, ә ниндидер бер чит кеше, әйтим дә кайтыйм, рухи сөяркә яклый.

Инде малай әнә быел алтынчы класста укый, егет булып килә. Ләкин әтисенә хат язарга да иренә, ә әтисе монда, ерак Кырымда дәваланып ята.

Әйе, соңгы елларда Гомәр бары тик Фәлинә белән генә яшәде. Аннан соң әле аның яраткан әнисе бар иде. Соңгы елларда ул гаиләдә булмаган назларны әнисеннән алды. Җай туры килгән саен авылга кайта, әнисе белән икәүдән-икәү генә сөйләшеп, серләшеп утыра. Ләкин Гомәр әнисе белән бер генә мәртәбә дә Фәлинә турында сөйләшмәде. Ул турыда сөйләшергә әнисеннән ояла иде. Әнисе дә улының Фәлинә белән булган арасын якынча төшенеп, күңеленнән тоеп йөрсә дә, ул

турыда авыз ачып сүз әйткәне булмады. Улының күңел яраларын кузгатасы килми иде ананың. Ләкин алар аннан башка да сүз табалар, бер-берсен аңлыйлар һәм сөйләшер сүзләре бетми торган иде. Гомәр авылдан күңел рәхәтлеге, рухи бер дәрт алып кайта иде.

Инде менә хәзер әнисе дә юк, күңел түрендә Фәлинә, дөресрәге, аннан якты хатирә генә калды. Әнисе үлгәч, Гомәр ни өчен Фәлинә белән бергә була алмауның сәбәпләрен эзли торган булып китте. Юк, ул мәктәпне һәм укытучыларны мәхәббәткә киртә итеп уйламый. Болай уйлау Гомәр тарафыннан намуссызлык, ким дигәндә мәктәпкә һәм укытучыларга карата хаксызлык булыр иде. Мәктәптәге ул тыюлар һич кенә дә Гомәр һәм Фәлинәнең киләчәген җимереп ташлау, аларга начарлык кылу өчен эшләнмәде ич. Киресенчә, укытучылар аларның яхшырак укып, белемле кеше булуларын, киләчәк тормышларына ныклы нигез булдыруларын теләделәр. Хәтта шул ук кырыс холыклы, тәрбия һәм тәртип мәсьәләләрендә кирәгеннән артыграк кыланып ташлаучан класс җитәкчесенең теләге бер генә — балаларга күбрәк белем бирү иде. Мәктәп директоры да, башка укытучылар да алардан бары тик шуны гына таләп иттеләр. Шулай булгач, ник ачулансын аларга Гомәр, ник үпкәләсен?

Шулай ук Фәлинәне дә гаепләп булмый. Яратмады түгел, яратты бит ул Гомәрне. Инде килеп тыйнаклыгы, теләсә кайда үбешеп йөрергә оялуы, кеше алдында Гомәрнең дә, үзенең дә начар исемен чыгарырга теләмәве өчен гаепләсенме аны Гомәр? Яки сугышларсыз, дөньялар тып-тын чакта яраткан ирен югалткан бичара әнисе сүзен тыңлаган өчен ачулансынмы? Дөресен әйткәндә, хәтта ул хатынга да үпкәсе юк Гомәрнең. Укытучы булып укытучыдан, үз баласын тәрбияләргә алынган кешедән шундый хәвефле хатлар алган кайсы ана баласына үгет-нәсихәт бирмәс?!

Әллә соң үзе гаепле булдымы Гомәр? Гаепле үк булмаса да, ялгышлары булды бугай шул аның. Хәзер ул үзенең ялгышларын яхшы аңлый, хәтта аларны җепкә тезгән кебек берәм-берәм тезеп тә чыга ала. Әлбәттә, аның беренче ялгышы үз йөрәген директорга ачуда иде. Мәктәптә шундый кагыйдәләр була торып, директор һәм укытучыларның мәхәббәткә карата шундый карашта торуларын күрә торып, серләрен ачарга кирәкми иде Гомәргә. Директорга бөтенесен сөйләп биргәннән соң аеруча кискенләшеп китте бит Фәлинә белән аның арасы.

Гомәрнең икенче ялгышы Фәлинәнең әнисен эзләп тапмавында. Мәктәптә укыган чакта хат язарга иде аңа, үзенең начар малай түгел икәнлеген аңлатырга иде. Үз баласының күңелен аңлый алган ана кеше баласының күңелен дә аңлый алган булыр иде әле. Яки мәктәпне тәмамлап колхозда эшли башлагач, бер барып кайтырга иде Башкортстанга. Үзе белән бер сөйләшеп, серләшеп утырырга иде. Эреткән булыр иде Гомәр ул бичара хатынның күңелен. Моңа аның Фәлинәгә карата булган саф мәхәббәте ярдәм иткән булыр иде.

Ләкин болар гаеп түгел, ә ялгышлар гына. Яшьлек, тәҗрибәсезлек ялгышлары. Һәм болар Фәлинә белән Гомәр арасындагы олы мәхәббәтне чәлпәрәмә китererлек үк зур сәбәпләр дә түгел. Ә ялгышлар мәсьәләсендә алар бер Гомәрдә генә түгел, мәктәптә дә, укытучыларда да, Фәлинәнең үзендә дә булды ич. Мәктәптәге ул каты кагыйдәләр, директор һәм укытучыларның мәхәббәткә карата булган катгый карашлары галиҗәнаб педагогика каршындагы ялгышлык түгелмени? Яки Фәлинәнең шул дәрәҗәдә куркак булуы, Гомәрнең директорга карата булган чын кешелекле ышанычын гафу итмәве, үз әнисенә үз йөрәген ачып, үз мәхәббәтенә ышандыра алмавы бәләкәй ялгышмыни?

Гомәр мәктәпнең, директорның, укытучыларның, Фәлинәнең һәм үзенең бөтен ялгышларын бер ноктага җыя да исәнгерәп үк китә. Әйе, бөтенесе бер ноктага җыелган бу гомуми ялгышлыклар, әлбәттә, ике

яшүсмер арасында булган саф, нәфис, тиз яраланучан, тәҗрибәсез, әшәкелекләрне бөтенләй белми торган нарасый мәхәббәтне бер сугуда үтереп ташларлык көчкә әверелә. Әйе, моны беркая да куеп булмый, моны икърар итүе никадәр генә кыен булса да, бу рәхимсез реальлек. Һәм шул ук вакытта тормыш агымы, закончалыклы, каршылыклы, һәртөрле ялгышлыклардан хали булмаган гомер сукмагы.

Ләкин Гомәрнең шәхси ялгышлары баягылар белән генә бетми бугай әле. Һәрхәлдә, Гомәр үзендә тагын ниндидер житешсезлекләр бар икәнен сизә, ләкин нинди икәнен тәгаен генә аңлап-төшенеп бетерә алмый. Шулай да, соңгы көннәрдә ул нәрсәнедер төшенә башлады бугай. Хәрзанга биргән теге дәфтәрләр аның бик күп ялгышларын юарга тиештер кебек тоела Гомәргә. Ул үзенең пассивлыгын, хандрасын, йомыклыгын әнә шул дәфтәрләрдәге дәрт, көрәш, омтылыш белән юарга тиеш шикелле. Ләкин Хәрзан ни әйтер бит әле. Ә Хәрзанга ышана Гомәр, Хәрзанның акылында ниндидер тугрылык, тоем бар. Гомәр моңа теге көнне Хәрзан җыр башкарганда тулысынча ышанды. Җыр ул халык күңеле, ә халык күңелендә — тугрылык, хаклык, акыл, рәхимлек.

## 8

Ноябрь азагында Зинаны өенә озаттылар. Ул киткәннән соң өч көн үткәч, Хәрзан Гомәр янына керде. Аның култык астында пөхтәләп газетага төрелгән дәфтәрләр иде. Дәфтәрләрен күрүгә Гомәр җиңелчә дерелдәп куйды. Хәрзан дәшми-тынмый гына төргәкне сүтеп дәфтәрләрне берәм-берәм өстәлгә куйды.

— Гомәр, әгәр мин бүген озаграк сөйләп ташласам, гафу итәрсең, яме,— диде аннары Хәрзан,— педагог кеше буларак, мин сөйләшкәндә, гомумән, фикерне тулысынча ачып бирергә яратам. Ә бүген миңа тагын да күбрәк сөйләргә туры киләчәк.

— Зарар юк,— диде Гомәр,— мин тыңларга әзер.

— Әлегә без бу дәфтәрләрне читкәрәк куеп торыйк, без аларга соңрак кайтырбыз,— дип, Хәрзан дәфтәрләрне, чыннан да, өстәлнең читенәрәк шудырып куйды.— Башта минем сиңа үз күңелемдә булган кайбер фикерләрне әйтеп китәсем килә. Миңа синең белән ачыктан-ачык сөйләшүе шактый кыен, чөнки син мәхәббәт мәсьәләсендә, димәк, Зина белән булган мөнәсәбәтләр аркасында мине гаиләсенә турылыксыз булган ирләр рәтенә кертергә хаклы.

— Юк, мин кешеләр турында капыл гына алай уйлый алмыйм. Кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр «бу азгынлык, ә бу азгынлык түгел» дип кырт кына бүлеп кую өчен артык катлаулылар бит. Мине ул кадәр шәрә моралист дип уйлама, Хәрзан.

— Ә син аклама мине, Гомәр. Минем Зина белән бу кадәр тирән мөнәсәбәтләргә керүем алай ансат кына акларлык күренеш түгел. Зина белән беренче мәртәбә биегәндә үк ялгышачагымны аңладым, бу ялгышка белеп бардым. Бу хыянәтем өчен мин үземне беркайчан да гафу итмәячәкмен. Үзенең назлары, холкы, рухи бай булуы белән Зина мине сукырайтты. Ләкин шул ук байлыклары белән күземне дә ачты ул минем. Зина белән танышканнан соң үткән шушы ай ярымнан артык вакыт эчендә мин тормышка, үземнең яшәү рәвешемә бөтенләй икенче төрле карый башладым. Зина миндә кешелек дөньясы тудырган рухи байлыкларга якынаю теләге уятты. Әдәбият, поэзия дигән гүзәл дөньяга табан этәреп җибәрде. Мин хәзер үземнең фәнемә хыянәт итмәгән хәлдә, аңа аз гына да зыян китермәгән хәлдә, үз-үземне рухи яктан баета барачакмын. Шул ук вакытта мин Рәмиләмне дә шуңа тартачакмын. Мин, бернинди кыенлыкларга да карамыйча, аны институтта

укытачакмын, балаларымны һәм аны рухи яктан баету өчен тырышачакмын. Бу теләкләрне миндә Зина кузгатты. Шул ук вакытта Зина миңа үз хатынымны, Рәмизәмне тагын да ныграк яратырга, үз итәргә ярдәм итте. Әйе, әйе, бәлки ул моны теләмәгәндер дә, ләкин мин Рәмизәмне Зина белән чагыштырып карадым, һәм Рәмизәнең тотрыклылык, гаиләгә бирелгәнлек ягыннан Зинага караганда мең мәртәбә өстен икәнен күрдем. Шуны күрү, шуны йөрәгем белән тою минем Рәмизәгә карата булган мәхәббәтемне әллә күпмегә арттырды. Мин аны гына, бары тик аны гына яратам, һәм бары тик аның белән генә бәхетле булачакмын.

Ләкин, Гомәр, үз хатыныңны бу юл белән сынап карау һич кенә дә бердәнбер юл түгел. Мин үземнең кешелек дөньясы тудырган рухи һәм сәнгати байлыкларга омтылырга тиеш икәнемне дә, хатынымның никадәр саф икәнен дә, аны укытырга кирәк икәнен дә Зина белән бәйләнешкә кермичә дә белергә тиеш идем. Әйе, тиеш идем, ләкин, нишлим соң, белмәгәнмен бит. Минә шушы урында теләсәң нишләт син мине, хет ас, хет кис, хет суй, дигәндәй, әмма белмәгәнмен. Ә ни өчен белмәгәнмен? Чөнки мин, һәрбер адәм баласы кебек үк, тумыштан бөтен нәрсәне белеп тумаганмын. Һәм тормыш безне, кызганычка каршы, үзенең гел матур яклары белән генә түгел, ә ялгышлыклары, хыянәтләре, абынулары белән дә тәрбияли. Ләкин бу минем аклануым түгел, Гомәр. Зина белән булган мөнәсәбәтем өчен ул мине беркайчан да гафу итмәс. Шуның өчен мин аның алдында тагын бер хыянәткә барам, ягъни үземнең Зина белән булган мөнәсәбәтемне аңа әйтмим. Бу минем Рәмизәне гомеремдә беренче мәртәбә алдавым булачак, ләкин ул соңгысы да булыр. Рәмизә минем бу кыңгыр эшемне беркайчан да белмәячәк. Без капчыкта ятмый, дигән мәкаль монда бөтенләй үк туры килеп бетми. Халык ул мәкальне изге теләктән чыгып кына уйлап тапкан. Ләкин, кызганычка каршы, тормышта һәр теләк тә тормышка ашмый шул. Тормыш дигән бу катлаулы нәрсәдә капчыкта ята-ята череп беткән безләр дә байтак. Минем хыянәтем Рәмизә өчен әнә шундый без булачак. Шулай булу минем өчен дә, Рәмизә өчен дә, аеруча балалар өчен дә әйбәтрәк булачак.

Минем тормыш менә шушы эздә. Анда берни дә җимерелмәгән, бары тик миңа, минем күңелемә кыен гына булачак. Ә менә синең тормыш тагын да катлаулырак, Гомәр. Мин сүземне дәфтәрләреңне хәзергә читкә куеп торыйк дип башладым, һәм синең тормышыңны дәфтәрләреңнән тыш кына күз алдына китереп карыйк. Ачуланма, Гомәр, мин синең турыда күзеңә туры карап, дөресен генә әйтәчәкмен. Аек акыл белән уйлап кара әле син үзең турында — кем соң син? Эшеңне яратып, димәк, кешеләргә, җәмгыятькә тулысынча файдалы итеп эшләмисең, гаиләң белән синең арада әрем ышыгы да юк, тормышта кулга-кул тотынып, җиңеллекләргә бергә шатланып, авырлыкларны бергә күтәреп яшәүче дуслар таба алмагансың, бары тик Фәлинә дигән бер букәй уйлап тапкансың да, шуңа табынып яшисең...

Кинәт Гомәрнең маңгаена имән күсәк белән китереп суктылармыни. Фәлинә турында мондый сүзне, мондый фикерне күтәрә алмый ул, юк, күтәрә алмый.

— Хәрзан,— диде Гомәр, үзен мөмкин кадәр тыныч тотарга тырышып,— минем турыда теләсәң нәрсә әйт, ләкин Фәлинәгә кагылма.

— Ә мин аңа кагылмыйм да,— диде Хәрзан.— Аңа инде мин дә, син дә һәм беркем дә кагыла алмый. Чөнки реаль Фәлинәнең үз ире, үз гаиләсе бар. Мин бары тик син үз күңелеңдә тудырган рәсем-Фәлинә турында гына әйтәм. Дөрес, синең аңа мәхәббәтең зур, күңелең саф. Ләкин моннан синең үзеңә, гаиләңә, Фәлинәгә, гомумән, синең ватандашларыңа, кешеләргә ни файда? Әгәр синең бу мәхәббәтең дөньядагы

бер генә, сыңар бер генә адәм баласын гына тәрбияләргә ярдәм итсә дә, мин аны тулысынча аклар идем.

Ләкин нәкъ менә шушы урында мин әңгәмәгә синең дәфтәрләреңне китереп кушам. Шәхес буларак, дәфтәрләрең белән бер бөтен итеп караганда, гаҗәеп кеше син, Гомәр. Әйткән сүзем алтын җирлеккә төшсен — бу дәфтәрләреңнән менә дигән китап чыга синең. Меңләгән адәм балаларының күңеленә саф җилләр өрүче, адәм баласының бөек мәхәббәтен раслаучы, тормышны сәнгать дәрәҗәсендәге гармоник бер күренеш итеп тоярга өйрәтүче китап чыга. Ләкин әле синең бу китап өстендә байтак тир сыгасың бар. Әгәр син бу язмаларны, чыннан да, китап итеп оештыра алсаң, көннәреңне-төннәреңне кызганмыйча эшләргә көч тапсаң, синең моңа кадәр булган мәлҗерек тормышың акланачак. Ә андый көч бар синдә, Гомәр, дәрт тә, сәләт тә, рух та бар.

Гаҗәеп, Гомәр бу сүзләрне Хәрзаннан түгел, ә Фәлинәдән ишеткәндәй булып утырды. Әйе, бу сүзләрне аңа Хәрзан түгел, ә Фәлинә әйтте бугай. Шулай булмаса, Гомәр бу кадәр тәмле итеп тыңлар идемени ул сүзләрне?!

*
* *

Ике көннән Хәрзан да кайтып китте. Шулай итеп, Гомәр тәмам күнегеп беткән дусларыннан аерылып ялгыз калды. Хәрзанны озатып кергәч, ул палатасында озак кына уйланып утырды да, Тәнзиләгә хат язарга булды. Ап-ак кәгазьнең иң өстенә, аерым юлга: «Исәнме, Тәнзилә, улым?!»— дип язып куйды да, озак кына шул өч сүзгә карап торды. Аннары шул өч сүздән соң бераз гына буш урын калдырды һәм салмак кына итеп язып та китте: «Тәнзилә, минем бу хатым сине гаҗәпләндермәсен. Синең белән минем арада булган мөнәсәбәтләр хәзер шул ноктага килеп җиткән ки, безгә кимендә бер ел аерым торырга кирәк. Шушы бер ел безне сынарга тиеш булыр. Врачлар әйтүенә караганда, минем исәнлеккә Кырым һавасы бик тә яхшы тәэсир итә. Бу яктан караганда да минем әлегә кайтмавым хәерле. Бер атнадан минем санаторийда булу срогым бетә, һәм мин кичә Алып каласы паркында үземә эш таптым. Мин бер елга парк эшчесе булып эшкә урнашам. Эштәгеләргә әйт, югары белем белән гап-гади эшче булып калуга гаҗәпләнмәсеннәр. Минем тагын үзем генә белгән эшләрем дә күп әле. Шушы бер ел эчендә бәлки мине улым да сагыныр. Алимент-мазар дип борчылма, мин сезгә һәр тапканымның яртысын җибәреп торырмын. Хәзергә хушыгыз».

Гомәр хат язылган кәгазьне пөхтәләп дүрткә бөкләде, өстәлдә яткан авиаконверт эченә тыкты һәм конвертның өчпочмаклы капкачын теләндә шудырып ябыштырып куйды. Аннары конвертка бөтен шартын китереп, индекс саннарын шакмаклар эченә сызып, адрес язды, хатны төшке ашка барганда почта әрҗәсенә салырга дип пальто кесәсенә тыкты. Ул боларның барысын да гаҗәеп бер тынычлык, салкын канлылык белән эшләде. Эшен бетергәч, барып балкон ишеген ачты. Инде декабрь җитеп килүгә карамастан, тышта җылы иде. Гомәрнең күзе балкон каршында гына үсеп утырган пар каштанга төште. Каштаннар инде ике ай буена бөтенләй яфраксыз, шәп-шәрә килеш утырсалар да, Гомәр аларга ни өчендер:

— Саргаймагыз, каштаннар,— дип куйды.

1976—77,
Кырым.

## Нурия Измайлова

### Юлга чыгам

«Агыйделнең аръягында
Бер энәгә — бер сыер!» —
Юк, юк, алай көлмәгез сез!
Дәрте барлар юл йөрер!
Күңелләрем иләсләнсә,
Әй, әйләнәм сабыйга!
Ышанам — мин юк җирләрдә
Могҗизалар барына:
Алтын таулар калыкканга,
Көмеш сулар акканга!
Ярсып, яшь гомерләр түгел,
Поезд гына чапканга...
Эзләрмен дә табармын кук —
Килер кебек бөек көн!
Миңа диган утрау бардыр —
Диңгезләр күп, ил иркен.
Дәртем таша. Юлга чыгам.
Озын торна-хыялым
Аккош булып йөзәр әле
Бер күлендә дөньяның!

### Кол

Минем биләмәләремдә
        Кол бул әле!
Боерсам — нур, ә боерсам —
        Гөл бул әле.
Минем алда йомшак кына
        Басып йөр син.
Баш и! Тезлән! ...Тик күңелемә
        Патша бул син!
«Аh, падишам!» — диган бул да
        Кол ит мине,
«Баш өсте!» дип, нур ит мине,
        Гөл ит мине...

•

Бер күз салсаң, гөл булырмын,
Берүк йолкып ташлама.
Карамасаң, таш булырмын,
Тик гөл чыгар таштан да...

•

Бездә яз бит. Ярдан чыкты хисләр,
Актарылдым синең каршыңа.
Сездә җирләр бигрәк туң икән шул,
Юк икән шул сыңар тамчы да...
Ах, боз булдым! Ап-ак бозлар булдым!
Эресәм дә, инде ташымам...

## Мәхәббәт һәм мәкер

Чирлә әле, чирлә әле
Үлем чирләре белән.
Саташ та шунда әйт әле:
«Үлим сөйгәнем белән».
Чакырырлар. Мин килермен.
Йөрәгеңне ачармын.
Йөрәгемнән йөрәгеңә
Тәмуг уты чәчәрмен!
Син үләрсең! Мин шатлыктан
Елый-елый көләрмен!
Йөрәгеңне үбәрмен дә
Күз яшьләрем сибәрмен...
Терелтермен! һәм әйтермен:
«Үтердем дә коткардым!
Күз яшем тамган йөрәккә
Хуҗа булып мин калдым!
Ай-йолдызлар, хатын-кызлар —
Бөтен күзләр! Белегез:
Мин җан керттем йөзләренә —
Карамагыз берегез!»
...Чирлә әле, чирлә әле
Үлем чирләре белән.
Терелмәсәң, үлим әйдә,
Үлим сөйгәнем белән!

•

Элек кигән күлмәкләрем сакланмаган,
Элек булган теләкләрем акланмаган,
Элек янып сөйгән ярым ятка калган.

Ул күлмәкләр — яшьлек төсе — онтылмаган.
Ул теләкләр искә төшсә, һушсыз калам,
Ул мәхәббәт төшкә керсә, утсыз янам.

Әй, сакламыйк әле җанның салкын күлен!

Күлдә аунап куанырга — кошлар түгел!
Сүнгән утлар — ул мәетләр — ышан, күңел!
Иссен җилләр — очсын күлләр! — бушан, күңел!

●

Корып була бу тормышны, ләкин
Борып булмый икән үзеңчә.
Дөнья чиксездер дә түгәрәктер...
Гомер — чикле. Вакыт — озынча.

## «Син көчле!» диючеләргә

Мин яңадан үз-үземә кайттым:
Аек башлы горур бер кеше —
Күп күлми дә, күп еламый торган,
Акыл — камил, рухият көчле.
Мондый кеше инде шәп төсле...

Үз-үземнән кире китәр идем
Киң күкрәкле көчле ярыма.
«Тилекәем!» — дисә, көләр идем
Һәм тилерер идем тагын да.
«Бәләкәчем!» — дисә, елар идем,
Тезләренә сарыла-сарыла.
Горур башкаемны ияр идем,
Үлән булыр идем алдында.
Акылсыз һәм көчсез калыр идем,
Көчле ярым булса янымда...

●

Яз килде дә, тауның күкрәгеннән
Агып итте карлар-ташкыннар.
Ә горур тау калды кара көеп,
Яшьләр коеп кыя ташыннан.
Беркөн кайтыр карлар, болыт булып:
Җылы яңгыр, салкын боз сибеп...
Тау аларны тагын кабул итәр —
Нишләсен тау? — хатын-кыз кебек...

## Ак тау һәм Мөхәммәт

Әйтә идең: «Мин — Мөхәммәт, син — тау.
Тау килмәсә, килер Мөхәммәт».
Ә калдыргач җилдә-яңгырларда,
Тау ватыла икән, ниһаять...

Боз тауларым сиңа эрер иде,
Таудай учак яксаң, Мөхәммәт!
Тик учагың бигрәк түбән иде,
Сүрән иде синең мәхәббәт...

Ап-ак таулар исләренә төшсә,
Киләм, диде, килер Мөхәммәт.
Тауны эзләр — анда инде үзән...
Әллә ничек икән бу хәят!
Әллә ничек булдың, мәхәббәт!
Әллә кайда йөрдең, Мөхәммәт!

●

Дәшмәүчеләр беркемне дә тыңламый
дип уйламагыз.
Дәшмәүчеләр бернәрсә дә аңламый
дип уйламагыз.
Дәшмәүчеләр барын аңлый, сизә
дип тә уйламагыз.
Дәшмәүчеләр барына да риза
дип тә уйламагыз.
Дәшмәүчеләр гомер буе шым яшәр
дип уйламагыз.
Дәшмәүчеләр берәгәйле бер дәшәр
дип уйламагыз.

Эндәшмәүчеләр турында
Бернәрсә дә уйламагыз:
Яхшы дип тә, яман дип тә;
Башлы дип тә, надан дип тә;
Олы дип тә, эре дип тә;
Үле дип тә, тере дип тә...
Бернәрсә дә уйламагыз —
Үз сүзен әйтмәгән кеше
Ул беркем дә түгел әле.

## Кояшлы көз

Чың-чың... чың-чың... Чыңлый күкләр,
Чыңлый нурлар, чыңлый һава.
Күзге көн бу, изге моң бу —
Сарылган ул болытларга,
Җилләргә дә уралган ул,
Чорналган ул чаганнарга,
Кояш яна чың-чың итеп,
Чың-чың килеп яфрак ява.
Шуңа болыт миннән биек,
Миннән биек алтын яфрак.
Кояш миннән мәрхәмәтле,
Җиңел җилләр миннән сафрак.

Җилгә — җиңел, миңа — авыр —
Вак таш баскан күңел тардыр,
Куенда да ташлар бардыр...
Кул авырдыр, тел авырдыр...
...Бәлки бу — җан газабымдыр?!
И дәһи моң! Илаһи моң!
Гөнаһлымын! Кил, син кирәк!
Урал миңа — күтәр мине
Үз-үземнән биегрәк!
Дога укыйм, кабул булсын:
Вөҗданыма шул моң иңсен —
Инде күңелем гел киң булсын,
Инде кулым гел мул булсын,
Авыр сүзем җиңел булсын...
Биеклеккә сәҗдә итим,
Түбәнлектән тәүбә итим,
Гөнаһларны яндырырга
Кояш кирәк — очып китим,
Бөек моңга кушылып китим!

...Чың-чың, чың-чың... Чыңлый кояш —
Нидер яна... Моңнар кала.
Чың-чың килеп мин дә яныйм!
Саф һәм җиңел моңга калыйм
Һәм сезне дә чорнап алыйм!

Әхәт Гаффар

# АК КАЕН ДЕГЕТЕ

хикәя



Шәймәрдән Касыймханов комбайнын төзәтеп бетергәч, киләсе җәй өчен әзерлек сызыгына куйды да, ике көн бер кая чыкмады — үз бакчасында бәрәңге алып ятты.

Инде менә ул алынып та бетте, Шәймәрдән бүген ял итә иде.

Һәм уйга калды. Уйлары гади — кышын кайда эшләп үткәрү хакында. Тегермәнгә барырга булды. Тегермәнче Мәүлет Нәбиенә врачлар анда бүтән эшләмәскә кушкан. Үпкә тирәсендә ниндидер чир тапканнар бугай. Урынына куярга кеше юк ди. Шәймәрдән ризалашты. Тегермәнче эше шәп, гомер-гомердән абруйлы.

Зәйтүнәсе бәрәңге алынып бетү уңаена кабак бөккәне пешереп, шуның өлгереп җитүен сагалый. Әнкәсе карчык мичтән күмер тарттырган, Шәймәрдәннең шуны урнаштырып йөрүе. Көз, музыкант скрипка көйләгән шикелле, күңелне үз тәэсиренә җайлый: хәрәкәтләр салмак, буш кырларга, урманга, бакчадагы юкә агачының коелып бетмәгән орлыкларына, картлар кебек, мәгънәле карала.

Күмер көйри. Кайнарлык бөркелә, кызыктыргыч алтын төс белән сулый. Зәйтүнә томалап куйган мич төбендә бөккән саклый. Әнкәсе күмер тулы чуенны күтәрер хәлдә түгел. Я төшереп чәчәр. Шәймәрдәнгә калды. Хатын-кыз эше инде дә, ярарсана.

Карлыган бакчасына чыгарып, кое төбенә утыртты. Чуен күмере кайнап тора. Ул аны китек таба белән каплап куйды. Җан кайнавын да шулай каплап була микән? Юктыр. Кеше — дөнья. Аның кояшы каплап бетермәлеме? Чуен гына түгел лә! Җан кояшы сүнү кеше өчен кояш сүнү белән бердер. Бу уе Шәймәрдәнне җанландырып җибәрде. Сүлпәнләнгән зәңгәр ялкын ялап алдымыни.

Инде нишлисе? Ишегалды себерүле. Абзар чистартылган. Мунча мичен төзәтәсе бар иде дә — кат-кат маташканчы, яңасы салыныр — ярар...

Эшсезлектән дә гайрәт чигә. Иялләшенгән. Торганына күпме генә әле, дөнья хәтле эшне төгәлләргә дә өлгергән. Әллә кайчан, фронттан алып кайткан гадәт. Күңеленә миң итеп беркеткән бер нәзер алып

кайткан иде: нинди эшне дә, кәнфит суырган кук итеп, тәмләп эшләрмен дигән иде. Нәзеренә дегет кушмам дигән сүзе дә бар. Каен ап-ак югыйсә, ә җир белән томалап, эченә ут салсаң, аннан да кара дегет саркый...

Шәймәрдәннең бите-кулы тыгыз итле, сеңерле. Һич кенә дә илле-не бирмәссең. Чәчәк авыруы ашаган битендә картлык буразналары күренми, шадралары аның яшен яшереп тота шикелле. Өстәвенә, холык-фигыле белән дә, тәнгә дә ир уртасы кебек елгыр — сөлек инде менә.

Аның теш казналары шыгырдап, уйнаклап алды. «Шайтан төкерегенә дегет кушып эчергере, ә! Тәнне тир белән юарлык бер эш заты калмаган бит! Мәсхәрә диген, күмер сүндереп йөре, имеш»,— дип карулашты ул эшсезлеккә.

Сызгыргалап, өйгә үтте. Бөккән пешмәгән иде әле. Исе генә, тәм томаны булып, бөтен өйне баскан. Шаяртып, кәтмәгәндә башка каплаган печән исе сыман, төчкертер дәрәҗәдә борынны ярып керә.

Шәймәрдән, стартер төймәсенә баскандай, тырнагы кара янган баш бармагы белән телевизорын кабызып җибәрде. Сәгать яңа гына унынчы киткән икән, бер малай, ике кыз тән күнекмәләре алып маташа.

— Безнең малайлар шикелле, колхоз бәрәңгесе алдырасы иде сезгә! Кирәге калмас иде бот күтәрүегезнең, — дип, шактый ук җиту кызның яткан җирдән физкультура ясап маташуын өнәмәде. Шуны-сы бар, ул моны килештермәүдән түгел, азмы-күпме көнчелек кот-кысы белән кытыклануыннан әйтте. Дөрес, ул балаларының һәм-мәсен укытып бетерде: үз янындагысы — тугызынчы класста укып йөргән Мөхәммәдьярыннан кала, өчесе дә югары белемле хәзер. Бәлки шушы хәчтерүшләр ише, аның оныклары да, иртән торгач, арык аяклары белән тырык-тырык килеп, физкультура ясаган була-дыр, хе-хе...

Белемле итте дә бит, ата сабагын гына колакка элмәде хәерсез-ләр: исәбе, берәрсен булса да Казанда калдырып, кәеф барында барыр-килер җир ясамак иде. Сабагыннан җил ялаган тузганактай, аның күңелен шәрәләндереп, әллә кайларга таралыштылар бит, тавык мие ашаган нәрсәләр! Казанга дип кузгалды исә, фронтташ дусты Илюша мәрхәмәтенә генә исәп тотарга кала.

Телевизорда гел шул нәмәстәкәйләр сикеренә. Кичләрен генә булса да, күздән яшь чәчрәтеп чыгарырдай берәр татар көе тап-шырмыйлар ичмаса! Кая инде иртән! Әллә ниткән гадәт алдылар бит әле тагын: җырларын үзебезчә башлыйлар да, аңламаслар дип-ме, бүтәнчә тәмамлыйлар... Бар иде заман — бәйрәмме, дус-иш киләме, бозау суйган көнме, каладан бәрәңге сатып кайтасыңмы — әзрәк салынса, каз муены шикелле торбасыннан тотып, патефон уй-натырга куя идең... Рәхәт иде. Хәзер дә шәп анысы. Зарланырлыкмы соң! Шәймәрдәннең телевизоры — иң зурысы. Инде чират — төсле-сенә.

— Нәрсә, гел пешмимени әле? Карын ачты ич. Хатын дим! Пешмимени әле?

— Пешми әле. Бәрәңге түгел, кабак бөккәне ич.

— Син үзең кабак бөккәне!.. Бер... бишесенә өстәп май сал. Өчәр бал калагы! Үзем ашыйм аларын.

Шәймәрдән болай каты телләнүен үзе дә өнәп бетермәде. Нәрсә-дер җитми, тик нәрсә? Түземсезлек, эшсезлек басты. Бөтен җире суынды, муены белән иңбашы пружина кебек җыерылды, менә-менә сикереп торыр да, берәр нәрсәгә тотыныр, ә анда инде ватамы-төзә-тәме — барыбер.

«Иртәнге почта», дип укыды ул телевизорда башланган тапшыру хакында. Кара, малай, патефон әйләндерә түгелме соң бу? Һе, патефон ич, мәлгунь! Менә, җен баласы!

«Тукта әле, безнеке дә тора түгелме туфраксада? Кая китсен мал булган нәрсә. Тормый гына карасын! Шундадыр».

Ишегалдына чыгып, мәче җәһәтлеге белән чардакка үрмәләде дә, аның кара авызлы ишегенә чумды.

Хәтерендәге патефон яңа иде әле. Баксаң, дерматин тышы купкан икән дә, әүвәлге ялтыраулы җирләре тутык, майлы тузан белән капланган.

Ачты, тоткасын куеп, борып карады — әйләнә! Ниндидер бер тәлинкә дә онытылып калган булган. Кул сырты белән тузанын сыпырып, каз муенсыдай кәкре башын шуңа чәнечте. Бераз гына гыжлап торды да, көй китте. Чит, колакка ятышсыз, ләкин күңелне җилкендерә торган тернәкле бер көй. Тик бераздан, акрынлап, коелган яфракның ботакларга кунып-кунып төшкәнедәй, җанга тиептиеп ала башлады, ике яр арасында адашып буталган җил астындагы күл сыман, әле шомарды, әле дулкынланды. Анда шатлык балы да, хәсрәт әчесе дә, дулкыны белән йөрәккә ягылырдай бер көч тә бар. Һәм ул җанны да әле артып, әле кимеп торган диңгез шикелле дулкынландыра, назлый иде. Күзен йомган гына иде — җитез хәтере, ак күгәрчен булып, үткәнгә очты... Австриянең бер шәһәрчегеннән табып алган иде ул бу патефонны. Сугыша-сугыша, гел шуны уйнатып йөргәннәр иде.

— О, Луи, Луи,— дип мактаган иде патефонны Америкадан килгән ит консервасына алышкан немец карты, карлыккан тавышы белән. Шушы тәлинкәне уйнатып та күрсәткән иде. Шушы икәне тәгаен истә: гел шул ялгыз быргы өзгәләнә дә, аңа кушылып, барабан ярсый.

— Луи, Луи Армстронг,— дип, төртеп-төртеп күрсәткән иде немец карты быргының ялгызы гына сызланган урыннарында.— Джаз, гут джаз. Танцен, танцен!..

— Танцен,— дип авыз эченнән кабатлады Шәймәрдән.— Танцен, җен баласы! — дип, чүгәләгән җиреннән күтәрелде ул.— Танцен!.. Ни гомердән бирле биегән юк! — дип мыгырдана-сүгенә, ритмлы авазлар чыгарган быргы көенә ул арт санын, телевизордан күргәненчә, бора-сикерткәли, аннан, колачын җәеп, кулларын уйната башлады.— Танцен бер! Кабыргаларың шалтырарлык итеп! И-иех, и-и-иех!

Күптән биеп караганы юк иде болай. Хәтта чүгеп-чүгеп тә алды. Галушына чардакка җәелгән туфрак тулды. Куркытылган тузанга, алтын хәнҗәр булып, түбә ярыгыннан өч кояш нуры кисеп керде. Тамакка наждак кәгазе ябыштырып куйгандай булды.

Хатыны тавышына гына искә килде.

— Ни җимерәсең анда?

Кисәк туктап, ул патефон муенын, өскә килгән казны томшыгыннан атарга җайлаган кебек, чөметеп кенә өскә күтәрде. Патефон гыжлап кына тора башлады.

— Нишлисең дим, юләр, бөккәннәргә чүп коеп бетердең ич, мәнсез!

Чардакның ачык ишегеннән сузылып кына тузан чыгып тора. Юшкәсе ачык мич авызыннан төтен бәреп торган шикелле. Иртәнге кояш алтынлаган шул тузан төтененнән Шәймәрдән үзе дә пәйда булды. Бүлдергәнгә риза түгеллеге маңгаендагы яра җөенең кызаруы булып йөзенә чыккан иде.

— Бөккән, бөккән! Пешмәдеме соң, карын ачты.

— Юк әле.

— Өстәп май сал. Өч бал калагы. Бер... җидесенә.

— Салдым. Унысына. Бишәр бал калагы.

— Әйтәм бөтен ишегалды исе белән тулды. Томанмыни! Борынны ярып керә.— Ул төчкереп куйды.— Хәтерлисеңме, әнкәңнән сине сорый баргач, кабак бөккәне пешергән идегез? Өчне ашаган идемме әле?

— Җидене генә.

— Һәркайсына өчәр бал калагы май өстәп салдың бугай.

— Әни салды. Унысына.

— Бүгенге норма шуннан калган, алайса.

Ул, аягын салындырып, баскыч басмасына утырды да тирләгән йөзен зур канәгатьләнү белән кояшка каршы куйды.

— Карале, хатын, әйдә кунак җыябыз.— Хатыны гаҗәпләнеп аңа карап куйды.— Кече хатын сорамыйм ич, нәрсә авызыңны ачтың!.. Җырлыйсы килә, бер бисе. Туйганчы. Тамак белән аякка үрмәкүч пәрәвез үрер болай.— Көтмәгәндә теленә килгән бу сүзенә сөенде.— Умыртып алыйк та, селкеп салыйк әле бер — кунак җыйыйк!

— Ниткән кунак? Үзегезнең арт-ал бушагач та. Күпме кәбестә күчәндә утыра әле, син барып җыймыйсың ич аны, гел безгә...

— Ярар, алайса, җыймыйбыз. Мин Казанга барып кайтам. Бер көнгә. Күн итекне чистарт. Кара аны, алтмыш өч сипкелеңнең һәммәсе күренерлек итеп ялтыратасы!

— Ниең калган ул җәһәннәм ераклыгында? Ичмасам сатарга бер... ун капчык бәрәңге алып барыйм дисәң, бер хәер.

— Армстронг тыңлый барам мин.

— Ниткән «әрем страмы» ул тагын?

— Исеңдәме, мин сугыштан кайткан көнне төн буе патефон уйнатып чыккан идек? Исеңдәме... «Сөйсәң сөй, сөймәсәң сөймә генә-ә!» дигәнгә охшаган бер төше? Каравылчы Сөббух бабай, кем исереп акыра, кемне кыйныйлар дип, йөгереп кергән иде... Менә шул тәлинкәдәге Армстронгның үзен күрәсе килә, җен баласы! — диде ул, Зәйтүнәгә патефон тәлинкәсен күрсәтеп.

— Чәче агара башлаган ир күгәрек патефонга биеп ятамы тик торганда? Кара ул башыңны — тузганак: өрдең исә, тараласың ич хәзер.

— Тик торганда шул. Патефон күгәрек, ә көе яңа ачылган ярамыни!.. Унбиш ел биелмәгән, ә Европаны айкап чыккан аяк тик торырга күнекмәгән — шуңа биелде.

— Уйлап та чыгарасың, билләһи, булмаганны.

— Булган, бик булган. Берлинга барып җиткәнче, шушы тәлинкәне уйнаттык. Белдеңме?

— Ни гомергә бер әйләндергән тәлинкәңнең ни икәнен каян белим мин? Сугыш безнең үзебезне тәлинкә итеп әйләндерде. Тик җыр түгел, ыңгырашу гына чыга иде.

— Гел әйләндерергә вакыты тими. Безнең вакыт Гитлер туктата язган дөньяны яңадан әйләндереп җибәрергә генә җитте.

Зәйтүнә өйгә кереп китте.

Ә Шәймәрдәннең күз алдына исән калган расчетының сөремле өрҗәгә куелган патефон тирәли урнашып, шартлаулар казып бетергән кырның суынган тынлыгында ялгыз торба изалануын тыңлавы төсмерләнеп алды. Әнә ул үзе, Шәймәрдән, станинага утырган килеш, күзен кысып, үле солы кырын күзәтә. Юл читендә бер калкып, бер югалган баганалар кебек, өйгә кайту юлында һәр станция саен шуны уйнатулары, кайтып кергән көнне дә башта тирә-күрше, аннары кызы белән улын тезенә утыртып, иң соңыннан Зәйтүнәсе белән

сагынулы сүзсезлектә калгач та шуны әйләндерүләре исенә төште. Луи Армстронг. Кызык исем, җен баласы! Бу чит исемне пуля сызгырулары, җирне соңгы кат сукалап калырга ашыккан шикелле, күзән җыергандай катып калган бармаклары белән җир тырныйтырный үлгән солдатлар елавы, сугыштан соңгы игеннәрне урган комбайн тавышы, трактор гөрелтеләре — һәммәсе хәтердән ничек йолыккалап бетермәгән икән? Нинди җепләр белән тегелгән икән ул ми тамырларына да, һәр авазы белән ничек шулай яктырып тора икән?!

Хәер, нәрсәсе гаҗәп? Алай дисәң, үзе үстергән-җыйган иген санын хәтеренә алмаса да, үзе азат иткән, сугышып алган күпме авылшәһәр исемен кабатлый алыр иде Шәймәрдән Касыймханов! Коттбус, Люббен, Цоссен, Беслитц, Лукенвальде, Тельтов һәм, ниһаять, Берлин... Бу аның туктаусыз сугышларда, әмма инде соңгы сугышларда үткән көрәш юлы. Луи Армстронг! Ничек шул хәтле сызландыра ала икән ул быргысын? Тылсымлы кодрәт белән микән, әллә гап-гади һәвәслек беләнме? Ничек кенә булса да, могҗиза могҗиза инде ул! Менә бүген дә аның эшсезлектән интеккән җанына чишмә булып бәреп керде. Бәреп керде дә, җилкән итеп, әллә кайларга илтеп ташлады. Татылмаган бөтен рәхәтлек, дөньяның бөтен сәерлеге, ул күрмәгән һәм күрмичә үлеп тә китәргә мөмкин булган бөтен нәрсә Шәймәрдән өчен әнә шул Л-У-И А-Р-М-С-Т-Р-О-Н-Гка сыеп беткән лөбаса. Әгәр язмышына язган юлларны тагын бер мәртәбә урап-урап йөрергә керешсә, елан булып боргаланган-сыргаланган, әкертен-әкертен җыела килеп, күкләргә күтәрелгәндәй яңгыраган бу быргы тавышын кабат очратыр иде микән ул — шуны беләсе килде. Дөньяда бер-берсенә охшамаган, бер-берсен кабатламаган нәрсә бар микән? Аңының тирән бер урынында «мин»не камап алган барлык әйберләр дә яшеренеп ятадыр әле дигән уй кыбырсып яши иде. Бу тойгысы да фронттан — үлемнең якынлыгын сизеп, әнә шул уе белән булса да үзенең үлемсез икәнлеген тоеп тынычланырга теләүдән калган. Кеше яшәргә килгән лөбаса. Кояш бата да калка, йолдызларны болыт каплый да, ул болытны җил куып тарата, орлык җиргә күмелә дә, орлык булып кабат әйләнеп кайта ич әле! Шәймәрдән бөтен тәне һәм аңы белән йолдызлар арасында кешеләр яши торган тагын бер «җир» барлыгына, һәм ул җирдә Луи Армстронгны тыңларга теләгән тагын бер «Шәймәрдән» яшәгәнлегенә ышана. Тик менә нәрсә кызык: ул «Шәймәрдән» күн итеген үзе чистарта микән, әллә хатынына куша микән?

Баскыч басмасына аягын салындырып утырган Шәймәрдән менә нәрсәләр уйлап һәм күзаллап алды. Дары сөреме белән каралгандай күренгән тузанлы битен инде кибәргә өлгергән тир сырлап куйган иде.

— Ярар, күн итекне үзем чистартам,— диде ул тавыклар чакырып, аларны ашатып йөргән хатынына.— Сиңдәге хәтле генә сипкел минем үземдә дә бар. Пештеме соң әле?

— Пеште.

— Өстән май да салдыңмы, өчәр бал калагы хәтле?

— Салдым.

Калага ул өйлә узгач кына килеп төште. Автобус аны Куйбышев мәйданына илтеп ташлады. Шәһәр аңа командасыз калган гаскәр булып күренде. «Бер оя кырмыскага икенче ояны кушканнармыни,— дип уйлады ул, аркылы-торкылы йөренгән халык, машина агымына карап.— Бар микән берәр ашыкмаганы хәерсезләрнең?»

Шаймәрдәннең өс-башы шәһәр кешеләренекенә биргесез: ә күн итеге елкылдап тора. Галстугы чуар, киң. Дөрес, әнә теге чандыр ирнеке сыман итеп, күкрәк кесәсенә, өчпочмаклап, галстук нише нәрсә бөкләп тыгылмаган. Кулъяулыгын ян кесәсендә йөртә. Рас тәртибе шулай икән, галстук түшендә булмаса да...

Шаймәрдән, кулъяулыгын алып, башта борын, күз тирәсендә йөртте дә шакмаклы пинжәгенең күкрәк кесәсенә тыгып куйды. «Зәһ-һәр»,— дип куйды ул үзенең ниндидер кибет тәрәзәсендәге чагылышына карап.

«Диңгез шаулыймыни!— дип уйлады ул, халык агымын күзләп. Мәгәр аның бер дә чын диңгез күргәне юк иде.— Миндә беркемнең эше юк. Адашкан кырмыска сымак торсам да. Кызганыч хәтта».

«Кем кызганыч?— дип сорады ул үз-үзеннән.— Халыкмы?»

«Юк,— дип җавап бирде бу сәер соравына.— Үзем кызганыч. Без дә яшибез санала инде, ә? Ә бит күпме шау кайнаган калалар бар!»

Нигәдер авылларына кергән юл өстендәге бер язу исенә төште. «Җиребезне чәчәк аткан бакча итик!» дип язылган иде анда. «Кая анда бакча — бөтен тәнен техника таптап бетергән авылның. Сугыш кырымыни! Ә киноларда Европаны күрсәтәләр — шау чәчәктә! Булмыйни! Җирләрен тәннәребез белән ашлап, каннарыбыз белән сугаргач... Менә шул...»

Авырттырып ук, арттан кемдер иңбашына китереп сукты:

— А-а, мал-лай! Танырлык түгел сине, Шаймәрдән абый! Шик-модерн!

Үзе дә беравык авызы ерык, тилгәннекенә охшаш борынлы егетне танымый торды. Аннары гына аңышты: тегермәнче Мәүлет Нәбиенең төпчек малае икән.

— Нәрсә саттың?— диде Нәби малае Фәйзелхак.— Бәрәңгедер инде. Уңдыңмы соң?

— Болай гына килеш. Коньяк эчмәмме бер туйганчы дип.

— Туйганчы дип, ә?— Фәйзелхак ышанмады.— Эчтеңме соң әле?

— Кая борылырга дип уйлап тора идем әле. Берәр шәбрәк җир әйтә алмыйсыңмы? Телевизордагы ишерәк...

— Тапмыйбызмы соң? Менә генә!— Фәйзелхак янәшәдәге биек бер йортның тәрәзәләренә ишарәләде.

— Ару гына күренә,— диде Шаймәрдән һәм, муенын каерып, бинаның тоташ пыяладан торган биек тәнен күзәтеп торды. Кепкасы, шапылдап, асфальтка килеп төшкәч кенә аңына килде.— Ярый, күрсәт.

Эчкә уздылар. Өстәлләр арасында түгәрәкләп калдырылган бер урында дәү таш, тагын ялтыратып буялган тармаклы агач төбе куйганнар.

Ерак почмакка узып утырдылар.

— Тансык шәһәр табигатькә,— диде Шаймәрдән, таш белән төпкә күрсәтеп, һәм өстәлгә бер уч акча чыгарып салды.

— Үпкәләтәсең,— диде Фәйзелхак.— Яшер. Бу киек бездә чылбырсыз тотыла.— Ул күкрәк кесәсенә сугып куйды.

Официант килеп җитте. Фәйзелхак тегесен-бусын алды.

— Мул шаярасың,— диде Шаймәрдән.

Фәйзелхак дикъкать итмәде. Бары тик:

— Әле һаман комбайндамы?— дип сорады.

— Шунда.

Беренче итеп коньяк китерделәр. Фәйзелхак аны рюмкаларга бүлеп тә куйды. Тик Шаймәрдән үз рюмкасын фужерга бушатты да тагын өстәп салды.

— Безнең расчетның нормасы шулай иде,— диде.

— Үпкәләтәсең. Өч йөз тәңкәне без уйнап кына алабыз. Баш исән булсын.

— Нинди баш? Баш белән эшли торганга укымадың бугай ич.

— Монтажчы бит мин. Анда, баш булмаса, кул ни дә кыра алмый... Ә! Әти-әни нихәл минем анда?

— Зарланмыйлар... Атаң колхоз мунчасына мунчачы булып урнашам дип калды.

— Мунчачы?— Фәйзелхакның иңбашлары пружинадай җыерылып килде.

— Нindidер үпкә чире таптылар... Врач шундый итеп баш чайкаган ди... Рентген белән бар әгъзаларенең сурәтен карточкага төшергәннәр.

— Соңгы кайтуымда бер дә аны-моны әйтмәде ич болай.

— Кайчан кайткан идең?

— Җәй. Сабан туенда, ахрысы.

— «Ахрысы!».. Эх, балалар!.. Сал әле печтик кенә, эне.

Беравык дәшми утырдылар.

— Атаң өй сипләтергә җыена.

— Әйткәне юк миңа.

— Кайсыгызга гына әйтеп бетерсен соң. Дүрт малай бит сез аның. Таралышып беттегез, җен баласы! Мина ярчыклары сымак. Сездән ата-ана җанында буш сагыш чокыры гына кала сөремләнеп. Атаң шулай ди... Карале, авылга кайтыр идең, Фәйзелхак... Җир сукаларга, җен баласы. Тракторчы ич син. Потенциаль танкист, димәк.

— Белмим. Эх, белмим.

— Беләсеңме, врач ник баш чайкаган?

— Чайкарлыгы булгандыр,— диде Фәйзелхак, сөмсере тәмам коелып.

— Ничек кенә әле!.. Беләсеңме ник?

— Ник?

— Ярчык ята ди күкрәгендә. Менә ник, җен баласы. Язгы боз сымак, кузгалган, димәк ки. Чит нәрсә ич, фашист калдыгы... Тәненең кабул итмәведер. Бактың исә, инде күнегергә тиеш шикелле... Юк икән! Чит нәрсәгә күнегелми, күрәсең. Җан белән генә түгел, тән белән дә күнекмәс нәрсә икән ул сугыш... Кайтыр идең син, эне, ә? Атаң чабындырыр иде, ә син аның аркасын уарсың. Эх, чабындырыр иде!

Озак утырганнар икән. Бер заманны сәгатенә күз төшерсә — алты тулып ята. Урамда эңгер-меңгер төшеп килә. Шәймәрдән үз-үзенә сынаулы уй белән текәлде: исермәгәнме? Ул-бу сизелмәде. «Откат шәп!»— дип уйлады ул торып баскач.

Фәйзелхак кызлар янына дип киткәч, Шәймәрдән такси эзләргә юнәлде. Җир астыннан чыгып, озын йорт буйлый атлый торгач, таксилар күреп, шунда ашыкты.

«Уһу, бер көтү ич болар! Хәзер әйләндереп чыгабыз бөтен тамаша йортларын! Кала булып кала хәтле җирдә берәр Луи Армстронг ише кеше табылмый калынмастыр». Үзенчә ул такси йөртүче шоферларны каладагы бөтен нәрсәне белә дип аңлый иде. Кайда нинди концерт-фәлән булганын да белергә тиешләр.

— Гаражга кайтыр якка булса, әйдә, утыр,— диде ул эндәшкән шофер.

— Рәхмәт, энекәш. Гараж кай очта соң?

— Түбән очта!— диде шофер. Шәймәрдән арттан әйләнә торган арада кузгалды да китте.

Тукталып торган һәр такси аны алмыйча китеп бара торды. Ул «кая?» дип сораштырган арада бүтән кешеләр тыныч һәм һаваланып кына кереп утыралар да китә иделәр. Ул да шулай итәргә булды.

«Үч итеп өйрәтәм мин сезне, печелмәгән маллар!» — дип уйлады ул машиналар хакында.

Яңа гына килгәне туктап калуга, Шәймәрдән ашыкмый гына кыланып, әченә кереп утырды да, утыргычның йомшаклыгына кинәнеп, күзен йомды. Ачса — тик торалар.

— Ник бармыйбыз? — дип сорады ул.

— Кая? Бу сиңа... туалет мәллә — кердең дә җәелдең!

— Ә син телеңне тыяр идең. Әйе! Синнән бит йомшак кәгазь сорамыйлар. Кәгазь бездә — менә! — Ул, шапылдатып, күкрәгенә сугып куйды.

— Чык моннан... терапевт!

Шәймәрдән, аның күзенең яхшы карамаганлыгына шикләнеп, карышырга кыймады...

Сәгать җиденче киткән иде инде. Урамнарда утлар кабынды. Әллә соң трамвай белән генә фронтташы янына китеп барсынмы?

Ләкин булырга тиеш бит бу каланың да берәр Луи Армстронгысы! Быргылы концерт күрергә килүен онытып, ул ничек тә бер таксига утырырга ант итте. Усаллык белән түгел икән, бәлки яхшылык белән җүн чыгар? Ул исә үзен яхшылык миссионеры булганы өчен ихтирам итә. Зәйтүнәсен дә шуның белән яулаган иде ич. «Уйлама да, чыкмыйм»,— дигән иде. Шәймәрдәннең: «Битеңдәге алтмыш өч сипкелең белән ант итәм, чыгасың!» — диюенә чыдамады... Үзе саный алмаган, буталган, иптәш кызыннан санаткан — алтмыш өч. Эресе, вагы...

— Йомыш бар иде, энекәй,— дип эндәште ул үзенә тәрттерә язып туктаган машина шоферына.

— Кая сиңа, абый кеше? Утыр. Җилдән җитез йөрибез.

Шәймәрдән шофер артындагы йомшак утыргычка кереп утырды.

— Миңа, иптәш, шундый җир кирәк иде...

— Апкил шуны, белмим нинеме?

— Берәр музыкалы төшкә илтеп куй әле син мине.

— Ресторангамы?

— Юк. Музыкалы... Концерт буласы берәр җиргә. Яктысына, кеше күплесенә.

Алгы ишекне ачып, таксига портфель тоткан зур гәүдәле, ялан башлы бер егет кереп утырды.

— Горкига,— диде ул кәрә-керешкә үк.— Без дүртәү.

— Буш түгел бит,— диде шофер.

— Син бәя күпертмә. Буш итмәбез. Кунакка барыш.— Егет Шәймәрдәнгә таба борылды.— Сиңа кысанрак булыр инде, абзый, төшеп тор. Ягез әле, егетләр...

— Сез нәрсә...— дигәнче, Шәймәрдән үзен сөйрәп төшергәннәрен сизми дә калды. Әмма ул тиз генә кереп китәргә торган егетнең якасыннан эләктереп алды да чәнчелдереп йолкып та чыгарды. Машинадан чыгып, каршысына портфельлесе басты. Портфелен бастырып куйды да, бөтен саны белән артка каерылып, аңа кизәнде:

— Авыл тузаны!..

— Эх, до-ре-ми! Син әле шулай тик тормастан... Сезнең ишеләргә өс бирсәм, дөньяда яшәмим дә мин! — дип, Шәймәрдән бар зәһәрлеге белән бусының кулын артка каерып та куйды. Портфелен тибеп очырыйм дип кизәнгән иде, иңбашына кактылар.

— Гражданин! Нишләвең?

Эндәшкән кешенең милиционер икәнлеген абайлагач, җиңел тын алды.

— Нишлим? Концертка барыш. Менә, болар сөйрәп чыгарды.

— Нигә сөйрисез аны?

— Сез нәрсә! Безнең әле кунакка барыш кына, ә аның кайтышы инде,— дип көлеште егетләр.

— Әйдә, аңлашырбыз,— диде милиционер Шәймәрдәнгә.— Өр әле!

— Дөрес, шул кирәк аңа, үзе бәйләнде,— диде шофер.— Егетләрдә гаеп юк.

— Син, ялагай!.. Намусыңның итек олтаны!..— дип калтыранды Шәймәрдән.

Милиционер егет аны урам буйлап алып китте. Ерак бармадылар.

— Ә минем хәзер син мине алып барган кебек итеп тылдан фашист алып кайткан бар, энекәш,— дип сөйләнде Шәймәрдән.— Мин дә дошманга әйләндем микәнни?

— Син түгел, эчүчелек безнең дошманыбыз, абый.

Исем-фамилия сораштырган арада, каршы ишектән чал чәчле, боек карашлы бер майор килеп чыкты. Шәймәрдән белән дежур лейтенант бәхәсенә колак салды.

— Нишләп эчеп йөрисез авылдан Казанга килеп?— дип сорады каршыдагы лейтенант.— Үзебезнекеләр дә җитәрлек.

— Эчәргә килмәдем мин, билләһи газим, эчәргә түгел. Туры килде әз генә. Миңа Луи Армстронг кирәк.

— У-у, эти кеше, эш харап ук икән бит сезнең. Армстронг эзләп йөрисезмени? Ван Клиберн кирәк түгелме?

— Нам клевер кирәк түгел. Колхоз люцерна бүлде.

— Горячка,— диде милиционер.

— Әйе, лейтенант, Армстронг эзләп йөреш. Австриядә чакта патефоннан уйната идек без аны. Анда берәү, снарядның амбразураны актарганы шикелле итеп, быргы уйнатып үзәкләрне өзгән иде.

— Турист булып барган идегезмени?

— Әйе, лейтенант. Гаубица көпшәсеннән карап йөрдек Европа мәҗараларын. Ник дисәң, һәр тәрәзәгә фашист оялаган иде.

— Армстронг та сезнең белән идеме?

— Безнең белән иде, лейтенант. Җиңеп кайтканда станция саен безгә уйнады.

— Ак горячка,— диде Шәймәрдәнне алып килгән милиционер.

— Кысылма!— дип кычкырды Шәймәрдән сабырлыгы сынып.

— Әйтәм ич...

— Таптыгызмы соң Луи Армстронгны? — диде лейтенант.— Әллә Америкадан, кабереннән уятып китерикме сезнең янга?

Шәймәрдән, урыныннан торып, кепкасын салды.

— Бусын белмәдем. Борчып йөрмәгез алай булгач. Сез мине чыгарып кына җибәрегез дә, үзем табармын әле берәрсен.

— Әллә берьюлы өчнеме? Дүрт борынга,— дип көлде милиционер.

— Күреп тордың ич минем ике борынга менеп төшкәнне. Кабахәтләрне кунакка җибәрдең дә, кунак булып килгән кешедән сорау аласызмы?.. Минем берәр концерт карыйсы килә. Җибәрегез сез мине.

— Сержант, син такси номерын язып калдыңмы?— дип сүзгә кушылды талчыккан карашлы майор.

— Юк иде шул, иптәш майор.

— Бар, тап, язып кил. Бел аны!

— Утыз өч тә уналты,— диде Шәймәрдән.

Майор яшел тышлы бер китап ачты да телефонга ябышты.

— Филармонияме?— диде ул.— Хәерле кич. Майор Җәмилов борчый сезне. Сезнең берәр урында джаз-фәлән... шуның ише берәр концерт бармыймы бүген?.. Диксиленд?.. Ленинградныкы укмыни? Рәхмәт... Фазыйлов, болай итик,— диде ул лейтенантка, трубкасын куйгач.— Спорт сараенда Ленинград артистлары уйный ди. Озат әле моны шунда... Гафу итәсез, кем әле?

Ул, елмаеп, Шәймәрдәнгә иелде.

— Шәймәрдән.

— Шәймәрдәнне шунда илтеп, кертеп куй. Башланырга ярты сәгать. Карасын... Миңа вакыт тими. Югыйсә без дә тыңлаган ул Армстронгны блиндажларда. Шәп уйный, әйеме, фронтташ?

— Шәп уйный иде, иптәш майор.

— Мин онытткан инде Коттбус, Люббеннарны. Берлинны гына онытырлык түгел. Бүген безнең истә җинаятьчелек Коттбуслары, эчкечелек Люббеннары. Җитәргә иде шуның Берлиннарына... Аннан Армстронглар тыңлап кына йөрер идең бу дөньяда.

«Бар дөнья каен кебек,— дип уйлады лейтенант янәшәсендә, машинада утырып барган Шәймәрдән.— Явызлык ялкыны көйдергән бәндәләр күңеленнән усаллык дегете саркый. Ярый әле, хәзер каеннарны дегеткә яндырмыйлар. Шаулап үсәләр, җанкайлар. Майор Җәмилов кебек».

Шәймәрдән Касыймханов машинаның кызыл палас җәелгән идәненә ялтыравыклы күн итегенең үкчә очын гына тидереп утырган иде.

«Хатынны да аласы калган,— дип үкенде ул.— Бик коры сөйләшенде әле бүген аның белән. Булмаганны...»

— Кем булып эшлисең?— дип сорады лейтенант.

— Иртәгәдән тегермәндә, — дип җавап кайтарды Шәймәрдән.

1975 ел, октябрь.

**Рафис Гыйззәтуллин**

*Туган җирем — җырларга күчкән Сарман ягы, Урта Кәшер авылы. Иске Кәшердә урта мәктәп тәмамлаганнан соң, Казан дәүләт педагогия институтының тарих-филология факультетында укыдым. Хәзерге көндә «Татарстан яшьләре» газетасы редакциясендә эшлим.*

*Әдәбиятка мәхәббәтем кечкенәдән башланды. Мине яшәешебезнең бүгенге матурлыгы да, мәңгелеге дә дулкынландыра.*

*Чеховны бик яратам, кыскалыкка аннан өйрәнергә тырышам.*



# КАЗЛАР

хикәя

Габделбәр үзенең улы Мирзанур белән больницага киленен алып кайтырга киткән иде.

Нурзидә исә үзалдына елмаеп, алар кайтуга бәбәй ашы пешерергә әзерләнеп йөри.

— Әби, казны керт инде. Чыгып киткәненә күпме...

Нурзидә уйнап утырган беренче оныгы Мәхмүт сүзләреннән сискәнеп китте.

— И-и-и, менә сиңа хәтер диген. Күптән чыгып киткән иде шул, улым. Йомыркалары суынып беткәндер инде.

Ишегалдында ата каз ялгызы иде.

— Ак каз, ана каз кайда икән? — дип сөйләнде Нурзидә.

Ата каз озын муенын югары күтәрде дә калын тавышы белән ишегалдын яңгыратып кыйгаклап җибәрде.

Нурзидә абзарларны карап чыкты.

— Дгә-дгә-дгә... Кайда соң син?!

Каз урамда да күренмәде.

Нурзидә кулын каш өстенә куеп, инеш буйларын, болынны күздән кичерде.

Тирә-як яшькелт-зәңгәр төстә. Яшел чирәмдә, бәбкәләрен ияртеп, әя-оя казлар йөри.

Казы күренмәгәч, Нурзидә яр буйлап зирек агачларына таба китте.

Агачлар арасыннан чыгып, инеш кырыена килеп җиткәч, ул тукталды.

— Кара инде, гөнаһ шомлыгы, башка урын беткәндер, монда кадәр килмәсәң. Тәмам дөньяны оныткан. Бәбкәләрең чыгам дип торганда. Чык әйдә, чык тизрәк...

Нурзидә суда утыручы ак казга карап шулай сөйләнергә кереште.

— Көш, көш, к-ө-ө-ш-ш-ш...

Каз, башын канат астына тыккан килеш, утыра бирде. Нурзидә ярдан балчык алып, суга ыргытты.

— Көш дим, көш-ш-ш...

Каз һаман утыруында булды. Нурзидә, аяк киемнәрен салып, суга керде.

— Йокладың мәллә? — диде ул, казның сыртына кагылып.

Куркып уяныр, йөзеп китәр дип уйлаган иде. Казның исе дә китмәде.

Нурзидә хәрәкәтсез калган казны ике канатыннан югары күтәрде. Аның муены салынып төште.

Ул, казны күтәргән килеш, су уртасында катып калды. Авызыннан сүзе чыкмады. Аягы язгы суда туңа башлагач кына, исенә килеп, ярга чыкты.

Йомырка өстендә озак утырган каз коры сөяккә калган. Нурзидәнең кулы аның әле чыгып бетмәгән җылысын тойды. Үлгән казны җиргә куйды да, сынган зирек агачына утырып, галошына кергән суны түкте.

— И җаныкаем, бәбкәләреңне иялтеп йөрер көн җиткәч кенә,— дип уйлады ул, казга карап.

Шул чак аның колагына кемнеңдер көлгән тавышы ишетелгән кебек булды. Нурзидәнең күңелендә инде онытылып баручы хатирәләр яңарды.

...Сугыш беткән ел иде.

— Нурзидә, сусадым, су гына эчерче.

Ул чиләгенә су тутырган җиреннән сискәнеп куйды. Озын толымнары, шуып, чишмә суына төште.

— Абау,— дип кычкырып җибәрде Нурзидә.— Син... бу синмени, Габделбәр?!

Аның каршында аркасына солдат капчыгы аскан, агач таякка таянган, үзләреннән берничә өй аркылы гына яшәгән Габделбәр басып тора иде.

Сугышка кадәр Нурзидәнең сөйгән егете Мирзанур белән тракторда эшләде Габделбәр. Мәликә белән өйләнешеп озак та тормадылар, сугыш башланды. Ут эченә алар икесе бергә кереп киттеләр. Мирзанурның үлгән хәбәре килде...

— Әйе, бу мин, Нурзидә. Әллә танымыйсың да инде? Менә сиңа күрше! Хәер, танымассың да... Киткәндә ике аяк белән идем шул. Нишлисең, калдырырга туры килде берсен. Аксаклап булса да кайтып җиттем менә...

— Исән кайтуың әйбәт булган, Габделбәр...

Нурзидә аңа зур чүмеч белән су сузды. Үзе Габделбәрнең су эчүен тын да алмый карап торды. Изүе ачылып торган шинельдән

Габделбәрнең берничә медален күреп алды. Мәһабәт гәүдәсен күздән кичерде.

— Рәхмәт, Нурзидә,— диде Габделбәр, авыз кырыйларын шинель җиңе белән сөртеп.— Ничек яшәдегез без юкта?

— Ярый инде, әнә бит,— диде ул, кышын мичкә ягарга дип салам түбәләре туздырылган өйләргә күрсәтеп.— Ә үзең ничек соң, Габделбәр?

Тегесе әллә ишетмәде, әллә инде үткәннәрне яңадан искә төшерәсе килмәде, сүзне икенчегә борды.

— Мәликә ничек яши?

— Яхшы... Исән-сау.

Нурзидә, Габделбәрнең үзенә текәлеп карап торуын күргәч, күзен читкә борды.

— Аның турында начар сүзләр ишеттем, хак сүзме шул?

— Әйтә алмыйм, Габделбәр... Ишеткәнем юк.

Нурзидә иелде дә чиләгенә су тутырырга кереште.

Күтәрелеп караса, Габделбәр шактый ераклашкан, сулы чиләк янында бер уч умырзая чәчәге сибелеп калган иде.

Кинәт Нурзидәнең Габделбәрне туктатасы, аңа барысын да сөйлисе килде, ләкин тыелып калды...

Күрше дипме, бергә уйнап үскән Мирзанурның сөйгән кызы дипме, Габделбәр үзе дә Нурзидәгә, ачынып, сыкранып, тормышы турында берничә тапкыр сөйләде. Ә соңга таба нидер әйтергә теләгән кеше кебек, сүзсез генә басып тора торган булды ул. Ә бер көнне көтмәгәндә кулына төргәк тотып Нурзидәнең өенә үк килеп керде.

— Нурзидә, мин сиңа килдем. Аңласаң, бу дөньяда мине син генә аңларсың. Башка мин аның белән тора алмыйм. Хыянәтче белән. Сугышта хыянәтчеләрне берсүзсез аталар. Мәхәббәткә хыянәт итүчеләрне дә шулай эшләр идем мин. Аңла мине, Нурзидә...

— Кешедән яхшы түгел, Габделбәр.

Ул тавыш-тынсыз гына караватка утырды. Шактый сүзсез тордылар. Беренче булып Нурзидә телгә килде.

— Утыр син, Габделбәр, түргә уз,— диде ул, ныклы бер карарга килеп, үзе Габделбәрнең йөзендәге ярасына карап тора иде.

— Кыйгак-кыйгак, га-га-га-а-а...

— Ай, нинди каз бу, Габделбәр?

— Берәүләрнең берсе дә юк, ул берүзе ике оя каз асрый. Тоттым да шуларның берсен алып килдем. Мә, абзарга чыгарып яп син аны, Нурзидә. Менә монда йомыркалары.

Ул төенчекне сакланып кына өстәлгә куйды. Шул көннән алар бергә яши башладылар. Ак каз күп итеп бәбкә чыгарды. Нурзидә белән Габделбәрнең дә малайлары туды. Аңа Мирзанур дип исем куштылар.

Кояшлы җәйге иртә иде. Авыз эченнән генә җырлап, бәбкәләрне болынга куа иде Нурзидә. Каршысына Мәликә килеп чыккач, уңайсызланып туктап калды.

— Нәрсә шыңшыйсың, шатлыгың эчеңә сыймый мәллә? Шулайдыр шул. Ирле булдың бит,— дип тезеп китте Мәликә.

— Алай димә, без яратышып торабыз.

— Яратышып, имеш. Ха-ха-ха. Ярату юк бит ул, беләсең килсә, юк, юк...

— Бар... минем өчен.

Хатыннар тавышына сәерсенеп, ана каз канатларын җилпеп кычкырып җибәрде.

— Минем каз белән баемакчы булдыгызмы? — Мәликә, җиргә иелеп, җәһәт кенә бер таш алды да казга ыргытты.— Миңа да булмасын, сезгә дә...

— Нишлисең! Кансыз!..

Урамдагы тавышны ишетеп, капкадан Габделбәр килеп чыкты.

— Туктагыз, нишлисез?!

Ул җирдә хәрәкәтсез яткан ана казга карап алды да, култык таягын югары күтәреп, Мәликәгә таба атлады.

— Бер гөнаһсыз бәбкәләрне ятим калдырдың!

— Тукта, Габделбәр, вакланма.

Нурзидә иренең алдына чыгып басты.

Мәликә, нилəрдер кычкыра-кычкыра, урам буйлап китеп барды.

Бәбкәләр хәрәкәтсез яткан әнкәләрен уратып алдылар. Башлары белән канат астына төртелделәр. Нурзидә урам уртасында кычкырып елап җибәрде...

Ул акрын гына урыныннан торды, канатлары як-якка каерылган үле казны сакланып кына агач төбенә салды.

«Бусы да Мәликә үтергән казга охшаган икән. Канатларының очында берничә кара кауры бар. Шушы охшашлык үткәннәрне искә төшерде бугай. Ярар, кайткач Габделбәргә әйтермен, килен яхшылап җирләр әле үзен»,— дип уйлады ул. Казны корыган ботаклар белән каплагач, кайтыр юлына таба атлады...

«Кайтып та җиткәннәр, ә мин үзләрен каршылый да алмадым инде»,— дип уйлады Нурзидә, капка төбендә торучы җиңел машинаны күреп.

Ишегалдындагы ялгыз ата каз капка тавышына каңгылдап куйды. Нурзидә ашыгып болдырга менде, кабаланып, өй ишеген ачты.

— Кайда йөрдең син, анасы, бу гомер? Оныгың да кайтып җитте, күр менә,— дип каршы алды аны Габделбәр шелтәләүле тавыш белән.

Габделбәр, агач таягына таянып, түр якка куелган сиртмәле арба янында басып тора. Коңгырт күзләре тагын да очкынлана төшкән.

Олы оныгы Мәхмүт тә уенын ташлаган. Ятсынып кына бишектәге энесенә карый. Әтисе белән әнисе бер-берсенә карап елмаялар. Күзләрендәге елмаю бөтен йөзләренә таралган...

— Мин хәзер, атасы,— диде Нурзидә, ә үзе сиздермәскә тырышып, яулык очы белән күзендәге яшьләрен сөртте...

# ҖӘЛИЛНЕҢ РУХИ ТУГАНЫ

*Испан шагыйре Гарсиа Лорка турында*

Федерико Гарсиа Лорка...

Бу исем егерменче гасыр поэзиясендә иң зур исемнәр — Назым Хикмәт, Пабло Неруда, Поль Элюарлар белән янәшә тора. Бөек лирик шагыйрь, испан шигырен иң нечкә хисләр, тирән фикерләр, якты, үзенчәлекле образлар белән баеткан Лорка язмышында безнең сөекле шагыйребез Муса Җәлил белән дә уртаклык бар: ул да нәкъ 38 яшендә фашистлар кулыннан һәлак була. Тормышы, үлеме, иҗаты турында төрле илләрдә йөзләрчә китаплар язылган, инде легендага әверелгән шагыйрь Испаниянең катлаулы язмышы, халыкның рухы, җан халәте символы булып яңгырый алды.

Егерменче гасыр испан шагыйрьләренең язмышы, гомумән, бер-беренә охшаш; фашист диктатурасына каршы рухи көрәш, Франкога нәфрәт, республика җиңелгәч эмиграция, чит илдә үлем яки фашист төрмәләрендә газаплар, террор корбаны булу...

Испаниянең атаклы биш шагыйрен бу язмыш читләп узмаган: Хуан Рамон Хименес, Рафаэль Альберти — гомере буе эмиграциядә яшиләр. Антонио Мачадо республика җиңелгәч үк Франциягә китеп, кайгыдан үлсә, Мигель Эрнандес күп еллар фашист төрмәсе газапларын татый — аны да хаклы рәвештә Җәлилнең рухи туганы дип атый алабыз! — шунда авырып үлә, Лорка исә фашистлар фетнәсенең беренче көннәрендә үк үтерелә...

Шушы тарихи фаҗига, язмыш уртаклыгы, аның котылгысыз булуын тою, көрәшләргә, корбаннарга әзер тору — бу чор поэзиясенең үзәгендә ята һәм ул — аның трагик коллизиясе. Бу — Лермонтов язганча, «Ватанга сәер мәхәббәт»: аны ярату да һәм аның өчен ачыну да... Шуңа да Лорка һәм аның каләмдәшләре поэзиясе — чор, заман, вакыт белән сөйләшү — диалог формасы ул.

...Федерико Гарсиа Лорка 1898 елның 5 июнендә Гранададан ерак түгел авылда туган. Гүзәл һәм кырыс Испания табигате, авыл, чиксез кырлар, көтүлекләр, әфлисун бакчалары, киңлекләр — аның хыялының гомерлек юлдашы. Төрле культуралар— антик, гарәп, яһүд, чегән катнашкан Андалузия һәм Кастилия буенча сәяхәт, яшьтән үк музыка һәм фольклор белән кызыксыну, бөек әдипләр Сервантес, Кальдерон, Лопе де Вега, Гонгора, Кеведо иҗатларын өйрәнү — Лорка поэзиясенә нигез әнә шулар. Аның шигырь китаплары — «Шигырьләр», «Канте хондо турында шигырьләр», «Беренче җырлар», «Чегән романсеросы», «Шагыйрь Нью-Йоркта» һ. б. моның дәлиле. Ул сайлаган жанрлар — классик испан романсы, җырлар, элегия, мадригал, баллада, газәл, касыйдә — Лорка поэзиясенең күп кырлы булуы турында сөйли.

Фольклордан өйрәнү — Лорка өчен беренче чиратта халыкчанлык мәктәбе һәм тирәнлек, шигъри рух, дөньяны танып белү, тою үрнәге. Мәңгелек темалар — туу, үлем, көрәш, табигатькә мөнәсәбәт — Лоркага хас трагик төсмерләрдә чагыла. Бу

аның «Марина Пинеда», «Башмакчының күркәм хатыны», «Канлы туй» кебек драма, трагедияләренең дә төп сыйфаты: монда аның образлар дәвамлылыгын, шигъри принципларын, төп рухын тоясың.

Шигырьләр традицион форма һәм яңалык — социаль эчтәлек синтезы булулары белән характерлы. Әйтик, «Романсеро»дагы «Испан жандармериясе турында» романс — моның бер мисалы. Фашистларга каршы нәфрәт, кисәтү булып яңгыраган бу шигырь жандармнарга да яхшы таныш була — шагыйрь юкка гына аларның «ышанычсызлар», (гәрчә Лорка бер партиядә дә тормаса да) «кызыллар» исемлегендә булмаган. 1936 елның августында шулар ук Лорканы Гранададан ерак түгел җирдә атып үтергәннәр...

Лорка — бөтен симпатияләре, карашлары белән демократия, республика, гади халык тарафдары була, шуңа да бүген аның иseме көрәш, поэзия символы булып яши.

Бөек испан шагыйре белән таныштыру өчен, бу санда без укучыларыбызга Лорканың берничә шигырен тәкъдим итәбез.

## Федерико Гарсиа Лорка

# ШИГЫРЬЛӘР

## Кереш моң

*Прелюдия*

Тупыллар китә тора —
Күлдә кала пакь эзләре.

Тупыллар китә тора,
Калдырып безгә җилләрне.

Җилләр төнлә йоклыйлар,
Кара ефәккә төренеп,

Җилләрдән кайтаваз килә,
Елгалар аша үр менеп.

Ябырыла күч-күч бөҗәк —
Хатирәләр тына күмелеп.

Тик кала нәни йөрәк,
Уч төбемдә тиберченеп.

●

Август.
Шикәрләнгән персик, лимон уты төшә
Бал чылаткан печән теземенә.
Һәм абрикос эчендәге төштәй,
Кояш чума ахак диңгезенә.

Һәм чәкәннәр көлә качып кына,
Чиллә кызуыдай сары көлү белән.

Тагын август...
Һәм сабыйлар тоткан татлы ипи
Түгәрәк ай кушып пешерелгән.

## Йөреп кайткач

*«Шагыйрь Нью-Йоркта» дигән китаптан*

Бу калада күк гөмбәзе баса, изә,
Елан холкын белгән урамнарда,
Кристаллашып, ак таш күккә ашкан җирдә,
Чәч кыркытмый йөрим, баш — пумала.

Моңсыз агач. Сынык-гарип бармак-тармак.
Сабый йөзе — күкәй кабыгыдай.

Күлдәвекләр сәләмәсен сөйри аяк.
Шыңшый, өнсез карап, җимерек чырай.

Кыршаулары белән җанны сагыш буа.
Һәм күбәләк... кара савытында.

Йөз көн яшәп йөз кыяфәт алдым үзем.
Каргыйм кыскан, изгән ят күк йөзен.

ӘХСӘН БАЯН тәрҗемәләре.

## Гитара

Әнә башлана
гитара үксүе.
Чәлпәрәмә килә
таң касәсе.
Әнә башлана
гитара үксүе.
О, син көтмә аннан
тынлыкны,
сорама син аннан
тынлыкны!
Бертуктамый
гитара елый,
арыкларда аккан судай елый.
Кардан яз сораучы
җилләр кебек елый,
ялварма син, көтмә
тынлыкны!
Шулай елый кичке кояш таңны сорап,
шулай елый юл югалткан юләр ядрә,
шулай елый уттай кызган кайнар комнар
салкын гүзәллеген сагынып төнбоекның.
Шулай саубуллаша кошлар тормыш белән
елан угы алда торганда.
О гитара,
биш йөгерек хәнҗәрнең
бичара корбаны!

## Хушлашу

Мин киткәндә бу дөньядан —
Япмагыз балконнарны.

Әфлисун ашый балалар.
(Балконнан күрәм аны.)

Уракчылар бодай ура.
(Балконнан карыйм аны.)

Мин киткәндә бу дөньядан —
Япмагыз балконнарны.

## Ай калыккан чакта

Ай калыккан чакта
кыңгыраулар тына.
Урман сукмаклары —
чытырманлык кына.

Ай калыккан чакта
диңгез — җирнең өсте,
ә йөрәгем минем
ялгыз утрау төсле.

Ай тулганда лимон
кирәк икән кемгә?
Табыннарда — яшел,
салкын җимеш кенә.

Ай калыккан чакта,
төнге бакчаларда —
янчыкларда елый
көмеш акчалар да.

**РАЗИЛ ВӘЛИЕВ** тәрҗемәләре.

**Мостафа Ногман**

# КОШЛАР БАЗАРЫНДА

«АЙДЫН-БИКӘ» ПОЭМАСЫННАН ӨЗЕК

Болгар иленең шаулы базары,
Гөрләп тора сорнай-сазлары,
Күләгәле чуар кибетләр,
Әкияттәге кала кебекләр.

Еллар... еллар шактый эз бәргән,
Без яшәгән җирләр үзгәргән,
Калкып чыккан яңа биналар,
Кешеләре башка, кем алар?
Дөнья чарыгы иренеп тормаган,
Бик күпләрнең гомерен урлаган,
Ә табигать — һаман бертөсле,
Мәрхәмәте чиксез, дөресле.
Мин уйларым белән калып тын,
Кошлар базарына юлыктым,
Хәйран булып торам, ходая!

Читлектәге кошлар моңая.
Бер таныш моң ишетәм кинәттән,
Агыла ул моң зарлы йөрәктән,
Чыңлап куя сазның моңнары,
Әкрен генә сызыла җырлары:
«Сагыну-сагыш тәяп күңелемә,
Кайтып килдем Болгар илемә...»

Мин сискәнеп киттем, ни шатлык!
Җыр иясен таптым ошатып,
Шул көй иде! Нәкъ шул җыр үзе!
Мөлаем карт икән!
Бер үзе
Уенсазын чиртеп тын гына,
Килде тоткын кошлар янына

---

«Айдын-Бикә» поэмасы — мәрхүм шагыйрь Мостафа Ногманның иң соңгы әсәре. Зур күләмле бу поэма ерак Болгар чорларыннан алып язылган, рухы белән романтик дастанга охшаш. Без бу санда шул поэманың бер өлешен укучыларыбызга тәкъдим итәбез.

Сиздермәскә теләп ничек тә,
Мин күзәтеп торам бер читтә.

Кошчыга карт әйтә шелтәсен:
— Син — бай кеше, читтән үтәсең,
Мин кош базарына килгәндә,
Алмый китмәсемне белгәнгә,
Комсызлыкның китереп хәйләсен,
Күтәрәсең кошлар бәясен!
Ул әрнүле ясап омтылыш,
Сайлап алды ике былбыл кош.

— Читлекләре нинди тимердән,
Мескеннәрем күпме тилмергән!
Хәзер-хәзер сезне коткарам,
Озак серләшергә юк арам.

Каенсарның тавы буенда,
Күкрәп үскән гөлләр куйнында,
Бер ялкынлы йөрәк күмелгән,
Шул йөрәкнең кайнар көленнән
Ике сәрби үскән бергәләп,
Ике йөрәк хисен бүлгәләп,

Шул сәрбигә кунып һәр таңны
Шатландырып мәрхүм апаңны,
Сайрашыгыз бергә, мин көтәм!

Кошлар очып китте читлектән.
Ике нокта уйный һавада,
Карт елмаеп карый аларга:

«Кешеләргә дә килер азатлык,
Илебездә балкыр зур шатлык!»

Моңсу күзләр балкый мөлаем,
Бик бәхетле кебек ул даим.

Уенсазын алып кулына,
Карт атлады китәр юлына.
Мин эзеннән барып бер атлам,
Бик сак кына дәшеп туктатам:

— Кичерегез, димен, бер кичтә
Мин ирешкән идем зур хискә!
Җырлаганны сезнең тыңладым,
Бу тылсымлы җырның моңнарын
Кичерә белә тик зар иясе,
Ә соң сезне кем, кем диясе?

Карт әсәреп миңа күз йөртте,
Һәм күңлендә саклап иркне:
— «Тәфтишләмә, диде, син ансын,
Кем булуым сиңа сер калсын!

Минем дә бар иде яшь чаклар,
Ялкын тулы кайнар кочаклар,
Таң калырлык сөйгән бер ярым,
Хәтерләсәм, сызыла уйларым.
Ул — гыйшкында янды хисләнеп,
Бу уенсаз — аннан истәлек!»

Яшь пәрдәсе сарган күк булды,
Тик ул аннан бик тиз котылды,
Күзләренә очкын, ямь биреп:
— «Ә мәхәббәт, диде, мәңгелек!
Буыннардан күчә буынга,
Бизәк өсти һәрбер урынга!

Ярым янды күптән утларда,
Мәхәббәтем күчте кошларга!
Мәхәббәт ул бөек бер тәңре!
Ул сихердә көчнең һәр әмре —
Якты бер шәм безнең каршыда,
Аңа табынып яши барсы да.
Җирдә хәят ерак көннәрдән
Шул бөек көч белән бизәлгән:
Ал таңнарга булган мәхәббәт,
Чын ярларга булган мәхәббәт,
Күркәм иргә булган мәхәббәт,
Болгар илгә булган мәхәббәт...

Мәхәббәтнең офыгы чикләрсез!
Кешеләр юк җирдә хисләрсез.
Хисләр ташып тора һәр халәт.
Җирдә шаһлык итә мәхәббәт!

# ХӘТЕРНЕҢ КАЙНАР КҮМЕРЕ

*Рус язучысы Михаил Зорин «Лампам минем сүнмәс» дигән истәлекләр китабы бастырып чыгарды. Анда ул Федор Гладков, Михаил Светлов, Михаил Исаковский, Всеволод Иванов һ. б. турында яза. Авторның Муса Җәлил турындагы истәлеге дә шушы китаптан алынды.*

— Учыңны күмер катлавына куйсаң, җылы бәрелгәнен тоярсың,— диләр шахтерлар.

Мичтә янган өй җылысы түгел. Өй җылысы, гамьсез-ялтыравык кафель салкыны калдырып, тәүлек тулганда гына бетә, ә күмер катлауларыннан, тирәннән килгән җылы, үзендә күзгә күренмәс тәшвишле, тынгысыз ялкын яшергән катлаулар җылысы сүнми дә, сүрелми дә.

Кеше хәтере дә шулай. Узып киткән елларның хатирәләрен, кичке шәфәкъ утында алланган урман буен, әнкәләребезнең елмаюын, аталарыбызның моңлы җыр сузуын, яшь йөрәкләрнең очрашуын, хәсрәтле сугыш елларын, ут чолгаган станцияләрдә балалар елавын саклый ул хәтер. Ялгызлыкның авырлыгын һәм яшәү шатлыгын тою — күмер катлавыннан килгән кайнарлыкны хәтерләтә!

Син тормышның ерак юлларында очраткан кешеләреңне күрәсең, аларның тавышларын ишеткәндәй, дусларча кул кысуларын, яратып аркаңнан кагуларын тойгандай буласың: әйдә, атла, курыкма. Алар, барын да яхшы итеп эшләдеңме дигәндәй, акыллы күз карашлары белән сине күзәтеп торалардыр кебек.

О, хәтернең кайнар күмере! Синең тәшвишле, тынгысыз ялкының беркайчан да сүнмәсен, һәрвакыт көйдереп торсын.

...Башка китаплар арасында ул үзенең «Моабит дәфтәре» дигән исеме белән күңелне тартты. Фашист төрмәсендә язылган шигырьләрне укый башладым. Исеменә яңадан кат-кат карап алдым: Муса Җәлил. Һәм укуымны дәвам иттем. Хәзер бу шигырьләрне бөтен дөнья белә.

Китапта авторның рәсеме дә бар: яшь, түгәрәк йөзле, җитди, ләкин ирен читләренә елмаю кунган. Кара чәчләрен кыектан ачып тараган, галстугын утызынчы еллардагыча зур төен ясап бәйләгән. Бар җире гади. Тик күзләре генә... Күзләре җанлы, акыллылык бөркеп тора. Йомшак елмаю һәм шаянлык бар аларда. Мин китапны алып өйгә киттем. Бу җанлы күзләрне элегрәк тә кайдадыр күргән кебек идем. Аның көлгән чагын да, хәсрәтле һәм ачулы, уйчан вакытын да күрдем кебек.

Һәм шунда, гомер катлаулары арасыннан утлы күмер җемелдәп куйды... Хәтернең кайнар күмере...

Мин Казанга танылган татар шагыйре Әхмәт Исхакка хат яздым.

«Хатыгызны укыгач, 1939 елның сентябрендә, язучыларның Одессадагы иҗат йортында Муса Җәлил белән бергә булган кадерле көннәрне тагын бер кат искә төшердем...»

Әхмәт Исхак күп нәрсәне хәтерли икән.

«Одесса театрында без «Фауст»ны тыңладык. Миндә Муса Җәлил белән төшкән берничә фото сакланган. Украин язучыларының шул вакытны иҗат йортында ял итүче хатыннары җыелып төшкән фото да бар. Икенче каттан вестибюльгә төшкәч, баскыч янындагы бүлмәдә Владимир Сосюра үзенең искиткеч шигырьләрен һәм Иван Франко

шигырьләрен укыганны да хәтерлим әле. Вестибюльдә үткәргән күңелле кичләр дә истә. Муса мандолинада, ә язучы хатыннарының кайсыдыр берсе пианинода уйный торган иде. Барыбыз да җырлыйбыз, биибез. Ә Муса мондый кичләрнең һәр вакыт үзәгендә була... Мин шушы кичәләрне оештырган шагыйрь, көр күңелле, шаян кеше Павел Матвеевич Усенконы да яхшы хәтерлим. Хатыны белән улы янына берме, икеме тапкыр балалар язучысы Ковальчук килеп китте. Муса ул малайны бик ярата һәм аның белән еш кына уйный торган иде...»

Бу хат көньяк кояшының эссесе бөркеп торган үткән еллар хатирәсен алып килде.

Муса Җәлил — бөтен дөньяга билгеле герой-шагыйрь, зур батырлыкка ия булган кеше — әле Моабит төрмәсе дә, Гитлер эшафоты да күренеп тормаган яшьлегенә кайтты... Одессага Муса Җәлил Казаннан 1939 елның августында үзенең якын дусты, талантлы татар шагыйре Әхмәт Исхак һәм аның хатыны Зәйнәп белән килгән иде. Үз дуслары белән Муса Җәлил язучыларның иҗат йортына урнашты. Икенче катта яшәде.

Иртәнге ашка яхшы костюмнан, җете ак күлмәктән килеп керде. Йөзе тыныч, елмаюлы. Төшке аш җиткәндә инде барысы да аның Муса Җәлил дигән шагыйрь булуын, Казаннан килүен, Одессаны ике сәбәп белән яратуын белеп алдылар. Сәбәпләре: бередә Пушкин «Евгений Онегин»ның берничә бүлеген язган һәм монда «Потемкин» броненосецының восстаниесе булган.

— Одессаның яратыр җире күп. Сез ничек уйлыйсыз? — дип көлә Муса.— Литфондта миңа Одессага июльдә барырга тәкъдим иткәннәр иде, баш тарттым. Эссе, курорттагы кебек тәртип... Сентябрьдә килдем... Сентябрь — шатлык ае...

Хәтер күп нәрсәне саклаган: шагыйрьнең кызу адымнарын, дәртле сөйләмен, кешеләр белән мөгамәләсендә ихлас күңелле булуын, шигъриятне яратуын... Бусы аның шигырь укыганда да, шигырь һәм шагыйрьләр турында сөйләшкәндә дә, үзе язган юллардан да, шигырь китапларын укыгандагы уйчанлыгыннан да, иҗади серләрен бүлешкәндә дә күзгә күренеп сизелә иде. Менә ничә көн инде шигыренең бер юлын яза алмый интегә. Каләмгә бака кебек салкын, чирканыч, шома сүзләр эләгә, ул аларны куа, ә алар аның бүлмәсендә яшәүләрен дәвам итәләр, әрсезләнеп кәгазенә дә сикерәләр, күрәсең.

Озак та үтмәде, иҗат йортында яшәүчеләрнең яңа кешеләр белән танышу һәм рәхәт ялдан туган яхшы кәефләре кинәт үзгәрде. Без Гитлер Германиясенең Польшага каршы юлбасарларча сугыш алып баруы турында ишеттек. Беренче каттагы холлда иртәнге аш алдыннан Варшаваны бомбага тотулары турындагы хәбәрне радиодан тыңладык.

— Бетте, дуслар! Икенче бөтендөнья сугышы башланды, — дип авыр сулап әйтте Муса Җәлил.

Кояшта инде шактый каралган тәбәнәк буйлы Муса украин шагыйрьләре Владимир Сосюра һәм Павел Усенко белән янәшә басып тора иде.

— Иртәме, соңмы, моны күтәргә кирәк иде, — дип дәвам итте ул.

Кешеләргә бер-берен аңлау, бигрәк тә дуслашу өчен беркадәр ара кирәк. Вакыт арасы, хисләр арасы, эчке җылылыкны, ихтыяр көчен, дуслыкның, якынлыкның кирәклеген тояр ара.

Муса Җәлил шундый араны санга сукмый торган кешеләрнең берсе иде. Ул тиз якынлаша, чөнки үзе, беренче булып, кешеләргә җылы караш һәм дуслык бүләк итә. Бернинди иркәлек, тәкәбберлек, бернинди мещанлык һәм ялганлык юк аңарда.

Одесса педагогия институтыннан Владимир Сосюраны кичәгә чакырып һәм анда шигырьләр укуын үтенеп студентлар килде.

Кызлар Владимир Николаевич Сосюраны өеннән чыгып килгән җиреннән баскычта очраттылар. Аклы-каралы шакмаклы күлмәге, алтынсу озын толымнары белән берсе бик истә калган.

Ул бертуктаусыз:

— Владимир Николаевич, зинһар өчен килә күрегез,—дип үтенә торды.

Сосюра кызлар чолганышында җиргә төшеп туктады. Шул вакыт аларга Муса Җәлил очрады. Сосюра аны кулыннан тотып алды да, кызларга борылып:

— Бу Татарстан шагыйре Муса Җәлил була. Аны да алыйк,—диде.

— Алабыз.

— Без бик шат.

— Үтенәбез...

Толымлы кыз катгый итеп:

— Без сезне алырга килербез, — диде.

Сентябрь булса да, көньякның җылы көннәре әле. Кара диңгез яры буенда бик тиз генә җитди һәм шаян әңгәмәләр башланып китә, шигырьләр укыла, төрле кызыклы хәлләр сөйләнә. Кинәт кенә Сосюра:

— Хәзер, менә шушы минутта, кемне яратасың?—дип сорады. — Уйлап торма, мәхәббәт уйлаганны көтми...

— Одессаны һәм бер ханымны... анысын әйтмим,—дип Муса җитди җавап бирде.

— Ә минем аның турында күпме томнар язганымны алла үзе генә белә,— дип көлде Сосюра.

— Одесса турындамы?—дип аңламаганга салышты Җәлил.

— Ул ханым турында,—дип ямансу тон белән әйтте Сосюра.

Иҗат йортында язучылар шаян шигырьләр, эпиграммалар, мәзәкләр һәм гади генә итеп рәхмәт сүзләре язган китап бар иде.

Бер яшь язучы иҗат йорты белән саубуллашып, үзенең тойгыларын шигырьгә салган. Шигырен акка күчереп утырган егет янына Муса килде дә карап тора башлады:

**Одесса — матур дамалар шәһәре,**
**Одесса — эпиграммалар шәһәре,**
**Одесса — демонстрацияләр шәһәре,**
**Одесса — нәфис грацияләр шәһәре,**
**Әдәби вариацияләр шәһәре.**
**Исемнәрдән күзләр камаша:**
**Багрицкий, Пушкин, Олеша,**
**Катаев, Петров һәм Инбер,**
**Артык сүз кирәкми һичбер.**
**Одессада зәп-зәңгәр күк,**
**Одесса матур чәчәк күк.**

Җәлил яшь егетнең иңенә кулын салды да язганнарын тиз генә укып болай диде:

— Тукта, бир әле каләмеңне,—һәм шунда өстәп куйды:

**Одесса — Ватаным күрке булса,**
**Барысы белән дә риза — Муса.**

Истәлекләр язылган китапны актарып чыккач, Муса башын чайкап куйды:

— Бер фикер килде әле: «Одесса язучылары һәм язучылар Одесса турында» дигән җыентык чыгарасы бар. Менә дигән китап булыр иде ул!..

Һәм ул Эдуард Багрицкийның озын шигырен һич төртелмичә күңелдән укый башлады:

**Клыкастый месяц вылез на востоке,**
**Над соснами, костяками скал...**
**Здесь он стоял...**
**Здесь рвался плащ широкий,**
**Здесь Байрона он нараспев читал...**

Муса шигырьне сөйләп бетерде дә, китапны күкрәгенә кысып, хыялланып әйтте:

— Ул җыентыкны «Александр Пушкиннан Григорий Захаровка чаклы» дип атаргадыр бәлки.

Григорий Захаров — Одесса шагыйре. Аз сүзле, тыйнак, уйчан — иҗат йортына еш килеп торды.

Җәлил Одессада туып үскән язучылар белән очрашуларын исенә төшерде. Барыннан да күбрәк Багрицкий турында сөйләде.

— Ул минем шигырьләремне тәрҗемә иткән иде,— дип горурланды Җәлил.— Бервакыт квартирасына бардым. Багрицкий китап укып утыра, үзе тәмәке тарта. «Чакырылмаган кунак татардан яман»,—дидем мин. «Барлык мәкаль дә акыллы һәм

үткен дип әйтеп булмый»,—дип җавап бирде Багрицкий. — Күбесе искергән... Бу мәкальне яратмыйм мин. Кара әле, бәләкәй татар малае,—ул вакытта мин тагы да тәбәнәгрәк идем,—берәр шигыреңне үз телеңдә укы әле».

Мин укыдым...

— Тагын,—дип үтенде Багрицкий.

— Безнең телне беләсезме әллә?

— Юк, ләкин телдәге рифмалар, ритмнар синең шагыйрьме, түгелме икәнлегеңне сүзләргә караганда күбрәк әйтә беләләр...

Мин тагын бер шигырь укыдым.

— Мәхәббәт турында ничек язасың?

— Аңламыйм сезне,—дидем уңайсызланып.

— Китаптагычамы?

Багрицкий миңа карап торды да:

— Кешегә иярмә, үзеңнең хисләрең турында яз, хисләреңне ачудан курыкма, мәхәббәт турында мещаннарча язу ялган, мәгънәсез, пычрак эш. Нәрсә ул мәхәббәт?

— Онытылумы?—дип сорадым.

— Башыңны югалту. Бер сүз белән әйткәндә, безне ярата торган иркә кызлар һәм яшь хатыннар яшәсен. Хатын-кызга карата ничек син?—дип сорады кинәт Багрицкий.— тотнаклымы?

— Ни мәгънәдә әйтәсез!

— Тиз игътибар итәсеңме, әллә бик үк тиз түгелме? Игътибар ит... Ярат... Шатлан...

Муса Җәлил күзләрен йомып тора да кинәт кенә барыбызга да шаян караш ташлый.

Бу шәһәрдә үзеңне кояшка, диңгезгә, хатын-кызларга, тормышка гашыйк булган Грин матросы кебек хис итәсең... Шайтан алгыры, тыелгысыз шатлык җитми безгә...

Владимир Сосюра үзенең шигырьләрен укыды, автобиографик зур поэма язуын әйтте. Хәтердә ике юлы калган:

**Минем бабамның бабасы Густав Сосюра булган,**
**Ул Прованса дигән якта туган.**

Бу поэма язылып бетеп басылганмы, юкмы, белмим, ләкин тантаналы бер тынлыкта Сосюраның шигырьләрен тыңлавыбызны яхшы хәтерлим. Шагыйрь, укудан туктап, кайбер юлларына аңлатма бирә иде.

Муса Җәлил Оренбургта булган бер хәлне көлеп сөйләде. Гражданнар сугышы барган елларда бервакыт иптәшләре белән мәдрәсәдән чыгып, алар акгвардияче казачий полковник Дутов гаскәрләренең мәчет һәм кәрвансарай янынна үтеп барганнарын карап торалар икән. Офицерлардан берәү дошми генә басып торган татар малайларына бармак төртеп күрсәтә дә көлеп:

— Әй, Чыңгыз хан нәселе, пычакларыгыз, кинжалларыгыз кая сезнең? — дип кычкыра.

Муса күзен кысып көлеп куйды:

— Ә без, Оренбург губернасы халкы, барыбыз да Пугачев нәселеннән. Пугачев вакытында Оренбург далаларында яшәүче барлык татарлар — оста мәргәннәр, кыю егетләр Пугачев белән киткәннәр. Әбием дә, әнием дә пугачевчы-татарларның буыннан-буынга күчеп килгән җырларын хәтерлиләр иде әле... Астраханьда туып Казанда яшәгән ата мәче турында җырлап күрсәтимме?

...Ике көннән студент кызлар кичәгә чакыра килде. Шакмаклы күлмәк кигәне дә бар иде. Сосюра белән Муса мине дә үзләре белән алып киттеләр. Студентлар Сосюраны шатланып каршы алды. Ул Мусаны да сәхнәгә менәргә кыстады, ләкин Муса, кулын селтәп, залда калды.

Сосюра дәртләнеп укыды. Муса башын алга сузып, игътибар белән тыңлап утырды. Шигырьләр аны дулкынландырган иде.

— Сосюрадан соң чыгыш ясап булмый...— диде ул.

Трамвайда бик соң гына кайттык. Муса студент яшьләр, Кара диңгез, гүзәл Одесса турында исе китеп сөйләде.

— Әдәбиятта, бигрәк тә поэзиядә «Потемкин» броненосецын кинода күрсәтелгән кебек көчле итеп язганнары юк әле,— диде Муса.— Ни өчен кызыл Одессага

ярдәмгә килгән француз матрослары турында поэмалар юк? Изге китапларда ходайның иң зур җәзасы итеп халыкларны бер-береннән аеруы турында язалар. Ә безнең идеяләр кешеләрне берләштерә. Мин коръәнне яхшы беләм, бала чактан ятладым,— диде һәм көлке итеп бармагы белән маңгаена төртеп алды.

Мин ул вакыт Муса Җәлилнең шигырьләрен, аның тормышын, үткәнен белми идем әле. Татарстаннан килгән шагыйрь — мин белгәне бары тик шул. Шат күңелле, шаян җырчы, һәр вакыт төрле кызыклар уйлап табучы, кешеләр белән тиз аралашучан, гади, бераз мәзәгрәк, яңгыратып көлә торган, елмаючан бу шагыйрь очрашкан бер кешесен үзенә әсир итә.

Бер йортта — ашханәдә, диңгез ярында, холлдагы ял сәгатьләрендә, әдәби һәм политик бәхәсләр вакытында, бик гади, көндәлек хәлләр турында сөйләшкәндә — бер ай буена аралаша торгач, кешенең характеры, аның тирә-яктагылар белән аралашу манерасы, стиле, күп нәрсәгә карашы бик ачык беленә. Ә Муса Җәлилнең тынак гадилеге, тормышны яратуы аның әйбәт кеше булуын сөйли иде.

Кичләрен Муса Җәлил:

— Үзебезнең учакка киттекме? — дип әйтә.

Шунда җыелып шигырь укый, җырлар җырлый, музыка тыңлый торган бүлмәне татарлар шулай дип йөртәләр иде.

Барыбыз да Муса әйткәнчә итеп:

— Бүген учакта бик күңелле булды,— дип раслыйбыз.

Ул вакытта Украинада, хәзерге Донецк шәһәрендә татар газетасы чыга иде. Газета каршында әдәби берләшмә эшли. Донбасс шахтерлары арасында татарлар күп. Аларның берсе — Гыйльфан Батыршин 1938 елны Хасан күле янындагы сугышта дан казанды — Советлар Союзы Герое дигән бөек исемгә лаек булды.

Муса Җәлил аның турында белә иде. Педагогия институтыннан кайткан кичне:

— Донбасстагы якташларым янына килеп торырга һәм шигырьләр яки берәр поэма язарга күптән хыялланам. Мин, әлбәттә, татарлар турында гына язмаячакмын. Мин руслар, украиннар турында, шунда бергә эшләгән бар халык турында язармын. Шагыйрь үз телендә иҗат итсә дә, аның йөрәге һәм шигырьләре бар халыкныкы булырга тиеш. Билгеле, әгәр ул рухы белән шундый шагыйрь булса,— дип сөйләп кайткан иде.

Одессада сентябрь елның иң матур аедыр, мөгаен. Әле эссе, әмма көйдереп алмый, хәлсезләндерми, җимеш агачлары уңыштан сыгылып төшкән, бөтен җирдә алма исе, бар җир яшел, өлгергән, җәй көнендәгечә шау-шулы һәм күңелле.

Кара диңгез үз җылысын акрынлап киметә, кайвакыт штормлап ала, ләкин зур давыл әле алда буласын сизенеп күбесенчә тын тора. Яр буен балыкчы шаландалары сырып алган, Одесса малайлары балык сатып йөри. Иҗат йортына ук китерәләр. Малайлар, чын сәүдәгәр кебек, товарларын мактый-мактый кыйммәт бәя сорыйлар, Муса сатулашмый-нитми ала.

— Ник шулай кыйммәт түлисең, Җәлил иптәш? — диләр хатыннар.

— Акчаны мин балык өчен түгел, Кара диңгез жаргоны өчен түлим. «Әй, ханым, карасаң күзлегең салып, күрерсең симез балык»... дип, Җәлил малайлар кебек тәкмаклый.

Муса Җәлил күп вакытын дусы Әхмәт Исхак белән үткәрә иде. Бервакыт Әхмәт су коенганда бик ерак йөзеп китә. Кинәт диңгез дулкынлана, шаулый, кайный башлый. Дулкыннар Әхмәтне тагын да эчкәрәк алып керәләр.

— Коткарыгыз! — дип кычкыра Әхмәт.

Ярдагылар куркып, каушап калалар.

Муса беренче булып суга керә, очлы ташларга басмаска тырышып, дусына ярдәмгә ташлана. Ләкин дулкын аны кире чигендерә. Муса ярдагыларга карап ала да кискен итеп:

— Кулга-кул тотынышып тезелик! — дип әйтә.

Барыбыз да суга керәбез һәм Әхмәт Исхакны коткарабыз.

Шул көнне Әхмәт Исхак шигырь язып, аны Муса дусына укый. Шигырь: «Без сине җиңдек, диңгез»,— дип атала. Михаил Львов тәрҗемәсендә бу шигырь Әхмәт Исхакның русча чыккан барлык җыентыкларында да басыла.

Диңгезне Муса ниндидер бер хәстәрле ярату белән ярата иде.

— Кара диңгез буенда яшәүчеләр нинди бәхетле, монда мин көн саен бер шигырь язар идем,— дип шаярта ул.

Муса Җәлил Одессага гаиләсеннән башка килгән иде. Без аның белән икенче катта, күрше бүлмәләрдә тордык. Минем ялгыз яшәвемне белгәч, әле барысы да йоклап яткан кайбер иртәләрдә дә ул әкрен генә ишегемне шакый торган булды:

— Кузгал, буйдак, коеныргa киттек...

Иртәнге аш алдыннан радионың сәгать алтыда биргән хәбәрләрен сөйли. Европада Гитлер Германиясе башлаган сугыш барганга Мусаның яңгыравык тавышын тыңларга бик күп кеше җыела иде.

Шундый иртәләрнең берсендә ул минем бүлмәнең ишеген ачты.

— Кызыл Армия Көнбатыш Украина белән Көнбатыш Белоруссия халкына ярдәмгә кузгалды,— диде ул.

Бу хәбәрне ишеткәндә кырынган чагы булган, ахры — бер ягында сабын күбеге, кулында ялтыравык пәке.

Радиодан Михаил Светлов, Лебедев-Кумач һәм Павло Тычина шигырьләрен укыйлар. Нык бәдәнле, кояшта янган Муса исә ак майкадан басып тора һәм кыенсынып әйтеп куя:

— Ә мин монда лирика язам — Кара диңгез, мәхәббәт... Ял белән хушлашырга вакыттыр, ахры,— ди.

Бу кичне ул мандолинада ниндидер моңлы, кайгылы көй уйнады. Башын кыек салып, тирән сагыш белән мандолина кылларына караган иде.

Китәр алдыннан ул барыбыз белән дә саубуллашып чыкты. Һәркайсыбызга җылы сүз тапты. Тәшвишле, сугыш еллары иде бит. Икенче бөтендөнья сугышы бара. Гитлерчылар Польшаны таптыйлар.

Җәлил, борынгы гадәт буенча, юлга кузгалыр алдыннан чемоданын куеп утырды.

— Өйгә кайтырга вакыт, Казанга... Ял иттек... Сентябрь шатлыклы ай...

Сүзләре ничектер бик моңсу, күңелсез булып ишетелде.

Аннары, кузгалып, чемоданы өстенә плащын куйды да, ашыгып диңгезгә төште, учы белән су алып юынды. Чәчләре юешләнеп, елмаюлы йөзеннән су тамчылары тәгәрәде.

— Әй, Кара диңгез!.. Әйбәт диңгез!..

Кулларын селтәп су тамчыларын койды:

— Үзем белән алып китәр идем шул диңгезне...

— Алып кара! — дип янаган булды Владимир Сосюра.— Идел генә азмы әллә сиңа?!

Муса ташка басып юына, дулкыннар аның туфлиләрен чылата, ә ул, шушы ярда соңгы кат басып торуын, соңгы кат диңгез белән хозурлануын сизгәндәй, аерылып китәргә теләми.

— Әй, Кара диңгез!.. Әйбәт диңгез!..

Һәм иелеп торган җиреннән безгә шаян караш ташлый.

Юк, өметсез һәм сагышлы аерылу булмады бу. Шулай чын күңелдән хушлашу — Мусаның гадәтендә икән.

Иртән Мусага балык сатучы теге ике малай йөгереп килде. Кулларында киптереп бауга тезгән балыклар. Алтын сыман кабыклы, зур, симез балыклар. Сайлап тезгән күк.

Верандадан бер хатын:

— Малайлар, балык сатасызмы? — дип кычкырды.

— Юк,— диде аларның берсе, күңелсез генә.

Таш баскычлардан күтәрелеп бүлмәгә керделәр дә, уңайсызланып, туктап калдылар.

— Кая керәсез? Кара син, спекулянтларны, бүлмәгә үк керәләр...— дип кычкырды аларга өй җыештыручы хатын.

— Без Муса абый янына.

— Муса абыегыз юк бит инде, китте Муса абыегыз...

Икенче каттан төшеп, моңаеп калган малайлар янына Сосюра килде:

— Чыннан да... китте ул...

— Без аңа балык китергән идек, юлга дип.
— Товарыгыз әйбәт, сатыгыз,— дип киңәш итте өй җыештыручы.
— Сатлык түгел... Муса абыйга дип әйткән идек...
Һәм саубуллашып та тормыйча, күңелсезләнеп китеп бардылар.
Верандадагы хатын гына әле һаман:
— Малайлар, күпме сорыйсыз? — дип артларыннан кычкырып калды.
Малайлар дәшмәделәр. Әйләнеп тә карамадылар.

1945 елның язында совет гаскәрләре Моабит төрмәсен азат иттеләр. Камера-каберләр, казаматлар, җәзалау бүлмәләре, сулы карцерлар, күселе карцерлар, дүрт стенасы да токлы — сәялеп кара! — карцерлар, үлем җәзасына хөкем ителгәннәр камерасы, көчле прожекторлар белән яктыртылган — күзне сукырайта — камералар, тоткыннарга тәҗрибә ясый торган камера-лабораторияләр.

Китаплар аунап яткан төрмә китапханәсендә сугышчылардан берәү иданнән немец китабын алды. Китапның соңгы битенә русча язылган көйдергеч сүзләр бар: «Мин — танылган шагыйрь Муса Җәлил, сәясәт өчен Моабит төрмәсенә ябылдым һәм атылуга хөкем ителдем... Минем сәламемне А. Фадеевка, П. Тычинага, туганнарыма тапшыруыгызны үтенәм».

Моабит төрмәсенә Муса Җәлил ничек эләккән? Моабитның дәһшәтле камераларына кадәр нинди канлы юллардан үткән ул?

Старая Руссо районындагы сугышларда авыр яраланган Муса Җәлилнең әсирлеккә төшүе билгеле.

Шагыйрьнең шигырьләрен укыганда аның «Двинага» дип аталган шигъри мөрәҗәгатен дулкынланып кабатладым. Шигырь астына 1943 елның октябре дип куелган.

**Двина, әгәр синең агымыңны**
**Борып булса иде кирегә,**
**Дулкыныңа төреп бу гәүдәмне,**
**Алып китәр идең илемә.**

Мин Ригадагы ул кичне, шигырьдән алган тәэсирләрем белән Иске шәһәр урамнарыннан Даугавага барган чагымны яхшы хәтерлим. Яшьлегемдә очраткан кешем турындагы истәлекләр икенче мәгънә алды. Шагыйрь Муса — шат күңелле, шук кеше, тормышка, диңгезгә, хатын-кызларга, балаларга гашыйк, шәфкатьле иптәш, җырчы — бу Муса Җәлил хәзер миңа бөтенләй икенче кеше булып күренде. Аны мин героик тормышы, концентрацион лагерьларда һәм гитлерчылар төрмәләрендә язган шигырьләре буенча таныдым.

Муса Җәлил Ригада булган микәнни? Аның урамнарын күргән, Даугавага карап торган, урман шавына колак салган микәнни?

Болар барысы да дулкынландыра, тынгылык бирми иде. Бу турыдагы материалларны ничек эзләргә? Каян башларга?

Һәм мин шул уйларым турында тагын Казанга, Муса Җәлилнең дусы Әхмәт Исхакка яздым. Ул бик озак җавап бирмәде, соңыннан белдем, больницада яткан икән. Старая Руссода яраланып әсир төшкәч нинди юллар үтүе турында Җәлилнең шигырьләре бераз сөйли, дип язды ул. Әхмәт Исхак Җәлилнең Одессада төшкән фоторәсемен дә җибәргән иде. Тагын ике картина күз алдыма килеп басты: берсе елмаеп пижамадан басып тора, дөньядагы бар мәшәкатьләрне онытып ял итүче, икенчесе — гимнастеркадан, рәхимсез сугышларга әзер торучы сугышчы-политработник, әсир шагыйрь, герой шагыйрь. Шушы ике образ бергә кушылып, әле дә булса күңелемдә саклана.

Озакламый Әхмәт Исхак хатыны Зәйнәп һәм кызы Алсу белән Ригага килде. Исхак Җәлилгә багышланган әдәби-биографик очерк яза иде.

Муса Германиягә озатылыр алдыннан Латвиядәге концентрацион лагерь аша узгандыр, дигән фикерне ул да әйтте.

Мин хәрби трибунал тарафыннан фашист җинаятьчеләренә Ригада уздырылган суд процессының стенографик отчетын ашыкмыйча, игътибар белән укып чыктым. Андый материалны укуы җанга тия. Юридик төгәллек белән язылган, бөртекләп

жыйналган, дереслеге расланган җинаять, көчләү, үтерү, вәхшәтлек фактлары бәгырьне телгәли, йөрәкне ачынып сикерергә мәҗбүр итә, тынны буа, һәм син тамакка ябырттырып төен утырганын сизәсең. Җинаятьчеләрнең үз күрсәтүләрен укуы аеруча авыр булды. Бу отчетларда Гитлер генералларының педантларча төгәллек белән сөйләгән сүзләре: күпме совет кешеләрен атканнар, күпмесен асканнар, ачлык белән җәфалаганнар, җәзага тартканнар, качып барганда атканнар. Бу «статистика» котны алырлык. Күп санлы күрсәтүләр арасында Балтик буендагы Гитлер палачы генерал Еккельн шаһитлегенә тап булам: Латвиядәге концентрацион лагерьга Ленинград, Волхов фронтларында әсир ителгән сугышчыларны китерделәр.

Старая Руссо янында каты сугышлар барганда Гитлер генералы — Волхов фронты тылының начальнигы — совет хәрби әсирләрен Рига янындагы лагерьларга җибәрүне таләп итә.

Үзе дә Саласпилстагы концлагерьның дәһшәтле көннәрен кичергән латыш журналисты Карлис Сауснитис та: «Совет Армиясенең әсирлеккә төшкән сугышчылары Саласпилс үлем лагеренең корбаны булдылар»,— дип язды.

Татар язучылары Гази Кашшаф һәм Рафаэль Мостафин герой шагыйрьгә багышлап язылган «Эзләнү дәвам итә» дигән китапларында Муса Җәлил яралана һәм 1942 елның 26 июнендә гитлерчыларга әсирлеккә төшә дип язалар. Мин Саласпилс лагере турындагы күп санлы материалларны укыдым, шушы тәмугта җәфаланган күпләгән кешеләрнең сөйләгәннәрен тыңладым һәм нәкъ 1942 елның җәендә лагерь баракларына Волхов фронтында әсир ителгән совет сугышчыларын китереп ябуларын ачыкладым.

Муса Җәлил әсирлеккә төшүен авыр кичерә. «Әсир» сүзе үзе үк аңа хурлык, кабахәтлек, түбәнлек тамгасы булып тоела. 1942 елның июлендә ул «Кичер, илем» дигән шигырен яза. Бу шигырь ачы кайгылы да, тирән сагышлы да һәм кыю да яңгырый.

Хәсрәтле юллар... Ләкин өметсез түгел, өмет белән яктыртылган:

**Волхов шаһит, изге сугыш антын**
**Соң чиккәчә керсез сакладым.**

Бу шигырендә Муса Җәлил концентрацион лагерьның чәнечкеле тимер чыбык белән әйләндереп алган коймаларын яза да, анда Муса һәм аның иптәшләренең качарга әзерләнүе турындагы юллар бар.

**Тик бер өмет: кара август төне**
**Илтер мине шунда җитәклэп.**
**Өстен килер түбән әсирлеккә**
**Үч һәм илгә керсез мәхәббәт.**

Документлар һәм Саласпилс тоткыннарының күрсәтүләре төрле вакытларда лагерьда каршылык күрсәтүче яшерен группалар төзелүе һәм әсирләрнең качып китү очраклары турында сөйлиләр. Шундый качуларның берсе нәкъ менә Муса Җәлилнең лагерьда булган көннәренә туры килә. Шагыйрь яшерен группалар белән тыгыз элемтәдә була, һәм әсирлектән качучыларга ярдәм итә. Җәлил үзе дә качарга әзерләнә, ләкин өлгерә алмый, аңа хыянәт итәләр.

Саласпилс тоткыннарының сөйләгәннәрен — фаҗига һәм газаплар турында, батырлык һәм ныклык, мәхәббәт һәм нәфрәт турында сөйләгәннәрен — байтак тыңлагач, мин Муса Җәлилнең тормышында, шигъриятендә чагылган бер сыйфаты: гомуми максат һәм омтылышлар белән берекжән сугышчан дуслыкка тугрылыгы турында уйландым. Иван Бунин көндәлекләренең берсендә мин болай дип укыган идем: «Юк, бер тормыш та башкага охшамый! һәм бу нигезсез дә түгел...» Бу фәлсәфә мине шаккатырды. Билгеле, күп еллар газиз иленнән аерылган Иван Бунинның тормыш шартларын, хәлен аңларга мөмкин. Бәлки бу юллар аның аяныч хәлендә, ачынып уйланган минутларында язылгандыр. Ә менә Муса Җәлил кебек кешеләр башка тормышка һәр вакыт ышандылар, хәтта иң куркыныч һәм катлаулы минутларда да өмет өзмәделәр, ышандылар. Гитлер концлагерьлары һәм төрмәләре шартларында бу бик куркыныч нәрсә булса да, кешеләрдәге барлык яхшылыкка, сафлыкка ышану Муса Җәлил тормышының асылы, мәгънәсе булып кала.

Куе урманнарда яшеренгән партизаннар турында өмет белән уйлап, «Урман» шигырен язганда Муса Җәлил Саласпилс наратларына мөрәҗәгать итмәдеме икән әле?

**Урман, урман, мине син чакырасың,**
**Наратларың җилдән тибрәтеп.**
**Син шаулыйсың, миңа канлы үч һәм**
**Соңгы көрәш җырын өйрәтеп.**

**Урман, урман, миңа чиксез авыр**
**Бу хурлыклы, түбән әсирлек!**
**Әйт син миңа, илдәш дусларымны**
**Кайсы почмагыңа яшердең!**

**Урман, урман, мине илт син шунда**
**Һәм корал бир минем кулыма!**
**Үләр идем аклап йөрәгемнең**
**Керсез антын сугыш кырында.**

Муса Җәлилнең бик күп шигырьләреннән, хисләре, төсмерләре, юл арасыннан укылган фикерләреннән, һәм бигрәк тә «Двинага» дип язылган дулкынландыргыч юллардан Латвияне төсмерләп була.

Шагыйрь үзе турында куркыныч дулкыннар белән көрәшеп агымга каршы йөзгән кеше кебек итеп яза. Сүз Муса Җәлил русчалап Двина дип атаган Даугава турында бара. Шагыйрь аның калку сыйфатларын бирә.

**Килешә алмый күңелем коллык белән,**
**Башны һаман шушы уй баса.**
**Йөгерек дулкыннарың кочагына**
**Ал син, Двина, мине булмаса.**

Без Әхмәт Исхак белән Даугава ярында озак утырдык. Исхак шунда бу шигырьне татарча укыды. Аның тавышында тирән моң һәм дусты белән чиксез горурлану тойдым мин.

Мин аңа үземнең эзләнүләрем, тапкан документларым, Саласпилс тоткыннары белән сөйләшүләрем турында сөйләдем. Бу эзләнүләрдә зур ышанычны Мусаның үз шигырьләреннән алганымны әйттем.

Латвиядә Муса Җәлилнең шигырьләрен чыгарырга җыенгач, Мирдза Кемпе белән сөйләшеп, аның «Двинага» дигән шигырьгә аеруча игътибар итүен үтенгән идем. Халык шагыйре Мирдза Кемпе бу шигырьне латышчага тәрҗемә итте.

— «Двинага»ны укыганда Муса безнең Даугава җилләренә йөзен куйгандыр, аның суларына карап торгандыр. Даугава аңа шундый куәтле сүзләр табарга булышкандыр дигән уй килде башыма,— диде миңа Мирдза Кемпе.

Муса Җәлилнең Латвиядә булуы турындагы эзләнүләр тукталмады әле. Ул дәвам итә. Бәлки яңа материаллар табылыр. Муса Җәлил концлагерьда күп шигырьләр язган бит, аларны русчага үзе тәрҗемә иткән һәм күп тоткыннар аны кәгазь кисәкчәләренә күчереп язганнар. Фашистлар тарафыннан үлемгә дучар ителгән күп кешеләр ул шигырьләрне күңелдән ятлаган, телдән-телгә күчергән.

Әхмәт Исхак язганча, Мусаның танылган шагыйрь икәнен белеп алгач, фашистлар аны Берлинга озаталар.

Муса Җәлил тормышында Моабит көннәре башлана. Гитлер төрмәләренең иң дәһшәтлесендә «Моабит дәфтәре»нең үлемсез юллары туа. Анда үч һәм нәфрәт тулы шигырьләр белән бергә, шаян һәм шатлык бөркеп торганнары да күп.

Авыр яра, әсирлек, фашистларның мәсхәрәләүләре, физик һәм рухи газаплар кешене сындырырга тиеш иде кебек, шулай булгалады да ул. Ә биредә — әсирлектәге иптәшләренең исен китәрерлек гаҗәеп бер ныклык! Моабит төрмәсендә Җәлил белән бергә утырган Андре Тиммерманс та Мәскәүгә, юбилей тантаналарына килгәч шул турыда, шагыйрьнең соңгы көннәре турында сөйләде.

Моны ни белән аңлатырга?

Минемчә, аны бу кешенең эчке дөньясының сафлыгы белән, гомерен әрәм үткәрмәвенә, намус белән яшәвенә инануы белән аңлатырга мөмкин. Шундый хис кенә кешегә ныклык бирә.

Җәлил кебек үк хәлгә төшкән бик күп кешеләрнең хатларын укыгач та моңа ышанырга мөмкин. Электр урындыгында үлем көтүче Сакко һәм Ванцеттиларның хатларын, Юлиус Фучикның «Муенда элмәк чагында репортаж»ын, Рихард Зоргеның үлем алдыннан әйткәннәрен, Краснодон яшь гвардияче геройларының тын алудай кыска запискаларын, тыныч көннәрдә Америка Кушма Штатларында җәзалап үтерелгән ирле-хатынлы Розенбергларны искә төшерик...

Ромен Роллан: язмыш кушуы буенча, кешеләр хәсрәтле вакытта күңелле, ә бәхетле минутларында кайгылы әсәрләр язалар, дигән фикер әйткән. Ләкин дусларыннан, туган иленнән, үзенең бөтен тормыш максаты булган көрәштән аерылган Муса Җәлил кебек кешеләр рухи ныклыкны үткәннәреннән, ваклык, эгоистлык, кабахәтлек, икейөзлелек белән пычранмаган үткән тормышларыннан алалар.

Үткән тормышның сафлыгы һәм халыкның җиңүенә ышану батырлык, ныклыкның чыганагы булса, истәлекләр күңелдә шаянлык һәм шатлык тудыра. Менә шуның өчен дә «Моабит дәфтәре»ндә көяшлы юллар күп. Еракта калган сентябрь — шатлык ае — җылы Одесса һәм Кара диңгез, Багрицкийның: «Әй, Кара диңгез, әйбәт диңгез!» кебек шигырьләре дә аңа шушы авыр көннәрдә күңел җылыткычы булгандыр дип ышанасы килә. Бәлки шул көннәрдә төшендә күргәндер ул, Кара диңгезнең йөрәккә якын пышылдавын яңадан ишеткәндер.

«Двинага» дигән шигырьдә шундый юллар бар:

**Мин теләдем көрәш дулкынында**
**Колач җәеп батыр йөзәргә.**

Шул юлларны укыганда мин Одессада күргән Муса Җәлилгә кагылышлы тагын бер вакыйганы искә төшердем. Көньякның җылы киче иде. Котырып диңгез шаулый. Давыл булырга тора. Бәкеннәрдә утлар кабынды, украинлы карт балыкчы көймәсен ярга тартып чыгарды да, күлмәк итәгенә кулын сөртеп, уйчан гына әйтеп куйды:

— Тынгысыз төн булыр бүген...

Муса Җәлил дулкыннарның шаулап ярга бәрелүен карап тора иде, картның сүзеннән елмаеп ул ташка утырды һәм чишенә башлады. Без аны суга керү уеннан кайтарырга тырыштык, ләкин ул беребезне дә тыңламады.

— Давыл — әйбәт ул,— дип елмайды Муса.

Ул суга якынрак килде, шатлыктан нидер кычкырды да, төнге дулкыннарга ташланды.

**Л. ИХСАНОВА** тәрҗемәсе.

Фуат Вәлиев,
Гүзәл Вәлиева

# ТАТАР ДЕКОРАТИВ СӘНГАТЕНДӘ КОШ СУРӘТЕ


Казан татарлары декоратив сәнгатендә үсемлек-чәчәк һәм геометрик орнаментлар, ягъни «чәчәк стиле» төп урынны алып тора дигән караш киң таралган. Күпләр көнкүреш әйберләре бизәкләрендә «җәнлек стиле» бөтенләй булмаган яки кайчандыр булган булса да, әллә ничә гасырлар элек үк инде ислам дине йогынтысында тулысынча юкка чыгарылган дип уйлый. Әмма декоратив сәнгатебезнең яшәешен, үсеш-үзгәреш юлларын болгар бабаларыбыз чорыннан алып, дәвердән дәвергә тулаем өйрәнү нәтиҗәләре мондый карашның бик үк нигезле булмавын күрсәтә. Болгар-татар көнкүреш әйберләрендә кош сурәтен, аның төрләрен генә күздән кичергәндә дә декоратив сәнгатебездә кош-җәнлек (зооморф) мотивларның шактый киң таралганлыгын, дәверләр һәм буыннар аша билгеле бер эзлеклелек белән үсеп килеп, зарури үзгәрешләр кичереп, үзенчәлекле чагылышларда хәтта хәзер дә яшәвен күрергә була. Алар алтын җеп белән һәм тамбур ысулы белән чиккән калфак, түбәтәй читекләрендә, алка һәм беләзек кебек ювелир әйберләрнең чокып ясалган сурәтләрендә, чүпләмле сөлге очларында, кабер ташлары һәм шамаил орнаментларында, һәм, барыннан да бигрәк, Казан арты авыллары өйләренең тәрәзә яңаклары сыр-бизәкләрендә еш очрый[1].

Кош сурәтләре югары сәнгатьлелек хасиятләре белән әллә ни аерылып тормый. Алар гомумиләштерелгән, шомартылып, контур-сызым рәвешендәрәк гәүдәләндерелә, әмма шулай да күп кенә очракларда реалистик сын-күренешләрен югалтып бетерми, теге яки бу очракта нинди кош сурәтләнгәнлеген аеру мөмкинлеге кала. Халык сәнгате һәвәскәрләре үзләре өчен гадәти булган чара һәм ысуллардан файдаланып һәм үз алларында торган композицион-декоратив максаттан чыгып, җәнлек һәм кошларның җанлы образын тудырырга омтылалар. Шул ук вакытта көнкүреш әсәрләрендәге стиль бердәмлеге дә нык саклана.

Кошлар дөньясының гүзәл җан ияләреннән лачын, карчыга, мәче башлы ябалак, аккош, кыр казы, үрдәк, әтәч, көртлек, күгәрчен белән бергә ике башлы фантастик кош сурәтләре дә көнкүреш әйберләрендә еш күренә. Барлык бу образлар традиция буларак халык сәнгатендә болгар (һәм болгарга кадәрге) дәверләрдән үк сакланып калган.

Зооморф затлар, шул исәптән төрле кош сурәтләрендә, әйткәнебезчә, халык осталарын чолгап алган реаль мөхит чагылыш таба. Ләкин, шуның белән бергә, алар халыкның шигъри иҗаты — риваять-легендалары, әкиятләре, бәетләре белән тирән

[1] Кара: Ф. Х. Валеев. Древнее и Средневековое искусство Среднего Поволжья. Пошкар-Ола, 1975 ел; Орнамент казанских татар. Казан, 1969 ел.



1 нче фото

бәйләнештә тора. Алай гына да түгел, җанлы табигать образларының тамырлары тагын да тирәнгәрәк — мәҗүси чор кешеләре яшәгән җәнлек культы чорына, аларның төрле йола-ышануларына, кош-тотемнарга табынган заманнарга алып китә.

Җәнлек образларында аерым бер символик мәгънә сакланган булса да, хәзер инде аны төгәл әйтеп бирү күп очракта мөмкин дә түгел. Вакытлар үтү белән алар халык хәтереннән җуелган, бары традиция көче белән һәм сәнгать әсәрләре буларак кына яшәвен дәвам иттергән.


Идел буе Болгарстанында рәсми төстә ислам дине кабул ителгәннән соң да халык арасында мәҗүсилек гореф-гадәтләре югалып бетми. Һөнәрчеләр үзләре ясаган әйберләрне мифологиягә нигезләнгән орнаментлар белән бизәүләрен дәвам иттерәләр. Мәгълүм булганча, Идел Болгарстаны, Русь дәүләте һәм Көнчыгыш Европаның башка феодаль дәүләтләре кебек үк, колбиләүчелек җәмгыяте баскычын читләтеп уза. Алар дәүләт буларак ыруглык җәмгыяте җимерекләрендә оешалар. Болгар сәнгате халыкчан тамырларының тирән булуы, халыкның художестволы фикерләвен чагылдыруы шуның белән аңлатыла да. Өстен катлауларның, болгар феодалларының сәнгать өлкәсендә дә хакимлек итүенә карамастан, сәнгатьнең реалистик элементлары озак гасырлар халык массасы, аның идеологиясе һәм авыз иҗаты йогынтысында үсә. Монголлар һөҗүменә кадәрге чорның ахырында гына болгар декоратив сәнгатендә зооморф мотивларга нигезләнгән иске стильнең акрынлап үсемлек-чәчәк орнаменты юнәлешендә хәрәкәт итүе күренә башлый. Җәнлек образлары мәгънәви эчтәлекләрен югалтуга, геометрик һәм үсемлек-чәчәк орнаменты эчендә күмелүгә йөз тоталар. Алтын Урда чорында бу процесс аеруча көчәя. Җанлы сурәтнең декоратив сәнгать әсәрләреннән китә бару процессын, ислам дине тәэсиреннән тыш, сәнгать-

нең үз эчке үсеш законнары белән дә бәйләп карарга кирәк. Яңа чор үз идеяләрен, үз тасвир чараларын алып килә. Мондый процесс болгар иле белән күп төрле культура-экономик бәйләнешләрдә торган башка шәрык илләре сәнгатенә дә хас.

Әмма болгар сәнгатендәге тирән зооморф мотивлар бөтенләйгә юкка чыкмый, Казан татарлары көнкүреш сәнгатендә декоратив бизәкләр рәвешендә яңа сыйфатка күчеп яшәвен дәвам иттерә.


Казан татарлары декоратив һәм көнкүреш сәнгатендәге кош образларына якынныраk тукталып үтик.

Менә «алтын» кош сурәте белән бизәлгән хатын-кыз калфагы (1 нче фото, 1 нче рәсем). Томшыгында гранат җимеше (уңыш һәм муллык билгесе), үзе миләш ботагы белән әйләндереп алынган бөҗра эчендә. Миләш агачы Казан татарларында тылсым көченә ия булган кодрәтле агачлардан исәпләнгән. Һәм шушы агачның ботагыннан ясалган бөҗра эчендәге алтын кош, әлбәттә, үзен явыз көчләр тәэсиреннән имин сизәргә тиеш булган. Бу композиция билгеле дәрәҗәдә болгар сәнгатендәге алтын үрдәк образы белән уртак яңгырашлы. Хатын-кыз колак алкасы эченә урнаштырылган ул үрдәк томшыгына туфрак валчыгы кабып тора, алар икесе дә бөҗра эчендә сурәтләнә. Үрдәк сурәте су стихиясе билгесе булса, бу кош сурәте күкне белдерә. Колак алкасында сурәтләнгән үрдәк су астыннан туфрак алып чыгып җирне барлыкка китерүче үрдәк турындагы болгар легендасы белән бәйле. Томшыгына җимеш капкан алтын кошчык сурәтендә үзгәргән формада шул ук легенда гәүдәләнә. Ул инде уңыш һәм муллык билгесе булып хезмәт итә. Монда без иске легенданың за-



2 нче фото

3 нче фото





маннар үтү белән яңа эчтәлек алуын күрәбез. Ирләр түбәтәе бизәгендә дә шундый ук идея гәүдәләндерелгән. Түбәтәй өстенә, түгәрәкләп, артыш җиләге чүпләүче «бәхет кошлары» чигелә (2 нче рәсем). Бу үсемлек татарларда, миләш кебек ук, сихри көчкә ия дип саналган. Аның җиләкле ботаклары кешене явыз рухтан сакларга тиеш булган. Алтын кошчыклар исә — бәхет, тормыш матурлыгы, байлык билгесе. Ләкин ул кошчыклар, халыкның күз алдына китерүенчә, шундый кечкенәләр ки, теләсә кем аларны күрә дә алмый. Шушы ук төргә караган бизәкләр арасында аллы-артлы очып баручы ике кош сурәте игътибарга лаек (3 нче рәсем). Бу чигүдә Сак белән Сок турындагы борынгы татар бәете сурәтләнә. Аналары тарафыннан каргалган Сак белән Сок, кошларга әверелеп, туган җирләрен мәңгегә ташлап китәргә мәҗбүр булалар. Бу борынгы бәеттә Иделнең түбән агымындагы Саксин шәһәре тирәсендә яшәгән һәм туган илләрен ташлап төрле җирләргә (шул исәптән, Идел Болгарстаны-

(ка да) күчеп китәргә мәҗбүр булган угыз кабиләсе — саксиннарның тарихи язмышы чагылса кирәк [1].

Ирекле композиция рәвешендәге бу рәсемнәрдән тыш Казан татарлары декоратив сәнгатендә кош сурәтләре чәчәк формасындагы бизәкләр итеп тә кулланыла. Алар аерым кабер ташлары орнаментында (мәсәлән, Арча районы Бәхтияр, Сулабаш авыллары зиратында) очрый (6 нчы фото, 20 нче рәсем). Кабер ташына кош сурәте ясау традициясе болгар чорыннан ук килә. Ул заманда ташка очып баручы ялгыз кош рәсеме төшерелгән. Ә XVIII һәм XIX йөзләрдә кош сурәтләре дүрткел чәчәк рәвешендә, динче фанатиклар бәйләнә алмаслык хәлгә китерелеп ясала. Кабер ташындагы кош сурәте, күрәсең, мәрхүмнең рухын гәүдәләндерә яисә аның җанын җәннәткә алып китәргә ярдәм итә дип исәпләнгән.

Болгар чоры сәнгатеннән үк килә торган һәм Казан татарлары көнкүреш сәнгатендә популяр булган кош сурәтләренең тагын берсе — мәче башлы ябалак. Аны ике зооморф җәнлек рәсеме уртасында да, йорт тәрәзәләре яңакларында ялгыз да очратырга мөмкин. Өч зооморф мотивны берләштерүче болгар геральдикасы Урта Идел һәм Урал буенда яшәгән халыклар арасыннан бары Казан татарларында гына тотрыклы сакланган. Мәсәлән, шундый геральдиканың берсендә мәче башлы ябалак ике балык сыман җәнлек арасына урнаштырылган (1 нче фото, 4 нче рәсем). Мондый мотив болгар сәнгатендә шактый киң таралган булган, хәзер исә аның мәгънәсе билгесез. Ябалак образының зирәклек билгесе булып йөрүендә шик тотмаска мөмкин. Кайчандыр бу урман кошына табыну гадәте булган. Аның сурәте-сыны сунарның уңышлы булуына, юлчыларны урманның явыз рухла-



4 нче фото

[1] Бу хакта кара: Татарстан тарихына материаллар, 1 чыгарылыш, Казан, 1948 ел, 104 бит; М. И. Артамонов. Хазар тарихы. Ленинград, 1962 ел, 420—423 битләр.

рыннан саклауга хезмәт иткән. Ә соңга табарак тылсым мәгънәсен югалтып, декоратив бизәк кенә булып калган.


Тәрәзә яңаклары декорында һәм схематик формада тукыма бизәкләрендә парлы кош сурәтләре дә бик еш кулланыла. Әмма бу очракта алар гәүдәләре белән күрсәтелми, бары тик башларын сурәтләү белән чикләнелә. (Монда да без болгар чорыннан ук килә торган һәм магия белән бәйләнгән борынгы форма — бөтенне аның өлеше белән алыштыруны күрәбез.) Бер очракта сурәттә сайрар кош, икенче урында аккош, кыр казы, лачын, урман кортлеге башлары шәйләнелә. Тукыма бизәкләрендә алар бик нык схемалаштырылган хәлдә бирелә. Соңгысы башкорт, чуваш, Обь елгасы угорлары көнкүреш сәнгате бизәкләренә дә якын тора. Аерма тик шунда, әлеге халыклар сәнгатендә кош сурәтләре чигүдә генә дип әйтерлек чагылдырыла һәм нинди кош икәнен танып булмаслык дәрәҗәдә үзгәргән була. Казан татарларында исә ул сурәтләр чиккән әйберләрдә дә, бизәкле тукымаларда да, ювелир бизәкләрендә, агачта һәм ташта да очрый. Мотив төрләре, реалистик тасвирлау дәрәҗәсе ягыннан караганда, Казан һәм Казан арты осталары эшләгән әйберләрдәге орнаментлар Идел болгарлары сәнгатенә аеруча якын килә һәм күп очракта бер бөтен тәшкил итә.




5 нче фото

Кош сурәтләренең төрле көнкүреш әйберләрендә элек ничек кулланылуы, ни дәрәҗәдә таралыш алган булуы һәм дәверләр үтү белән функцияләренең ничек үзгәрүе аккош, кыр казы мисалында ачык күренә. Аккош, каз, үрдәк сурәтләрен болгарларның бик күп көнкүреш әйберләрендә очратырга була. Алар металлдан эшләнгән йорт кирәк-ярагы, пычак, кашык саплары, керамик савыт-саба һәм башкаларны бизи, түгәрәк скульптура рәвешендә дә, рельеф итеп чокып та, ажурлы бизәк итеп тә ясала. Ул сыннар, төрле әйберләрнең формасына яраштырылып, бер бөтен тәшкил итеп, аларны җанландырып һәм анык бер символик мәгънә биреп тора. Башка җәнлек сыннары кебек үк кош сурәте дә бер урында реалистик планда, җанлы итеп тасвирланса, икенчесендә шартлы-схематик төстә бирелә, ягъни тегеләр яки бу җәнлектә яшеренгән сихри көчнең шартлы билгесе хезмәтен генә үти. Мисал өчен бронза көзгегә ясалган кыр казлары рәсемен карап үтик (2 нче фото, 2 нче рәсем). Ул композициясенең төгәллеге, тирән образлылыгы белән хәйран калдырырлык. Казлар югарыдан очып барган итеп түгел, ә яңа гына җирдән күтәрелгән итеп тасвирлана. Муен борылышлары, томшыкларының ачылган булуы белән художник казларның ниндәндер куркып, кинәт һавага күтәрелеп киткәнлегенә ишарәли. Рәсемнең сюжеты ибн Фадлан язып калдырган бер мифның эчтәлеге белән аңгыраш таба кебек. Легендада башкорт дип йөртелгән кабиләне, торналар кычкырып, дошман һөҗүменнән саклап калуы хакында хәбәр ителә. Бронза көзгегә каз рәсемнәре төшерү болгар сәнгатендә электән килгән тотрыклы традиция булып тора.

Болгар осталарының иң популяр орнамент-бизәкләре арасында каз яисә аккош муены рәвешендә ясалган интеграль спираль формасы кызыксыну уята. Баш детальләре бирелә бик җанлы сурәтләнә, яхшы танылып тора. Болгар сәнгатендә спираль мотивы бик киң таралган. Ул әле саф геометрик форма, әле үсемлек орнаменты рәвешенә кереп, туктаусыз үзгәреп тора (2 нче фото, 3—7 нче рәсемнәр). Ныклабрак




6 нчы фото




карасаң, бу спираль мотивы башлангычында каз яки аккош муенынан күчереп алынган орнамент ятканлыгын күрәсең. Бишенче рәсемдә казның башыннан кечкенә калку урын торып калганлыгы, томшыгы үсемлек кыягы белән алыштырылганлыгы беленә. Шуннан соң инде спираль тулысынча үсемлек орнаментына әверелдерелә, художник хыялы аңардан чәчәк мотивы тудыра.

Болгар чоры мотивларын Казан татарлары декоратив сәнгать әсәрләре белән янәшә куеп карау кызыклы нәтиҗәләргә китерә. Мәсәлән, Казан арты торак йортлары тәрәзә бизәкләрендә шул ук спираль һаман да актив кулланыла (3 нче фото, 1—8 нче рәсемнәр). Каз томшыгы элементында стилизация көчәя төшкән. Кайберләре исә гади спираль булып кына калган. Тәрәзә кыегын бизәүче каз-үрдәкләр борынгы болгар легендасындагыча әле һаман да томшыкларында туфрак кисәге тотып торалар.

Шул ук спиральне тукылган сөлге очларында, чигүләрдә, ювелир әйберләрендә дә очратып була. Тик ул инде монда геометрик яисә үсемлек мотивы рәвешендә килә (4 нче фото, 4—7 нче рәсемнәр).

Сөлге орнаментында шулай ук, нык схемалаштырылган формада, ике башлы кош сурәтен хәтерләтүче геометрик бизәк киң таралган. Бу фигурада да канатларын киң җәеп басып торучы каз сурәте тәсмерләнә (4 нче фото, 1, 2 нче рәсем). Шуннан чыгып, Казан татарларының тукылган әйберләрендәге мөгезне хәтерләтүче геометрик фигураның да (4 нче фото, 3 нче рәсем) кайдан алынганлыгын сиземләргә була. Бу шул ук үзара кисешүче ике каз муены сурәтеннән үзгәргән мотив булырга тиеш. Себер халыкларының орнаментын тикшерүче С. В. Иванов[1] раславынча, шундый ук мотив ханты, манси, удмурт, Дунай болгарлары, каракалпак, кыргыз орнаментлары өчен дә хас күренеш.

Канатларын җәйгән ике башлы кош сурәте Казан татарлары декоратив сәнгатендә гомумән мөстәкыйль орнамент төре булып аерылып тора. Аларны тәрәзә яңакларында, хатын-кыз чулпыларында, тукыма бизәкләрендә күрергә мөмкин. Сурәтләр күбесенчә реалистик характерда: ике башлы лачынмы, карчыгамы, ябалак яисә кәртлекме (5 нче фото, 1, 2, 3 нче рәсем) — шактый яхшы танила.

Әгәр башкорт, чуваш, Обь буе угорлары иҗатында барлык кош сурәтләре диярлек нинди дә булса бизәк эчендә орнаменталь мотив, деталь рәвешендә чагылса, Казан татарлары сәнгатендә алар мөстәкыйль орнамент тәшкил итәләр һәм бу яктан да турыдан-туры болгар сәнгате әсәрләренә барып тоташалар. Ике башлы кош сурәте мәсьәләсендә дә бу нәкъ шулай. Кайчан һәм ничек барлыкка килгән соң алар? С. В. Иванов аны «ялгыз сынны симметрияләштерү нәтиҗәсе» дип карый. Бәлки шулайдыр да. Әмма биредә ул сыннарга нинди мәгънә бирелүен ачыклау кызыклы.

Ерак тарихка мөрәҗәгать итсәк, ике башлы кош сыннарының безнең эрага кадәр II гасырдан алып, безнең эраның V гасырына кадәр Урта Идел-Чулман буйларында яшәгән пьянобор культурасы кешеләре әйберләрендә үк инде киң таралыш алганлыгын күрербез[2]. Бу культура иясләре үзләренең кием-салым детальләрен, коралларын төрле-төрле кош һәм җәнлек сурәтләренә охшатып ясый һәм бизи торган булганнар. Корбан итеп торган хайваннарны да сурәт белән алыштырганнар. Пьянобор чоры ахырларына табан төрле җәнлек билгеләрен бер сурәткә кушу, кош сыннарын кеше сынына ишарә итеп сурәтләү — антропоморфлаштыру гадәткә керә башлый. Канаты җәюле ике яки өч башлы кош сурәтенә кеше кыяфәте биреп тасвирлыйлар. Башта тотемистик күзаллаулардан чыгып ясалган җәнлек сурәтләре пьянобор чоры ахырында фантастик сыйфатлар ала һәм турыдан-туры ата-баба культына килеп бәйләнә (6 нчы фото, 1, 2 нче рәсем). Әмма бу процесс әле шактый элегрәк Көнбатыш Себер угорлары культурасында башлана. Алар да кош һәм җәнлек сурәтләренә кеше сыйфатлары бирәләр. Күрәсең, безнең эрага кадәр берничә гасырлар элек үк инде Идел-Кама һәм Обь елгалары буенда яшәүче кабиләләр бер-берсе белән аралашканнар, бер-берсенә культура йогынтысы ясаганнар. Җәнлек сурәтләрендәге әлеге мотивлар ахыр чиктә борынгы Вавилон, Сүрия, Мисыр культураларына да барып тоташа[3].

Ике башлы кош мотивы һәм башка фантастик сыннарның шул дәрәҗәдә киң таралуы, күп санлы угор һәм төрки кабиләләр тарафыннан үзләштерелүе аларда яңа культлар урнашу, танып-белү һәм күзаллауларда, дини карашларда яңалык туу белән бәйле.

Болгар көнкүреше әйберләрендә ике башлы кош сурәтләре инде шактый стилизацияләнгән, шомарган хәлендә күренә. Алар ниндидер бер шәүлә рәвешендә күз алдына басалар. Кайбер сыннарда кошның башы да чак кына шәйләнерлек калку урын итеп кенә бирелә. Башка кайбер детальләргә дә ишарә генә ителә (6 нчы фото, 3—11 нче рәсемнәр). Бу бигрәк тә болгар ювелир сәнгатенә, керамикага хас күренеш. Казан татарларының агачны кисеп эшләгән сурәтләрендә, ювелир сәнгатендә, XV—XVI йөзгә караган савыт-сабада да шул ук хәл (12—19 нчы рәсемнәр).

Шулай итеп, Казан татарлары, башкорт, чуваш, Обь буе угорлары сәнгатендә ике башлы кош сурәтенең нык таралуы бу мотивның бер чыганактан килүе, Урта Идел, Чулман буйларында, Уралда һәм аннан да Көнчыгышта яшәгән борынгы угор һәм Идел болгарлары сәнгате белән уртаклыгы хакында сөйли.

---

[1] С. В. Иванов. Орнамент народов Сибири как исторический источник. Мәскәү-Ленинград, 1963 ел.

[2] «Пьянобор культурасы» дип, Татарстан АССР Пьяный Бор (хәзер Красный Бор) авылы тирәсендәге археологик табылдыклар буенча аталып йөртелә.

[3] В. И. Авдиев. Борынгы Шәрык тарихы. Ленинград, 1953 ел.

Мансур Вәлиев

# РУХИ ТӘҖРИБӘ ТУРЫНДА

Художникның язылa торган әсәренә яктылык тәрәзәдән түгел, ә йөрәгеннән төшә.

Кирико,
XVIII гасыр француз художнигы.

...Беренче карашка ул фильмда болай искитәрлек бер нәрсә дә юк иде — сугыш чоры тасвирлана, вакыйга немецлар кулында калган бер авылда бара. Аксаклавы аркасында фронтка китә алмаган укытучы егет мәктәптә балалар укыта, аларны фашизм йогынтысыннан саклап калу өчен тырыша. Ул бу куркыныч көчкә каршы корал күтәреп кенә түгел, ә эчтән дә, кешедә иң гуманлы идеяләрне саклау һәм үстерү белән дә көрәшергә мөмкин икәнен расларга тели. Балалар үзләре дә тик ятмыйлар — күперне ватып немецларның бер машинасын елгага капландыралар һәм бер офицерларын үтерәләр. Шул ук көнне аларны кулга да алалар. Укытучы егет бу хәбәрне ишетү белән партизаннарны эзләп урманга — ярдәм сорарга китә. Ләкин, ачыкланганча, партизан отряды әлегә аның укучыларын коткарырлык хәлдә түгел икән. Ике-өч көн эчендә отрядка өстәмә көч килергә тиеш, шуннан соң гына отряд командиры укучыларны азат итәргә барырга сүз бирә. Һәм командир, отрядның урнашкан урыны дошманга сизелүдән куркып, укытучы егеткә хәзергә авылга кайтуны тыя. Килеп туган шушы авыр һәм четерекле ситуациядә укытучы егеткә инде башкача бернинди чара да калмый, ирексездән, ике-өч көнгә отряд белән калырга туры килә. Ләкин ул тынычлана алмый, чөнки аның укучылары дошман кулында — явызлык, ерткычлык авызында, ә ул — аларның укытучылары — иректә, куркынычсызлыкта, балалардан читтә... Алар бит дәрес вакытларында фашизмга, кешелексезлеккә каршы бергә, бер йөрәк, бер җан булып нәфрәтләнгәннәр иде! Юк! Укытучы егетнең отрядта калырга тиешлеге салкын акыл белән үлчәгәндә дөрес кебек булса да, барыбер ул кеше күңеле, күңелләрнең бер-берсенә булган олы тугрылыгы өчен — хыянәт! Тормыш агымының көтелмәгән борылышларына, сәбәпләргә ышыкланып, шулар белән үзен-үзе акларга теләгән хыянәт! Нечкә тоемы белән әнә шул зур җинаятьне сизенгән укытучы егет, отрядтан качып, авылга, немецлар кулына кайта. Үзенең үлеменә үз аягы белән кайта!

Тышкы вакыйгалардан чыгып фикер йөрткәндә, чынлап та, монда әллә ни яңалык юк кебек. Ләкин кинофильмны караганда укытучы егетнең шушы кискен адымны атлау алдыннан булган психологик халәтен, аның күңелендә барган катлаулы кичерешләр көрәшен, бәрелешен үз йөрәгең аша үткәрәсең, шул бәрелешнең бер газабын үзеңдә тоясың. Әйтерсең син үзең бүгенге тормышта, менә хәзер, шундый

катлаулы хәлдә калгансың һәм ике юлның берсен сайларга — бер кискен адым атларга тиеш. Аларның берсе үлем белән тәмамлана, ә икенчесе сине тормышта калдыра... Җаныңның бер кисәген — намусыңның бер өлешен үтерү хисабына, шул һәлакәтнең канлы туфрагында синең мескен тәнең яшәвен дәвам итә ала...

Бу киноны карап чыккан кайбер яшьләрнең сүзләреннән аңлашылганча, алар фильмдагы әнә шул тирән мәгънәле ситуацияне тоеп җиткерә алмадылар. Әлеге егет язмышының трагик хәле һәм кайбер замандашларымның аңа карата, кешедәге шушы халәткә карата салкын битарафлыгы хәтердән бик озак чыкмады, күңелдә күп төрле уйлар тудырды. Ә бераздан бу битараф игътибарсызлыкның яшь шәхес өчен үтә актуаль булган бер проблема белән бәйләнгән булуына төшендем. Ул проблеманы яшь кешенең, бу очракта яшь язучының рухи тәҗрибәсе дип атарга мөмкиндер. Бу язмада әнә шул мәсьәлә — рухи тәҗрибә турындагы кайбер уйлануларым белән уртаклашасым килә...

Нәрсә соң ул рухи тәҗрибә?

Без төрле аңгәмәләрдә, чыгышлар вакытында, матбугатта «тормыш тәҗрибәсе» дигән сүзне еш ишетәбез. Ул гадәттә сүз тормышны, реаль яшәешне, кешеләрне белү һәм аңлау хакында барганда, «тормышны өйрәнергә кирәк» дигән төсмер салыбрак, шундый контексттарак әйтелә. Әйе, мондый таләпнең көче әле дә кимемәде, иҗат кешесе өчен генә түгел, гомумән, җитди итеп, халыкка һәм илгә чын мәгънәсендә файдалы булып яшәргә теләгән һәр шәхес өчен тормышны, аның кырыс һәм көчле кануннарын тирәнтен аңлау, практик эшчәнлегендә шуларны искә алып хәрәкәт итү — үтә мөһим нәрсә. Ләкин әлеге «тормыш тәҗрибәсе» беренче дәрәҗәдә әһәмиятле булып калган хәлдә — иҗат кешесе өчен икенче бер мәсьәләнең, «рухи тәҗрибә» дигән байлыкның да булу шарты гаять зур. Хәтта бүгенге язучы иҗатында уйнаган роле белән, аның әһәмияте «тормыш тәҗрибәсе» дигән таләпкә тигезләште. Бу хәлнең чынбарлыктан килүче табигый сәбәпләре дә бар. Мәгълүм булганча, соңгы елларда халыкның рухи тормышы шактый тирәнәйде. Шуның нәтиҗәсе буларак әдәбият-сәнгать тә кешеләр тормышын сурәтләгәндә тышкы вакыйгаларга нигезләнеп кенә, шулар буенча барып кына түгел, ә кеше психологиясенең, аның күңел яшәешенең эченәрәк кереп, шәхеснең иң тирән күңел төпкелләренә төшеп, андагы бөтен чынбарлыкны күреп һәм тоеп эш итә башлады. Иҗат кешесе өчен үз замандашының күңел дөньясын, рухи тормышын нык белү дә бүген үтә зур әһәмияткә ия, бу сыйфат еш кына язучы әсәренең уңышын билгели торган эчке бәйлыкка, әсәргә кирәк булган төп хасияткә әйләнде. Әмма кеше күңелен белү без әйтергә теләгән рухи тәҗрибәнең бер тармагы гына, ул үзе генә язучы әсәренә чын уңыш китерә алмый әле. Бүгенге иҗатчы өчен зуррак һәм колачлырак, үзенә күбрәк сыйфатларны берләштерә торган нәрсә — рухи тәҗрибә муллыгы кирәк.

Иҗат кешесенең рухи тәҗрибәсе... Ул — язучы күңеленең, аның эчке дөньясының кичерешләр сферасы зурлыгы, ул сфераның әйләнә-тирә тормыштагы, яшәештәге психологик процессларның мөмкин кадәр күбрәген үзенә үткәрергә сәләтле булуы. Ягъни язучы шәхеснең тормышта туа торган иң нечкә төсмерләрне, иң кечкенә дулкыннарны да тоя, сизә торган зур тәҗрибәле күңеле, рухы, җаны булу. Тормыш тәҗрибәсе кешенең, иҗат кешесенең, җыеп кына әйткәндә, дөнья күргән булуын күздә тота. Димәк, биредә тормышның күбрәк тышкы аспекты, тышкы чагылышы беренче урынга куела. Ә рухи тәҗрибә исә язучы шәхесенең тормыш фактлары, вакыйгалары белән таныш, алар белән очрашкан булуын шарт итеп санаган хәлдә, күбрәк игътибарны фактларның, вакыйгаларның эченә, үзәгенә, аларның төсмерләрен бар тулылыгында нечкә итеп тоя һәм кичерә алуга, тормыш диалектикасы белән органик тоташа алуга юнәлтә. Бер караганда ул тормыш тәҗрибәсенең тирәнәйгәнрәк, дөньяны тулырак итеп тоюга, күрүгә таба якынайган баскычы кебек. Әмма бу мәсьәлә мөстәкыйль бер проблема, әдәби иҗат көчләре юларга тиешле әһәмиятле бер үр итеп каралырга тиеш дип уйлыйм.

Рухи тәҗрибә зурлыгының әдәби әсәрдә ничек чагылуын күрү өчен соңгы елларда укучыларга бик күп кызыклы роман, повестьлар биргән рус прозасына тукталыйк. Менә бер мисал — Валентин Распутинның «Яшә һәм исеңдә тот» повесте. Әсәрдә фронттан качып үз авылында яшеренеп яткан кешенең кичерешләре тасвирлана. Ләкин повестьның уңышы, сәнгатьчә кыйммәте вакыйгалар оригинальлегендә түгел.

Язучы бире дә, шул вакыйга аша, шәхес җанында барган кешелеклелек һәм кешелексезлекнең (мескенлек, дөнья каршында йомшаклык, үз җаның өчен курку) бәрелешүен күрә, шул көрәш диалектикасын бар реальлегендә иң башта үзе тоя, кичерә алган һәм аннары укучыга да җиткерә алган. Язучы күңеленең тирән һәм олы кешелек кичерешләренә байлыгы, шәхесенең чигенмәс һәм принципиаль көрәшче булуы — әсәрне бүгенге рухи яшәешнең иң алгы сызыгында яшәтүче, шуның уңышын билгеләүче төп сыйфатлар, минемчә, әнә шулар.

Үз алдыбызга тагын бер сорау куйыйк. Укучылар массасы һәм әдәби тәнкыйть тарафыннан бу әсәр ни өчен шул кадәр җылы каршы алынды соң?

Бирелә җәмгыять тормышындагы рухи ихтыяҗ, әчке зарурият шактый роль уйнады кебек. Ул ихтыяҗ — 60—70 нче елларда халкыбызның материаль тормышы нык яхшыру, «ничек яшәргә?» дигән сорауга меңләгән төрле җавап бирә алу һәм гаять күп төрле сайлау мөмкинлеге булу белән бәйләнгән, ахрысы. Үзе алдында күп мөмкинлекләрне күреп торган һәм аларча яши дә башлаган кеше, билгеле бер моментта, яшәвенең ниндидер бер ныклыгын, аңа тынычлык, күңел юанычы, ышаныч бирә алырдай, шуңа сәләтле һәм тирәнгә киткән тамыры бармы-юкмы икәнен белергә тели башлый. Ә ул эзли торган тамыр — кешелеклелек дигән олы көч, олы бер энергия запасы белән, бердәнбер һәм зур орлык белән тоташкан була. Кеше үз тормышының әнә шул тамырын эзләгәндә, аның күңелендә, әлеге кинодагы кебек бәрелешләр — күп төрле яшәү ысуллары белән кешелеклелеккә барып тоташа ала торган бердәнбер тамыр арасында кискен көрәш драмалары туа. Кеше шул чорда тормышның үзенә тынгылык бирми башлаган якты һәм кара көчләрен сизеп ала. Ә ул әчке драматизм халәте, үз чиратында, кешедә тышкы дөньядан аваздашлык табу теләге тудыра, рухи контактка керүне сорый башлый. Ягъни кеше күңелендә бер көчле рухи ихтыяҗ туа. В. Распутинның «Яшә һәм исеңдә тот» повестеның укучылар тарафыннан яратып кабул ителүе, минемчә, реаль тормышта яшәгән әнә шундый атмосфера, ихтыяҗга бәйләнгән. Әлеге ихтыяҗ, әлбәттә, кыска гомерле түгел, тормыш катлаулана барган саен ул зарурият үсә генә бара. Димәк, әлеге әсәрнең дә әһәмияте кимемәячәк, арта гына барачак.

Чыңгыз Айтматовның «Диңгез яры буйлап чабучы ала эт» повестеның да («Знамя» журналы, 1977, 4 сан) укучылар арасында зур популярлык казануы язучының җәмгыять тормышында иң өлгереп җиткән рухи проблемаларны вакытында һәм нечкә итеп сизә алуы, аларны бар тулылыгы белән, сәнгатьчә оста һәм үтемле гәүдәләндерә белүенә бәйләнгән. Повестьның төп герое булган яшь малайның Олы Томанда адашмыйча исән калып, үз ярына — чыгып киткән Ярына кайтып җитүе — укучы күңеле өчен зур рухи батырлык, чорыбызның сәнгать әсәре тарафыннан ачылган олы мәгънәле батырлыгы.

Илебез халыклары әдәбиятлары соңгы елларда нәкъ әнә шундый әсәрләр белән үз алларына партия тарафыннан куелган зур бурычны — халык рухын, халык күңелен нечкә сәнгатьлелек белән тәрбияләү бурычын үтәүдә нык активлаштылар, үзләренең көчен һәм эзләнүләрен арттырдылар. Нәтиҗә буларак, шул нечкәлеккә ирешү аркасында, тулаем әдәбиятның да халык алдында абруе үсте, укучыларны үзенә тарту сәләте артты. Әдәбият кеше күңеленә (димәк, тормышка да) тәэсир итүче реаль көчкә, җәмгыятьнең рухи тормышын активлаштыручы бер катализаторга әйләнде.

Реаль тормыштагы драматизмны, катлаулы чынбарлыкны сизгер тотып алуның уңышлы мисалларын үзебезнең татар әдәбиятыннан да күп табарга мөмкин. Мәсәлән, тәнкыйтьчеләр һәм прозаиклар секцияләре үткәргән «Революция һәм язмышлар» дип исемләнгән зур дискуссиядә катнашучылар Гариф Ахуновның «Идел кызы» романында революцияне кабул итүгә бәйле бик күп мәсьәләләр нечкә тасвирланган дип бәяләделәр. Бу роман уңае белән үз-үзебезгә шундый сорау да бирергә мөмкин кебек. Хезмәт ияләре интересларын күздә тоткан революцияне тасвирлаганда, бүтән образлар белән бергә, Габбас мулла кебек кешеләргә дә игътибар итү — әсәр идеясе өчен нәрсә бирә алыр икән? Андый тип шәхес революция темасын ачыклауга нинди яңалык кертә алыр? Тормыш вакыйгаларының тышкы чагылышын гына күргән язучы Габбас мулла кебек образда бәлки зур мөмкинлек тапмас иде һәм аның урынына үз башыннан шау-шулырак вакыйгалар кичергән кешеләрне кертергә тырышыр иде. Ә «Идел кызы» романында Габбас мулла образы нәкъ менә революциянең олылы-

гын, аның тормышны тирәннән актарып килә торган, үтә җитди һәм көчле агым икәнлеген ачып сала. Дөрес, бу герой революциягә илтә торган юлны әле таба алмый, ул юллар буталчыклыгында адашып һәлак була. Ләкин әсәрдә бик ачык сизелә — аның күңел юнәлеше, хезмәт кешесе гаиләсеннән чыккан намуслы зат буларак, җанының нечкә омтылышы революциянең якты идеалларына, аның нигез матурлыгына таба бара. Әгәр дә ул тагын күпмедер яши алган булса, һичшиксез, революция яклы көчләр белән аңлаша алыр һәм анда үзенең реаль урынын да тоя башлар иде. Әнә, шулай итеп, язучы әйтергә теләгән фикер — революциянең зурлыгы, тормышчанлыгы әсәрдә нечкәрәк, тирәннәнрәк, димәк, сәнгатьлерәк итеп китереп чыгарыла. Ә моңа ирешүдә, әлбәттә, язучы шәхесенең тормыштагы нечкәлекләргә игътибарлы булуы, зур рухи тәҗрибәсе хәлиткеч роль уйнаган. Элеккерәк еллардагы әдәби иҗат тормышыннан Әмирхан Еникинең «Әйтелмәгән васыять», «Рәшә» повестьларын искә төшерсәк тә — язучы күңеле чынбарлык белән нечкә тоташа алганда нинди уңышлы сәнгать әсәрләре иҗат ителүен яхшы күрербез. Менә «Әйтелмәгән васыять» — аның язылуына инде 13 ел вакыт үткән. Ә ничек актуаль яңгырый ул! Бүген, күпләгән кешеләрнең үз күңелләрендә шәһәрчә яши башлау үзгәрешен кичерүе заманында, элеккеге кадерле һәм ияләнгән тормыштан аерылу, аның белән мәңгегә хушлашу чорында, шул аерылышуның рухи тетрәнүләрен кичергәндә бу әсәр юл яктыртучы ут кебек җемелдәп, кешеләргә табигый һәм дөрес үсү юнәлешен күрсәтеп тора. Ә бит әлеге повесть иҗат ителгән чорда язылган шактый әсәрләр инде мәгънә ягыннан тонykланып, төссезләнеп калды. «Әйтелмәгән васыять» исә үзенең тирәнлеген, сәнгатьчә көчен һаман күбрәк итеп ача тора! Әйе, язучының бай рухи тәҗрибәсе булу һәм тормышка тирән үтеп керү кирәклеге хәзерге әдәби процесста шактый универсаль таләпкә әйләнде. Ул инде еш кына әсәрнең уңышын хәл итүче бердәнбер сыйфат булып та тора.

Ләкин соңгы елларда басылып чыккан күп кенә әдәби әсәрләрне укыганда, аларда еш кына әнә шул «рухи тәҗрибә» дигән күңел байлыгының азлыгы үзен сиздерә. Бу, күрәсең, язучыларыбызның моңарчы гел тормышның тышкы чагылышына — фактка, вакыйгага гына игътибар итәргә иялә нгән булулары, әдәби тәнкыйтьнең дә әсәрне анализлаганда аны тормышның җанлы организмы итеп түгел, ә «сюжет», «идея» кебек төшенчәләрнең механик җыелмасы төслерәк кабул итүе нәтиҗәседер. «Соңгы елларда безнең проза нишләп бөтенсоюз укучысының игътибарын җәлеп итәрлек әсәрләр бирә алмый?» дигән борчулы сорауга да менә шушы хәл шактый ачыклык кертә кебек. Безгә вакыйгаларның, фактларның эченә үтеп керердәй рухи тәҗрибә куәте җитеп бетми, нәтиҗәдә, иҗатчының бүгенге реаль чынбарлык алдында берникадәр көчсезлеге ачыклана.

Рухи тәҗрибәнең әдәбиятта ничек чагылуы хакындагы гомумирәк фикерләрдән соң, инде бүгенге көндә иҗат итүче яшь язучыларыбызның рухи тәҗрибәләре мәсьәләсенә әйләнеп кайтыйк. Алар күңелендә әнә шул кадерле байлык никадәр соң? Яшь язучыларыбызның күңел көчләрен билгеләүче эчке энергияләре нинди микъдарда? Соңгы вакытта басылып чыккан яки әдәби җәмәгатьчелектә фикерләр уяткан кайбер әсәрләр нигезендә шул турыда уйланып алыйк.

Романтик ашкыну, олы эшләргә һәм үз-үзеңне тиз арада расларга омтылу — һәр заман яшьләренә хас сыйфатлар. Һәм шушыларга бәйле рәвештә, яшьләр дию белән, күп чагында безнең күз алдына үз-үзенә нык ышанган, өлкәннәрне искелектә гаепләргә ашыгучы, фыртрак кыяфәтле яп-яшь егет килеп баса. Хәтта кайчагында әнә шундый тип безнең күз алдында бөтен бер буынның символы кебек тә гәүдәләнеп ала.

Әйе, яшь буынның яңача, үзенчә фикерләве — дөрес һәм кирәк. Аның һәр хакыйкатькә үз тәҗрибәсе, үз акылы белән барып җитәргә теләве дә бик аңлашыла. Карл Маркснең да иң яраткан әйтеме «һәр нәрсәне шик астына ал!» дигән девиз булган бит. Әлеге лозунг яшьләрне еш кына ачышларга, дөньяга, яшәүгә карата яңа һәм зур сүз әйтергә дә алып килә. Дөрес, ул вакыт-вакыт кешеләр яшәешен тотып торган иң изге хакыйкатьләргә, озак еллар сыналып килгән байлыкларга дикъкатьсез булуга, санга сукмауга, исәпләшмәүгә үк тә китереп чыгара.

Берара безнең яшь язучылар иҗатында да шуңа охшашрак күренеш булып алды. Тормышта берегеп тоташкан ноктапар булмау, яшәү хакында аның үзеннән, анда

кан-яшь түгеп, күп нәрсәгә шаһит булып яшәгән үз күңеленнән чыгып түгел, ә кайдадыр очратып ошаткан матур һәм оригиналь карашлар, фикерләр буенчарак язу сизелде. Ягъни тормыш үзәгеннән яшь язучы күңеленә яшәү суты китерә торган, тере элемтә урнаштыручы тамыр юк иде. Әнә шундый тормыш суты килмәү, үз чиратында, җиңелчә оригинальлеккә, тыштан отышлы кебек тоелган, матур күренгән эпизодлар, кызыклы-кызыклы аерым фикерләр, детальләр белән мавыгуга китерде. Ә яшь язучының әйләнә-тирәсендә булган язмышлар һәм тормыш читтә калды.

Яшь язучылар иҗатында кичерелгән әнә шундый халәттән икенче сыйфат үзгәрешенә күчеш процессының шактый символик күренеше Марсель Галиевнең «Кар абагалар» повестенда ачык күренә. Повестьның төп герое Данияр (Данияр характерының диалектикасы авторның үз иҗат принципларына шактый тәңгәл килә, аларның эзләнүләре бер-берсенә авазлаш) салкын матурлык, җиңелчә оригинальлек катламын үтеп, реаль кешеләр яши торган чын хисләр, чын кичерешләргә омтылып яши. Әсәрнең исеменә үк күтәреп куелган образ — кыш көне тәрәзәгә табигать ясый торган бизәк, кар абагалар — нәкъ әнә шул салкын матурлык катламы. Автор шул катламны, күңел тәрәзәсендәге кар абагаларны эретеп, урамдагы, дөньядагы кешеләрне күрергә, алар белән җан уртаклыгы табарга, алар белән бергәләп сөенергә, кайгырырга тели. Аның күңеле әнә шул зур дөньяга сусаган. Ләкин повесть герое ул дөньяга ничек, нинди юл белән чыга алыр? Әсәрдә әлегә моңар җавап юк. Димәк, бу мәсьәлә авторның үзе өчен дә ачыкланып җитмәгән. Тормышка ничек чыгу юлы билгесез әле. Хәлбуки, ул «ничек?»нең очы әлеге дә баягы шул «рухи тәҗрибә» дигән эчке байлыкка барып тоташа.

Бу нисбәттән караганда яшь язучы Азат Ганиевнең элегрәк басылган «Сүзсез җыр» повесте һәм күптән түгел прозаиклар секциясендә тикшерелеп уңай бәя алган «Иман» әсәре игътибарга лаек. Автор яшәүнең җитди рухи катламына шактый якын килә, кешене бөтен барлыгы белән колачлап алырга омтыла. Дөрес, соңгы әсәрдә кайбер композицион кытыршылыклар да юк түгел. Ләкин повестьның төп әһәмияте — аның эчтәлегендә, андагы бай мәгънәле коллизияләрдә. Повесть герое тормышта үзенең ныклы урынын, ышанычлы позициясен булдыру өчен армый-талмый көрәшә, шул максат белән бик күп укый, кешеләрне, яшәүне җентекләп өйрәнә — шулай итеп, ул тормыштагы рухи ныклыгын, үз иманын үҗәтләнеп, шашынып диярлек эзли. Ул җирдә үз-үзенә ышанып яшәргә тели. Һәм әнә шул катлаулы рухи эзләнү процессының тулылыгы, тирәнлеге, тормыш өчен мөһимлеге ягыннан яшь язучының повесте киң катлау укучылар көткән, чын мәгънәсендә тормыш өчен кирәкле булган әсәрләргә якын тора.

Алдарак карап киткән «Кар абагалар» повестенда герой олы тормышка кушылып, катнашып китү юлын эзли, «ничек?» дигән сорауга җавап табарга тели дигән идек. Ә бу әсәр әнә шул «ничек?»кә бер җавап — яшәүнең өметле бер юнәлешен тәкъдим итә. Рухыңдагы кешелеклелек тавышына, үз намусыңа, үз асылыңа тугры булу сине кешеләрнең күңел түренә алып керер, андагы җылыны, ихлас яшәүне, гап-гади бөеклекне үз каның, үз җаның, үз тәнең белән тоярга — кешечә яшәргә өйрәтер. Эчке дөньяның киңлеге, аның ачыклыгы, кешеләр яшәеше белән тоташа алу, яшь язучы шәхесен тормышның бер җанына, сизү органына әйләндерә.

Рухи тәҗрибәләренең әсәрләрендә чагылышы ягыннан караганда әдәбиятта беренче адымнарын гына атлаган Нәбирә Гыйматдинова, Сәгыйть Хафизов һәм Заһир Садыйков повестьлары да үзенчәлекле. (Мин «Идел» альманахында һәм вакытлы матбугатта басылган «Китмә, улым», «Яшьтәшләр», «Ялгышсыз язмыш» әсәрләрен күздә тотам.) Дөрес, әлегә бу яшь авторларга әдәби осталык җитеп бетми. Аларның әсәрләрендә матур детальләр, фикерләр, отышлы, ялтыравыклы, оригиналь картиналар да табып булмый. Ләкин, аның урынына, повестьларны укыганда яшь язучы өчен, һәм, гомумән, һәр чын язучы өчен иң мөһим, иң асыл сыйфат булган бер күренеш белән очрашасың. Ул — язучы шәхесенең тормыш белән тоташкан булуы. Язучы күңеленә тормыш стихиясенең җанлы килеш үтеп керә алуы.

Сүз уңаенда яшь язучыларыбыз арасында еш очрый торган ике тип шәхескә, яшәү принциплары, рухи тәҗрибәләре алар иҗат итә торган әсәрләрдә ничек, нинди булып килеп чыгуына да тукталып үтәсе килә. Бу исә без сөйли торган проблема-

ның конкрет рәвештә яшь иҗатчыларда ничек гәүдәләнүен күрергә мөмкинлек бирә сыман.

Димәк, ике тип шәхес. **Беренчесе.** Ул инде күптәннән яза, үзен әдәбият дөньясында байтактан үз кеше итеп тоя. Ул китаплар, хәзерге вакытта исеме еш яңгырый торган барлык язучыларның мөмкин булган бөтен әсәрләрен җыя. Алар белән бик еш мактанырга ярата. Язган әсәрләре нигездә аның үз тормышына, ул яшәгән урынга, эшкә кагылмый. Хәер, аның яши, кайгыра, борчыла, нәрсәнедер кире кага, яисә кемнедер яклап тартыша торган реаль урыны, бер яшәү ноктасы, җирлеге дә юк сыман. Ул бик күп фактлар, вакыйгалар белә, әңгәмә вакытларында аларны еш сиптерә. (Күрәсең, аның уйлавынча, ул фактлар заман дәрәҗәсендә торуны күрсәтергә тиешләр.) Кеше буларак ул бер дә ачылып бетми, «кешеләр белән тулысынча якынаерга ярамый, югыйсә синең алар өчен кызыгың калмый» дип саный. Һәм аның әсәрләрендә дә син кемнедер кабатлаган матур фикерләрдән башканы таба алмыйсың. Шулай итеп, ахырга хәтле ачылып бетмичә кызыклы күренергә теләгән автор, гомумән, кызыксыз: тормышта да, иҗатта да кызыксыз булып чыга. Һәм шунда «якын җибәрмәү» дигән нәрсәнең бер маневр икәнен, күңел бушлыгының сизелүеннән качуда бер чара гына булуына төшенәсең.

**Икенче тип шәхес.** Ул тыштан караганда ничектер басынкы, хәтта, әйтергә мөмкин, мескенрәк кыяфәттә. Гомумән, теге тип яшь язучы кебек кыю, әрсез түгел. Теләсә нинди әңгәмәгә кушылып та китә алмый. Тик торудан уңайсызланып, катнашырга теләсә дә — аның сүзләре көлкерәк, җайсызрак чыга. Ләкин сиңа бервакыт аның белән икәүдән-икәү генә калырга туры килә. Һәм шунда син аның нинди зур дөньялы, тирән яшәешле кеше икәнен сизә, аңлый башлыйсың. Ул үзен дулкынландырган уйларын сөйли, синең кем булуыңны, аннан нәрсә көтүеңне искә дә алмыйча, бар күңелен ачып, бөтен күңел җәрәхәтләре, куанычлары белән сиңа тулысынча түгелеп сөйли. Син инде бу чакны теге тип белән сөйләшкәндәге кебек, өзек-өзек матур фикерләр, цитаталар тыңламыйсың, ә тулган һәм дулкынланып, тирбәлеп тора торган тынгысыз бер дөнья күрәсең. Аның язганнары — ул яшәгән тормышның үзе. Анда кеше, тере кешенең җанлы дөньясы була! Әнә шундый шәхес күңелендә яшәп алу сине дөньяның, тормышның эченә алып керә, үзенә ияртеп тирәнгә алып төшә, шунда яшәтә. Димәк, синең эчке дөньяң да, синең күңелең дә тирәнәя.

Яшь иҗатчылар арасында әнә шундый шәхесләр очрый. Алар мисалы безгә чын әдәбият өчен нинди шәхес кирәк булуын, киләчәктә кемнәрнең олы һәм җитди әсәрләр яза алачагын шактый ачык күрсәтеп тора. Үзенең бөтен барлыгы белән реаль яшәешкә тоташкан шәхес кенә кеше күңеле якын итәрлек, аңа җылы һәм рухи азык бирә алырлык әсәрләр иҗат итә. Чөнки аның үзенең дә эчендә рухи тәҗрибәсе, кадерле һәм изге кичерешләр байлыгы күп була. Һәм бүгенге көндә язучылар ирешкән төп уңышлар да, иң беренче чиратта, әнә шул зур мөлкәт белән бәйләнгән.

Әмма рухи тәҗрибә байлыгы әлегә күп кенә яшь иҗатчыларыбызга җитенкерәми кебек. Бу җитешсезлек аларга олы әдәбиятка кереп китәргә, киң катлау укучылар массасы игътибарга алырлык әсәрләр иҗат итәргә комачаулаучы төп киртә, шул юлда үтеләсе мөһим биеклек. «Рухи тәҗрибә» дигән әнә шул күңел байлыгына язучы өчен хәзер бик мөһим булган башка нәрсәләр: тормыш агышының иң үткен һәм олы мәсьәләләрен вакытында сизеп алу, аларны тоюда һәм сурәтләүдә психологик нечкәлек, тормыш каршында иҗади кыюлык һәм бүтән сыйфатлар да нык бәйләнгән. Димәк, рухи тәҗрибәнең язучы иҗатында тоткан урыны шактый киң, зур һәм мөһим икән.

Ә рухи тәҗрибә дигән байлык шәхес күңелендә ничегрәк туплана соң?

Тормыш тәҗрибәсе, билгеле булганча, кешенең күп дөнья күрүе, тормыш эчендә кайнавы, кешеләр белән нык аралашуы, аларны белергә тырышуы аша җыела, шулай барлыкка килә. Ә рухи тәҗрибә исә бераз башка юл беләнрәк, үзенчәрәк туплана бугай. Аның нигезе — шәхеснең күңел сизгерлеге, рухи дөньясының нечкәлеге. Шәхеснең әйләнә-тирә тормыштагы барлык ситуацияләрне, коллизияләрне кабул итә алуы. Ягъни А. М. Горькийның Сергей Есенин турындагы язмасында әйтелгәнчә — «йөрәкнең дөньядан ниндидер калканнар белән сакланмаган хәлдә булуы».

Әнә шундый нигезгә, әдәбият-сәнгать өчен бик уңдырышлы булып җитешәчәк туфракка, яшь шәхес үсә-үсә яңа көч, энергия туплый. Кечкенәдән шәхестә тормыштагы нечкәлекләргә карата игътибарлылык тәрбияләнсә, шул нечкә кыллар аша тормышны, аның тирән аһәңен сиземли башлау булса, моның әһәмияте шәхес тарафыннан үзләштерелсә — кешенең рухи тәҗрибәсе үсү өчен шартлар уңайлаша, мөмкинлекләр зурая. Шуның өстенә кечкенә вакытта ук әдәбият һәм сәнгать дөньясы белән очрашу, шул һаваны сулап үсү, шул шифалы чишмәгә тоташу — булачак язучы һәм, гомумән, нечкә тоемлы шәхес формалашу өчен үзләре бер яңа дөнья, рухи баю, рухи өлгерә башлау җирлеге бирәләр. Әдәбият-сәнгать әсәрләре белән рухлану ул күңелнең тагын да матурая, нечкәрә төшүе, үзенә кунган тузаннан чистарынуы дигән сүз.

Ә шулай да, кеше күңелен барыннан да бигрәк, тормыш үзе тәрбияли. Ләкин чын һәм ихлас тормыш булса гына! Әнә шундый тормыш үзе эчендә үсүче шәхескә искиткеч күп материал, чимал бирә. Яшь шәхеснең рухи дөньясы дөнья биргән шул фактларны күңел казанында эшкәртә-эшкәртә, шул авыр эшкәртүнең бар газабын җанында татый-татый, акрынлап, бик акрынлап үзенә рухи тәҗрибә туплый. Кеше буларак (һәм, әлбәттә, иҗат кешесе — язучы буларак) үсә, көчәя, тирәнәя, җитдиләнә бара.

Безнең яшь язучыларыбыз да хәзер үз юлларының «тормышка, кешеләргә зур игътибарлылык» дигән җитди этабына якынлашып киләләр. Кайберләре тыштан гади кебек күренгән, ләкин эчтән бик олы булган реаль тормышка бераз читләтебрәк карап йөргәннән соң, чын кичерешләргә сусап, яңадан «тормышка игътибарлылык» дигән позициягә кайталар. Яшь язучыларның соңгы еллар иҗатында әнә шундый куанычлы үзгәреш, тирәнгә, эчкә таба хәрәкәт сизелә. Әйе, ничек кенә, кайсы баштан гына тотынып карасаң да, барыбер, иң көчлесе, иң нык тәэсир итә торганы булып — тормыш, әйләнә-тирәдәге кешеләрнең реаль яшәеше кала. Галиҗәнаб Тормыш үзе кала!

# АРЫШЛАРНЫҢ ИСЕ ТӘМЛЕРӘК...

*Сибгат Хәким әсәрләренең ике томлыгы басылып чыгу уңае белән*

**Язар өчен илһам эзлә, диләр,**
**Урын эзлә, диләр, ямьлерәк.**
**Никтер минем шигъри хисләремә**
**Арышларның исе тәмлерәк!**

**С. Хәким.**

Узган ел Татарстан китап нәшрияты Сибгат Хәким поэмаларын аерым том итеп бастырып чыгарды. 1976 елда басылган шигырьләр җыентыгы белән бергә бу басманы шагыйрь сайланма әсәрләренең әлегә кадәр дөнья күргән иң тулы җыелмасы дип санарга мөмкин. Хәсән Туфанның ике томлыгыннан соң Сибгат Хәким шигырьләре һәм поэмаларының яңа басмасы соңгы еллар татар совет поэзиясендә зур вакыйга булып тора.

Һәр ике томга әдипнең заман сынавын үткән тормышчан әсәрләре сайлап алынган. Уннарча ел элек иҗат ителгән күп кенә шигырь һәм поэмалар тагын бер тапкыр җентекләп карап чыгылган, кыскартылган, аерым өлешләр өр-яңадан язылган. Болар инде чын каләм остасы булып танылган шагыйрь кулы белән эшләнгән.

Сибгат Хәкимнең ике томлыгы укучылар өчен гадәти бер бүләк кенә түгел. Бу томнар шагыйрьнең бөтен иҗат юлын баштанаяк күздән кичерергә мөмкинлек бирә. Аларда шагыйрь үзе туып-үскән, тәүге тапкыр Тукай шигырьләрен, халык җырларын һәм әкиятләрен ишеткән туган як темасы кызыл җеп булып сузыла.

Казан арты...

Көлсу туфраклы, соры комлы, рәшә уйнаган офыклар читендә куючылланып утырган чыршылар, кояш нуры белән өртелгән ак каеннар үсә торган як. Ул элек-электән үзенең оста куллы һөнәрчеләре, хезмәт сөючән олы җанлы кешеләре белән дан тота. Сибгат Хәким шигырьләрендә бу як нәкъ әнә шулай сурәтләнә. Шагыйрь үзенең туган ягын ихлас күңелдән сөя һәм аны башка бер җир белән дә алыштырырга риза түгел. Аның иҗатында туган як темасы халык темасы белән тыгыз үрелгән. Чөнки ул үзе дә халык арасыннан үсеп чыккан, аның тамырлары бик-бик тирәндә.

Кайчандыр Хәкимовлар буынының очында Мәмкә атлы карт торган. Авыл халкында аның исеме белән бәйле бер истәлек сакланган: имеш, авылдашлары Мәмкәне межа яручы, җир бүлүче итеп сайлыйлар. Ул, озын һәм авыр зынҗырны сөйрәп, иген басулары буйлап атлый. Артыннан тигез, туры эз сызылып кала. Бик күп нәрсә җир бүлүченең тәҗрибәсенә, иң мөһиме, аның гаделлегенә, риясызлыгына бәйләнгән. Җир болай да аз, икмәккә саран, аны бүлгәндә чак кына ялгышуың да кемне дә булса барлы-юклы ризыгыннан мәхрүм итәчәк.

«Безнең буын — озын чылбыр ул» шигырендә шагыйрь үзенең Мәмкә бабасын болай дип искә ала:

Мәмкә торган буын башында,
Бер сүз белән әйтсәк: межачы...
Авыл белән авыл арасын
Ярып узган дөнья нужасы.

...Хәзер дә бар Мәмкә елгасы,
Бар да дөрес, бар да чын монда.
Җир бүлгәндә шушы елгада
Елаган ул ятып чылбырга.

Шушы гаделлекне, намуслылыкны Хәкимовлар нәселенең башка вәкилләре дә үзләренә мирас итеп алалар. Һәм шагыйрь үзен очында Мәмкә торган өзелмәс чылбырның — крестьян токымының бер буыны итеп саный.

Буын-буын озын чылбырны,
Һич өзелмәс моңлы шул җырны
Ничә еллар инде, ни заман
Үзем сөйрим хәзер межадан.

«Югалган эзләр» шигырен укыганда күз алдыбызга шагыйрьнең «киң җилкәле, ак алъяпкыч япкан, билбавына үткен балтасы кыстырылган» әтисе килеп баса. Без анық таза мускуллы, кан тамырлары беленеп торган беләкләрен, сумала исе сеңгән сөялле кулларын күрәбез. Ул — туа-тумыштан бөтен җаны-тәне белән хезмәт кешесе. Кешегә бәя биргәндә хезмәт төп критерий итеп алына.

Шагыйрьнең әнисе Гәзза тугыз бала тәрбияләп үстерә. Аңарга күңел киңлеге, булганны бәрәкәтле итеп тоту өчен кирәкле хәстәрлек, тормыш һәм кешеләр хакында айнык фикер йөртә белү хас. Туган якларына кайткач, шагыйрь әнисе белән озак-озаклап сөйләшеп утыра торган була, аңардан үзен борчыган бик күп сорауларга акыллы җаваплар ала. Шуңадыр, Сибгат Хәким лирикасында Ана образына олы урын бирелә. Авыр югалтудан туган көенечле хисләр белән сугарылган «Васыятьләр» поэмасы моның ачык мисалы булып тора. Ана образы шагыйрь аңында туган як, Ватан һәм халык образы белән кушыла. Үлем түшәгендә яткан әнисенең соңгы васыяте анық колак төбендә яңгырый:

...кайткала, ташлама бу йортны
Бабаңнар рухы бу нигездә...

Ялгыз хуҗалык булып яшәүче крестьян тормышының һәм хезмәтенең авырлыгын С. Хәким үз иңнәрендә татып белә. Үзләренә бүлеп бирелгән уч төбе хәтле җирне эшкәртү өчен дә Хәкимовларга күпме көч һәм тир түгәргә туры килә! Ләкин шагыйрь күңеленә ул авыр елларның мохтаҗлыгы һәм ачлыгы гына түгел, шау-шулы бәйрәмнәре бүләк иткән якты истәлекләр дә сеңеп калган. «Васыятьләр» поэмасында ул шундый бәйрәмнәрнең берсен тасвирлый.

Барсы да халыкта, фәкать шул
Халыкта, мин кабат аңладым:
Шул Казан артының күңелдә
Бастырдым мин кала-тауларын.

Җыены, бәйрәме... Басуда
Рәхәт бер җылысы ашлыкның.
Ат, арба, канатлы тарантас
Буеннан-буена Ашытның.

Картлар һәм карчыклар болында,
Түшендә шуышып йөргәне.
Болында егерме авылның
Яшьлеге, гармуны, йөрәге.

Мондый бәйрәмнәр, гадәттә, түбәсендә болгар заманнарыннан калган хәрабәләр һәм кабер ташлары сакланган тау итәгендә үткәрелгән. Ул изге урын булып саналган. Тау астыннан бәреп чыккан чишмәгә уннарча, йөзләрчә чакрымнардан гыйбадәт кылырга килә торган булганнар. Тауның үзе турында исә күп санлы легендалар, бәетләр һәм дастаннар сөйләнгән. Шул рәвешчә, шагыйрь бала чагыннан ук тарихның үзе белән йөзгә-йөз очрашкан.

Поэзиягә С. Хәким Тукай белән рухланып килә. Аның беренче уңышлы әсәрләре — «Пар ат» һәм «Шагыйрьнең бала чагы» поэмалары да шул хакта сөйли. Бу поэмалар турында инде аз язылмады. Алар сугышка кадәрге татар совет поэзиясендә этап булып саналырлык әсәрләр дип бәяләнделәр.

1971 елда шагыйрь Тукай темасына яңадан әйләнеп кайта һәм фәлсәфи уйлануларга бай, иң уңышлы әсәрләреннән берсе булган «Кырыгынчы бүлмә» поэмасын яза. Шунысы кызыклы, бу поэманы язарга аны укучылардан килгән хатлар этәрә. Алар С. Хәкимнән «Шагыйрьнең бала чагы» поэмасын дәвам итүен, Тукайның яшьлек һәм гомеренең соңгы еллары турында язуын сорыйлар. Шагыйрь әлеге поэманы дәвам итми, әлбәттә. Чөнки ул тәгәлләнгән бер бөтен әсәр. Әмма укучыларның хатлары аны уйланырга мәҗбүр итә. Һәм нәтиҗәдә шагыйрь яңа әсәр язып чыкты. Аңарда Тукай татар халкының милли горурлыгы гына булып түгел, тапланмас намусы булып та гәүдәләнә. «Кырыгынчы бүлмә»дә хикәяләү дә вакыйгаларны бер-бер артлы сөйләп чыгуга түгел, тирән фикерләүгә, драматизмга, фәлсәфи уйлануларга корылган.

Бөек Ватан сугышының беренче көннәреннән үк татар язучыларының дүрттән өч өлеше яу кырына китә. Аяусыз сугыш беркемне дә сайлап-аралап тормый. Татар әдәбияты үзенең бик күп талантлы, үзенчәлекле вәкилләрен югалта. Аларның күбесе Сибгат Хәкимнең якын дуслары,

замандашлары һәм каләмдәшләре. Фронтовик әдипләребез соңгы сулышларынача Фатих Кәрим биргән изге антка тугрылыклы булып калдылар:

Кайту да юк ләкин, кавышу да,
Дошманнарны әгәр җиңмәсәк.
Данлы җиңү байраклары белән
Илнең кайгы яшен сөртмәсәк.

Үзенчәлекле һәм көчле поэтик авазларның куәтле хорында Сибгат Хәкимнең фронт лирикасы да бар. Дөрес, бу елларда шагыйрь әллә ни күп язмый. Аның бу чорда иҗат иткән шигырьләре сугыш еллары татар поэзиясендә дә, шагыйрьнең үз иҗатында да күренекле урын тотмый. Ул шигырьләрдә әле эчке яну, хисләр киеренкелеге җитенкерәми. Ләкин аларда оста тотып алынган детальләр, вакыйга һәм күренешләр конкретлыгы бар. Болар әле киләчәктә язылачак картина өчен ашыгыч рәвештә кәгазьгә төшерелгән эскизлар. Бу шигырьләрдән тирән фәлсәфә белән сугарылган зур күләмле әсәрләргә кадәр әле шактый ара бар.

Моны нәрсә белән аңлатырга соң?.. С. Хәким үз иңнәрендә сугышның барлык авырлыкларын күтәрә, солдатлар белән бергә салкын окопларда туңа, тоташ ут астында алар белән бергә һөҗүмгә бара, сугышчылар белән соңгы сыныгын, бер төрерлек тәмәкесен бүлешә. Бу елларда Сибгат Хәким өчен үзенә тапшырылган рубежны кулда тотудан, яисә бик аз югалтулар исәбенә нинди дә булса исемсез биеклекне дошман кулыннан тартып алудан да зуррак бурыч булмый. Ә бу бурычны үтәп чыгу бөтен көчеңне, бөтен барлыгыңны бирүне таләп итә. Шигырьләр исә кыска вакытлы ял арасында, привалларда, кан һәм үлемне онытып торырга тырышкан минутларда гына языла.

Сугыштан соң берничә ел узгач шагыйрь болай дип яза: «... сугышларда мин — үз гомеремдә беренче тапкыр дисәм дә ялгыш булмас — кешеләрне таныдым, совет кешеләренең көчле, бөек рухына сокландым. Хәзер менә шактый еллар узганнан соң артка борылып карыйсың да, сине ул вакытта көрәшкә илһамландырган көчнең, ышанычның каян килгәнен яхшырак төшенәсең. Сугышта сине чиксез куандырган нәрсә — ул үзеңне дошманыңнан күп көчле хис итү. Син аннан техникаң белән генә түгел, иң изге теләкләрне, идеяләрне тормышка ашыручы совет кешесе буларак өстен, син үз эшеңнең хаклыгы, гуманлы булуы белән аннан буй җитмәс дәрәҗәдә югары торасың...» Шагыйрьнең сугыш трындагы иң күренекле әсәрләреннән «Дуга» поэмасы һәм полкташларына багышланган лирик шигырь циклларының сугыштан соң дистәләрчә еллар үткәч кенә язылуы, күрәсең, очраклы хәл түгел.

Сөйгәннәрен, гаиләләрен сагынган, азат җирдәге тыныч хезмәткә сусаган сугышчы-солдатларның яу кырыннан кайтуы сугыштан соңгы совет поэзиясендә үзәк темаларның берсе булды. Бу темага язылган шигырьләрдә бөек җиңү шатлыгы тойгысы, яңа тормыш төзүченең кайнар хисләре чагылды. Ул мотивлар Сибгат Хәким поэзиясендә дә көчле яңгыраш тапты һәм барыннан да элек пейзаж лирикасында гәүдәләнде. «Туган як», «Туган җир», «Таң атканда», «Бу кырлар, бу үзәннәрдә» шигырьләренең исемнәре үк шул хакта сөйлиләр. Бу шигырьләрдә туган-үскән җиреннән дүрт ел буена аерылып торган лирик геройның илгә булган мәхәббәте яңача, өр-яңа көч белән гәүдәләнде.

Әлеге шигырьләрне укыганда Расул Гамзатовның: «Туган якка мәхәббәт ачлыкны хәтерләтә. Аны басарга мөмкин түгел», — дигән акыллы, зирәк сүзләре искә төшә. Шагыйрь, чыннан да, туган җирен сагынып җырси. Ләкин аның хисләрендә күзгә бәрелеп, кычкырып тора торган аһ орулар юк. Ул хисләр төптә, бик тирәндә ята.

Сибгат Хәкимнең сугышка кадәр иҗат ителгән шигырьләрендә дә туган як табигатенә чын күңелдән соклану, аны ярату хисе зур урын алып тора. Һәм артык берни дә түгел. Ә сугыштан соң язылган шигырьләрдә — туган җиргә мәхәббәте үлем белән йөзгә-йөз очрашуларда сыналган лирик герой. Бу ярату хисе инде бөтенләй башка төрле. Ул шигырьләрдә туган җиргә, туган якка мәхәббәт лирик геройның патриотизмын чагылдыру өчен хезмәт итә. Шулай итеп, шагыйрьнең табигать күренешләрен тасвирлаган лирик әсәрләре дә социаль яңгырашка ия булу дәрәҗәсенә күтәрелә.

Аннан соң Сибгат Хәкимнең баштагы шигырьләрендә туган як темасы традицион рухта чишелеп килде. Аларда я халык җырлары интонациясе, я Тукай һәм Такташ поэзияләре аша таныш булган образлар үзләрен бик нык сиздерәләр. Шулай ук бу чорда рус классиклары йогынтысының да көчле булуын әйтеп үтәргә кирәк. Инде сугыштан соңгы шигырьләрдә яу кырында чыныгу алган көчле рухлы кешенең йөрәк тибешен тоясың. Дөрес, аның

лирикасы, элеккечә, поэзиябез традицияләреннән аерылгысыз. Шул ук вакытта шагыйрьнең кабатланмас индивидуаль йөзе көннән-көн ачыграк билгеләнә бара.

Дөрес, С. Хәкимнең бу чор иҗатында күпмедер дәрәҗәдә әлегә мәшәкать-хафасызлык сизелә. Бу, күрәсең, тиңдәшсез героизм үрнәге булган кырыс сугыш чорыннан тыныч тормышка күчү «кыенлыклары» белән аңлатыладыр. Сугыштан соңгы тормышка ияләшкәнче, аның авыр, кичектергесез проблемаларына мөрәҗәгать иткәнче шагыйрьгә береаз вакыт кирәк була.

С. Хәким берничә ел буена «Бакчачылар» исемле зур күләмле лиро-эпик поэма өстендә эшли. Сугыш тәмамлангач языла башлаган бу әсәр 1952 елда гына тәмамлана һәм басылып чыга. Шагыйрь, үзенә хас булган гадәт буенча, 1957 елда аңарга яңадан әйләнеп кайта һәм күп кенә төзәтүләр, өстәүләр кертә. Поэманың төрле вариантларын чагыштырып карасаң, шагыйрьнең профессиональ осталыгы торган саен үсә баруын күрәсең. Беренче карашка бик бәләкәй булып тоелган төзәтмә дә образларга яңа яңгыраш бирә, аларның художество тәэсирен көчәйтә. Сибгат Хәкимнең иҗади йөзе лирик шагыйрь буларак билгеләнә. Ул чынбарлыктагы вакыйга һәм күренешләрне, сихри каләм көче белән җанландырып, үз йөрәге аша үткәрә белә. Шагыйрь һәм тәрҗемәче С. Липкин әйткәнчә, без аның шигырьләрендә фактларга гына түгел, аннан да әһәмиятлерәк нәрсәгә — хискә ышанабыз. Башка тәнкыйтьчеләребез дә С. Хәким поэзиясенең кичерешләргә һәм хисләргә бай, кеше күңеленең яшерен серләрен ачып бирергә сәләтле булуын басым ясап әйтәләр. Иҗатының бу үзенчәлеге аның җырларында аеруча калку чагыла.

Шагыйрь җыр өчен махсус текстларны бик сирәк яза. Композиторларыбыз, гадәттә, аның лирик шигырьләрен үзләре сайлап көйгә салалар. Һәм, көйгә салынгач, ул шигырьләргә яңадан канат үсеп чыккандай була, алар бөтенләй яңа тормыш белән яши башлыйлар. С. Хәким сүзләренә язылган җырларда халык җанының иң матур сыйфатлары — тормыш сынавын узу өчен кирәкле чыдамлык, Ватанга мәхәббәт, кешелек горурлыгы кебек олы хисләр гәүдәләнә. Бәлки аларда, әйтик, рус халык җырларындагы киңлек һәм иркенлек житенкерәмидер. Алар ифрат тыйнак, басынкы. Ләкин бу тыйнаклык, оялчанлыкта бай хисләр гаммасын тоясың. С. Хәким сүзләренә язылган җырлар сугыш елларында халыкның җиңүгә булган ышанычын арттырдылар, ә тыныч чорда кешеләрдә мәхәббәт һәм дуслык кебек җаваплы һәм озын гомерле хисләр тәрбияләүләр. Шагыйрь бай сурәтләү чараларына халыктан өйрәнә, татар халык җырларына хас булган параллелизмнардан оста файдалана, бу традицияләрне үстереп, аларны яңа буяулар белән баета. Аның сүзләренә иҗат ителгән иң әйбәт җырлар күптән инде татар җыр классикасына керделәр. Мәсәлән, «Күңелем Ленин белән сөйләшә», «Таң атканда», «Казакъ дустыма», «Тынычлык солдатлары», «Житенче кыз җыры», «Чын йөрәктән», «Кем уйлаган», «Барысы да йөрәктә» һәм башкалар.

Ничектер, шулай бервакыт мин Сибгат Хәким сүзләренә язылган күп санлы популяр җырларның авторы композитор Рөстәм Яхиннан шагыйрьнең шигырьләре аны кайсы яклары белән җәлеп итүе турында сорадым.

— Аның шигырьләре лиризм белән шул кадәр сугарылганнар, — дип җавап бирде композитор,— алар үзләреннән-үзләре көйгә салуны сорап торалар. Иң мөһиме, ул шигырьләр әзер трафаретка корылмаганнар. Аларга һәрбер очракта яңача якын килергә, яңа буяулар эзләргә кирәк.

Әйе, Сибгат Хәким — җырдагы шаблонга, әзер алымнарга каршы чыккан шагыйрь. Аның һәр тексты — үз алдына, мөстәкыйль рәвештә яши торган һәм ахыранача эшләнеп беткән лирик шигырь. Ләкин шул ук вакытта шагыйрь җыр жанрының үз кануннары барлыгын да яхшы аңлый. Кайчандыр ул җырның драматизмга ия булырга тиешлеге турында язып та чыккан иде. Җырда үзенә күрә сюжетны тәшкил иткән эчке психологик хәрәкәт булырга тиеш. Бу, әлбәттә, җырның нигезендә нинди дә булса вакыйга ятырга тиеш дигән сүз түгел. Әмма анда аерым юлларны, строфаларны бер-берләренә беркетә, бәйли торган хис булу мәҗбүри.

Шагыйрьнең «Юксыну» шигыре һәм шул ук исемдәге җыр тексты, нигездә, икесе ике нәрсә. Беренчесендә лирик геройның мәктәптәш дустына аңлатып бирә алмаган мәхәббәте турында сүз барса, икенчесендә узган сугыш белән бәйле уй һәм тойгылар, аерылу һәм югалту хисләре тасвирлана. Җырның тексты шигырьгә караганда өч тапкырга кыскарак, эчтәлеге, фикере исә тирәнрәк һәм киңрәк. Ә менә

«Фазыл чишмәсе» җыры башта өч кенә куплеттан торган. Җыр Мехчылар клубында беренче тапкыр башкарылганда артистлар да, тыңлаучылар да, автор үзе дә аның төгәлләнеп җитмәгәнлеген сизәләр. Хәтта хатын-кызлар арасыннан берсе урыныннан торып: «Ник туктап калдыгыз? Дәвам итегез!» — дип кычкыра. Эш монда җырның кыска булуында түгел, ә сюжетның психологик яктан ахырынача эшләнеп җитмәвендә. Шагыйрь җыр текстына тагын ике строфа өсти. Һәм аның бүгенге көндә җырлана торган варианты туа.

Җыр — күпмедер дәрәҗәдә иң демократик поэтик жанр. Ул шагыйрь сүзен гадәттә шигырь укымаучыга да илтеп җиткерә, тыңлаучының үзенә дә сиздермәстән, аның күңелендә матур тойгылар уята. Шуңа күрә дә бер әйбәт җыр халыкның культура тормышында кайбер калын романнарга караганда да әһәмиятлерәк роль уйнарга мөмкин.

Лиризм тирәнәю белән беррәттән Сибгат Хәким иҗатында тематика киңәю, шигырьләренең социаль-политик яңгырашы көчәю, гражданлык тойгылары үсү процессы да бара. Шагыйрьнең утызынчы елларда вакытлы матбугат битләрендә басылган беренче шигырьләре үк инде югары идеяләр белән сугарылган, шул чорның актуаль бурычларын үтәүгә юнәлдерелгән. Бу чорда ул авылда кумәк хуҗалыклар оештыру һәм яңа фабрика-заводлар төзү турында яза. Яңа социалистик стройның җиңүен раслау белән бергә, Октябрь казанышларын саклап калу кирәклеге идеясен үткәрә. Әмма әлегә ул шигырьләрдә риторикадан котылып бетә алмау, әзер схемалар белән эш итү үзен шактый сиздерә. Ул шигырьләр әле шагыйрьнең пейзаж һәм интим лирика өлкәсендәге байтак әсәрләреннән күп кайтышлар. Аларда күтәрелгән проблемаларның шагыйрь тарафыннан әле җитәрлек кичерелмәгәнлеге күзгә бәрелеп тора.

Илленче елларның икенче яртыларында Сибгат Хәким үз иҗатында сыйфат ягыннан алга таба зур сикереш ясый. Ә бу сикереш аның иҗат биографиясендә үтелгән юл белән генә түгел, тормыш куйган таләпләр белән дә аңлатыла. Ватан язмышы аның үз язмышы белән бергә үрелә. Гомуми пафостан һәм үзенә хас булмаган яңгыравыклы сүзләрдән баш тартып, шагыйрь үз иҗатындагы иң матур сыйфатларны — эчкерсезлекне, сурәтләү чараларының, тәгъбирләренең табигыйлеген, тәэсирлелеген саклап кала, аларны тагын да үстерә һәм көчәйтә төшә.

С. Хәким иҗатындагы әлеге ике сыйфат — лиризм һәм иҗтимагый пафосның бергә кушылуы механик рәвештә генә бармый. Аның поэзиясенең иҗтимагый яңгырашын һәм идея-эстетик әһәмиятен тагын да көчәйткән өр-яңа сыйфатлар табыла. Үзенең иҗат йөзен таба барып, ул башка беркемгә дә охшамаган, меңнәрчә укучылар яратып өлгергән шагыйрьгә әверелә. Ләкин ул үзенең осталыгы, кабатланмас булуы белән масаймый, катлаулы образлар белән эш итәргә тырышмый, кайвакытта «хәзерге заман стиле» дип әйтелә торган нәрсәдән дә ерак кача. Аның төп үзенчәлеге — үзе булып калуында, уй һәм кичерешләренең табигыйлегендә. Ул бары тик үзен тирәнтен дулкынландырган, асылына ахырынача төшенгән, җанына тынгылык бирмәгән нәрсәләр турында гына яза. Шуңа күрә аның шигырьләре укучыны үзләренең художество дөреслеге белән ышандыра, яулап ала.

С. Хәким иҗатында лирика һәм публицистиканың бер бөтен һәм тыгыз, нык тукымага әверелүенә мисал итеп аның «Күңелем Ленин белән сөйләшә» дигән шигырен китерергә мөмкин. Бу шигырь күптән инде мәктәп дәреслекләре битләрендә үзенә лаеклы урынны алды. Беренче карашка, шигырь табигать күренешләрен сурәтләгән гадәти юллардан башланып китә кебек:

Казан әле, Казан уянмаган,
Яфрак белән яфрак серләшә.
Нәрим таңда Ленин урамында,
Күңелем Ленин белән сөйләшә...

Җәйге матур таңны күреп сокланудан туган борчусыз салмак хис акрынлап икенче бер олы хис белән алышына. Шагыйрьнең тавышы көчәйгәннән-көчәя, фикере үткенләнгәннән-үткенләнә, киеренкеләнгәннән-киеренкеләнә баруын тоябыз. Шагыйрьнең поэтик мөхитендә бөтен ил, бөтен планета урын ала.

Без узарга тиеш, әй, юллар бар,
Зур эшләргә чакырып ил дәшә.
Юлга шулай чыгар алларыннан
Күңелем Ленин белән сөйләшә.

Бу шигырь белән В. Маяковскийның «Иптәш Ленин белән сөйләшү» дигән күренекле әсәре арасындагы уртаклыкны күрү кыен түгел. Ләкин ул уртаклык әсәрнең язылу алымында гына. Ә калган бөтен нәрсә — шигырьнең гади һәм эчкерсез лирик интонациясе дә, хисләрнең табигыйлеге дә, фикерләү рәвеше дә С. Хәкимчә, шагыйрьнең үзенеке.

Шагыйрь лирикасында күзгә бәрелеп тормаган яшерен бер агым бар. Аның иҗатында халык белән, аның уйлары һәм кичерешләре белән тыгыз бәйләнешне тоясың. Шагыйрьнең йөрәге укучы йөрәге белән бергә тибә. Боларның барысы бергә аның поэзиясенә киң популярлык бирә. С. Хәким поэзиясенең гражданлык яңгырашы һәм социаль тирәнлеге «Ленин фәрманы белән» һәм «Язгыгыз, җир уллары» поэмаларында үзенең иң зур чагылышын тапты. Бу әсәрләре өчен шагыйрьгә Г. Тукай исемендәге республика һәм Горький исемендәге РСФСР премияләре бирелде. Бу поэмалар турында инде күп язылды, шуңа күрә аларга махсус тукталып тормыйм. Бары тик шагыйрьнең Ленин темасы өстендә эшләгәндә үзенә һәм үзенең талантына карата ифрат дәрәҗәдә таләпчән булуы турында гына әйтеп үтәсе килә. Моны «Баһавиның моңы» поэмасы мисалында да ачык күрергә мөмкин.

Ленинның Кокушкино чоры тормышында бер кызыклы факт бар. Яшь Володяны күреп белүчеләр бала чакта аның күршедәге татар авылы Апакайда яшәгән Баһави исемле көтүче малай белән дус булуы хакында сөйлиләр. Бу фактны, мөгаен, «матурларга», Баһави һәм Володяның очрашу моментларын уйлап чыгарырга, диалоглар кулланырга мөмкин булыр иде. Әмма шагыйрь ул юлдан бармый. Кайчандыр көтүче малай Баһави сутән үрелгән чыбыркысын сөйрәп узган Апакай буйлап йөри ул. Апакайда инде күп нәрсәләр үзгәргән. Баһавиның да йорты сакланмаган. Аның урынында бары тик әрем һәм сары үги ана яфраклары каплап киткән чокыр гына калган. Табигый, монда инде шигырьгә төп образ булып сары чәчәк килеп керә. Сары чәчәк — аерылу, кайгы, җирсенү символы, татар халык җырларында киң таралган образ. Кокушкино болыннарындагы сары чәчәкләрне, мөгаен, Владимир Ильич та еш исенә төшергәндер.

Әсәрнең тукымасына килеп кергән сары чәчәк әнә шул рәвешле поэтик образ булып әверелә һәм өр-яңа эчтәлеккә ия була. Ул чәчәк күпчелек татар укучыларына таныш булган борынгы татар җырын хәтерләтә. Бу җыр яшь Володяның күңеленә сеңеп кала һәм соңыннан ул аны үзалдына кабатлап йөри.

Себер үзе... Йорты тирәсендә
Биек итеп койма кой нигә —
Баһавиның моңы килеп керде
Әкрен генә кыяр-кыймыйча.

Күргәнебезчә, чәчәк образының идея эчтәлеге киңәя, шигырьнең фикере юлдан-юлга тирәнәя. Бу чәчәкләр конкрет бер урынны, билгесез бер көтүче малайны һәм аерым бер җырны гына искә төшереп калмыйлар, ә бөтен Татарстанны, татар халкын күз алдына китереп бастыралар. Бала чакта бөек юлбашчының хәтеренә кереп калган һәр нәрсә аның киләчәктәге юлын билгели.

Ят сагышлар бассын юлларыңа,
Юлларыңа бассын Альплар...
Марсельезаларның арасында
Татарның бер моңын алып бар!

Нинди тирән фикер, нинди киң караш! «Марсельезалар арасында» яңгыраган борынгы татар халык җыры — шагыйрьнең йөрәге аша узган уйлану-кичерешләрнең, иң изге хисләрнең образлы чагылышы. Әбит боларның барысы да конкрет күзәтүләрдән башланган. Шагыйрь үзенең поэмасын шул ук чәчәкләр белән тәмамлый:

Апакайда йөрдем, көтүендә
Уйный тайлар, уйный яшь атлар.
Мәңгелек ут сыман, тугайларда
Яна дөрләп сары чәчәкләр.

Менә шагыйрьнең «Ярлар, ярлар...» исемле ике генә строфадан торган лирик шигыре. Беренче строфада конкрет бер табигать күренеше тасвирлана:

Чыр-чу килә бөтен тирә-юнем,
Коелып калган чыбык йә салам.
Ярлар, ярлар, сез зур кәрәз төсле,
Күпме кошлар оя ясаган...
Ярлар, ярлар, халык күңеле кебек,
Сез катлаулы, тордым оялып,
Җырларыма минем сездә урын
Табылыр микән? Тик бер оялык.

Шагыйрь аңында елга ярлары халык язмышына, Ватан язмышына барып тоташа. Шул рәвешле табигать күренешләре, шагыйрьнең фикерләвендә җанланып, өр-яңа эчтәлек белән тулылана. Бердәм сафта үз урыныңны — җырларыңа оя кору өчен кирәк булган урынны табу — шагыйрьне әнә шул нәрсә борчый, аның лирикасы әнә шул хактагы уй белән сугарылган.

Сибгат Хәким шигырьләрен укыганда аның аңында һәр вакыт киеренкелек булуын тоясың. Ул әзер поэтик штампларны, буш фразаларны беркайчан да кабул итми. Үзенең иҗаты белән шагыйрь тормышта нәрсәне дә булса үзгәртергә сәләтлеме?.. Татар шагыйрен әнә шул характердагы сораулар борчый. Һәм бу гомуми сүзләр, гомуми фикер йөртү генә түгел. Бу — шагыйрь алдына йөрәк үзе куйган зур сорау. Ул сорауга бары тик бөтен иҗатың, бөтен тормышың белән генә җавап бирергә мөмкин.

**РАФАЭЛЬ МОСТАФИН.**

# ҮР АРТЫННАН ҮРЛӘР КҮРЕНӘ...

**1963** елның апрель ае. Казан университеты. Тарих-филология факультетында гыйльми совет утырышы бара. Залга күренекле галимнәр, киң җәмәгатьчелек вәкилләре җыелган. Бүген монда университетның татар теле һәм әдәбияты кафедрасы доценты Мирфатих Зәки улы Зәкиев филология фәннәре докторы дигән гыйльми дәрәҗә алу өчен диссертация яклый. Секретарь совет әгъзаларын, залда утыручыларны диссертантның тормыш юлы белән таныштырып чыга: 1928 елның 14 августында крестьян гаиләсендә туган. 1936 елда Ютазы урта мәктәбенә кереп, 1946 елны шул ук районның Кәрәкәшле урта мәктәбен тәмамлаган. Мәктәптә уку белән бергә, каникул вакытларында авылда көтү көткән, тимерче булган, колхозның ревкомиссия члены итеп сайланган. 1946 елда Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга кергән һәм аны бик яхшы билгеләренә генә тәмамлап, 1951—1954 елларда кафедра каршында проф. Л. Җәләй җитәкчелегендә аспирантура үткән. Аспирантураны диссертациясен вакытыннан алда яклап тәмамлаган. 1954—1960 елларда татар теле кафедрасында өлкән укытучы һәм доцент булып эшләгән...

Диссертант, кафедра артына басып, үзе башкарган хезмәт турында сөйли. Аның темасы — «Татар әдәби теленең синтаксик төзелеше». Бу көн килеп җиткәнче, күпме эш эшләнгән: хәзерге татар әдәби теленең синтаксисына багышланган ике монография, «Татар теленең синтаксик төзелеше» исемле утыз табаклык монография, урта мәктәпләр өчен синтаксис дәреслеге һәм программалар, дистәләгән мәкаләләр язылган.


Оппонентлар — Мәскәү профессорлары Б. А. Серебренников һәм Е. И. Убрятова, Уфадан профессор Җ. Г. Киекбаев диссертантның хезмәтенә югары бәя бирәләр.

Берничә ай үтүгә, Бөтенсоюз Аттестацияләү комиссиясе М. З. Зәкиевне филология фәннәре докторы итеп раслый. Бер елдан аңа профессор исеме бирелә. Аңа нибары утыз биш яшь була.

М. З. Зәкиев — Казан университетының татар теле кафедрасына нигез салучы да. Кандидатлык диссертациясен яклап, кафедрада эшли башлагач, ул муеннан гыйльми эшкә чума, укыту-тәрбия эшләрендә тел һәм әдәбият кафедрасы мөдире Х. Госманның ышанычлы ярдәмчесе булып китә. 1960 елдан татар теле һәм әдәбияты кафедрасы икегә — тел һәм әдәбият кафедраларына аерылган вакыттан алып 1965 елга хәтле М. З. Зәкиев кафедра мөдире булып эшли.

Үзенең фәнни, оештыру, тәрбияви эшчәнлеге белән инде танылып өлгергән яшь галимне 1965 елда Казан дәүләт педагогия институтына фәнни эш буенча проректор итеп күчерәләр. 1967 елда ул институтның ректоры итеп билгеләнә һәм хәзерге көнгә хәтле шул постында эшли. Педагогия институты соңгы ун ел эчендә гаять зур уңышларга иреште. Институтның социалистик ярыш нәтиҗәләре буенча Россия Федерациясе педагогик югары уку йортлары арасында беренче урынга чыгуы да М. З. Зәкиев җитәкләгән коллективның нык, ышанычлы адымнар белән һаман алга баруы турында сөйли. Студентларның укуын, көнкүрешен, ялын оештыруда институтның казанышлары зур.

Институтта фәнни, укыту һәм тәрбия эшләренең югары дәрәҗәсен билгеләп, 1977 елда хөкүмәтебез аның байрагына Хезмәт Кызыл Байрагы орденын такты.



*Профессор М. З. Зәкиев үзенең эш кабинетында.*

Үзең эшләмичә, башкаларны эшләтеп булмый. Үзең янмыйча, башкаларны яндырып булмый. Профессор М. З. Зәкиев көне буе институтта. Соңгы кеше булып киткән көннәренең исәбе-хисабы юктыр. Институтның барлык эшләрен нечкәләп белә. Берсен генә дә икенче дәрәҗәдәге эшкә исәпләми. Фәнни, уку-укыту, төзелеш, комсомол, профсоюз, спорт эшләре — һәрберсен вакытында һәм уңай хәл итәргә кирәк.

Ректорның кабул итү бүлмәсендә көне буе эшлекле җанлылык: кафедра мөдирләре җыелышы; ректорат утырышы; студент стипендия сорап гариза белән килгән; галимнең аспиранты консультация көтеп утыра; аның элекке шәкертләре консультациягә килгәннәр яки болай сагынып, күрәселәре килеп утыралар; нәшрияттан бик тиз карап чыгар өчен корректура китергәннәр; яңа гына почта килгән; Уфадан, я Саратовтан, я Мәскәүдән берәр галим көтеп утыра... Ректор һәр мәсьәләне җентекләп тикшереп, оператив рәвештә тиешле чаралар күрергә ярата. Аның гадәте шул: «Бүгенгене иртәгәгә калдырма».

Ничек өлгерә икән бу кеше? дип үз-үзеңә кат-кат сорау бирәсең. Чыннан да, ул — СССР Фәннәр академиясе каршындагы тюркологлар комитеты члены, «Советская тюркология», «Совет мәктәбе» журналларының редколлегия члены, Казан шәһәр комитеты депутаты, КПССның Бауман райкомы бюросы члены, ТАССР Мәгариф министрлыгы коллегиясе члены, РСФСР Мәгариф министрлыгының милли филология буенча гыйльми комиссиясе председателе...

Бу елларга хәтле үк шулай булган: университет елларында группада комсорг, үзе укыта башлагач — группа җитәкчесе, студентларның фәнни түгәрәге җитәкчесе, факультетның партбюро члены, партбюро секретаре...

Бөтен илебезгә танылган институт җитәкчесе булу җиңел түгел. Ләкин Мирфатих Зәкиев үзенең яраткан фәненнән бер көнгә дә аерылып тора алмый. Көне буе институт эшләрен хәл итеп утырса да, кичләрен, ул, онытылып, алдагы кичне өзелеп калган фикерләрен искә төшерә, соңгы елларда үзен бөтенләе белән биләп алган проблемаларны өйрәнә... Беренче фәнни мәкалә язуына егерме алты ел үткән. 1952 елдан башлап, «Совет мәктәбе», «Казан утлары» журналларында, газеталарда аның беренче мәкаләләре басыла. Алар татар теле синтаксисының аерым мәсьәләләренә, тәрҗемәләргә, матбугатта яңа чыккан китапларга, дәреслекләргә багышланган. 1954 елда «Хәзерге татар әдәби телендә хәбәр» дигән темага кандидатлык диссертациясе яклаганнан соң, галим күп кенә еллар буе синтаксисны өйрәнә. 1958 елда КДУ студентлары өчен дәреслек итеп чыгарылган «Хәзерге татар әдәби теле. Синтаксис» татар теленең синтаксик төзелеше буенча беренче махсус монография иде. Бу хезмәт университетта фәнни эшләр буенча бирелә торган беренче премиягә лаек булды. Ә галимнең «Татар теленең синтаксик төзелеше» (КДУ, 1963 ел) исемле монографиясе барлык төрки телле республикаларда синтаксис буенча эшләүчеләр өчен күп еллар

бүе файдалы кулланма булып кила. Хезмәтнең рус телендә язылган булуы аның фәнни-практик дәрәҗәсен тагын да күтәрә. Ирексездән М. Казембек сүзләре искә килеп төшә. «Общая грамматика турецко-татарского языка» дигән хезмәтенең керешендә ул болай дип язган: «Озак та үтмәс, төрек-татар телләренең мин язганга караганда тулырак һәм төгәлрәк синтаксик кагыйдәләр җыелмасы рус телендә басылып чыгар: бу өлкәдә мине дәвам иттерүчеләргә чын йөрәктән зур уңыш телим» (1846 ел, 7 бит). Яшь татар галименең төрки телләрдән татар теле синтаксисын монографик планда тикшереп чыга алуы М. Казембек теләгән уңыш иде.

Галим соңгы елларда татар халкының формалашуына мөнәсәбәтле рәвештә татар теленең барлыкка килүе мәсьәләләренә зур игътибар бирә. Дистәләрчә мәкаләләрендә, «Туган тел үсеше» (Казан, 1967 ел), «Татар халкы теленең барлыкка килүе» (Казан, 1977 ел) кебек хезмәтләрендә бу проблема шактый нигезле хәл ителә. Соңгысына язылган рецензияләрнең берсендә билгеләп үтелгәнчә, М. З. Зәкиев хезмәтенең иң әһәмиятле ягы шунда: «ул телне лингвистика кысасында гына түгел, ә бәлки халык тарихы, аны өйрәнүче фәннәр (археология, антропология, этнография һ. б.) белән тыгыз бәйләнештә карый. Тел күренешләренә комплекслы якын килү автор тикшеренүләренең кыйммәтен арттырган һәм андагы нәтиҗәләрнең яңгырашын да көчәйткән. Шуның аркасында бу китапта тел тарихы аша халыкның катлаулы тарихын да шактый дәрәҗәдә күзалларга мөмкинлек туа» («Социалистик Татарстан», 1978 ел, 16 февраль саны).

Галимнең мавыгып эшли торган тагын бер өлкәсе бар. Бу — урал-алтай телләренең тарих-генетик уртаклыгын алга сөрә торган алтаистика фәне. Сүз уңаенда әйтеп китик: бу проблеманы төрки тел белемендә бөтен кыюлыгы белән күтәреп чыгучы галим башкорт профессоры Җәлил Киекбаев була. М. З. Зәкиевне дә бу өлкәгә ул «индерә». Бу иҗади дуслык еллар буе дәвам итә.

Киң күңелле, ачык йөзле, талантлы тел галиме, актив җәмәгать эшлеклесе, язучы һәм фольклорчы Җәлил ага Киекбаев турындагы истәлекләр китабында («Дәртле йыр», Өфе, 1974) М. З. Зәкиев Җәлил аганың бер сүзен искә төшерә: «Ялгыз агачның чын мәгънәсендә матур, төз, биеккә омтылып үсүе табигатьтә бик сирәк очрый... Димәк, агачның үсүе өчен урман булу кирәк, ә ялгыз агач урман түгел әле ул. Тормыш максатың үзеңне күрсәтү түгел, ә кирәкле эш эшләү булса, якын-тирәңдә үзең кебекләрне булдырырга, үстерергә кирәк, шунда гына чын мәгънәсендә алга китеп була, эшне югарыга, биеклеккә күтәреп була», (41 бит) дип әйткән аңа Җ. Г. Киекбаев. Бик иртә аспирантлар белән җитәкчелек итә башлаган М. З. Зәкиевнең шәкертләре ике дистәгә якын. Алар Казан, Саратов, Башкорт дәүләт университетларында, Казан, Баку, Стәрлетамак педагогия институтларында, Казанның фәнни-тикшеренү институтларында, матбугат органнарында эшлиләр. Алар арасында ике фән докторы һәм унбишләп фәннәр кандидаты бар.

Ректор булу өстенә, М. З. Зәкиев 1965 елдан бирле педагогия институтының татар теле кафедрасын җитәкли. Укыту процессын камилләштерү, яңа лекция курслары, ярдәмлекләр, дәреслекләр әзерләү, программалар төзү һәм бастырып чыгару, фәнни җыентыклар төзү һәм башка мәсьәләләр буенча кафедрада зур һәм нәтиҗәле эш алып барыла.

«Хезмәтенә күрә хөрмәте», ди халык. Хөкүмәтебез галимнең хезмәтләренә югары бәя бирде. М. З. Зәкиев Хезмәт Кызыл Байрагы ордены һәм медальләр, «СССРның югары мәктәбе», «СССРның мәгариф отличнигы» значоклары белән бүләкләнде. 1970 елда аңа Татарстанның, 1976 елда РСФСРның атказанган фән эшлеклесе дигән мактаулы исемнәр бирелде.

Шушы елның августында профессор М. З. Зәкиевкә илле яшь тула. Илле яшь ул иҗади гомернең яртысы гына. Без, аның хезмәттәшләре, галимне кайнар котлыйбыз һәм аның яңадан-яңа фән үрләренә күтәрелә баруын, тел белемен берсеннән-берсе кыйммәтле яңа хезмәтләр белән баетуын телибез.

**ӘДҺӘМ ТЕНИШЕВ**, профессор.
**ФЛЕРА САФИУЛЛИНА**, доцент.

*ЕЛМАЕП ТА, КӨЛЕП ТӘ...*

**Шәүкәт Галиев**

# ӘЗ-МӘЗ МӘЗӘК

ЯКИ

# КОТБЕТДИННЕҢ КЫРЫК ТАРТМАСЫ

*АВТОРДАН.*

*Үзем дә уйламаганда язылган китап булып чыкты бит әле бу! Менә мәзәк — көтмәгәндә туган ул китап үзе... чирек гасыр буе диярлек язылган!*

*Йөзләгән куен дәфтәрләрендә җыелып килгән мәзәкләремнең бер өлешен сезгә дә укытырга булдым, кадерле укучылар. Ә кызыксызларын сылтарга Котбетдин бар! Әгәр дә мәгәр әзрәк елмайтырдайлары очрый калса: «Мәзәген генә түгел, Котбетдинен дә үзем тудырдым!» — дия алам.*

*Котбетдиннең «метрикасы» яңадан чыга башлаган «Чаян» журналының 1952 елгы 1 санында теркәлгән. Ялгызына күңелсез булыр дип, 1958 елны Сәйфетдин белән дуслаштырдым. Үстереп мәшәкатьләнмәс өчен, туганда ук «сакаллы сабый» иткән идем мин аларны. Ул чакта үземнән ике тапкыр олырак иделәр, инде кордашлар булдык... Шаян кешеләр картаймый ди бит — Котбетдин белән Сәйфетдин дә һаман бер чама. Ә без картайсак та шул шаяннарны кайгыртып кына картаербыз инде...*

*Минемчә, мәзәк — бәләкәй генә спектакль ул. Вакыйга безнең көннәрдә бара, темалары актуаль, катнашалар: Котбетдин белән Сәйфетдин һәм башкалар...*

*Беренче пәрдәне, юк ла... беренче тартманы ачар алдыннан мәзәкнең кырык тартмачысы Котбетдиннең бер теләген җиткерергә тиешмен: зинһар өчен, эш вакытында укый күрмәгез бу мәзәкләрне! Начальнигыгыз сытык чыраегызны күреп: «Ник шул кадәр кәефсез син!? Артыграк арып җибәрдеңме әллә?» — дип, яраткан эшегездән аерып, берәр ял йортына җибәреп куюы бар... Ә ял йортында инде мәзәк укырга була.*

## Белмимнең беленме артмый

*Котбетдиннең бик белеп әйткән сүзе.*

**ЙӨЗҮ**

Сәйфетдин бер галим турында сөйли:

— Бик мәгълүматлы кеше, фәндә ул йөзә генә!

— Беләм мин аны, бер аягы белән җирдән тырнап бара! — ди Котбетдин. — Әллә ни тирәнгә керә алмый...

## ҮЗ БИЗМӘНЕ

— Үземнең әллә ни вакыт калмый, әмма күршем китапны су кебек эчә! — ди Сәйфетдин мактанып.

— Минем күршегә җиткерәлми икән, — ди Котбетдин. — Минем күрше аракы кебек эчә...

## ХӘСТӘРЛЕ

Берәү һәр вакыт аркасына капчык белән китаплар асып йөри.

— Нәрсәгә алар?

— Сөйләшкәндә цитата кирәк булса, өйгә чабыйммы? — Шунда ук калын бер китап ала, актара торгач, эзләп таба: «Китап — белем чишмәсе!»

## АКЫЛЛЫ

— Кичә акыллы дигән сүзләреңнең бүген беркатлы икәненә төшенәсең, — дип көрсенгән Сәйфетдин.

— Анысы ярый! Былтыргы беркатлы сүзләрен быел да акыллы дип йөрүчеләр бар әле! — дип юаткан аны дусты.

**Акылың алтын булса,
аны алтын тешләр
куйдырырга гына сарыф итмә!**

*Котбетдиннең акыл тешләре арасыннан чыккан сүзе.*

## ТАКЫР

Бөдрә чәчле берәү Котбетдиннең такыр башына карап әйтә:

— Нишләп коелды икән, агай, бу чәчләрең?

— Күп уйлаганга.

— Шулай да ямьле түгел инде...

— Нишләмәк кирәк, кайсы баш тыштан такыр, кайсы баш — эчтән...

## ЧИКЛӘВЕК

Әстерхан чикләвеге баш өчен файдалы дигәнне ишеткәч, Сәйфетдин чамасыз ашаган да, эче авыртып ята:

— Кайчан акыл керер миңа, ах, тиле баш, тиле баш!

— Кара әле, кара, файдасы тия түгелме соң? — дип сөенә Котбетдин. — Үзеңә дөрес бәя бирә башладың!

## АЧЫШ

Берәү ачыш ясагандай әйтә:

— Беләсеңме, тормыштагы каршылыклар, бәхетсезлекләр кешене тәҗрибәле, акыллы итә!

— Синең көнкүреш артыгы белән шәп булган икән, алайса, — ди Котбетдин.

## КЕМНӘР КАЛА

— Төрле фикерләр килә башка. Кайсы шунда ук онытыла, — ди Сәйфетдин. — Фикерләр киләләр дә китәләр — без калабыз, Котбетдин...

— Без киләбез дә китәбез — фикерләр кала! — диген. — Хәер, кайсы кешенең фикерләре үзеннән алда китәләр...

## ЯХШЫ ЭТ

Нәселле этен кич йөртергә алып чыккан берәүгә юлыга Котбетдин. Тегенең бөтен сөйләгәне шул эте: ул акыллы да, ул тәртипле дә, ул тыңлаучан да, ул тагын әллә нәрсәләр икән!

— Үзе алдында сөйләмә, бозарсың! — ди Котбетдин.

— Әй, ул аңгыра нәрсә аңлый соң!

## ТАНЫШЛАР

Кем турында сөйләсәләр дә, юньсезгә чыгарып тора бу кеше. Әле дә бергә эшләүче агай турында:

— Би-ик яхшы беләм мин аны, ахмаклыкның аргы ягына чыккан нәрсә ул! — ди.

— Сез ул аргы якта еш күрешәсезме әллә? — дигән Котбетдин.

### ЭЧКЕ КУЛЬТУРА

Каракүл бүрек, кыйммәтле пальто кигән бер адәм кукраеп кына йөри, сөйләшкәндә «эчке культура» дигән сүзләр дә кыстыргалый...

— Эчке культурасы тышкы кием булып күренә калса, бу кеше... шыр ялангач булыр иде... — дигән Котбетдин.

### БУГАЗ

Сөйли дә сөйли берәү, тыңлый да тыңлый Котбетдин: «Бушбугаздыр бу!»

Сөйли дә сөйли теге, тыңлый да тыңлый Котбетдин: «Кушбугаздыр бу!»

Сөйли дә сөйли теге, тыңламый Котбетдин: «Бишбугаздыр бу!»

### ОСТАЛЫК

Берәү сөйли, Котбетдин тыңлый, тыңлаган саен гаҗәпләнүе арта:

— Ай-һай-һай!

Тора-тора да шуны кабатлый:

— Ай-һай-һай!

— Бик оштатасыз, ахры,— дигән сөйләүче беразга туктап.

— Осталыгыңа хәйраннар-вәйраннар калып утырам — шул хәтле сөйләп тә, ялгыш та мәгънәле бер сүз ычкындырмадың!

### МОНЫ ТУКТАТЫП БУЛМЫЙ

— Әгәр дә мәгәр бу иптәшнең җыелышта сөйләүгә киткән җегәрен эшкә җигеп булсамы, — дип хыяллана Котбетдин, — аның башы өстендә көне-төне зур-ур прожектор янып торыр иде!

— Көндез электр сарыф итү эшмени?

— Анысын аның теләгәндә сүндереп тә була, Сәйфетдин!

### ЛЕКЦИЯДӘН КАЙТКАЧ

— Я, Котбетдин абзый, ничегрәк булды лекция?

— Ул лектор сөйләгәндә чебен очкан тавыш та ишетелми... Алар да йоклап беткән була...

### БҮТӘН ОЕШМАДАН

Бик дәрәҗәле банкетта мәгълүм генә бер ханым биергә чакыргач, Котбетдин:

— Бии белмим шул, гафу итегез, — ди.

— Ничек инде? Шундый җирдә эшләүче шундый кеше бии белмиме?

— Без бит аяк белән эшләмибез, гафу итегез! — ди Котбетдин. — Без бүтән оешмадан!

## Күп сөйләүченең уйларга вакыты калмый

*Сәйфетдиннең үз тәҗрибәсеннән.*

### ОЗАК ЯШӘҮНЕҢ СЕРЕ

Тәнәфессез-нисез тоташтан ике сәгатьләп барган җыелышларның берсендә:

— Попугай озак яши икән, менә укып кара,— дип, Сәйфетдин гәҗит суза.— 180 гә җитә ди...

— Кеше әйткәнне кабатлаучылар озак яши шул,— ди Котбетдин.

— Әле бу трибунадагы иптәшне тагын 150 ел тыңлыйсы бар микәнни?

— Тыныч бул, ул чакта инде аны син түгел, оныкларың тыңлар...

### ОЗАККА КИТКӘЧ

Шактый сыек көн тәртибе тирәсендә сүз куерып киткәч, Сәйфетдин:

— Үгезнең мөгезеннән алырга кирәк иде! — дип ачынып утыра.

— Мәсьәләсе мүкләк бит, кай җиреннән эләктермәк буласың? — ди Котбетдин.

### МӘГЪЛҮМАТ

Фәнни-популяр журнал укыштырып, шуның эчтәлеген сөйләп аптыраткан берәү:

— Дөньяда иң аз сөйләшә торган халык — финнар, иң күп сөйләшүчеләр — итальяннар, бразилиялеләр, мексикалылар икән! — ди.

Котбетдин абзый сөйләүчегә хөрмәт белән карый:

— О-о, болай булса, син итало-бразиломексиканец түгелме икән?

### КЕМ КҮПМЕ СӨЙЛӘШӘ

Котбетдин тагын хатын-кызның күп сөйләшүе турында шаярта башлагач, Хөббениса түзми:

— Сөйләшмибез, сөйләшмибез дип, сез, ирләр, күбрәк тә сөйләшәсез әле! — ди.

— Булыр да... Сез бит кыска гына әйтәсез: «Кайда йөрдең?» Ә безгә озын итеп аңлатырга кирәк...

### СУЗНЕҢ ФАЙДАСЫ

Җыелыш бара фермада. Озакка сузылгач, Котбетдин кузгала башлый:

— Җәмәгать, сүз бозау имезә, диләр, бозауларыгыз туктыр да, әйдәгез, сыерларны ашатырга чыгыйк!

### ЮАНЫЧ

Кулы-кулга йокмаса ни әйттең дә, телетелгә йокмый шул, бертуктаусыз сөйләнә сатучы:

— Кулларым икәү генә, күрмисезме! Дүрт түгел бит!

Котбетдин исе китеп тора:

— Ә теле дүртәү бугай!..

### УЧЕТКА ЯБЫЛГАН

Бер кеше турында сүз кузгалгач, һәркем үз мөнәсәбәтен белдерә:

— Тешләре камашканчы гайбәт сөйли ул! — ди Хөббениса.

— Гайбәт аңа һава белән су кебек кирәк, — ди Сәйфетдин.

— Ул гәҗитне дә дөнья гайбәтен эзләп укый! — дигән була Сәйфетдин хатыны да.

— Чү, җәмәгать, кызмагыз, — ди Котбетдин. — Авызы «учетка ябылган» — җавапка тартканнар. Үзегез аның урынына калмагыз...

### ҖЫЕЛЫШ

Урамнан берәү үзалдына сөйләнеп кайта. Гаҗәпләнеп карыйлар бу кешегә.

— Нәрсәсе гаҗәп? — ди Котбетдин. — Гадәти күренеш — бер кешелек җыелыш бу!

### ХИКМӘТЕ БАР

Берәү Котбетдингә дусты турында:

— Тыйнак та кеше инде Сәйфетдин, үзе «алдан килгән — урын өчен!» дияр, үзе бер җыелышта да алга узмас, иң артта утырыр... — ди.

— Шул урын өчен алдан килә — таярга уңайрак, — ди Котбетдин.

### ЙОКЫ КАЧКАН

Җыелыштан кайткач, Котбетдин йоклый алмый ята:

— Вәт, әкәмәт! Җыелышта үлепләр йокы килә, ә өйгә кайткач — ап-аяз... Сөйлә әле, хатын, берәр нәрсә... Юк, син йокы кача торган итеп сөйлисең шул! Гомумирәк сөйлә, безнең җыелыштагы кебегрәк итеп...

## Мактаганда арттырып җибәрсәң дә бер сүз әйтмиләр, тәнкыйтьләгәндә киметеп әйтсәң дә үпкәлиләр

*Котбетдиннең җыелыштан соң ясаган нәтиҗәсе.*

### «КҮЗ ТИМӘСЕН!»

Трибунага чибәр генә ханым чыккач, Сәйфетдин:

— Тфү, тфү, күз тимәсен! — ди.

— Тфү, тфү, сүз тимәсен, диген, шактый усал хатын ул... — дип төзәтә аны Котбетдин.

### «ҖАНКЫЙТЬ»

Бер җыелышта утырганда Сәйфетдин:

— «Тәнкыйть» дип дөрес әйтмибездер, «җанкыйть» кирәктер... Җанны кыя бит, тәнне түгел! — ди. Котбетдин үзенчә аныклый:

— Икесе дә үз урынында дөрес: бүтәннәргә тисә — тәнкыйть, үзеңә элексә — җанкыйть...

### БИРДЕ КИРӘГЕН

Сәйфетдин җыелыштан шактый соң кайтып, йокыдан да соң гына уяна да кәефләнеп ята:

— Әйттем әле! Бирдем кирәген! Шул кирәк ул юньсезгә! Авызын ачты да калды! Шулай йөзенә бәреп әйткәнне гомер күрмәгәндер!.. Ярый, бәхете инде — төшемдә булды бу хәлләр!

### БЕР ХӘРЕФ

Котбетдин ферма сарыклары кайтып барганны карап тора:

— Начар көткәннәр көтүчеләр, бер хәрефен югалтканнар сарыкларның...

— Ул нинди хәреф тагын?! — дигән председатель.

— «Сарык»ның «с»сын югалтканнар, «арык» кына калган...

### КҮЗНЕ АЧЫП

Гөмбә җыеп йөргәндә күз кабагына чыбык төртелгәч, Сәйфетдин:

— Ярый әле, күземне ачып барган чак булмаган! — дип сөенә.

— Әкәмәт, күзеңне ачыбрак карасаң, бусы да кагылмас иде! — дип төрттергән Котбетдин...

### КУУЧЫ БАР

— Кая ашыгасың, артыкнан куып килүче юктыр ич? — дигән кибет каршында тәмәке төтәтеп утыручы берәү.

— Бар шул, дөнья куа! — дигән Котбетдин.

### ЯҢА СЫНАМЫШ

Котбетдиннән сорадылар:

— Кояш ни өчен кызарып чыга?

Котбетдин әйтте:

— Йоклап ятучылар өчен оялып...

Котбетдиннән сорадылар:

### ЯЛГЫШКАН

Котбетдин, бик борчылып, мәҗлестәш ханымнан гафу үтенә:

— Зинһар кичерә күрегез, кичә кызмача хәлдә: «Сез чибәр ханым!» — дип мактап, теңкәгезгә тиеп беткәнмен...

## Эш пешмәсә, эч поша

*Котбетдиннең түшәмгә карап ятканда уйлаган уе.*

### ТЕЛ-ТЕШ...

Конфет сатып алгач, Котбетдин:

— Конфет комбинаты директоры бик дөрес сүзле кеше икән! — дигән.

— Шулаймыни? — дип гаҗәпләнгәннәр.

— Шулай! — дигән Котбетдин.— «Безнең конфетлар тел-теш тидерерлек түгел!» дигән иде, чыннан да, ни телгә, ни тешкә тидерерлек түгел.

### СИМЕРТӘ ТОРГАЧ

Калган ашлар әрәм түгелә дип, бер ашханәдә дуңгыз симертмәк булганнар. Ә ул, ни хикмәттер, ябыга бара икән... Мал докторына күрсәтәләр.

— Бар җире сау-сәламәт, юньләп ашатырга гына кирәк!—дигән тәҗрибәле врач.

— Кеше ашаганны ашый инде! — дигән директор.

— Кеше бәлкем ябыгыр өчен ашыйдыр, моңа бит симерергә кирәк! — дигән Котбетдин.

## Берәүләр — эш карый, берәүләр — теш казый...

*Котбетдиннең шулар арасында торып әйткән сүзе...*

— Ә ни өчен кызарып байый?

Котбетдин әйтте:

— Уянмаганнар өчен оялып...

### ХӘЕР

Вокзалда чегән хатыны хәер сорашып йөри:

— Балаларымны ашатырга берничә тиен бирегезче...

Сузылган кулына акча салганда күрә Котбетдин — бармак саен алтын балдак!

— Вак акчасы юктыр мескеннең,— дип җәлләп кала Котбетдин.

### ДӨРЕСЛЕК

Гыйльметдин бүлмәдә әрле-бирле йөри, үзе сәгатькә карый:

— Бер урында торсаң да, сине «йөри» диләр. Мине, йөрсәм дә, «тик тора» диләр. Кайда монда дөреслек?

— Кил әле, миңа булыш, дөреслекне бергәләп табарбыз! — дип кычкыра ишегалдында кое казып ятучы әтисе.

### БОРЫНГЫДАН

Сәйфетдин тел галимнәре кызыгырлык ачыш ясаган:

— Иң борынгы фразеологик әйләнмәне беләсеңме? «Койрыкны сыртка салып!» Моны кеше койрыклы чагында ук әйткән.

— Мин икенче нәрсә турында уйладым,— дигән Котбетдин.— Койрыкны сыртка салып йөрүче җилкуарлар бик борынгыдан килә икән!

### ХӨРӘСӘННӘР

Ял көнне Сәйфетдинне сәгать уннарда гына уяталар. Караватына торып утыра да, өйдәгеләрне битәрли башлый:

— Шушы көнгә хәтле йоклатмасагыз! И хөрәсәннәр дә инде — иртәрәк уятырга ярамаган! Хәзер менә торасы да килми...

### ИКЕ АВЫРУ

Сәйфетдин эшкә чыкмый калган Котбетдиннең хәлен белергә килгән:

— Ни булды әле сиңа?

— Урында ятам менә, кузгалдым исә, акырам — радикулит...

— Гыйльметдин дә авырыймы әллә?

— Аның радиокулит — көне буе урында ятып радио акырта!

### ӨЛГЕРЛЕК

Торып, юынып, эшләрен караштырып өлгергән Сәйфетдин малаен орыша:

— Ялкау малай! Төш житеп килә, урын да җыймагансың!

— Кичкегә җәеп өлгергән диген, әти!

### КОМАНДИРНЫ КЫЗГАНА

Хөббениса түтәй иртән оныгын уята алмый гаҗизләнә. Армиягә китәсе малай, дип, командирларны кызгана:

— Мондый малайларны ничек уятыр командир бахыр... Берсен уятып күпме иза чигәсең!

### СЫНАМЫШ

Оеп-оеп, йөгенеп утыра да:

— Йокы килә, яңгыр явар, ахрысы... — ди Хөббениса.

— Синең йокы килгән саен яңгыр ява торган булса, җирне күптән су басар иде! — ди Котбетдин.

## Абруең югалса, табылдыклар өстәленнән эзләмә

*Котбетдиннең начальнигына әйтәсе килгән тәкъдиме.*

### ОХШАШЛЫК

Ишегалдында йөргән әтәч бөртек таба да, дөнья куптарып, тавыкларны җыя һәм... үзе кабып йота!

— Безнең местком председателе сыман икән бу — бер путевка бар, дип җыеп киңәште дә, үзе Кырымга китеп барды, — ди Котбетдин.

### ТӨШӘ-ТӨШӘ...

— Кибет мөдирен эшеннән алганнар иде, идарәгә зам итеп куйдылар,—ди Сәйфетдин.— Аннан да төшерделәр. Тагын югары куялар...

— Төшә торгач, тәмам күтәрелеп беткән икән! — дигән Котбетдин.

### АЛТЫН СӘГАТЬ

Кабул итү бүлмәсендә көтеп утыра-утыра да сыкранып куя Котбетдин:

— Алтын сәгатемне югалттым бит...

Күршесе сискәнеп куя:

— Алтын?!

— Алтын шул — иртәнге эш сәгатем!

### ТУРЫСЫ

— Син нәрсә, тәртә йоткан кебек йөрисең! — ди берәү, Котбетдиннең, имеш, горурлыгыннан көлә.

— Дугасын син йоткансың ич,— дигән Котбетдин, тегенең начальниклар алдында кырыкка бөгелүенә төрттереп.

### ЭРЕЛЕ-ВАКЛЫ...

Үзен бик зурга куеп йөргән берәүдән йомыш йомышлап чыга Котбетдин. Соңыннан Сәйфетдин сорый:

— Я, ниндирәк адәм теге?

— Ерактан гына эре күренә икән ул, якын килеп карасаң, шактый вак кеше...

### ӘҢГӘМӘ

Бергә укыган яшьтәшем зур начальник булган һәм үз итеп минем белән сөйләшеп утырырга кабинетына чакырды. Кердем. Кем beләндер телефоннан сөйләшә. Трубканы колагы белән иңбашына кысып кына кулын сузды. Бер трубканы куеп, икенчесен алды. Ул арада кемдер эш белән керде, телефоннан сөйләшеп торган җитәкче белән эшен хәл итеп чыгып китте. Мин утырам. Телефонны тыңлаган арада исәнлек сорап ала да, тагын дәвам итә. Бер сәгать утырдык.

— Күп вакытыгызны алдым, китим инде, — дисәм, җибәрми:

— Тагын бераз сөйләшеп утырыйк әле, Сәйфетдин дус, кайчан очрашырбыз анары... — ди дә телефонга ябыша.

### УТЫРТКАН

— Рәхим итегез! — дип, бүлмәгә кергән начальнигына урын тәкъдим итә Котбетдин.

— Начальник башым белән шушы өтек урындыкка утырыйммы?

— Ә сез башыгыз белән утырмагыз!— дигән Котбетдин.

### АВЫРУ-СЫРХАУ

Бер иптәш, төчкерүен дә зур авыруга санап, мактанырга ярата икән: үзен тыңлата, гел игътибар үзәгендә...

Котбетдин аны кызгана:

— Терелеп китсә нишләр бу, мескенем... Бөтен абруен югалта бит!..

## Намустагы тапны химчистка бетерә алмый

*Котбетдиннең саф күңеленә килгән уйлардан.*

### АЛДАУ

Котбетдин кибеттән сыр сатып алган. Ничектер сизенеп калды — кибетче артыграк салды бугай... Уйланып кайта — кире бирергәме, юкмы? Ярар, кибетче дә алдансын бер!

— Кайткач караса — брынза. Бик сөенә Котбетдин:

— Ярый әле, мине алдаганнар! Үзем алдадым дип эчем пошкан иде!

### ЮГАЛТУ

Сәйфетдин оялып кына сөйли:

— ... Акча таптым. Кемнеке икәнне дә белеп торам, шайтан котыртты бит, кызыгып үземдә калдырдым... Уянып киттем дә, төшемдәге эшемә оялып ятам... Төштәге табышым өндә югалту булып җанны тырнап тора...

— Юкка кыйналма — бир акчаңны, бүген төшемдә үзем хуҗасына кайтарыр-

мын! — ди Котбетдин, дустына булышырга теләп...

### ЫШАНЫЧНЫ АКЛАМАДЫ

— Теге агай беркөн алган акчаны бирдеме әле?

— Юк, бирми инде ул аны!

Күп тә үтмәде, теге агай керде, Котбетдингә акчасын кайтарды... Котбетдин оялып калды:

— Ышанычны акламады... Кайтармаса оятьы аңа була иде... Инде миңа калды.

### БУКЕТ

Болынга чыккан кешеләр ярыша-ярыша чәчәк җыялар. Берсе кызыгып сары чәчәк өзә дә икеләнеп кала:

— Хыянәт төсе диләр...

— Ә син аны үзеңә калдыр, — ди Котбетдин. — Үзеңә дә хыянәт итәрсең микән?

### БОРЧУ

Сәйфетдин зарлана:

— Үрнәк итеп куеп, мактап кына харап иттеләр газиз башларымны! Әчми, тартмый диләр... Ничек тартасың, ничек эчәсең — әйбәт дигәч, әйбәт булырга туры килә... Шулай, рәхәтләнеп бер кешечә яши алмыйча, гомерләрең заяга узып китсә нишләрсең...

Котбетдин дустына авырлык килгәндә күтәрешергә әзер:

— Кайгырма, булышырбыз — ул якларын безгә калдыр!

### БИОГРАФИЯГӘ БЕР СҮЗ

Бер егет судта биографиясен сөйли:

— Туганмын. Укыганмын. Эчкәнмен. Сугышканмын...

— Үзеңә өч ел, биографияңә бер юл өстәлер, — ди Сәйфетдин. — «Утырганмын» диярсең.

## Дуслык — күңелгә кирәк, йөрәккә — терәк

*Котбетдиннең Сәйфетдиннән ишетәсе килеп йөргән сүзләре.*

### ИГЪТИБАР

Эре панельле йортта яшәүчеләр берберсенә аеруча игътибарлы. Үз фатирында Котбетдин төчкерсә, Сәйфетдин:

— Исән бул! — дип кенә тора. Димәс иде дә, ачулана теге:

— Ишетмәмешкә салышма, чукрак стеналар юк монда! — ди.

### БҮЛӘК

Берәү кызыксына:

— Сәйфетдиннең туган көненә ни алдыгыз?

— Пианино.

— Шундый зур бүләкме?!

— Безгә нәрсә — җыйнаулашып илле сум җыйдык, калганын үзе өстәгән итте шунда...

### ЯХШЫЛЫК ЭШЛИЛӘР

Җыелышта Сәйфетдиннең персональ эше карала. Кызганып кына, каты бәрелмичә генә сөйлиләр. Берәү түзми, чәчрәп чыга:

— Әй, сез, дуслары, яхшылык эшлибез дип, батырасыз бит кешене! Якларга түгел, аңларлык итеп әйтергә кирәк бүген!

— Шелтә бирергә кирәк, алайса, — ди бер дусты уңайсызланып кына.

— Тагын да якынрак күрүче юкмыни? — ди Сәйфетдин.

— Эшеннән алырга кирәк! Сабак булсын! Тәзәлсен! — диде икенче дусты.

— Җавапка тартырга!! — дип йомгаклады иң якын дусты Котбетдин.

## УЗДЫРГАН

Таныш-белешләр Сәйфетдиннең исәнләшми-нитми генә узып баруын күреп хәйран калганнар:

— Кара әле, кара моны, яңа түн алдым дигәч тә, сәлам дә бирми башлады!

— Безне генә түгел, үз өен дә танымый узып киткән әле! — ди Котбетдин.

## АЕРМА

— Колга буе үскәнсең инде!

— Ә син — кәрлә!

— Ник мине кимсетәсең?

— Үзең «колга» дидең...

— Мин синең артык ягыңны әйтәм, син бит минем ким ягымнан көләсең! — дигән Сәйфетдин үпкәләп.

Ул таныш-бәлешләр аркылы эш йөртә. Ә син!..

*Хөббенисаның Котбетдингә танышлык белән әйткәне.*

## ЗАМАНА БАЛАСЫ

Бишектә Гыйльметдин елый. Тирәсендә әти-әнисе үрсәләнеп йөри.

— Кайлардан гына табасы шул имезлек дигәнне! — ди Хөббениса.

— Танышларыгыз юкмыни? — дип, тагын да катырак елый башлый бала.— Ничек яшәрсең мондый әти-әни белән?..

## ФАЙДА

Сәйфетдин хезмәттәшенең кулын кыса:

— Рәхмәт инде, җыелышта минем эш тикшерелгәндә синең зур файдаң тиде!

— Нишләп? Мин бит сүзгә катнашмадым да!

— Катнашмавың белән файда эшләдең дә — каршы килмәдең... — дигән Сәйфетдин.

## БАЙ КЕШЕ

— Акча ваклап бир әле! — ди Сәйфетдин бер танышына.

— Хәзер, хәзер! — ди теге. Портманетын ала, бүлемнәрен кат-кат актарып карый — эресе дә, вагы да юк...

— Вәт бай кеше! Акчасы югын да белми! — ди Сәйфетдин кызыгып.

## ТӨШКӘ КЕРЕГЕЗ

Бер таныш очрап, Котбетдингә яхшы мөнәсәбәтен белдергәндәй:

— Син минем төшемә кердең, — ди.

Тәрбияле кеше буларак, Котбетдин:

— Вакытлы-вакытсыз кереп борчыганым өчен гафу итегез. Вакытыгыз булганда, минем төшкә дә кергәләгез! — ди.

## МОДАГА ИЯРЕП

Мода турында сүз чыккач, Сәйфетдин:

— Хәзер итәкләр минидән максига таба китте, — ди.

— Кайсыбер кибетләрдә итәк астыннан әйбер озатулар да нәкъ шул юнәлештә үсә, — дигән Котбетдин.

## НИЧЕК БЕТЕРЕРГӘ!

Фельетон укыгач, Сәйфетдин:

— Әшнәлек тә әшнәлек дибез, ничек бетерергә соң үзен?! — ди.

— Танышлыксыз булмастыр, мөгаен! — ди Котбетдин.

## ҮЗ ИТЕП

Ничәнче тапкыр ательедан нәүмизләнеп буш кул белән кайткан Сәйфетдин Котбетдингә эчен бушата:

— Таныш тегүчегә костюм тегәргә биргән идем. Ике ай йөртте. Килгән саен шатланып каршылый, юмалап озата... Танышлык белән тектерәм шул, юкса әллә кайчан бүтәннәр кебек ду килеп, якасыннан алып эшләткән булыр идем, жалу кенәгәсе белән өркетер идем...

### ЖИДЕ БАЖАЙ

— «Жиде бажайны бүре ашаган...» — дип сөйли башлаган кешегә каршы төшә Котбетдин, үз фикерен әйтә:

— Бер-берсен ашаганнар да, бүрегә сылтаганнардыр әле! Беләм мин хәзерге бажайларны...

### ЯХШЫ ТҮГЕЛ

— Шатланам да, кайгырам да, Сәйфетдин, теге иптәш мин уйлаганнан шактый әйбәт кеше булып чыкты бит...

— Алайса, ник кайгырасың?

— Инде мин үзем ул уйлаганнан начаррак булып калдым ич!

### УЕН ТҮГЕЛ

— Хәтерлисеңдер, Сәйфетдин, без яшь чакта «йөзек салыш» уены бар иде...

— Тезелешеп утыралар, учларын куышландырып. Берәү, башкаларга сиздермичә генә, йөзек салып китә...

— Хәзер шуны «йөзлек салыш» итеп уйнаучылар бар. Кемгә салганын белү тагын да кыенрак...

## Кеше кунагы тиз китүчән була...

*Котбетдиннең сәгатькә карап уйлануларыннан.*

### ЯҢАРЫШ

Капкадан килеп керүгә, кунак ишегалдындагы үзгәрешне күреп ала:

— Былтыр ак тавыклар иде, быел һәммәсе дә кызылдан икән!

— Сез кунак булып киткәннән соң нәсел яңартырга туры килде... — ди хуҗа.

— Алайса, без быел да яңалык китерәбез! — ди Котбетдин. — Киләсе елга ниндиләр булыр икән?

### ХӘЛЕНӘ КЕРӘ

Килгән көнне үк кунак китәр юлга самолет белешмәкче.

— Килмәс борын китү турында уйлыйлармы? — ди хуҗа.

— Уйламыйм уйлавын, — ди Котбетдин. — Хуҗаның күңеле булсын дип соравым — үземә дә килгәннәре бар, үземнән беләм...

### «ӘТӘЧ БУЛЫП»

— Бер тавыгыбыз әтәч булып кычкыра башлады, хәерлегә түгелдер! — ди хуҗа, пычагын кайрап. Кунак моңа бик канәгать — кунак моны елмаеп тыңлый...

Иртән караңгыга чыкса, хуҗа кеше ни күрсен — кунак тавыкларны әтәч булып кычкырырга өйрәтеп ята...

### ӘТӘЧ ТАВЫШЫ

Котбетдин белән Хөббениса, элекке чакларын сагынып, кунакка кайткач, урынны печәнлектән сайлыйлар. Көн дә әтәч кычкырып уята:

— Торырга вакыт! — ди Котбетдин кәефләнеп.

Тора-бара әтәчләр тавышы сирәгәя, ялгыз әтәчнең гайрәтле тавышы гына кала.

— Китәргә вакыт! — ди Котбетдин моңсу гына...

### САГЫНГАН

Җитди генә бер мәҗлестә, моңачы дәшми утырган бер абзый, йөз граммнан күңеле тулып, моңлы гына итеп җырлап җибәрә:

Безнең дә бар мачыбыз,
Сезнең дә бар мачыгыз;
Безнең мачы сезгә барса,
Зинһар, ишек ачыгыз!

Җырлап бетерүе була, елап җибәрүе була.

— Сагынган бу, мәчесен бик сагынган! — ди Котбетдин. — Тизрәк озатырга кирәк!

*(Ахыры бар)*

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## МУСА ҖӘЛИЛ — ГАРӘП ТЕЛЕНДӘ

Гарәп теленә шагыйрь Аднан Хаки Шехаб тәрҗемә иткән бу китап 1977 ел ахырында Багдад шәһәрендә басылып чыккан. Муса Җәлил шигырьләренең гарәп телендә әле беренче тапкыр чыгуы. Китапның тиражы зур түгел, «Моабит дәфтәрләре»ннән алынган шигырьләрнең саны да аз. Ләкин, шуңа да карамастан, бу — зур политик һәм культура әһәмиятенә ия булган вакыйга.

Муса Җәлилнең герой-шагыйрь, патриот шагыйрь булуы гарәп укучысына китапның беренче битендә үк ачыла: титул битендә «Көрәшче шагыйрь, Советлар Союзы Герое» дип язылган. Фоторәсемдә — яшь Муса һәм аның «Җырларым» шигыреннән алынган юллар.

Аднан Хаки Шехабның кереш мәкаләсе укучыларга Муса Җәлилнең Ватанын чиксез яратуы, әсирлеккә төшүен бик авыр кичерүе, ләкин рухи төшенкелеккә бирелмәве турында сөйли. Тәрҗемә ителгән шигырьләр дә шуны раслый. Барлыгы 29 шигырь. Китапка соңгы сүзне доктор Җәлил Камалетдин язган.

Тәрҗемәче турында да берничә сүз. Аднан Хаки Шехаб элек Төньяк Гыйрак эшләре министрлыгының статистика һәм планлаштыру бүлеге начальнигы булып эшләгән. Әле күптән түгел генә Мәскәүнең Г. В. Плеханов исемендәге халык хуҗалыгы институты аспирантурасын тәмамлады. Аднан Хаки Шехаб экономика мәсьәләләре буенча үзенең фәнни эшен әдәби эшчәнлек белән уңышлы бәйләп алып бара. Аның Муса Җәлил шигырьләрен тәрҗемә итүе һәм бастырып чыгаруы — Совет һәм Гыйрак халыклары арасындагы дуслыкны үстерүгә кертелгән бер өлеш.

Гарәп халыклары Г. Тукайның «Шүрәле» поэмасы, Г. Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар»ы (Г. Ишмөхәммәтов тәрҗемәләре) белән танышканнар иде инде. Хәзер бу исемлеккә герой-шагыйрь Муса Җәлил исеме дә өстәлде. Китапның бер данәсе Татарстан Дәүләт музеенда бар.

## ШИГЫРЬ БӘЙРӘМЕ

Ел саен апрель аенда Габдулла Тукайның туган көннәрендә Тукай-Кырлайда шигырь бәйрәме үткәрү традициягә әйләнде. 25 апрельдә Тукай мемориалына бер төркем шагыйрьләр һәм язучылар шигырь бәйрәменә килделәр. Шагыйрьнең тууына 92 ел тулуга багышланган тантаналы митингны Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе, СССР Верховный Советы депутаты Гариф Ахунов ачты. Митинг Кырлай урта мәктәбе укучылары чыгышы белән башланды.

Митингта шагыйрьләр С. Хәким, И. Юзеев, Г. Рәхим, Зөлфәт, Р. Хәлиуллина, Ш. Маннапов, Н. Мадьяров, Р. Вәлиев һәм яшь шагыйрә Ф. Җамалетдинова үзләренең шигырьләрен укыдылар.

Аннан соң язучылар Тукай һәйкәленә чәчәкләр куйдылар, Тукай мемориалын карадылар.

*

* *

Казандагы шигъри бәйрәм В. И. Ленин һәйкәленә чәчәкләр салу белән башланып китте.

Шуннан соң әдәбият һәм сәнгать эшлеклеләре Александр Сергеевич Пушкин, Габдулла Тукай һәм Муса Җәлил һәйкәлләренә чәчәкләр салдылар.

Аннары М. Җәлил исемендәге татар дәүләт опера һәм балет театры бинасы янындагы Г. Тукай һәйкәле янында шигъри митинг башланды. Аны кереш сүз белән Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе Гариф Ахунов ачты.

Шигъри митингта шагыйрь Равил Фәйзуллин быелгы лауреатлар исеменнән чыгыш ясады. Аннары Сибгат Хәким, Нури Арсланов, Әхмәт Исхак, Михаил Скороходов, Нәби Дәүли, Мөхәммәт Садри, Галимҗан Латыйп, Рәдиф Гатауллин, Гәрәй Рәхим, Ренат Харис, Гөлшат Зәйнашева, Мөдәррис Әгъләмов, Зөлфәт, Роберт Миңнуллин, Фәннур Сафин һәм башка шагыйрьләр чыгыш ясады.

Шигырь сөючеләр алдында РСФСРның халык артисты, Г. Тукай премиясе лауреаты Фәхри Насретдинов Тукай шигыренә язылган «Пар ат» җырын башкарды.

Шигъри митингта КПСС өлкә комитетының культура бүлеге мөдире М. М. Мусин, ТАССР культура министры И. Н. Алиев, партиянең Казан шәһәр комитеты секретаре А. Г. Кадыйрова катнашты.

## ТУКАЙГА БАГЫШЛАНГАН КИЧӘ

Язучыларның Г. Тукай исемендәге клубында сөекле шагыйребез Габдулла Тукайның туган көненә багышланган әдәбимузыкаль кичә үткәрелде. Анда ТАССР Дәүләт музее каршындагы ветераннар со-

веты ансамбле махсус әзерләнгән программа белән чыгыш ясады.

Әдәби-музыкаль кичә З. Яруллинның «Тукай маршы» белән ачылды. Ветераннар Тукай шигырьләренә язылган җырларны һәм шагыйрь үзе яраткан халык көйләрен зур осталык белән башкардылар. Ансамбльнең «Туган тел»не башкаруын кичәдә катнашучылар аеруча яратып кабул иттеләр.

## ЯШЬ ЯЗУЧЫЛАР КОНФЕРЕНЦИЯСЕ

Партиябез Үзәк Комитетының «Иҗат яшьләре белән эшләү турында»гы карарын тормышка ашыру йөзеннән, районнарда яшь язучыларның зона конференцияләре үткәрү матур традициягә әверелде. Мондый конференцияләр Апас районында, Чаллыда уздырылган иде инде.

Габдулла Тукайның туган көнен бәйрәм итү көннәрендә Арча культура йортында яшь язучыларның чираттагы зона конференциясе үткәрелде. Бирегә Казаннан бер төркем язучылар һәм тәнкыйтьчеләр килде. Конференциядә Арча, Биектау, Балтач, Саба районнарында торып эшләүче яшь авторлар, мәктәп укучылары, татар теле һәм әдәбияты укытучылары катнашты.

Бирелә яшь язучыларның әсәрләре укылды, алар буенча фикер алышу булды, киңәшләр бирелде.

Поэзия секциясендә Ш. Маннапов, Н. Мадьяров, Р. Хәлиуллина һәм Н. Габбасов шигырьләре тикшерелде. Ике авторны — Нәҗип Мадьяров белән Шамил Маннаповны конференция исеменнән СССР Язучылар союзына член итеп алырга тәкъдим итәргә дигән карар чыгарылды.

Проза һәм драматургия секциясендә Н. Гыйматдинова, А. Вергазов повестьлары, Ю. Сафиуллин, Р. Хәмидуллин һәм Фоат Садриев пьесалары тикшерелде. Бу әсәрләр Татарстан китап нәшриятына тәкъдим ителделәр.

Конференцияне йомгаклау утырышында Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе язучы Гариф Ахунов чыгыш ясады. Ул яшьләрнең иҗатына уңай бәя бирде, уңышлар теләде.

## РОМАН ТУРЫНДА СӨЙЛӘШҮ

Г. Бәшировның «Җидегән чишмә» романы буенча берничә җирдә укучылар конференциясе узды. Татарстан Дәүләт музеенда уздырылган конференциядә әдәбият белгечләре, хезмәт ветераннары, язучылардан Гәрәфи Хәсәнов, Кыям Миңлебаев катнаштылар.

КДУ һәм пединститутта уздырылган конференцияләр дә бик җанлы үтте, студентлар һәм укытучылар катнашты.

Барлык конференцияләр дә авторның катнашы белән узды. Г. Бәширов иҗат процессы, роман өстендә эшләве турында сөйләде, күп санлы сорауларга җаваплар бирде. Конференцияләрдә катнашучылар һәм чыгып сөйләүчеләр әсәргә югары бәя биреп, аның актуаль темага язылуын әйттеләр.

## ЯҢА КИТАП

Мәскәүдәге «Советская Россия» нәшриятында чыккан бу китапның исеме «Дуслык меридианнарында» дип атала. Җыентыкка социалистик илләрдәге язучыларның һәм журналистларның Октябрь ватаны һәм халыклар дуслыгы турындагы әсәрләре тупланган. Китаптагы 24 авторның берсе румын Василе Никонорович Әлмәт, Ромашкино ятмасы, нефть предприятиеләре турында сөйли.

«Татарлар — бик кунакчыл, игътибарлы, сизгер кешеләр һәм үткен акыллары белән аерылып торалар. Алар мондагы нефтьчеләрнең күпчелеген тәшкил итәләр», — дип яза ул.

## ИҖАТ ЯШЬЛӘРЕНЕҢ ДИСКУССИОН КЛУБЫНДА

Һәр атнаның чәршәмбе көнендә яшь язучылар, шагыйрьләр, югары уку йортларыннан студентлар Язучылар союзына әдәби бәхәсләр клубына җыелалар. Инде гадәткә кереп бара торган бу очрашуларны яшьләрнең «Идел» альманахы редакторы Мансур Вәлиев алып бара. Үткән ике ай вакыт эчендә генә дә клубта күп кенә кызыклы сөйләшүләр булып узды. Мәсәлән, «Әдәбиятта заман бармы?», «Әдәбиятка эксперимент кирәкме?», «Тагын иркенле шигырьләрме?» дигән темаларга кызу бәхәсләр булды. Соңгы вакытта яшьләр Татар дәүләт академия театрының баш режиссеры Марсель Сәлимҗанов, язучы һәм тәнкыйтьче Рафаэль Мостафин, шагыйрь Радиф Гатауллин, прозаик Нурихан Фәттах белән очраштылар. Чыңгыз Айтматовның «Пегий пес, бегущий краем моря» исемле повесте турында кызыклы сөйләшү булды.

## ЯШЬ АРТИСТЛАР СЕМИНАРЫ

26—27 апрельдә Казанның Актерлар йортында яшь актерларның I республика семинары булды. Аны кереш сүз белән ВЛКСМ өлкә комитеты секретаре Ф. Ә. Илдарханова ачты. Доклад белән ТАССР культура министры урынбасары Р. М. Харисов чыкты. Семинарда республика театрларында эшләүче яшьләрнең иҗаты турында сәнгать фәннәре кандидаты И. И. Илялова һәм совет театр сәнгатенең үсеш юллары турында «Театр» журналының җаваплы секретаре Н. И. Жегин иптәшләр чыгыш ясады.

Семинар эшендә КПСС өлкә комитетының культура бүлеге мөдире М. М. Мусин катнашты.

## ЯШЬ РӘССАМНАР КҮРГӘЗМӘСЕ

Казанның Яшьләр үзәгендә яшь рәссамнар күргәзмәсе ачылды. Мондый күргәзмәләр инде җәмәгатьчелекне үзенә тарта торган традициягә әйләнә бара.

Күргәзмәдә яшь рәссамнардан Ф. Якупов, З. Гимаев, С. Слесарский, М. Гимейн, Ф. Хасьянова, Ю. Каспина һәм Ф. Фәсхетдинов картиналары куелган.

## «ИДЕЛ» БЕЛӘН ОЧРАШУ

Моннан нәкъ 40 ел элек, 1938 елның 14 апрелендә Татарстан Үзәк Башкарма Комитеты карары белән язучылар клубына Г. Тукай исеме бирелгән иде. Шул уңай белән бу «әдәби җомга» Тукай варисларына — яшьләрнең «Идел» альманахы авторларына багышланды. Кичәне альманахның редколлегия члены Гәрәй Рәхим алып барды. Шагыйрьләрдән Зөлфәт, Р. Миннуллин, Ф. Сафин, Г. Садә чыгыш ясадылар. Яшь прозаиклар һәм шагыйрьләр, альманах авторлары, үзләренең әсәрләрен укыдылар.

Кичәнең икенче яртысында Мехчылар культура сараеннан Татарстанның атказанган культура работнигы Разия Яруллина җитәкчелегендәге «Иделкәем» вокаль ансамбле җырлар һәм биюләр башкарды.

## СПЕКТАКЛЬ ПРЕМЬЕРАСЫ

«Җиләк вакыты бер генә...» Прозаик һәм драматург Әхәт Гаффаровның шушы исемдәге драмасы буенча эшләнгән спектакль премьерасы булды. Аны Татар дәүләт республика кучмә театрында Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Тукай премиясе лауреаты Равил Тумашев куйган. Сәхнә бизәлешен Татарстанның атказанган культура работнигы Петр Баландин эшләгән. Спектакль безнең замандашларыбыз — авыл кешеләре хакында. Әсәр кешелеклелек, матурлык, тугрылык һәм мәхәббәт турында сөйли.

Бу — язучының шушы театрда куелган икенче әсәре. Моңа кадәр биредә аның «Иртәгә улың булам» дигән драмасы куелган иде.

## ШАЛЯПИН КАЗАНДА

М. Горькийның Казандагы музей-йортында яңа экспозиция ачылды. Ул Ф. Шаляпинның тормышы һәм иҗаты, аның бөек пролетар язучысы белән дуслыгы турында сөйли.

Бу ике бөек кешенең яшьлеге Казанда узган.

Музейда Шаляпин квартирасын тулысынча күз алдына китерергә мөмкин: рояль, язу өстәле, опера арияләре язылган пластинкалар...

## АРТИСТ БӘЙРӘМЕ

9 апрельдә язучыларның Тукай клубында Тукай премиясе лауреаты, Татарстан халык артисты Айрат Арслановның 50 еллык юбилеена багышлап кичә булды. Юбиляр үзенең репертуарында булган Тукай, Х. Туфан, В. Маяковский, Э. Межелайтис һәм башка татар һәм совет шагыйрьләренең әсәрләрен укыды.

Соңыннан концерт булды.

## ЯЗУЧЫЛАРНЫҢ ӘЛМӘТ БҮЛЕГЕНДӘ

26 апрельдә Әлмәт шәһәренең Техника йортында поэзия һәм җыр кичәсе үткәрелде. Кичәне кереш сүз белән Татарстан Язучылар союзы Әлмәт бүлеге җитәкчесе Әдип Маликов ачты. Шагыйрьләр Тукай премиясе лауреаты Г. Афзал, С. Сөләйманова, К. Булатова һәм Әлмәт әдәбият берләшмәсе членнары үзләренең шигырьләрен укыдылар.

Кичәнең икенче бүлегендә Әлмәт татар дәүләт драма театры артистлары һәм шәһәр үзешчәннәре көче белән зур концерт куелды.

Көндез Тукай һәйкәле янында шигъри митинг булды. Мәктәп балалары Г. Тукай шигырьләрен укыдылар, шулай ук шагыйрьләр чыгыш ясады. Шәһәр хезмәтчәннәре бөек шагыйрь һәйкәленә тере чәчәкләр куйдылар.

* * *

Бүлек язучылары, Әлмәт драма театры коллективы һәм шәһәр җәмәгатьчелеге вәкилләре белән берлектә, драматург Сәет Кальметовның 60 еллыгын билгеләп үттеләр. Юбилярга Татарстан Язучылар союзы идарәсе, Әлмәт язучылары бүлеге һәм шәһәр оешмалары исеменнән котлау адреслары, истәлекле бүләкләр тапшырылды.

* * *

Язучы Мәхмүт Хәсәнов һәм яшь шагыйрь Нур Әхмәдиев Бөгелмә шәһәрендә һәм районында бернич көн эчендә тугыз әдәби очрашуда катнаштылар. Алар медицина, кооператив, профессиональ-техник училищеларда, индустриаль-педагогия техникумында, сукырлар җәмгыятендә, мәгариф работниклары йортында, Карабаш поселогы культура сараенда, Кодаш сигезьеллык мәктәбендә һәм Татар Димскәе авылы клубында чыгыш ясадылар. Язучылар татар һәм рус телләрендә үзләренең әсәрләрен укыдылар, әдәбият проблемаларына кагылышлы мәсьәләләр буенча күп төрле сорауларга җавап бирделәр.

## МАКТАУЛЫ ИСЕМНӘР

Совет сынлы сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен Лениногорск балалар художество мәктәбе директоры **Мәснәви Хәертдинович Хәертдиновка**, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1978 ел, 10 апрель Указы белән, **Татарстан АССРның халык художнигы** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Совет театр сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен Әлмәт дәүләт драма театры артисткасы **Ләлә Махияновна Садыйковага**, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1978 ел, 10 апрель Указы белән, **Татарстан АССРның халык артисткасы** дигән мактаулы исем бирелде.

# ХӘЙ ВАХИТ



Күренекле драматург, Татарстан АССРның атказанган сәнгать эшлеклесе, Г. Тукай премиясе лауреаты, «Казан утлары» журналының редколлегия члены Габделхәй Каюм улы Вахитов шушы елның 7 июлендә кинәт вафат булды.

1918 елның 20 декабрендә республикабызның Биектау районы Мәмдәл авылында крестьян семьясында туган Хәй Вахит тормыш юлын укытучы булып башлый. Бөек Ватан сугышында Кызыл Армия җыр һәм бию ансамблендә хезмәт итә, соңыннан бронепоезд дивизионында разведчик була.

Бик иртә яза башлаган Хәй Вахитнең «Дулкыннар» исемле беренче китабы 1939 елда ук басылып чыга. Иҗат юлын балалар өчен шигырьләр һәм сәхнә әсәрләре язып башлаган язучы зур әдәби мирас калдыра.

Татар академия, республика күчмә, Минзәлә, Әлмәт театрларында Хәй Вахитнең «Беренче мәхәббәт», «Рәхим итегез», «Кайда соң син?», «Карлыгач канат кага», «Соңгы хат», «Күк капусы ачылса», «Илһамия», «Туй алдыннан», «Мәхәббәтең чын булса», «Давыл», «Ике килен-килендәш», «Оныта алмасаң нишләрсең» һ. б. исемдәге сәхнә әсәрләре уйнала.

Казан дәүләт консерваториясенең музыка теориясе факультетын тәмамлаган кеше буларак Хәй Вахит татар опера сәнгатен үстерүгә мөһим өлеш кертте. Ул «Самат», «Дим буенда», «Җиһангир», «Мәхәббәт җыры», «Кияүләр» кебек тамашачы яратып карый торган музыкаль сәхнә әсәрләре дә иҗат итте.

Тирән партиялелек белән сугарылган пьесаларында Хәй Вахит үзенә генә хас лиризм һәм җылылык белән совет кешеләренең рухи үсүләрен, характерлары ныгуын сурәтли. Аның әсәрләрендәге уңай геройларның изге ниятле, олы йөрәкле булуына, югары идеаллар белән янып яшәүләренә сокланмый мөмкин түгел. Шуңа да аның пьесалары Үзбәкстан, Казагыстан, Әзәрбәйҗан, Эстония, Башкортстан, Чувашия, Удмуртия һәм Кумык сәхнәләрендә, Астрахань, Березники, Красноярск, Куйбышев, Кисловодск, Оренбург, Пермь, Ставрополь, Саратов, Ульяновск, Чиләбе һ. б. шәһәр театрларында зур уңыш белән барды.

Коммунистлар партиясе һәм Совет хөкүмәте драматургның эшенә лаеклы бәя бирделәр. Ул орден һәм медальләр белән бүләкләнде. Аңа ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе дигән мактаулы исем бирелде, ул Г. Тукай исемендәге республика премиясенә лаек булды.

Коммунист Хәй Вахит күп төрле җәмәгать эшләре алып барды. Ул берничә тапкыр Татарстан Язучылар союзы идарәсе члены итеп сайланды. Язучылар союзы каршындагы драматурглар секциясен җитәкләде. Язучылар союзы партия оешмасының секретаре булды. «Казан утлары» журналының редколлегия члены иде.

Хәй Вахит исеме татар совет әдәбияты һәм театр сәнгате тарихында якты сәхифә булып калды.

## Хөрмәтле укучыбыз!

Журналыбызның 9 нчы санында Р. Кәрамиевның «Очар кошлар белән янәшә» дигән повестен бирә башлыйбыз.

Әсәр узган бишьеллыкларның удар төзелеше булган Казан оргсинтез заводын салучы яшьләр тормышын сурәтли. У. Саттаровның шушы ук санда басылачак «Кызым хикәяләре» яшь балаларның самими характерын чагылдыра.

Поэзия бүлеге бай. Сез анда Ә. Баянов, Г. Латыйп һәм күп кенә яшь шагыйрьләрнең шигырьләрен күрерсез. Тугандаш халыклардан үзбәк, башкорт, чуваш, мари шагыйрьләренең иҗат үрнәкләре кызыклы.

Дөнья халыклары сентябрь аенда бөек әдип Л. Н. Толстойның тууына 150 ел тулган көнне бәйрәм итәчәк. Шул уңайдан журналыбыз О. Кадыйровның «Тәрҗемәләр һәм цензура киртәләре» дигән мәкаләсен урнаштыра.

Мәгърифәтче Хөсәен Фәезхановның тууына 150 ел, күренекле балалар язучысы, М. Җәлилнең көрәштәше А. Алишның тууына 70 ел тулу уңае белән басылган материалларны да сез шушы санда укырсыз.

Бүгенге поэзия турында сөйләшүгә язучылар һәм галимнәр генә түгел, журнал укучылары да катнаша. Бу айда сүзне бер төркем укучыларыбыз алачак. Әдәби тәнкыйть, культурабыз тарихына материаллар, китап күзәтү, әдәбият һәм сәнгать бүлекләре дә сезне күп яңалыклар белән таныштырыр.

М. Гайнуллинның «Мин әдәбиятка ничек килдем» дигән истәлеген, М. Садри тарафыннан җыелган һәм аның сүз башы белән бирелгән Себер халык җырларын, әкиятләрен, Ш. Галиевнең «Әз-мәз мәзәк яки Котбетдиннең кырык тартмасы» дигән юмористик парчаларының ахырын да кызыксынып укырсыз дип уйлыйбыз.

Хөрмәтле укучыбыз!

Вакытында чарасын күрмәү аркасында кайбер иптәшләр узган елларда журналыбызга языла алмый калдылар. Озакламый 1979 ел өчен газета-журналларга язылу башланачак. «Казан утлары»н даими укып барырга теләсәгез, аңа вакытында язылып калырга тырышыгыз.

Журналның индексы 73210.

Язылу бәясе елга 6 сум.

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210